И. В. ЛИПСИЦ

ИКЪТИСАД

ИКЪТИСАД
И. В. ЛИПСИЦ

И. В. Липсиц

И К Ъ Т И С А Д

ТӨП КУРС



***Игорь Владимирович ЛИПСИЦ** — икътисад фәннәре докторы, Дәүләт университеты— Мәгариф һәм фән министрлыгының, РФ Икътисади үсеш һәм сәүдә министрлыгының Югары икътисад мәктәбе (ДУ—ЮИМ) ординар (гомерлек) профессоры, ДУ—ЮИМның Югары менеджмент мәктәбе деканы.*

И. В. Липсиц икътисади матбугатта чыккан күп санлы мәкаләләр һәм Россиядә базар икътисады буенча яшүсмерләр өчен йөзәрләгән мең тираж белән басылган «УДИВИТЕЛЬНЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ В СТРАНЕ ЭКОНОМИКА» дигән беренче дәреслек авторы буларак мәгълүм.

Аның тарафыннан язылган «ЭКОНОМИКА БЕЗ ТАЙН», «РАСКРЫВАЯ ТАЙНЫ ЭКОНОМИКИ» (Л. Л. Любимов һәм Л. В. Антонова белән бергә), «ОСНОВЫ ЭКОНОМИКИ» (Л. Л. Любимов белән бергә), «ЭКОНОМИКА» (ике томда), «ЭКОНОМИКА» (Хуҗалык эшчәнлеге тарихы һәм аны заманча оештыру) кебек гомуми белем бирү мәктәпләре өчен чыккан дәреслекләр һәм уку ярдәмлекләре 1993—2000 елларда бик зур тиражлар белән дөнья күрде. 1991 елда аның тарафыннан укылган «Основы рыночной экономики» радиокурсы бөтен илгә яңгыраган шундый эчтәлектәге беренче тапшыру булды. «Россия университетлары» телеканалы оештырган Ачык телевизион университетның «Икътисад факультеты» кысаларында ул укыган икътисад буенча лекцияләр зур яңгыраш тапты.

Ул — шулай ук вузлар өчен чыгарылган дүрт дәреслек авторы да.

И. В. Липсиц «Ватан алдындагы хезмәтләре өчен» орден медале (2 нче дәрәҗә) белән бүләкләнде.

И. В. ЛИПСИЦ

ИКЪТИСАД

ТӨП КУРС

Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 10—11 нче сыйныфлары өчен дәреслек

Россия Федерациясе
Мәгариф һәм фән министрлыгы
тарафыннан тәкъдим ителгән

КАЗАН • «МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ • 2006

УДК 373.167.1:33*10/11
ББК 65.9(2) я721
Л57

Липсиц И. В.

Экономика. Базовый курс: Учеб. для 10, 11 классов общеобразоват. учрежд.— 5-е изд., перераб.— М.: Вита-Пресс, 2006.

Рецензентлары:

икътисад фәннәре докторы *В. М. Гальперин*, икътисад фәннәре докторы *Л. Л. Любимов*, икътисад фәннәре докторы *В. А. Рубе*, икътисад фәннәре докторы *Е. В. Савицкая*, фәнни хезмәткәр *Л. Б. Азимов*, фәнни хезмәткәр *Д. А. Петрин*, методист *Л. Н. Поташева*

Охраняется Законом РФ «Об авторском праве и смежных правах». Воспроизведение всей книги или ее части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

Липсиц И. В.

Л57 Икътисад. Төп курс: Татар урта гомуми белем бирү мәкт. 10—11 нче с-флары өчен д-лек / И. В. Липсиц; Русчадан И. И. Кадыйрова, М. Х. Вәлиев тәрҗ.— Казан: Мәгариф, 2006.— 271 б.: рәс. б-н.
ISBN 5-7755-1020-8 (ООО Издательство «Вита-Пресс»)
ISBN 5-7761-0837-3

Әлеге дәреслек гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары өчен микро- һәм макроикътисад буенча белем нигезләренең кереш курсын колачлый. Мәктәпләрдә әлеге предметны өйрәнү бер уку елы буена дәвам итә.

Дәреслектә җәмгыятьнең хуҗалык тормышы икътисад фәненең каттый һәм логик модельләре нигезендә генә түгел, ә күптәрле бизнес тарихын һәм дәүләт сәясәтен колачлап, гади һәм аңлаешлы тел белән житкерелә.

Дәреслек берләштерелгән «Җәмгыять белеме»нең төп баскыч рәвешендә тәкъдим ителгән курсын («икътисад» модуле) һәм аерым уку предметы буларак икътисад курсын өйрәнү өчен — 10—11 нче сыйныфларда, шулай ук социаль-икътисад һәм социаль-гуманитар профильләр буенча белем алуга әзерләнү өчен 9 нчы сыйныфта да кулланылырга мөмкин.

ISBN 5-7761-0837-3

© Липсиц И. В., 2006, с изменениями
© Художественное оформление.
ООО Издательство «Вита-Пресс», 2002
Все права защищены
© Татарчага тәрҗемә, «Мәгариф» нәшрияты, 2006

УКЫТУЧЫ ӨЧЕН КЕРЕШ СҮЗ

ХӨРМӘТЛЕ ХЕЗМӘТТӘШЛӘР!

Әлеге дәреслек «урта (тулы) гомуми белем бирү стандартлары»на туры китереп төзелде (икътисад — төп баскыч һәм җәмгыять белеменең состав өлеше).

Икътисад буенча белем бирү стандартларын эшләү әлеге курсның югары сыйныф укучылары өчен уку планы элементына әверелүен белдерә. Һәм бу — икътисадчылар яки менеджерлар әзерләүче, керү имтиханнары тапшырганда икътисад буенча белемле булуны таләп итүче университетлар саны арту белән генә бәйләнмәгән. Монда шунысы аеруча мөһим: икътисади белемнәр яшьләр гомуми белеменең аерылгысыз өлешенә әверелеп бара.

Бу дәреслек белән эшләү сезнең өчен кызыклы булыр һәм әллә ни катлаулы тоелмас дип өметләнәбез. Әгәр дә инде ниндидер кыенлыклар туган очракта, аларны хәл итүдә **«Мәктәптә икътисад дәресләре»** («Уроки экономики в школе»: «Вита-Пресс» нәшрияты) дигән укытучылар өчен кулланма ярдәмгә килер, аны минем хезмәттәшем — ДУ—ЮИМның (Дәүләт университеты — Югары икътисад мәктәбе) микроикътисад кафедрасы мөдире Елена Владиславовна Савицкая язды. Анда укытуны оештыру буенча тәкъдимнәр генә түгел, ә дәресләрнең әзер сценарийлары да бирелгән. Алар дәрес материалын аеруча катлаулы моментларга басым ясап аңлатудан; сораулар, мәсьәләләр һәм күнегүләр тупланмасыннан (чишелешләре белән); өй эшләреннән; укучыларга тарату өчен кирәкле материалдан, контроль эшләр вариантлары (чишелешләре белән) һәм статистик кушымталардан гыйбарәт.

Моннан тыш, шул ук авторның укучылар өчен эш дәфтәрләре дә нәшер ителде. Аларда төрле биремнәр, ягъни тестлар (сайлап алуны күз алдында тоткан күп санлы сораулар), исәпләү мәсьәләләре, күнегүләр, фикер йөртү өчен сораулар, аерым бер икътисади хәлне тикшерү-карау өчен биремнәр урын алган.

Әгәр дә дәреслекне камилләштерү буенча теләк-ниятләрегез булса, үземә язуыгызны үтенәм (минем электрон почта адресы — ilipsitsl@yandex.ru).Дәреслекнен киләчәк басмаларында мин аларны истә тотарга тырышырмын.

Игорь Липсиц,
и.ф.д. Дәүләт университеты —
Югары икътисад мәктәбе профессоры, Мәскәү

УКУЧЫЛАР ӨЧЕН КЕРЕШ СҮЗ

Илебез үз тарихының иң авыр чорларын кичерә, һәм иң күп мәсьәләләр нәкъ әнә шул икътисад өлкәсендәге реформалар белән бәйләнгән. Хәзер без барыбыз да җәмгыятьнең яңа икътисади системасын булдыру кебек аеруча авыр процесс эчендә кайныйбыз. Һәм шуңа күрә дә икътисади яктан белемле кешеләргә ихтыяҗ аеруча кискен.

Икътисади процесслар агышын белү, икътисад өлкәсендә эшләп, аларны оештыру белән шөгыльләнүчеләргә генә кирәк түгел. Күчеш төре икътисадында — безнең илдә хәзерге вакытта нәкъ әнә шундый икътисад урын алган — аеруча катлаулы тормыш күзәтелә, һәм ул илнең һәр гражданы алдына күп санлы авыр мәсьәләләр куя. Әлбәттә, үз эчке сиземләвенә ышанып, аларның иң дөрес җавапларын да эзләп карарга мөмкин, әмма бик нык ялгышуың ихтимал.

Бу дәреслек шундый хәл килеп чыкмасын өчен язылды да инде. Аның максаты сез якын киләчәктә очрашачак мәсьәләләрнең, проблемаларның сәбәпләрен һәм асылын аңлатудан, икътисад дөньясында иң кулай гамәлләрне табарга өйрәтүдән гыйбарәт. Әлбәттә, бу — тормышның барлык очракларын искә алып төзелгән киңәшләр җыентыгы түгел, әмма аның ярдәмендә икътисад законнарын төшенергә мөмкин, ә бу исә авыр икътисади ситуацияләрдән чыгу юлларын табуны шактый җиңеләйтәчәк.

Бу дәреслек белән эшләү сезгә файдалы гына түгел, ә кызыклы да булыр дип өметләнәм, чөнки икътисад дөньясы конфликтлар һәм гадәти булмаган хәл-вакыйгалар белән тулы. Мин, аларның кайберләре турында сөйләп, җәмгыятьнең хуҗалык тормышын икътисад фәненең катгый һәм логик модельләре нигезендә генә түгел, бизнес һәм дәүләт сәясәтенең күптөрле һәм озын тарихы җирлегендә дә аңлатырга тырыштым.

Мин сезгә мавыктыргыч уку һәм алдыгызда торган мәсьәләләрнең икътисади яктан уңышлы хәл ителүен телим!

Игорь Владимирович Липсиц,
ilipsitsl@yandex.ru

Әлбәттә, балаларга икътисад буенча бирергә теләгән бар мәгълүматны да бер китапта гына туплап бетереп булмый. Әгәр дә укучылар һәм укытучылар бу дәреслек темалары буенча өстәмә мәгълүмат алырга теләсәләр, аны бернинди түләүсез Интернетта табарга мөмкин. Анда түбәндәге материаллар кертелгән:

1) *Черкасова В. А.* Книга для чтения по экономике для преподавателей экономики (архивлаштырылган MS Word — ZIP, 111 Kb форматында)

Интернеттагы адрес — http://www.ilipsits-marketing.com/state/AB:navID.45/AC:1.1606873838/AA:navID.45/1606876332;

2) *Липсиц О. И.* Книга для чтения по экономике для учащихся 9 класса общеобразовательной школы (архивлаштырылган файл MS Word — ZIP, 197 Kb форматында)

Интернеттагы адрес — http://ilipsits-marketing.com/state/AB:navID.45/AC:1.1606873838/AA:navID.45/1606876861;

3) *Липсиц О. И.* Хрестоматия по экономике для учащихся 10 класса общеобразовательной школы (архивлаштырылган файл MS Word — ZIP, 119 Kb форматында)

Интернеттагы адрес — http://ilipsits-marketing. com/state/AB:navID.45/AC:1.1606873838/AA:navID.45/1606876229.

ТАСИС программасы проекты кысаларында әзерләнеп, әлеге дәреслектә бирелгән бу интернет-кушымталар укытучылар һәм укучыларны дәресләр өчен өстәмә материал белән тәэмин итә, чөнки аларда дәреслектә бәян ителгән курс темалары буенча матбугатта чыккан кызыклы басмалар кертелгән.

Дәреслекне укыганда өстәмә материал алу өчен, шулай ук Интернеттагы түбәндәге чыганаклардан файдаланырга мөмкин:

http://www.ecsocman.edu.ru — «Экономика, социология, менеджмент» дигән белем бирү порталы. Дәүләт университеты — Югары икътисад мәктәбе укытучылары тарафыннан алып барыла. Икътисад фәне, социология һәм менеджментның төп мәсьәләләре буенча шактый күләмле материалны (шулай ук тулы текстлы мәгълүматны) колачлый. Материаллардан бушлай файдаланырга мөмкин.

http://www.akdi.ru — «Экономика» дигән консультацияләр һәм эшлекле мәгълүмат агентлыгы;

http://www.eeg.ru — Россия Федерациясе Финанс министрлыгының Икътисади экспертлар төркеме сайтындагы макроикътисади статистика;

http://www.vedi.ru/statbase.htm # 1 — «Веди» аналитик лабораториясе сайтындагы макроикътисади статистика;

http://www.nns.ru/analytdoc/anal2.html — Милли электрон китапханә сайтындагы икътисад мәсьәләләре буенча аналитик докладлар;

http://www.online.ru/sp/iet/trends/ — Күчеш чоры икътисады институты сайтындагы Россия икътисады торышына күзәтүләр;

http://www.exin.ru/test/doc.html — Эксперт институты сайтындагы Россия икътисады проблемалары буенча аналитик докладлар;

http://referats-tv.stars.ru/link/ — Интернетта укучылар өчен бирелгән мәгълүмати чыганаклар исемлеге;

Либертариум китапханәсе

http://www.libertarium.ru/libertarium/library — Мизес, Хайек һ. б. авторларның китаплары һәм мәкаләләре, берничә җыентык, шулай ук аерым мәкаләләр тәкъдим ителгән;

Europrimex Corp. сайтындагы китапханә

http://www.europrimex.com/education/center_line.htm — төрле бизнес юнәлешләре буенча On-line — дәреслекләр, мәкаләләр һәм күзәтүләр;

E-Management

http://e-management.newmail.ru/ — предприятие икътисады, менеджменты һәм маркетингы мәсьәләләре буенча тулы текстлы басмалар;

Күчеш чоры икътисады институты

http://www.iet.ru/ — күчеш чоры икътисады мәсьәләләре буенча китаплар, мәкаләләр;

Marketing

http://www.marketing.spb.ru/ — маркетинг мәсьәләләренә багышланган сайт: уку ярдәмлекләре, монографияләр, мәкаләләр, программалар белән тәэмин итү, маркетологлар конференцияләре;

Корпоратив финанслар

http://www.cfin.ru/ — финанс анализы теориясе һәм практикасы, инвестицияләр, менеджмент, финанслар. Кризиска каршы ярдәмлек. «Аудит и финансовый анализ» журналы архивлары. Эшләүче предприятиеләрнең бизнес-планнары. Проектларны инвестицион анализлау һәм идарә итү программалары;

Бандурин А. В. сайтындагы фәнни хезмәтләр китапханәсе

http://science.newmail.ru/ — китапханәгә төрле авторларның дипломнары, докторлык һәм кандидатлык диссертацияләре, дәреслекләре, китаплары һәм мәкаләләре кертелгән;

Бандурин А. В. сайтындагы фәнни хезмәтләр китапханәсе

http://www/fiper.ru/ — сайтта «Социально-экономические проблемы России» белешмәлеге һәм «сорау — җавап» рәвешендә төзелгән «Просто о сложном» дигән брошюралар сериясе урнаштырылган;

Дөнья капитализмы кризисы. Джордж Сорос

http://capitalizm.narod.ru/ — икътисад проблемалары, сәясәтчеләр һәм аларның киңәшчеләре — тикшеренү институтлары һәм аналитик ведомстволар белгечләре, финанс эшлекләләре эшчәнлеге белән кызыксынучылар өчен китап;

Икътисади фикер тарихы (eng)

http://socserv2.socsci.mcmaster.ca/~econ/ugcm/3113/ — икътисад теориясе классикларының инглизчә текстлары.

Э Ч Т Ә Л Е К

Укытучы өчен кереш сүз 5

Укучылар өчен кереш сүз 6

Дәреслеккә интернет-таяныч 7

Беренче бүлек

ИКЪТИСАДНЫҢ ТӨП МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

§ 1. Нәрсә ул икътисад 13

§ 2. Икътисади ресурсларның чикләнгәнлеге һәм шуңа бәйле проблемалар 20

Икенче бүлек

ИКЪТИСАДИ СИСТЕМАЛАРНЫҢ ТӨРЛӘРЕ

§ 3. Икътисади системалар турында төшенчә. Традицион һәм базар системалары 32

§ 4. Командачыл һәм катнаш система 35

Өченче бүлек

БАЗАР БЕЛӘН ИДАРӘ ИТҮЧЕ КӨЧЛӘР

§ 5. Сорау нәрсә ул 44

§ 6. Товарларны тәкъдим итү нәрсәдән бәйле 49

Дүртенче бүлек

БАЗАР НИЧЕК ЭШЛИ

§ 7. Базар бәяләре формалашу 55

§ 8. Эшләүче базар, яки Сәүдә эше чынлыкта ничек оештырыла 59

Бишенче бүлек

АКЧА ДӨНЬЯСЫ

§ 9. Акча барлыкка килү сәбәпләре һәм аның формалары 74

§ 10. Хәзерге икътисадта акча функцияләре 79

Алтынчы бүлек

БАНК СИСТЕМАСЫ

§ 11. Банклар барлыкка килү сәбәпләре һәм аларның төрләре 88

§ 12. Кредит белән тәэмин итү принциплары 92

§ 13. Илнең кредит-акча системасын көйләүдә Үзәк банкның роле 95

Җиденче бүлек

КЕШЕ ХЕЗМӘТ БАЗАРЫНДА

§ 14. Хезмәт базарының икътисади табигате 103

§ 15. Хезмәт хакы ни ул һәм нәрсәдән бәйле 107

Сигезенче бүлек

ХЕЗМӘТ БАЗАРЫНЫҢ СОЦИАЛЬ ПРОБЛЕМАЛАРЫ

§ 16. Профсоюзлар һәм хезмәт конфликтлары 118

§ 17. Хезмәт хакы формалашуның социаль факторлары 121

Тугызынчы бүлек

ЭШСЕЗЛЕКНЕҢ ИКЪТИСАДИ ПРОБЛЕМАЛАРЫ

§ 18. Эшсезлекнең сәбәпләре һәм төрләре 131

§ 19. Эшсезлекне ничек киметергә мөмкин 137

Унынчы бүлек

ФИРМА НӘРСӘ УЛ ҺӘМ БАЗАРДА НИЧЕК ЭШЛИ

§ 20. Фирмалар ни өчен төзелә 143

§ 21. Фирма эшчәнлегенең икътисади нигезләре 150

§ 22. Эшмәкәр һәм фирма төзү. Отышлы бизнес оештыру шартлары 161

Унберенче бүлек

ГАИЛӘЛӘР АКЧАНЫ НИЧЕК АЛАЛАР ҺӘМ ТОТАЛАР. КЕРЕМНӘРНЕҢ ТИГЕЗСЕЗЛЕГЕ ҺӘМ АНЫҢ НӘТИҖӘЛӘРЕ

§ 23. Гаилә керемнәре һәм чыгымнары 175

§ 24. Инфляциянең гаилә икътисадына йогынтысы 180

§ 25. Гражданнар байлыгындагы тигезсезлекләр һәм аларны киметү мөмкинлекләре 182

Уникенче бүлек

ДӘҮЛӘТНЕҢ ИКЪТИСАДИ БУРЫЧЛАРЫ

§ 26. Дәүләтнең икътисадны көйләүдә катнашу формалары һәм сәбәпләре 190

§ 27. Ил икътисадындагы макроикътисади процесслар 198

Унөченче бүлек

ДӘҮЛӘТ ФИНАНСЛАРЫ

§ 28. Салымнар — дәүләт керемнәре чыганагы 210

§ 29. Дәүләт бюджеты ничек формалаштырыла һәм сарыф ителә 218

Унҙүртенче бүлек

ИКЪТИСАДИ ҮСЕШ

§ 30. Икътисади үсеш нәрсә ул һәм аны ничек тизләтергә мөмкин 228

§ 31. XXI гасырда кешелек дөньясын нинди икътисади мәсьәләләр борчый 232

Унбишенче бүлек

ХАЛЫКАРА СӘҮДӘНЕ ОЕШТЫРУ

§ 32. Халыкара сәүдә һәм аның ил икътисадына йогынтысы 237

§ 33. Валюта базары һәм валюталарның алмаштырылуы 245

Уналтынчы бүлек

XX–XXI ГАСЫРЛАР ЧИГЕНДӘ РОССИЯНЕҢ ИКЪТИСАДИ КОРЫЛЫШЫ

§ 34. Россия икътисады нинди категориягә керә 252

§ 35. Россия Федерациясендә күчеш тибындагы икътисад формалашу 255

Икътисади терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге 260

Тәкъдим ителгән әдәбият исемлеге 270

Икътисадның төп мәсьәләләре

БҮЛЕКТӘ КАРАЛУЧЫ МӘСЬӘЛӘЛӘР:

1. ИКЪТИСАД НИ ӨЧЕН КИРӘК?
2. КЕШЕЛӘР НИ ӨЧЕН ХЕЗМӘТТӘШЛЕК ИТӘ?
3. КЕШЕ ТЕЛӘКЛӘРЕНЕҢ ЧИГЕ БАРМЫ?
4. ИЛ БАЙЛЫГЫ НӘРСӘГӘ БӘЙЛЕ?

Финикия портындагы мөһаҗирләр, хеттлар, еврейлар, ассириялеләр, фарсылар. Сәүдәгәрләр корабларга товар төйи.

...Не мог он ямба от хорея,
Как мы ни бились, отличить.
Бранил Гомера, Феокрита;
Зато читал Адама Смита
И был глубокий эконом,
То есть умел судить о том,
Как государство богатеет,
И чем живет, и почему
Не нужно золота ему,
Когда *простой продукт* имеет.

А. С. Пушкин

§ 1. Нәрсә ул икътисад

Әлеге дәреслек битләрендә безне икътисад проблемалары турында сөйләшү көтә. Һәм шуңа күрә иң элек «икътисад» сүзенең мәгънәсен төшенү зарур. Бу сүз ике төрле мәгънәдә кулланыла.

Беренчедән, кешеләрнең үзләре куллану өчен, ихтыяжларын канәгатьләндерү өчен кирәкле әйберләрне, **байлыкларны** булдыруга юнәлдерелгән эшчәнлеген оештыру алымын шулай дип атыйлар. «Икътисад» сүзенең әлеге мәгънәсенә синоним буларак «хуҗалык» сүзе кулланыла.

***ИХТЫЯҖ** — кешегә хас хаҗәт, ягъни аның организмы эшчәнлеген, иминлеген тәэмин итү яки канәгатьлек кичерүе өчен зарур нәрсәләргә мохтаҗлык тою ул.*

Икенчедән, «икътисад» кешеләрнең тормыш кирәкләренә, байлыкларына чиксез ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен, чикле ресурслардан ничек файдалануларын өйрәнүче фәнне белдерә. Икътисад фәне кешеләрнең гамәлләрен өйрәнгәнгә күрә, ул тарих һәм философия кебек үк иҗтимагый (социаль) фәннәргә кертеп карала.

1-1 рәсемендә күренгәнчә, икътисад тормышында өч төрле катнашучы була: гражданнар (гаиләләр), фирмалар һәм дәүләт. Алар бер-берсенә йогынты ясыйлар, үз эшчәнлекләрен турыдан-туры, шулай ук житештерү факторлары (ягъни байлыкларны житештерүдә файдаланылган ресурслар) базарлары һәм куллану товарлары (кешеләр тарафыннан турыдан-туры файдаланылган байлыклар һәм базар алыш-биреше аша кешеләр аларны үзара алмашалар) базарлары аша бер-берсенә яраштыралар.

***БАЙЛЫКЛАР (БЛАГА)** — кешеләр тарафыннан үз ихтыяҗларын канәгатьләндерү чарасы буларак бәяләнүче һәрнәрсә.*

***ИКЪТИСАД** — хуҗалык эшчәнлеге процессында катнашучыларның гамәлләрен өйрәнүче фән.*



1-1 рәсем.
Икътисад төзелеше

ҖИТЕШТЕРҮ ФАКТОРЛАРЫ — кешеләр тарафыннан тормыш байлыкларын, кирәк-яракларын булдыру өчен файдаланылучы ресурслар.

Җәмгыятьнең икътисади тормышында фирмалар һәм дәүләт башкарган роль бәяләп бетергесез. Әмма шулай да икътисадта катнашучы төп зат — кеше, гаилә. Икътисадчылар аны башкача итеп йорт хуҗалыгы дип атыйлар. Эш шунда ки, нәкъ менә йорт хуҗалыклары хаҗәтләрен, аларның байлыкларга булган аерым ихтыяҗларын канәгатьләндерү хакына һәр илдә хуҗалык эшчәнлеге тормышка ашырылырга тиеш тә инде.

ЙОРТ ХУҖАЛЫГЫ — үз карамагындагы җитештерү факторларыннан файдалану исәбенә керемнәр алу ысулларын, үл керемнәрне шәхси куллану өчен, товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр алуга тотуны мөстәкыйль хәл итүче бер яки берга яшәүче берничә кеше.

Йорт хужалыгының иң гади төре — әти-әниләрдән һәм балалардан торучы, бер фатир яки йортта яшәүче һәм уртак хужалык алып баручы гаилә. Мондый гаиләнең өлкән әгъзалары хезмәт кебек җитештерү факторына ия булалар, алар, билгеле бер түләү хакына, үз хезмәтләрен фирмаларга файдалану мөмкинлеге бирәләр һәм шуның өчен хезмәт хакы рәвешендә керем алалар. Шуннан соң бу керемне ничек итеп тотарга — азык-төлек, кием-салым алыргамы, торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләргәме, җәйге ял өчен кулланыргамы икәнлеген хәл итәләр.

Әмма йорт хужалыгы әгъзаларының милегендә хезмәттән тыш (әгәр дә алар коммерция оешмалары, ягъни фирмалар милектәше булсалар) башка җитештерү факторлары да, мәсәлән фабрикалар, җир кишәрлекләре һ. б. булырга мөмкин. Бу җитештерү факторларын файдаланудан да йорт хужалыгы керем алырга мөмкин. Һәм, ниһаять, илнең барлык йорт хужалыклары илдәге табигать байлыкларының һәм алар исеменнән хөкүмәт идарә иткән башка милекнең милектәше (совладелец) булып торалар. Шуна күрә дә, ахыр чиктә, ил хужалык эшчәнлегендә кулланган бар нәрсә һәм әлеге эшчәнлек нәтиҗәсендә барлыкка китерелгән һәрнәрсә йорт хужалыкларына, ягъни ил гражданнарына карый, аларның хужалык эшчәнлегендәге гамәлләре илдәге барлык хәл-вакыйгаларны һәм аның ничек үсешен билгели.

Шулай итеп, икътисад фәне кешеләрнең теге яки бу хужалык ситуацияләрендә үз-үзләрен ничек тота алу мөмкинлекләрен һәм нәтиҗәдә ни килеп чыгачагын өйрәнә. Мондый өйрәнүләрнең нәтиҗәләре кешеләргә, фирма һәм дәүләтләргә икътисад өлкәсендәге фикерләрнең нәрсәгә китерәчәген алдан күрергә һәм акыллырак, нигезлерәк карарга килергә ярдәм итә.

Мәгълүм булганча, Җирдәге барлык тереклек ияләре табигатьтән тукланып яши, әмма бары тик кешеләр генә үз ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен кирәкле нәрсәләрне кыргый табигать биргәнгә караганда төрлерәк һәм күбрәк итеп табарга өйрәнгән.

Әмма барлык байлыкларны да үзең булдырырга, табарга кирәк түгел. Мәсәлән, һаваны без үзебез җитештермибез, ул безгә табигать тарафыннан бүләк ителгән, һәм без мондый төр байлыкны ирекле рәвештә алабыз. Шуңа күрә дә икътисад фәне барлык байлыкларны ике төркемгә бүлеп карый:

1) ирекле (табигать тарафыннан бирелгән, бүләк ителгән) байлыклар;
2) икътисади байлыклар.

Ирекле байлыклар — болар кешеләр ихтыяҗына караганда күбрәк күләмдә булган зарури байлыклар (күбесенчә табигать байлыклары). Шуңа күрә аларны җитештереп торасы да юк, кешеләр алардан ирекле рәвештә генә түгел, ә бушлай да файдалана ала.

Шулай да кешеләр ихтыяҗының төп өлеше ирекле байлыклар түгел, ә **икътисади байлыклар,** ягъни кеше тарафыннан булдырылган товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр хисабына канәгатьләндерелә. Аларның күләме:

— кешеләр ихтыяҗын тулысынча канәгатьләндерү өчен җитми;
— бары тик җитештерү факторларын, ягъни алардан башка җитештерү процессы бара алмаган элементларны куллану хисабына гына арттырыла ала;
— теге яки бу юл белән бүлеп бирелә.

Кешеләр хәзер борынгы заманнарга караганда яхшырак яши икән, бу нәкъ әнә шул икътисади байлыкларның (азык-төлекнең, кием-салымның, торакның һ. б.) күләмен арттыру һәм сыйфатын яхшырту хисабына ирешелә.

Кеше тәгәрмәч уйлап таба, кыргый хайваннарны кулга ияләштерә, игенчелекне булдыра һәм ут белән эш итәргә өйрәнә. Әмма шулай да Җир халкының бүгенге

муллыгы һәм куәте чыганагы уртак бурычларны хәл итү хакына барлык тырышлыкларны берләштерүдән гыйбарәт. Алар арасында иң төп бурыч тормыш өчен кирәкле байлыкларны тагын да күбрәк житештерүгә, ягъни кешеләр тормышын яхшырту шартларын тудыруга юнәлтелә.

Тормышта кирәкле байлыкларны житештерү өчен кешеләр табигать ресурсларын, үз хезмәтләрен, махсус җайланмалар (корал, җиһаз, җитештерү объектлары) куллана. Болар барысы да *житештерү факторлары* дип атала.

Җитештерү факторларын өч төп төргә бүлеп карау кабул ителгән:

1) хезмәт;
2) җир;
3) капитал.

Җитештерү факторы буларак **хезмәт** турында сөйләгәндә, без кешеләрнең товар җитештерүгә һәм хезмәт күрсәтүләрне булдыруга юнәлдерелгән эшчәнлеген күз алдында тотабыз. «Хезмәт сатып алу» дигәндә исә, билгеле бер вакыт дәвамында кешенең аерым төр хезмәтен файдалануга хокук алуны истә тотабыз.

ХЕЗМӘТ — кешеләрнең хезмәт күрсәтү рәвешендә файдаланылучы акыл һәм физик сәләтләре, күнекмәләре һәм тәҗрибәсе ул. Алар икътисади байлыклар җитештерү өчен кирәк.

Җир турында җитештерү факторы буларак сөйләгәндә, без икътисади байлыкларны җитештерү өчен яраклы барлык төр табигый ресурсларны күз алдында тотабыз.

Капитал турында сөйләгәндә исә, җитештерүдә файдаланылучы бина-корылмаларны, станок һәм җиһазларны һ.б., ягъни товар җитештерү һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган бар нәрсәне күзаллыйбыз (капитал һәм аның төрләре турында җентеклерәк текстны 8 параграфтан карагыз).

Икътисади процессларны анализлау җиңелрәк булсын өчен, хезмәттән җитештерү факторларының тагын бер төрен аерып чыгаралар; ул да булса — **эшмәкәрлек сәләтләре.** Без шушы сүз белән кайбер кешеләргә хас булган түбәндәге сыйфатларны атарбыз:

1) иң зур файда ясау өчен, сатып алучыларга кайсы товарларны уңышлырак тәкъдим итеп булуын яки инде булган товарларны җитештерүнең нинди технологияләрен кертергә кирәклеген дөрес бәяли белү;

2) тәвәккәллек, ягъни туплаган акчасын яңа коммерция проектына салудан һәм ул проектны тормышка ашыруга киткән көч, вакыт әрәмгә узуыннан курыкмау;

3) җәмгыятькә кирәкле байлык-муллыкны булдыру өчен, башка җитештерү факторларын уңышлы куллануны көйләү.

Эшмәкәрлек сәләтләренең хезмәттән ни белән аерылуы беренче карашка аңлашылмаска да мөмкин, чөнки бизнесны оештырган кеше — эшмәкәр үзе дә яллаган хезмәткәрләре белән иңгә-иң эшли һәм алар эшенең берничдә аермасы юк кебек. Әмма бу аерма бар һәм ул шактый зур: ялланып эшләүче хезмәткәр бары тик милекче-эшмәкәр кушканны гына эшли һәм хәзер үзе башкарырга тиешле эш өчен генә җавап бирә.

Ә эшмәкәр исә, үз сәләтләренә таянып, фирмасында нәрсә, күпме һәм ничек җитештерелергә тиешлеген хәл итә. Алай гына да түгел, аның карарлары

киләчәккә юнәлгән була, ә бу исә алдан күрә белүне, нинди бәягә һәм күпме сата алачагын чамалауны таләп итә. Нәкъ әнә шушы булдыклылыкны истә тотып, икътисадчылар эшмәкәрлек сәләтләре турында җитештерүнең аерым үзенчәлекле факторы буларак сөйлиләр.

Шунысын билгеләп үтик: ялланган җитәкче (менеджер) эшмәкәр дип атала алмый, чөнки ул эшне үз акчасы хисабына алып бармый һәм фирма уңышсызлыкка очраганда, ул бары тик үз эшен һәм хезмәт хакын гына югалта. Ә фирма хуҗасы исә фирманы төзергә тоткан барлык акчасын югалтырга мөмкин.

Икътисади эшчәнлек өчен XX гасырда элекке чорларга караганда да тагын бер үзенчәлекле җитештерү факторының әһәмияте аеруча арта: ул — **мәгълүмат,** ягъни кешеләргә икътисад дөньясында аңлы эшчәнлек алып бару өчен кирәкле белемнәр һәм хәбәрләр. Бу ресурсның күләмен төгәл билгеләп булмый, гәрчә аның кыйммәте гаять зур һәм даими төстә арта бара.

Кешелек, икътисади ресурсларны (җитештерү факторларын) куллану ысулларын камилләштереп, үз хуҗалык эшчәнлеге нигезенә ике мөһим элементны кертте: **махсуслаштыру** һәм махсуслаштырылган хезмәт җимешләрен **алмашу.**

Хезмәтне махсуслаштыру кешеләрнең гасырлар дәвамында туплаган тәҗрибәләренә нигезләнә. Алар арасында иң мөһимнәре түбәндәгеләр:

1. Кешеләр арасында аңлы хезмәт бүленеше.
2. Кешеләрне яна һөнәрләргә өйрәтү һәм яна күнекмәләр булдыру.
3. Кооперация, ягъни уртак максатка ирешү хакына (мәсәлән, катлаулы эшләнмә әзерләү яки завод кору) хезмәттәшлек итү мөмкинлеге.

МАХСУСЛАШТЫРУ — аерым төр эшчәнлекнең аны яхшырак алып бара белүче (башкаручы) кеше яки хуҗалык оешмасы карамагында туплануы.

Археологлар һәм тарихчылар фикеренчә, хезмәтне махсуслаштыру моннан 12 мең ел элек башланган. Игенчелек культураларын эшкәртүнең утрак тормышта яшәгәндә дә ачтан үлмәскә ярдәм итүен кешеләр беренче тапкыр әнә шул вакытларда төшенгәннәр. Димәк, азык эзләп күчеп йөрүдән туктарга һәм үз йортыңны корырга мөмкин булган.

Нәкъ әнә шул вакытта иҗтимагый хезмәт бүленеше килеп чыккан: кайбер кешеләр аучыларга, кайсылары терлекчеләргә, ә кайберләре игенчеләргә әверелгән. Ә хәзер исә һөнәрләр саны бихисап. Күпчелек һөнәрләр, профессияләр махсус күнекмәләр һәм хезмәт алымнарына өйрәнүне (кайчакларда күп еллар дәвамында) таләп итә.

Хезмәтне махсуслаштыруның кыйммәте нәрсәдә соң, ни өчен ул җәмгыятьтә хуҗалык тормышының нигез ташына әверелде? Моның берничә сәбәбе бар.

Беренчедән, кешеләр тумыштан ук төрле, ягъни алар төрле сәләтләргә ия була. Шуңа күрә аларның теге яки бу эшне башкару сәләте, мөмкинлеге дә төрле дигән сүз. Махсуслашу исә һәр кешегә үз сәләтен тулырак ачарга, хезмәтен җиңеләйтергә мөмкинлек бирүче эшне, профессияне, эшчәнлек төрен табарга булыша.

Икенчедән, махсуслашу кешеләргә үзләре өчен сайлаган эшчәнлекне алып барганда осталыкларын камилләштерергә мөмкинлек бирә. Ә бу исә җитештерелгән әйберләрнең яки күрсәтелүче хезмәтләрнең сыйфатын тагы да күтәрергә булыша.

Өченчедән, осталык үсү әйберләр җитештерүгә киткән вакытны киметергә ярдәм итә, бер төр эштән икенчесенә күчкәндә вакыт югалтулардан коткарып кала.

Башка сүз белән әйткәндә, махсуслаштыру кешеләр тарафыннан үзләренә кирәкле икътисади байлыкларны җитештергәндә, иң беренче чиратта, без хезмәт дип атаган ресурсны оештырганда кулланылган барлык ресурсларның (җитештерү факторларының) **җитештерүчәнлеген** арттыру ысулына әверелә.

Җитештерүчәнлек турында сөйләгәндә, билгеле бер вакыт эчендә икътисади ресурс берәмлеге (мәсәлән, кеше) ирешкән файдалы нәтиҗәне күз алдында тотабыз. Мәсәлән, бер кешенең хезмәт җитештерүчәнлеге бер вакыт берәмлеге эчендә (1 көн, 1 ай яки 1 ел) ул җитештергән әйберләр күләменә тиң була. Ә игенбасуының җитештерүчәнлеге 1 ел эчендә 1 га сөрүлек җирдән җыеп алынган уңыш күләме белән исәпләнә.

Махсуслаштыруны тагы да көчәйтү хисабына җитештерүчәнлекне арттыру танылган америкалы инженер һәм эшмәкәр Генри Форд үрнәгендә күзәтелә. Ул, өзлексез (конвейерлы) җитештерүне көйләгәндә, җыю конвейерын куллана.

Нәкъ менә хезмәтне махсуслаштыру һәм шул рәвештә җитештерүчәнлекне арттыру нәтиҗәсендә, кешеләр үзләре өчен кирәк булганга караганда күбрәк әйберләр җитештерә башлаган. Димәк, аларның ул әйберләр белән алыш-биреш ясау, алмашу мөмкинлеге туган һәм бу вакыты-вакыты белән генә түгел, ә даими мөмкинлеккә әверелгән. Әйтергә кирәк, үзләре җитештергәннәр белән алыш-биреш ясау — кешеләрне, ике аякта йөрү яки фикерләү сәләте кебек үк, Җирдә яшәүче башка тереклек ияләреннән аерып торучы үзенчәлекле сыйфат. Бөек шотланд икътисадчысы Адам Смитның (1723—1790) тапкыр сүзләренә караганда: *«Бер этнең икенчесе белән сөяк алмашканын әле беркемнең дә күргәне юк».*

Даими төстә товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр белән алмашу кешеләр эшчәнлегенең иң мөһим өлкәсе булган сәүдә нигезендә ята. Сәүдә билгеле бер товарларны җитештерү яки төрле хезмәт күрсәтүләр буенча махсуслашкан кешеләрне һәм фирмаларны тулаем ил яки планета хуҗалыгына берләштерә. Махсуслаштыру үсеше сәүдәдән башка бөтенләй мөмкин булмас иде, һәм, димәк, кешеләргә кирәкле икътисади байлыклар күләмен тагы да арттыру авырлашыр иде.

***ТОВАР** — алмашу өчен җитештерелгән матди предмет, җисем.*

***ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ** — файдалы эшчәнлек рәвешендәге, кешеләр башка хезмәт күрсәтүләргә яки товарларга алмаштыра ала торган матди булмаган игелек.*

***СӘҮДӘ** — хезмәт күрсәтү һәм товар кебек байлыкларны акчага сатып-алып алмашу. Бу гамәл ирекле һәм ике як өчен дә файдалы була.*

Алай гына да түгел, махсуслаштыру һәм сәүдәнең үзара үрелеп баруы:

— кешеләрнең үз файдалары өчен төрле бихисап байлыкларны алу теләге белән

— һәр кешенең ул байлыкны чикле күләмдә җитештерү сәләте арасындагы каршылыктан котылырга ярдәм итте.

Генри ФОРД

Махсуслаштыру һәм хезмәт бүленеше өлкәсендә кеше уйлап тапкан иң гаҗәеп могҗизаларның берсе, җитештерүне арттыруның куәтле чарасы — конвейер.

Аны киң күләмдә куллануны кертеп җибәргән кеше Генри Форд (1863—1947) була. Ул массакүләм автомобиль төзелеше атасы, сәләтле һәм бик кырыс кеше буларак танылa. Ул төзегән автомобиль җитештерү компаниясе (исәп буенча инде өченчесе, чөнки җитештерүне оештыру тәҗрибәсе җитмәү сәбәпле, баштагы икесе бөлгенлеккә төшкән була) бер ел эчендә ике тапкыр артып киткән заказларны үтәп өлгерә алмый башлагач, ул конвейер куллану турындагы фикергә килә.

Һәм шулчак 1913 елның язында магнето (кабызу системасының төп элементы) җыю цехында Форд дөньядагы беренче конвейерны эшләтеп җибәрә. Элек магнето җыючы кеше өстәл артында эшли, аның каршында шушы әйберне җыю өчен кирәкле магнит, шөреп һәм клеммалар тупламы ята. Оста җыючы бер сменага (9 сәг) 40 лап магнето җыеп өлгерә.

Яңа система буенча һәр җыючы бер генә эш төрен үтәргә тиеш була (ягъни элек магнето җыю буенча бөтен операцияләрне башкара алганнан да күбрәк махсуслаша), шуннан соң әлеге эшләнмә күршесе кулына күчә.

Бу исә бер магнетоны җыярга киткән вакытны 20 минуттан 13 минут 10 секундка кадәр кыскартырга мөмкинлек бирә. Ә инженерлар элекке тәбәнәк җыю өстәлен югарырак күтәртелгән йөгерек тасмага алыштыруны уйлап тапкач, эш тизлеге тагы да арта, җыю вакыты 5 минутка гына кала. Нәтиҗәдә хезмәт җитештерүчәнлегенең 4 мәртәбә артуын исәпләп чыгару әллә ни авырлык тудырмый!

Форд конвейерлы җыю ысулын барлык цехларга да кертеп җибәргәч, автомобильнең хәрәкәт частен җыю өчен вакыт 12,5 сәгатьтән 93 минутка кадәр кыскара, ягъни хезмәт җитештерүчәнлеге 8,1 тапкыр арта. Һәм бу хәл Форд заводының хезмәт җитештерүчәнлеген тулаем күтәрергә мөмкинлек бирә. 1914 елда машиналар чыгару ике тапкыр артса да, анда эшләүчеләр саны шул кала. Ә элек исә, шулкадәр санда машиналар чыгару өчен, Форд ялланган хезмәткәрләр санын да ике тапкыр арттырырга тиеш булган.

Бу гаҗәеп нәтиҗә Форд компаниясен АКШның иң эре автомобиль фирмасына әверелдерә, һәм аның исеме уйлап табуы белән кешеләрнең яшәү дәрәҗәсен яхшырту мөмкинлеге биргән шәхесләрнең берсе буларак мәңгегә кешелек тарихына языла.

Хезмәт җитештерүчәнлегенең болай артуы Фордка машиналарны конкурентларына караганда кимрәк чыгымнар белән чыгару, арзанрак итеп сату һәм базарны үз кулына алу мөмкинлеге бирә. Мондый шартларда аның конкурентлары да үз предприятиеләрендә конвейер кертергә мәҗбүр булалар.

Чыннан да, сез хәтта үз бүлмәгездә дә махсуслаштырылган хезмәтнең төрле өлкәләрендә эшләүче житештерүчеләр (төзүчеләр, йорт җиһазы осталары, пыяла өрүче, балта остасы, электрчы, машина төзүче һ.б.) әзерләгән әйберләрне күрерсез. Бер генә кеше дә без бүген файдаланган әйберләрне житештерү өчен кирәкле күптөрле һөнәрләрне үзләштереп бетерә алмый. Алай гына да түгел, һәр әйберне житештерү өчен вакыт та кирәк, әгәр дә кеше үзенә кирәкле бар нәрсәне мөстәкыйль рәвештә әзерләсә, ул үзенең күпчелек ихтыяжларын, иң яхшы очракта да, бары тик олыгайган көнендә генә канәгатьләндереп өлгерер иде.

Шуңа күрә дә кешеләр махсуслаштыру һәм махсуслаштырылган хезмәт җимешләре белән даими алмашып торуның бергә үрелгән әйберләрне күбрәк, күптөрлерәк һәм тизрәк алырга мөмкинлек бирүен төшенгәннәр.

Әгәр дә ил махсуслаштыру һәм сәүдә итүне оста итеп үзара беркетә алса:

— махсуслашу хезмәт житештерүчәнлеге үсешенә китерә;

— хезмәт житештерүчәнлегенең үсүе кешеләр ала алырлык әйберләр күләмен арттыра;

— арткан әйберләр күләме сатуга тәкъдим ителә һәм кешеләрнең алардан файдалануын арттыруны, сатучыларның (житештерүчеләрнең) керемнәре күбәюне тәэмин итә;

— сәүдә итү нәтиҗәсендә алынган керемнәр житештерүне үстерүгә, хезмәтне махсуслаштыруны камилләштерүгә тотыла.

Символик төстә бу бәйләнешне кешелекнең икътисади үсешен исәпләүче сәгать рәвешендә күзаллап булыр иде (1-2 рәс.). Бу сәгатьнең циферблаты бөтен чакта һәм уклары дөрес якка әйләнгәндә — ил байый, ә кешеләр көннән-көн яхшырак яшиләр.

1-2 рәсем.
Икътисади сәгать

Әгәр дә илдә махсуслаштыру үсеше бозылса яки житештерүчәнлек кимесә, сәүдә бик зәгыйфь үссә яки кешеләр үз керемнәре, табышларының бер өлешен әйберләр житештерүгә кертмәсә, бу ил икътисади кыенлыклар алдында кала. Әгәр дә икътисади прогресс сәгате дөрес эшләмәсә яки инде бөтенләй туктап калса, ахыргы нәтиҗә бер үк төрле булачак: кешеләр тормышы начарланачак.

Әлеге кагыйдә барлык илләргә дә, хәтта үз карамакларында табигый байлыклары булу сәбәпле, гражданнарына яхшы яшәү тәэмин ителгән илләргә дә кагыла. Әлбәттә, мондый байлыклар булу яхшы яшәүгә илтүче юлны җиңеләйтә, әмма җир асты хәзинәләре, сөрүлекләр яки урманнар байлыгы үзеннән-үзе рәхәт тормышны тәэмин итә алмыйлар.

§ 2. Икътисади ресурсларның чикләнгәнлеге һәм шуңа бәйле проблемалар

Хуҗалык эшчәнлегенең (икътисадның) беренче бурычы төп (биологик) ихтыяҗларны канәгатьләндерүдән гыйбарәт була. Нәкъ шулар кешеләрнең конкрет ихтыяҗларын (мәсәлән, ашыйсы килү теләге билгеле бер төр ризыкка ихтыяҗны тудыра) формалаштыра да инде.

1-3 рәсем.
Кешеләрнең төп тормыш ихтыяҗлары

1-3 рәсемендә күренгәнчә, кешеләрнең ризыкка, киемгә, торакка, куркынычсызлыкка, авырганда дәвалануга булган ихтыяҗлары төп ихтыяҗларга керә.

Аңлашыла ки, бу ихтыяҗларның барысы да кешеләрнең гап-гади исән-сау яшәү шартларын чагылдыра. Хәер, бу шартларны гына тәэмин итү дә гаять катлаулы бурыч булып әверелә. Хәтта XXI гасыр башына да кешелекнең бу бурычны тулысынча хәл итә алганы юк — әле бүген дә Җирдә яшәүче миллионлаган халыклар ачлыктан интегә, тораклары булмаудан газап чигә, алар хәтта гап-гади медицина хезмәте белән дә тәэмин ителмәгән.

1-4 рәсем.
Маслоу төзегән «Ихтыяҗлар пирамидасы»

Америкада яшәүче мәшһүр социолог Абрахам Маслоу кешеләрнең барлык төр ихтыяҗларын «ихтыяҗлар пирамидасы» рәвешендә күзалларга мөмкин дип исәпли.

Әмма чынлыкта исә безнең цивилизация хуҗалыгы механизмы алдында торучы тагы да катлаулырак бурыч бар, ни өчен дигәндә, кешеләрнең ихтыяҗлары колачы физиологик яшәү шартларына караганда күпкә кимрәк. Бу ихтыяҗларның барысын да канәгатьләндерү өчен кеше ирешә алганнан да күбрәк ресурслар кирәк.

Кеше мондый чикләнгәнлек белән үз тарихы таңында ук очраша. Ул вакытларда кешеләргә кирәкле бердәнбер житештерү факторы жир, ягъни табигатьнең үз ресурсы була, чөнки безнең ерак бабаларыбыз өчен аның жимешләре алар таба алырлык, ирешерлек бердәнбер байлык санала.

Кешеләрнең матди теләкләре белән аларны канәгатьләндерә алу мөмкинлекләре арасында килеп туган аерма шартлы рәвештә 1-5 рәсемендә күрсәтелгән. Монда күрсәтелгән күтәрелә баручы сөзәк сызык — кеше таба алган табигый ресурслар. Алар иң элек файдалы казылмалар ятмаларын эшкәртү, гидроэлектростанцияләр кору, чирәм жирләрне үзләштерү исәбенә арта. Текә күтәрелүче сызык — кешеләр ихтыяжы. Күрәбез ки, кешелек үсешенең беренче дәверендә табигатьнең аз санлы кешеләр ыруын тукландырып торырлык потенциаль мөмкинлекләре кешеләр ихтыяжларыннан артыграк була. Әмма тора-бара кеше ихтыяжларының саны арту һәм колачы киңәю аркасында, кешелек бөтенләй үзгә хәл алдында кала (рәсемдә «Дефицит» дип билгеләнгән зона).

Һәрхәлдә, археологлар раславынча, моннан 10—16 мең ел элек үк кешелек, кабиләләр саны артып ризык житмәү сәбәпле, беренче тапкыр үлеп бетү куркынычы алдында кала. Бу хәлдән ул бары тик игенчелек һәм терлекчелек белән шөгыльләнә башлап, азык-төлек житештерергә өйрәнүе аркасында гына чыга ала.

Шул заманнардан башлап кешеләрнең ихтыяжлары һәм планетада яшәүче кешеләр саны һаман да үсә бара. Гәрчә кешеләр соңгы мең еллар дәвамында

1-5 рәсем.
Табигый ресурсларның икътисади чикләнгәнлеге туу сәбәпләре

яшәү өчен кирәкле әйберләрне булдыру максатында табигать ресурсларын гына түгел, җитештерүнең башка факторларын (хезмәт һәм капитал) файдаланырга өйрәнсәләр дә, алар күләменең үсеше кеше ихтыяҗлары үсешеннән барыбер калыша.

Нәкъ менә шул бөтен җәмгыять тормышын билгеләүче төп икътисади проблемага әверелә һәм икътисад фәненең игътибар үзәгендә тора.

Чикләнгәнлек — күп нәрсәләрне колачлаучы күренеш. Кеше ихтыяҗларын канәгатьләндерүнең һава, яңгыр, кояш жылысыннан башка барлык чаралары чикләнгән күләмдә була. Шунысы игътибарга лаек: без физик мәгънәдәге чикләнгәнлек түгел, ә икътисади чикләнгәнлек турында сүз алып барабыз.

***ЧИКЛӘНГӘНЛЕК** — кешеләр алырга теләгән әйберләр муллыгын җитештерүгә кирәкле барлык төр ресурслар күләменең җитешмәве.*

Чыннан да, без Җир куенында ятучы нефтьнең 128,6 млрд т күләмендә булуын беләбез икән, бу әлеге ресурсның физик чикләнгәнлеге турындагы мәгълүмат була. Әгәр дә кешеләр нефтьне кулланмаса, бу физик чикләнгәнлек икътисади проблемага әверелмәс иде. Әмма кешеләр нефтьне актив төстә файдалана, һәм әгәр дә ул барлык илләрдә дә булып, һава һәм кояш яктысы кебек җиңел генә бирелсә, аны куллану колачы бүгенге тәэмин ителеш мөмкинлегенә караганда күпкә артыграк булыр иде. Бүген исә нефть аны чыгару һәм транспортта күчереп йөртүгә түләү мөмкинлеге булганнарга гына эләгә.

Димәк, икътисади проблема әлеге ресурсның физик чикләнгәнлегендә түгел, ә аны башка ресурсларны тоту хисабына алу мөмкинлегендә чагыла.

Мисал өчен, инде әйтеп үтелгән нефтькә кире кайтыйк. Аның өстәмә күләмнәрен җир куеныннан чыгару өчен, чикләнгән күләмдәге башка күптөрле ресурсларны сарыф итәргә туры килә. Мәсәлән, скважиналар бораулау яки нефтьне җир астыннан суыру өчен электр энергиясе, нефтьчеләр хезмәте, металл (аннан нефть чыгару өчен кораллар һәм нефтьүткәргеч торбалар ясыйлар) һ.б. таләп ителә.

Шулай итеп, кешелекнең хуҗалык эшчәнлеге кыска чикмәнне күп мәртәбәләр үзгәртеп тегүне хәтерләтә — бер ихтыяҗны канәгатьләндерү өчен башкаларына кирәкле ресурсларны табарга туры килә. Әлбәттә, кешелек мөмкинлекләренең һәм ул файдаланган ресурслар күләменең үсүе бу чикмән размерын даими төстә зурайтырга булыша, һәм кешелек бу чикмән эчендә үзен көннән-көн яхшырак хис итә. Әмма чикләнгән ресурсларны файдаланучы һәм аларны үзләренә алу хокукы өчен үзара көрәшүче сфералар (төрле әйберләр, байлыклар житештерүче өлкәләр) арасында бу ресурсларны бүлгәләү мәсьәләсе һаман да көн тәртибендә кала бирә.

Ни өчен икътисади ресурслар (җитештерү факторлары) һаман да чагыштырмача чикләнгән була соң?

Хезмәтнең чикләнгәнлеге һәр илдәге хезмәткә яраклы кешеләрнең саны һәрвакыт төгәл билгеле булуы белән бәйләнгән. Өстәвенә физик һәм акыл сәләтләре, хезмәт күнекмәләре буенча гражданнарның бер өлеше генә аерым төр эшләр башкаруга яраклы була.

Җирнең (табигый ресурсларның) *чикләнгәнлеге* ил географиясе һәм аның куенындагы файдалы казылмалар булу-булмау белән билгеләнә. Файдалы казылмалар

эзләүгә тотылган иң зур чыгымнар да, әгәр дә табигать әлеге илгә мондый бүләкне бирмәгән булса, аларны табуны тәэмин итә алмый.

Капиталның чикләнгәнлеге илнең үткәндәге үсеше, аның нинди житештерү потенциалы тупларга өлгерүе белән билгеләнә. Мондый чикләнгәнлекне яңа заводлар төзеп, шоссе, газүткәргечләр сузып, өстәмә хезмәт жиһазлары әзерләп киметергә мөмкин (әмма икътисади чикләнгәнлекне жиңеп булмаганлыктан, аны бетереп булмый). Ләкин боларның барысы өчен дә күп вакыт һәм башка ресурсларны сарыф итәргә туры килә.

Эшмәкәрлек сәләтләренең житештерү факторы буларак чикләнгәнлеге һәр кешегә дә табигый эшмәкәрлек сәләте бирелмәве белән аңлатыла. Без XIX гасыр ахыры — XX гасыр башында яшәгән күренекле эшмәкәрләр исемнәрен юкка гына хәтерләмибез. Алар арасында Рябушинскийлар, Морозовлар, Елисеевлар, Кузнецовлар, Мамонтовлар бар.

Ресурсларның чикләнгәнлеге берничә мөһим нәтижәгә китерә.

Аларның беренчесе — милеккә хокук туу. Кешеләр инде ерак заманнарда ук икътисади ресурсларны милек итеп беркетергә омтылганнар. Кешелек тарихына шушы күзлектән карасак, иң борынгы заманнардан алып бүгенге көнгә кадәр аеруча кыйммәтле ресурсларга ия булу хокукы өчен каршылыклар һәм көрәш баруын күрербез.

Ахыр чиктә, болар барысы кешеләрне милеккә ия булу кагыйдәләрен тәртипкә китерү зарурлыгына этәрә. Шуңа күрә дөньяның һәр илендә бүген хаклы рәвештә милеккә ия булган кешеләрнең (мәсәлән, алар милекне сатып яки мирас итеп алган булырга мөмкин) әлеге милеккә карата түбәндәге юридик хокукларын билгеләүче законнар гамәлгә куелган:

1) ия булу, ягъни әйбергә бары тик физик контроль хокукы;

2) файдалану, ягъни әйбердән шәхси файдалану хокукы;

3) идарә итү, ягъни әйбернең кайчан һәм кем тарафыннан файдаланылуын хәл итү хокукы;

4) табыш алу, ягъни әйбердән шәхси файдаланганнан соң яки ул әйбердән башкаларга файдаланырга рөхсәт иткәннән соң килгән байлыкка хокук (башкача әйтсәк — үзләштерү хокукы);

5) әйбернең «капиталь кыйммәтенә» хокук. Бу хокук әйбердән читләштерү, куллану, аны үзгәртү яки юк итү хокукын күз алдында тота;

6) куркынычсызлык хокукы, ягъни законсыз төстә тартып алудан (экспроприациядән) иммунитет;

7) әйбернең мирас буенча күчүе яки васыять буенча алу хокукы;

8) вакытның чикләнмәве;

9) зыян салырлык итеп файдалануны тыю, ягъни әйберне башкаларга зыян китерерлек итеп файдаланудан тыелу;

10) түләтү тәртибендәге жаваплылык, ягъни бурыч өчен әйберне тартып алу мөмкинлеге;

11) калдыклылык тәртибе, ягъни кемгәдер тапшырылган вәкаләтләрнең вакыты узганнан соң яки башка сәбәпләр аркасында ул вәкаләтләрнең юкка чыгуыннан соң «үзеннән-үзе» кире кайтуын көтү.

Башка барлык кешеләр бу хокукларны хөрмәт итәргә тиеш һәм читләр милегендә булган ресурсларны көч белән тартып алу тыелган, мондый хәл булган

очракта җәза куркыначы яный. Мондый яшәү тәртибенә кешеләр күп кан коюлар һәм җан кыюлар хисабына ирешә, чөнки мөлкәтне бүлү омтылышлары һәрвакыт элекке хуҗаларның көчле каршылыгына очрый.

Бүгенге икътисади системаларда төрле критерийлар буенча классификацияләнүче күп санлы милек төрләрен күрәбез:

— үзләштерү формасы буенча: *индивидуаль* милек (шәхси ярдәмче хуҗалык, хезмәт хуҗалыгы, шәхси хезмәт эшчәнлеге, шәхси милек); *коллектив* милек (кооперативлар, коллектив предприятиеләр, аренда предприятиеләре, ширкәтләр (иптәшлекләр), акционерлык предприятиеләре, ассоциацияләр); *дәүләт* милке (гомумдәүләтнеке, муниципаль, дәүләт территориясендәге төзелмәләрнеке);

— милеккә хокук формасы буенча: *хосусый* милек (гражданнар, юридик затлар, предприятиеләр, берләшмәләр, оешмалар милекләре); *уртак* милек (уртак предприятиеләр һәм оешмалар милке); *дәүләт* милке (федераль республикалар һәм дәүләт составындагы башка төзелмәләр, муниципаль милек);

— субъектлар һәм объектлар буенча: *объектлар* (продукт, эш көче, җир, табигый ресурслар, йортлар, кыйммәтле кәгазьләр һ.б.); *субъектлар* (аерым гражданнар, коллективлар, төркемнәр, гаиләләр, дәүләтләр һ.б.).

Әмма гадилек өчен милек төрләрен без берничә төп төркемгә бүлә алабыз (1-6 рәсем.):

1) хосусый (шәхси) милек;
2) дәүләт милке;
3) муниципаль милек;
4) милекнең башка төрләре.

Алар арасында аермалар нинди һәм төрле илләрдә милекнең бу төрләре ни өчен бергә янәшә яши соң?

Хосусый милек булганда, милеккә ия булу, эш итү һәм файдалану хокукы закон тарафыннан аерым кеше кулына бирелү белән аерылып тора. Әлбәттә, хосусый милек хуҗалары уңайлылык һәм файдалы булсын өчен үз милекләрен берләштерергә дә мөмкин. Шундый очракларда акционерлык, пай, уртак милек барлыкка килә. Мондый милеккә йортлар, фатирлар, җир (болар «күчемсез милек» төшенчәсе белән билгеләнә), гаиләләрнең шәхси көнкүреш кирәк-яраклары, төрле предприятиеләр, **интеллектуаль милек** дип аталган иҗади һәм фәнни эшчәнлек нәтиҗәләре керә.

Әмма кайчакларда хосусый милеккә караганда муниципаль милек (аны кайбер илләрдә коммуникаль милек дип атыйлар, латинча *communis* «гомуми милек» дигәнне белдерә) уңайлырак булып чыга. Милекнең бу төре атамасы латинча *muni recipio* — «йөкне үз кулыма алам» сүзеннән килеп чыккан, ул шәһәр һәм авыллар, шулай ук башка муниципаль төзелмәләр хуҗа булган милекне белдерә. Монда милеккә хокукны муниципаль төзелмә исеменнән җирле үзидарә органнары тормышка ашыра. Әлеге милек Россия Федерациясе законнары тарафыннан җирле үзидарә органнарына тапшырыла (мәсәлән, Мәскәүдә барлык муниципаль милек белән шәһәр мэры җитәкчелегендәге Мәскәү Хөкүмәте идарә итә).

Муниципаль (коммуналь) милектә, гадәттә, хосусый милек итеп алу гаять катлаулы булган яки алардан алыначак файда күзлегеннән караганда әллә ни табышлы булмаган милек, мәсәлән, шәһәр урамнары, сүүткәргеч торбалар һәм

канализация, метро, гомуми белем бирүче мәктәпләрнең, медицина оешмаларының күбесе, ял парклары һ.б. керә. Алар хезмәтеннән шәһәрнең бар халкы, хәтта бу хезмәткә түләү сәләте булмаган иң ярлы кешеләр дә файдалана алырга тиеш. Шулай итеп, аерым бер кешегә шәһәр паркындагы сукмакларның милектәше (совладелец) булу кирәкми, һәм ул, шәһәрнең башка халкы белән бертигез дәрәҗәдә, коллектив милектәге объектларның милектәшенә әверелә. Ә шәһәр яки поселок халкы сайлап куйган җирле хакимият органнары аларның максатчан файдалануы өчен җавап бирә.

Ниһаять, аерым шәһәр халкы гына түгел, ә илнең бар халкы файдаланырлык милек объектлары бар; бу объектлар хезмәтен җәмгыять бөтенге көндә бушлай тәкъдим итүне кулай күрә. Болар илнең теләсә кайсы төбәгендә яшәүчеләрне дәвалаучы эре медицина үзәкләре, Россиянең төрле почмакларыннан килгән студентларга белем бирүче эре университетлар, дәүләт идарә органнары биналары, армия һәм чик буе частьлары кораллары, акча сугучы Гознак фабрикасы һ.б. булырга мөмкин. Мондый объектлар дәүләт милке дип беркетелә, алар белән дәүләт органнары идарә итә, боларның хезмәткәрләрен ил гражданнары сайлап куйган президент (үзе яки инде ул билгеләп куйган чиновниклар аша) билгели.

Милек һәм аңа керүче объектлар төрләре ничаклы күп булмасын, закон күзлегеннән караганда алар бертигез әһәмиятле һәм тигез хокуклы. Һәрхәлдә, ил каршылыксыз яшәсен һәм иң яхшы шартларда үссен өчен, бу шулай булырга тиеш тә.



1-6 рәсем.
Милек төрләре

Ресурсларны гражданнар һәм алар берләшмәләре милке итеп беркетү аларны, аерым түләү хисабына, шул ресурслар кирәк булганнарга бирү мөмкинлеген тудыра. Димәк, ресурсларга, яки башкача әйтсәк, җитештерү факторларына ия булу анын хуҗаларына керем чыганагы булып әверелә. Мондый факторлар керемнәренен формалары бик күптөрле булырга мөмкин, һәм алар сатылучы ресурслар төреннән бәйле була.

ФАКТОРЛАР КЕРЕМНӘРЕ — җитештерү факторлары хуҗаларының аларны әйберләр, байлыклар җитештерүне оештыру өчен файдалануга биргәннән килгән керем.

Әгәр дә кеше эшләргә сәләтле булып, аны гына сата, ягъни ялланып эшли икән, моның өчен ул хезмәт хакы ала. Җир кишәрлеге яки төгәл билгеле күләмдәге табигый ресурс хуҗасы аны хуҗалык максатларында үзе файдаланса яки башкаларга файдалануга биреп торса, керем ала, бу *рента* (латинчадан *reddita* — «түләнгән») дип атала.

Эшмәкәр, капитал (биналар, корылмалар, җиһазлар) хуҗасы, аларны үз фирмасы эшчәнлеген тәэмин итү өчен кулланса, бу фирма **табышының** бер өлеше рәвешендә керем ала. Шул ук вакытта табышны ул фирма өчен капитал туплап кына түгел, ә бу капитал ярдәмендә дә алырга мөмкин, чөнки, беренчедән, сатып алучыларны кызыксындырырлык хезмәт күрсәтүләрне, товарлар җитештерүне оештыра, икенчедән, сатып алучылар бу хезмәт күрсәтүләр һәм товарларга аларны җитештерүгә киткән чыгымнардан күбрәк бәя түләргә әзер тора. Башкача әйткәндә, табыш — җитештерүгә, эшне оештыруга капитал хуҗасы тоткан чыгымнарга караганда сатып алучылар күбрәк бәядән алырга әзер булган хезмәт күрсәтүләр һәм товарлар җитештерүне оештыру осталыгы өчен килгән керем ул.

Әмма капитал хуҗасы хезмәт күрсәтүләр яки товарлар җитештерү белән үзе шөгыльләнмичә, бу капиталдан вакытлыча файдалану хокукын башка затларга һәм фирмаларга биреп торырга мөмкин. Бу очракта да ул табыш ала, әмма мондый табыш башка төрле булып *процент* дип атала. Әлеге атама бу табыш күләменең башка кешеләргә яки оешмаларга файдалануга тапшырылган капиталның акчалата **кыйммәте** процентларында билгеләнүе белән бәйләнгән.

Кешеләр ихтыяҗына караганда ресурсларның чикләнгәнрәк булуы сайлап алу проблемасын китереп чыгара. Кешеләргә бу ресурсларны ничек тотарга икәнлекне, ягъни аларны нинди әйберләр җитештерүдә яки хезмәт күрсәтүләр оештыруда файдалануны сайлап алырга туры килә. Шул ук вакытта, чикләнгән ресурсларны файдалануның бер вариантын сайлап, кешеләр аларны башка нәрсә өчен файдалану мөмкинлеген югалталар. Димәк, һәр сайлап алуның үз бәясе бар, аны икътисад фәнендә **альтернатив чыгымнар, кулдан ычкынган файда** яки **сайлап алу бәясе** дип атыйлар.

***ТАБЫШ** — а) бухгалтерлык исәбендә һәм салымнар салуда — товарлар сатудан килгән керемнең аларны җитештерүгә һәм сатуга киткән чыгымнар суммасыннан артыграк булуы; б) икътисад теориясендә — товарларны реализацияләүдән килгән керемнең аларны җитештергәндә кулланылган барлык ресурсларның гомуми альтернатив кыйммәтеннән артык булуы;*

***КАПИТАЛНЫҢ АКЧАЛАТА КЫЙММӘТЕ** — билгеле күләмдәге капиталны сатып алганда түләнгән яки аны сатканда алырга мөмкин булган акча суммасы.*

***САЙЛАП АЛУ БӘЯСЕ (АЛЬТЕРНАТИВ ЧЫГЫМНАР)** — иң кирәкле әйберләрнең кеше өчен булган кадере; чикләнгән ресурслардан сайлап алу юлы белән файдаланганда, аларны алу мөмкинлеге калмый.*

Бу бәяне билгеләү өчен, искә төшерик: ресурсларның чикләнгәнлеге, җитмәве аркасында читкә кагылган вариантларны тормышка ашырып булмаячак, чөнки мона кирәкле ресурслар сайлап алынган вариантны тормышка ашыру өчен сарыф ителгән. Әйтик, сөрүлек җиргә карабодай чәчелгән икән, бу җиргә инде тагын бәрәнге дә утыртып үстерү физик яктан мөмкин хәл түгел.

Чикләнгән ресурсларны файдалануның читкә кагылган вариантлары, димәк, алар китерә алган файда һәм байлыклар, сайлап алу бәясен формалаштыру нигезен барлыкка китерә дә инде. Нәкъ менә нигезен, ә бәянең үзен түгел, чөнки бу бәя, башка бәяләр кебек үк бертөрле генә итеп билгеләнә. Инде сайлап алганнан соң ирешмәслек булып әверелгән барлык әйберләр әлеге бәя сыйфатында чыгыш ясый ала. Бу сайлап алган варианттан соң икенче урында калган әйберләр яки байлыклар гына шундый бәя дип аталуга хаклы.

Нәрсә турында сүз барганы яхшырак аңлашылсын өчен, бер мисал карап үтик. Сезнең кулыгызда яки велосипед, яки костюм, яки модалы туфли алырлык акча бар, дип уйлыйк. Барыннан да бигрәк сезнең яңа велосипед аласыгыз килә. Теләгәннәр арасында костюм икенче урында тора, ә туфлиләр кирәклелек шкаласы буенча бары тик өченче урынга кала. Әгәр дә сез акчаны, чыннан да, велосипед алуга тотсагыз, мондый сайлап алуның бәясе костюм була (туфли түгел яки берьюлы костюм һәм туфли түгел), ягъни башкача әйтсәк, сез костюм алмау хисабына, велосипед алган буласыз. Әлеге логика кешеләр тормышының логикасын тәшкил итә, чөнки икътисад дөньясында кешеләргә атлаган саен нәрсәнедер сайлап алырга туры килә. Кешеләр һаман да икътисадның өч төп соравына җавап эзләргә мәҗбүр булалар:

1. НӘРСӘНЕ ҺӘМ КҮПМЕ ЖИТЕШТЕРЕРГӘ, ягъни кулланучыларга нинди товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр тәкъдим ителергә тиеш?

2. НИЧЕК ЖИТЕШТЕРЕРГӘ, ягъни кулда булган чикле ресурслар хисабына, әйберләрне җитештерүнең кайсы юлын кулланырга?

3. Хезмәт күрсәтүләрне һәм товарларны КЕМ ӨЧЕН ЖИТЕШТЕРЕРГӘ, ягъни аларны үзенә милек итеп кем алырга мөмкин?

Беренче сорауга җавап биргәндә, кешеләр чикле ресурсларны төрле әйберләр җитештерүчеләр арасында бүлә. Әйтик, кулда булган металлдан суыткычлар әзерләргә исәпләсәләр, металл кухня плитәләре җитештерүче предприятиеләргә түгел, ә суыткыч чыгаручыларга китерелә, плитәләр җитештерелми кала.

Кешеләр ничек җитештерергә кирәклеген хәл иткәндә, «Нәрсә җитештерергә?» дигән сорауга җавап булырлык әйберләр җитештерү өчен кулай ысулларны (технологияләрне) сайлыйлар. Мәсәлән, Россиядә төп ризыкларның берсе бәрәңгене, кул хезмәте һәм табигый ашламалар кулланып, ярдәмчел җир хуҗалыгында үстерергә мөмкин. Шулкадәр үк бәрәңгене, куәтле авыл хуҗалыгы техникасы кулланып һәм химия сәнәгате җитештергән минераль ашламалар сибеп, эре аграр предприятиеләрдә дә үстереп була.

Технологик мөмкинлекләрнең һәр варианты чикле ресурсларны куллануның үз комбинациясен һәм масштабларын билгели (берсе өчен зур хезмәт кую таләп ителә, икенчесе өчен күп электр энергиясе кирәк, өченчесе зур капитал салуны сорый).

Икътисади ресурсларның чикле булуы, шулай ук аларны куллануның күп вариантлылыгы, бер яктан, кеше, фирма яки ил сайлап алган вариантның колачын, ә икенче яктан, шул вариантны тормышка ашыргач ирешеләчәк икътисади нәтиҗәләрне билгели. Шуңа күрә дә иң яхшы вариантны сайлап алу җиңел мәсьәлә түгел, ул төрле ресурсларны чагыштыру, аларның бәяләрен исәпкә алуны таләп итә. Икътисадчылар бу мәсьәләне хәл итүнең махсус, ә кайчакларда гаять катлаулы юлларын (методларын) таптылар. Әлеге методлар вузларда һәм бизнес мәктәпләрендә өйрәтелә.

Товарларны һәм хезмәт күрсәтүләрне кем өчен әзерләргә дигән сорауга җавап биргәндә, кешеләр кемгә күпме әйбер туры килергә тиешлеге мәсьәләсен дә хәл итәләр. Бар халыкка да тигез бирелергә тиешме әллә юкмы? Әгәр дә тигез түгел икән, кемгә күпме булырга тиеш? Кемгәдер башкаларга караганда күбрәк бирергә мөмкин һәм шулай кирәк тә икән, күпмегә күбрәк бирергә? Яшәү шартларындагы гаделсез аермаларны күреп, кешеләрнең ачуы тумасын өчен әйберләрне ничек бүләргә?

Кешелек үз тарихы дәвамында әлеге икътисади сорауга түбәндәге алымнарга таянып җавап бирергә тырышып карый:

— *традицион* — бүлеп бирү җәмгыятьтә булган традицияләргә таянып гамәлгә ашырыла;

— *үзәкләштерелгән* — бүлеп бирү үзәк икътисад идарәсе органы тарафыннан башкарыла;

— *базарга нигезләнгән* — бүлеп бирү базар механизмы нигезендә тормышка ашырыла.

Дөньяның күпчелек илләрендә (һәм иң бай барлык илләрдә) бүгенге көндә бүлеп бирүнең катлаулы базар механизмы өстенлек итә. Монда әйбер, бер яктан, сатучыга кулай булган бәяне бирергә әзер торган кешегә эләгә, ә икенче яктан, сатып алучы ул әйбер өчен күпме түләргә ризалашса, сатучы кулына шулкадәр сумма керә. Димәк, базар механизмы мәгънәсе чынлыкта бик гади булып чыга: алмашу сатучы һәм сатып алучының мәнфәгатьләрен яраштыру нигезендә тормышка ашырыла. Аларның икесе өчен дә үзара килешү кулай, килешмәгән очракта сатып алучы теләгән әйберсен ала алмый, ә сатучы сатылмаган товарлар өеме эчендә акчасыз кала.

Сөйләнгәннәргә йомгак ясап, без икътисади акыллылык рецептының беренчесен төзи алабыз.

Беренче рецепт

Махсуслаштыруны һәм сәүдә үсешен һәрьяклы яклау, шулай ук икътисади эшчәнлекне оештыру алымнарын һәм формаларын даими төстә камилләштерү зарур.

БҮЛЕКНЕҢ ТӨП ЭЧТӘЛЕГЕ

Икътисад нәрсә ул. *«Икътисад» термины белән кешеләрнең үзләренә кирәкле әйберләрне, байлыкларны булдыруга юнәлдерелгән эшчәнлекне оештыру ысулын, һәм шулай ук бу эшчәнлек барышында кешеләр гамәлләренең закончалыкларын өйрәнүче фәнне атыйлар. Кешеләр (гаиләләр), фирмалар һәм дәүләт хуҗалык эшчәнлегендә катнашучы төп затлар була. Алар үз эшчәнлекләрен турыдан-туры элемтә нигезендә һәм шулай ук базар аша эш итеп тә яраштыралар. Шул рәвешчә, икътисад фәне базарлар, фирмалар, дәүләт оешмалары эшчәнлеген оештыру мәсьәләләрен, шулай ук гаилә икътисады белән бәйләнгән проблемаларны өйрәнә. Әлеге проблемалар микроикътисад дип аталган бүлеккә карый. Илнең барлык икътисади тормышын (акча системасы һәм инфляция, эшсезлек, икътисади үсеш, тышкы сәүдә һәм дөнья икътисады) колачлаган проблемалар макроикътисад тарафыннан өйрәнелә. Икътисад өлкәсендәге хезмәттәшлек кешеләргә үз хәлләрен тизрәк яхшыртырга мөмкинлек бирә. Мондый хезмәттәшлек нигезендә җитештерү ресурсларының төп төрләрен кулланып җитештерүчәнлекне арттыручы махсуслаштыру ята. Махсуслаштыру үсеше бары тик махсуслаштырылган хезмәт (хезмәтнең тармакларга аерылуы) җимешләре белән алмашырга мөмкинлек бирүче сәүдә яшәгәндә генә тормышка аша.*

Икътисади ресурсларның чикләнгәнлеге һәм ул тудырган проблемалар. *Кешелекнең төп икътисади проблемасы кешеләр ихтыяҗларының чиксез булуыннан һәм икътисади ресурсларның (хезмәтнең, табигый ресурслар, капитал һәм эшмәкәрлек сәләтенең) алар белән чагыштырганда чикләнгән, яки азрак булуыннан килеп чыга. Бу кешеләрне сайланучы әйбернең алар өчен әһәмиятен һәм түләнергә тиешле бәясен чагыштырып сайларга мәҗбүр итә. Үз хуҗалык эшчәнлекләрен оештырганда кешеләр һәрвакыт «Нәрсә һәм күпме җитештерергә? Ничек җитештерергә?» дигән сорауларга җавап эзләргә мәҗбүр булалар. Шушы сорауларга иң дөрес җавап таба белү, ахыр чиктә, һәр илнең байлыгын һәм анда яшәүче гражданнарның тормыш дәрәҗәсен билгели.*

ФИКЕР АЛЫШУ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Фән һәм техника прогрессы кайчан да булса ресурслар чикләнгәнлеген җинә алыр дип өмет итеп буламы?
2. Ни өчен әйберләрне бүлгәндә тигезләү принцибын тормышка ашыру илнең бар халкының тормыш дәрәҗәсе үсешен акрынайта?

Икътисади системаларның төрләре

БҮЛЕКТӘ КАРАЛУЧЫ МӘСЬӘЛӘЛӘР:

1. КЕШЕЛӘРНЕ ЭШЛӘТҮ ӨЧЕН НИЧЕК КЫЗЫКСЫНДЫРЫРГА?
2. КОНКУРЕНЦИЯ ФАЙДАЛЫМЫ?
3. БАЗАРНЫҢ «КҮРЕНМӘС КУЛЫ» НӘРСӘ УЛ?

АКШ президенты Герберт Гувер 1929 елда чыгыш ясаганда америкалыларны илнең барлык гражданнары тормышы чәчәк атар, һәм «һәр табакта тавык ите, һәр гаражда икешәр машина торыр» дип ышандыра. Әмма базар икътисадында беркайчан да иртәгесе көнгә ныклап ышанып булмый. Һәм 1929 елның 24 октябрендә Американың үсеш тәгәрмәче рельслардан төшә...



Планлаштыру түгел... ә уңышлы планлаштырып булу мөмкинлеге шик уята.

Ф. А. Хайек

§ 3. Икътисади системалар турында төшенчә. Традицион һәм базар системалары

Бик озын тарих дәвамында кешелек, сынаулар һәм ялгышулар аша, хуҗалык эшчәнлеген оештыруның иң яхшы ысулларын эзли, һәм бу эзләнүләр әле һаман дәвам итә. Бу авыр юлга әйләнеп карап, без хуҗалыкны оештыруның берничә вариантын күрербез, аларны цивилизациянең **икътисади системалары** төрләре дип атыйлар. Алар арасындагы аерма җәмгыятьнең «НӘРСӘ житештерергә? НИЧЕК житештерергә? КЕМ ӨЧЕН житештерергә?» дигән төп икътисади сорауларга ничек җавап эзләвеннән һәм илдә милекнең кайсы төре өстенлек итүеннән бәйле була. Шушы позициядән чыгып, без икътисади системаларның 4 төп төрен аерып карый алабыз:

1) традицион;
2) базар (капитализм);
3) командачыл (социализм);
4) катнаш.

Аларның иң борынгысы — **традицион икътисади система.**

ИКЪТИСАДИ СИСТЕМАЛАР — җәмгыятьнең хуҗалык тормышын оештыру формалары. Алар аерыла:
1) кешеләрнең, фирмалар һәм дәүләтнең хуҗалык эшчәнлеген координацияләү ысулы буенча;
2) икътисади ресурсларга карата милек төре буенча.

ТРАДИЦИОН ИКЪТИСАДИ СИСТЕМА — икътисади тормышны оештыру ысулы. Анда җир һәм капитал кабиләнең уртак милке була, ә чикләнгән ресурслар бик озак вакытлар яшәгән традицияләр нигезендә бүленә.

Мәсәлән, әгәр дә кабилә берничә буын дәвамында арпа иккән булса, ул һаман да шуны дәвам итәргә һәвәс булачак. «Бу табышлымы соң? Башка берәр нәрсә игеп карасаң ни булыр? Житештерүне оештыруның кайсы ысулы дөресрәк булыр?» кебек сораулар монда беркемнең дә башына килеп тә карамый.

Әлбәттә, вакытлар узу белән, традицияләр дә үзгәрә, әмма бу бик акрын бара. Мондый үзгәрешләр бары тик кабилә яки халыкчаның (народность) тышкы яшәү шартлары шактый үзгәреш кичергәндә генә күзәтелә. Бу шартлар тотрыклы булганда, хуҗалык тормышы традицияләре бик озак вакытлар буена сакланырга мөмкин. Россиядә, мәсәлән, төньяк халыклары тормышын оештыруда традицион икътисади система элементларын әле бүген дә табарга була.

Икътисади ресурсларга карата милек турында искә алсак, традицион системада ул коллектив, ягъни күмәк милек булган, анда аучылык урыннары, сөрү җирләре һәм болыннар кабиләгә яки общинага караган.

Вакытлар узу белән, традицион икътисади система элементларыннан кешелекнең ризасызлыгы күзәтелә башлаган. Тормыш күрсәткәнчә, җитештерү факторлары коллектив милектә түгел, ә аерым кешеләр яки гаиләләр кулында булса, нәтиҗәлерәк файдаланылган. Дөньядагы иң бай илләрнең берсендә дә җәмгыять тормышының нигезен коллектив милек тәшкил итми. Ә иң ярлы илләрдә мондый милек калдыклары сакланып калган.

Тәҗрибә шуны раслый: базарлар һәм фирмалар чикләнгән ресурсларны бүлеп бирү һәм тормыш өчен кирәкле әйберләрне, байлыкларны җитештерү күләмен арттыру бурычын аксакаллар советына, ягъни традицион системада җитди икътисади карарлар кабул иткән органга караганда яхшырак хәл итәләр.

Менә ни өчен традицион икътисади система, вакытлар узу белән, дөньяның күпчелек илләрендә кешеләр тормышын оештыру нигезе булудан туктый. Аның элементлары арткы планда кала һәм икенчел әһәмияткә ия булган төрле гореф-гадәтләр һәм традицияләр рәвешендәге кыйпылчыклар булып кына саклана.

Дөньяның күпчелек илләрендә кешеләрнең хуҗалык итүдәге хезмәттәшлеген оештыруның башка формалары әйдәп бара, алар **базар системасын** тәшкил итә.

Аның нигезен тәшкил итәләр (2-1 рәсем):

— хосусый милеккә хокук;

— икътисади ирек;

— конкуренция.

Хосусый милеккә хокук — аерым кешенең закон тарафыннан танылган һәм якланган хокукы ул. Бу хокукка таянып, кеше билгеле бер төр ресурслар күләменнән (мәсәлән, җир кишәрлегеннән, күмер ятмаларыннан яки фабрикадан) файдаланырга, аның белән эш итәргә, димәк, шуннан керем алырга мөмкин. Капитал кебек җитештерү ресурслары төренә ия булу һәм шуңа нигезләнеп керем алу мөмкинлеге мондый икътисади системаның капитализм дигән икенче атамасы туууга сәбәп булды.

2-1 рәсем.
Капиталистик икътисади система нигезләре

БАЗАР СИСТЕМАСЫ — капитал һәм җир аерым затлар милкендә булган, ә чикләнгән ресурслар базар законнары буенча бүленә торган икътисади тормышны оештыру ысулы.

ХОСУСЫЙ МИЛЕК — аерым гражданнарның һәм алар берләшмәләренең теләсә кайсы төр икътисади ресурслар күләменә (өлешенә) ия булуга, файдалануга һәм идарә итүгә дәүләт тарафыннан танылган хокукы.

Иң элек хосусый милеккә хокук бары тик корал көче белән генә яклана, ә милекчеләр рәтендә бары тик корольләр һәм феодаллар гына була. Әмма соңрак, сугыш һәм революцияләр кайнаган озын юл узганнан соң, кешелек милек алырлык кереме булган һәр граждан хосусый милекчегә әверелерлек цивилизация төрс ала.

Хосусый милеккә хокук икътисади ресурслар хуҗаларына алардан ничек файдалануны мөстәкыйль хәл итү мөмкинлеге бирә (бары тик җәмгыять мәнфәгатьләренә генә зыян китерерлек булмасын). Шуның белән бергә, икътисади ресурслардан чикләнмәгән файдалану ирегенең икенче ягы да бар: хосусый милек хуҗалары аннан файдалануның үзләре сайлаган вариантлары өчен икътисади яктан тулысынча җаваплы булалар. Башкача әйтсәк, алар сайлаган вариант уңышлы булып чыкса, файда күрәләр, ә ялгышкан очракта үз милекләренең бер өлешен яки тулысынча ук югалтырга мөмкиннәр.

Икътисади ирек — җитештерү ресурсларына ия булган һәр кешенең, керем алу өчен, алардан ничек һәм күпме файдалануны мөстәкыйль хәл итә алу хокукы ул. Шул ук вакытта һәр кешенең тормыш муллыгы үзе ия булган ресурсны (үзенең эш көчен, хезмәт күнекмәләрен, үз кулы белән ясаган әйберләрне, үз җир кишәрлеген, үз фабрикасы продукциясен яки коммерция операцияләре оештыру осталыгын) базарда нинди уңыш белән сата алуыннан бәйле була.

Җитештерү факторлары һәм товар базарлары — башкача әйтсәк, товар алмашу һәм җәмгыятьнең чикләнгән ресурсларын бүлү буенча билгеле рәвештә оештырылган эшчәнлек:

1) теге яки бу хуҗалык инициативасының уңышлылык дәрәҗәсен билгели;

2) милекнең үз хуҗаларына китергән керем күләмен формалаштыра;

3) чикләнгән ресурсларны файдаланучы альтернатив сфералар арасында аларны (ресурсларны) бүлгәләү пропорцияләрен күрсәтә.

Базар механизмының уңай ягы һәр сатучыны, уңышка ирешү өчен, сатып алучылар мәнфәгате турында кайгыртырга мәҗбүр итүдән гыйбарәт. Әгәр дә ул моны эшләмәсә, аның товары кирәксез яки артык кыйбат булырга һәм керем урынына зыян гына китерергә мөмкин. Шул ук вакытта сатып алучы да сатучы мәнфәгатьләре белән исәпләшергә мәҗбүр — ул товарны базарда урнашкан бәяне түләп кенә ала.

Конкуренциягә корылган базарлар чикләнгән җитештерү ресурслары һәм алар ярдәмендә булдырылган байлыкларны бүлүнең кешелеккә мәгълүм иң уңышлы ысулына әверелә.

Конкуренция бүген икътисад нигезләренә житди йогынты ясап, хуҗалык эшчәнлеген оештыруда гаять зур роль уйный. Яхшы түләүле эшкә урнашырга теләүче кешеләр, үзләренең тәҗрибәләрен яки квалификацияләрен конкуренциягә лаек сыйфатлары итеп күрсәтеп, бер-берсе белән көндәшлек итәләр. Бер үк төрле товар

житештерүче фирмалар, үз продукцияләренең сыйфатын югарырак дәрәҗәдә дип аңлатып, сатып алучылар акчасы өчен көрәшәләр. Сатып алучылар исә базарга аз санда гына чыгарылган модалы яна әйберне алырга теләп, аның хуҗасы булу өчен ярышалар һәм сатучыларга тагы да югарырак бәя тәкъдим итәләр һ.б.

КОНКУРЕНЦИЯ (КӨНДӘШЛЕК) — билгеле бер төр чикләнгән ресурсларның күбрәк өлешен алу хакына барган икътисади ярыш.

Конкуренция булганда, чикләнгән ресурслар икътисади аргументлары куәтлерәк көндәшләр кулына керә. Конкуренциянең уңай ягы әнә шуннан гыйбарәт тә инде. Мәсәлән, сатып алучыларның чикләнгән акча средстволары өчен конкуренция көрәшендә фирма үз товарларын бары тик конкурентларга караганда яхшырак сыйфатлы, әмма азрак чыгымнар тотып житештерсә генә жиңәчәк, чөнки ул аларны арзанрак бәягә сата алачак. Сатып алучылар арасындагы дефицит товар өчен көрәштә эшчәнлекләре югарырак бәяләнгән һәм яхшырак түләүгә лаек булганнар жиңеп чыга, чөнки алар товар өчен иң кыйбат бәяне тәкъдим итә ала. XX гасырның 90 нчы елларында чит ил житештерүче фирмалары белән конкуренция килеп чыгу аркасында, Россия фирмалары тәмле генә түгел, ә матур итеп төрелгән азык-төлек әзерләргә, яңа төр соклар чыгаруны үзләштерергә, яңа автомобиль модельләре һәм йорт жиһазының яңа төрләрен житештерүне өйрәнергә мәжбүр булдылар. Бу хәлдән, әлбәттә, иң элек сатып алучылар отты.

Әлбәттә, базар системасының кимчелекләре дә бар (бу турыда алдарак сөйләнәчәк әле). Аерым алганда, ул кешеләрнең керемнәре һәм байлыклары арасында бик зур аермалар китереп чыгара: кемнәрдер байлык эчендә йөзә, ә кемнәрдер хәерчелектә интегә. Бу хәлне без бүгенге Россиядә күзәтә алабыз.

Керемнәрдәге мондый аерманы күреп, кешеләр элек-электән капитализмны «гаделсез» икътисади система дип аңлаталар һәм камилрәк тормыш тәртибе турында хыялланалар. Мондый хыяллар XIX гасырда марксизм дип аталган ижтимагый хәрәкәт туута китерә. Бу хәрәкәтнең атамасы аның төп идеологы, немец журналисты һәм икътисадчысы Карл Маркс исеме белән бәйләнгән. Ул һәм аның фикердәшләре базар системасы үз үсеше мөмкинлекләрен файдаланып бетерде һәм кешелек тормышының алга үсүен тоткарлый башлады дип раслыйлар. Һәм аны социализм (латинчадан socium — жәмгыять) дигән яңа икътисади система белән алыштырырга тәкъдим итәләр.

§ 4. Командачыл һәм катнаш система

Командачыл икътисади система барлыкка килүгә Беренче бөтендөнья сугышыннан соң дөнья илләрендә килеп туган икътисади хәл сәбәп була. Бу сугыш йомгаклары, ирекле базар мөнәсәбәтләренең дәүләт контроленнән тыш киң колач белән үсүе 1929 елгы Бөек депрессиягә китерә, һәм ул дөньяның барлык илләренә диярлек кагыла. Базар «чоңгылы»ннан бердәнбер чыгу юлы дәүләт ролен үзгәртүдән һәм икътисад белән идарә итүнең үзәкләштерелгән органнарын төзүдән гыйбарәт дип табыла. Командачыл икътисади система иле булган Советлар Россиясенең гражданнар

сугышы елларында икътисад белән идарә итүдәге һәм илне сугыштан соң 1921—1929 елларда кризистан чыгарудагы уңышлары моңа мисал булып тора.

Моннан соң дөньяның барлык илләрендә дә үзәкләштерелгән идарә органнары төзелә, Германиядә, Италия һәм Испаниядә өлешчә планлы хуҗалыкка күчәләр (Германиядәге «Дүртьеллык план», 1936 ел).

КОМАНДАЧЫЛ ИКЪТИСАДИ СИСТЕМА — икътисади тормышны оештыру ысулы ул. Бу система яшәгәндә, җир һәм капитал дәүләт милкендә була, ә чикләнгән ресурслар үзәк идарә органнары күрсәтмәләре буенча һәм планнар нигезендә бүленә.

XX гасырның командачыл системасы эшчәнлеген илебезнең әле күптән түгел генә узган тарихына карап ташлап аңларга мөмкин. Ул елларда житештерүче предприятиеләрнең эшчәнлеге түбәндәге тәртиптә көйләнә:

НӘРСӘ ҖИТЕШТЕРӘСЕН Дәүләт план комитеты билгели;

НИЧЕК ҖИТЕШТЕРӘСЕН тармак министрлыгы билгели, житештерү технологиясен ул күрсәтә һәм җиһазлар алуга кирәкле акчаны да ул бирә;

КЕМГӘ САТАСЫН Дәүләт тәэминат комитеты хәл итә. Житештерүнең яңа циклы өчен кирәкле бөтен ресурсларны кемнән сатып аласын да ул билгели.

НИНДИ БӘЯДӘН САТАСЫН Бәяләр билгеләү буенча дәүләт комитеты күрсәтә, шулай ук ул дистә еллар дәвамында үзгәрмәгән бәяләр белешмәлекләрен дә раслый;

ЭШЧЕЛӘРГӘ КҮПМЕ ТҮЛИСЕН Хезмәт һәм хезмәт хакы дәүләт комитеты күрсәтә;

Предприятиеләргә килгән керемне НИЧЕК ФАЙДАЛАНАСЫН Финанс министрлыгы хәл итә;

Житештерүне үстерү өчен НӘРСӘ ТӨЗЕРГӘ икәнлеген Дәүләт төзелеш комитеты билгели;

Нинди максатлар өчен банктан КҮПМЕ АКЧА АЛАСЫН Дәүләт тармак банкларының берсе билгели;

Чит илләргә НӘРСӘ САТАРГА яки аннан нәрсә сатып алырга икәнлеген Тышкы сәүдә министрлыгы хәл итә.

Әйтергә кирәк, икътисадта планлаштыру — бик нигезле идея. Ул предприятие, фирма яки ферма эчендә тормышка ашырыла, боларда план:

1) аерым бер хужа кушуы буенча төзелә. Бу хужа сайлап алынган план күрсәткечләренең дөреслеге һәм планның уңышлы үтәлеше өчен тулысынча матди җаваплылыкны (хәтта бөлгенлеккә төшкәндә дә) үз җилкәсендә күтәрә;

2) эш буенча килешүгә (сделкага) партнерларны ирекле сайлап алу һәм үзара сату-алу бәяләрен ике якның да ризалыгы белән билгеләү нигезендә тормышка ашырыла;

3) сатып алучыларның ихтыяжы буенча нигезлелеге тикшерелә;

4) карарлар кабул итүче һәм алар өчен җаваплы булган затлар туплаган әһәмиятле икътисади мәгълүматка таяна.

Америка Бөек депрессияне ни өчен хәтерли

XX гасырның 20 нче еллары Кушма Штатлар өчен икътисади чәчәк ату чоры була — 1929 елга бу ил дөнья сәүдәсенең гомуми күләмендә беренчелеккә ирешә, ә Латин Америкасындагы 20 илнең 14е АКШ финанс контроле астында тора. Шуңа күрә дә АКШ президенты Герберт Гувер 1929 елгы бер чыгышында америкалыларны илнең барлык гражданнары тормышы чәчәк атар, һәм «һәр табакта тавык ите, һәр гаражда икешәр машина торыр» дип ышандыра.

Мондый өметле вәгъдәләр йогынтысында барлык америкалылар тиз генә баеп киту вакыты җитте дип исәпләп, уйлап-нитеп тормыйча, хәтта кыйммәтле кәгазьләр белән спекуляция кебек хәвефле операцияләргә алыналар. Хуҗабикәләр һәм тимер юл кондукторыннан алып министрларга һәм президентка кадәр бар халык, үзендәге кыйммәтле кәгазьләрнең даими кыйбатлана баруын күреп һәм шуның аркасында үзенең көннән-көн байый баруын сизеп, рәхәтләнеп биржада уйный.

Әмма базар икътисадында беркайчан да иртәгесе көнгә ныклап ышанып булмый. Һәм 1929 елның 24 сентябрендә Американың үсеш тәгәрмәче рельслардан төшә. Якынлашып килүче икътисади бәла Нью-Йорктагы фонд биржасындагы төшенкелектән башланып китә. Анда сатылучы кыйммәтле кәгазьләрнең бәяләре төшә башлый, баштарак бу бик акрын гына бара, тора-бара тизләшкәннән-тизләшә. Ахыр чиктә, алар якынча 4,5 тапкыр арзаная һәм бу кәгазьләргә ия булган гаять күп санлы америкалылар кисәк кенә банкротка әверелә. Үзләренең бөлүе турындагы хәбәрне алгач, югары кат тәрәзәләреннән ташланган банкирлар тарихын америкалылар әле бүген дә бик яхшы хәтерли.

Әмма аерым кешеләр генә бөлгенлеккә чыкмый. 1929—1933 елларда 130 мең фирма ябылырга мәҗбүр була, якынча 1 млн авыл хуҗалыгы фермасы аукционда сатып җибәрелә. Үзенә акча салучыларга 5 млрд доллар бурычы калган 8 мең банкның түләү сәләте югалу икътисад өчен аеруча куркыныч була.

Бу хәл илкүләм паниканы китереп чыгара, кешеләр үз акчаларын таләп итеп банк ишекләренә ташлана. АКШ президенты Гувер урынына килгән Франклин Рузвельт, илнең банк системасы җимерелүен китереп чыгармас өчен, «банк каникуллары» турында карар чыгара, ягъни икътисадтагы паника беразтынычланганчы гына булса да банклар эшен туктатып тора.

Ябык предприятиеләр эшчеләре һәм җирсез калган фермерлар эшсез кала. Эшсезләр саны 17 млн кешегә җитә — һәр өченче кеше хезмәт хакыннан читтә кала. Ил күген өметсезлек болыты каплый, ачлыктан үлү чынбарлык хәлгә әверелә: 1931 елда гына да бары тик Нью-Йоркта ачлыктан 2 мең кеше дөнья куя.

Әлеге караңгы еллар Джон Стейнбекның «Ачу тәлгәшләре» дигән романында сурәтләнә. Ул елларда АКШ юллары буйлап көнлек кенә булса да эш табу өмете белән йортсыз, эшсез калганнар өере йөри. Мамык уңышы җыюда аз түләүле иң авыр эшне дә таба алмасалар, алар өметсезлектән Вашингтонга «ачлык походлары» оештыра, хөкүмәттән икмәк һәм эш таләп итә.

Бары тик дүрт елдан соң ил икътисады бик авырлык белән генә кризистан чыга башлый. Әлеге кризис АКШ тарихына һәм дөнья икътисады тарихына Бөек депрессия буларак кереп кала.

Ил күләмендә планлаштыру аеруча сугыш вакытларында кулай була. Мондый чакларда илне агрессорлардан саклау бурычы аерым кешеләр һәм фирмалар мәнфәгатьләренә караганда беренче урынга чыга.

Әгәр дә закон хосусый милекченең үзенә караган ресурслары белән мөстәкыйль эш итүен чикләгән очракта гына, дәүләт икътисади ресурслардан файдалану белән командалык итә ала.

Әгәр дә бөтен ресурслар да (житештерү факторлары) гомумхалык милке дип игълан ителеп, чынлыкта алар белән тулысынча дәүләт һәм партия чиновниклары эш итсә, бу гаять куркыныч икътисади нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Кешеләрнең һәм фирмаларның керемнәре чикләнгән ресурслардан никадәр уңышлы файдалануларыннан, аларның хезмәт нәтиҗәсе җәмгыятькә никадәр кирәк булудан тормый башлый. Әмма башка критерийларның әһәмияте арта:

а) предприятиеләр өчен — товарлар җитештерү буенча план йөкләмәләрен үтәү һәм арттырып үтәү дәрәҗәсе. Предприятие җитәкчеләрен нәкъ шуның өчен орденнар белән бүләклиләр һәм министрлар итеп куялар. Бу товарларның сатып алучыларны кызыксындырмавы мөһим булмый. Әгәр дә мөмкин булса, алар башка төрле әйберләрне алырлар иде. Шулай ук бу товарларны җитештерүгә артык зур ресурслар тотылуы, һәм товарның гаять кыйммәт булуы турында беркем дә уйлап карамый. Сатып алучы, ахыр чиктә, барыбер шыксыз йорт җиһазы яки иләмсез зур станок алырга мәҗбүр була. Чөнки альтернатива юк — башка төрле җиһаз җитештерелми һәм предприятиеләр план күрсәтмәләре буенча шундый станокны алырга тиеш булалар, һәм моның өчен акча бүлеп бирелә;

б) кешеләр өчен — аеруча дефицит товарларны (машиналар, фатирлар, йорт җиһазы, чит илләргә юлламалар h.б.) бүлүче җитәкчеләр белән үзара мөнәсәбәтләр характеры, яки «ябык бүлү урыннары»на юл ачучы хезмәт вазифасына ия булу. Мондый урыннарда дефицит нәрсәләрне җиңел генә сатып алырга мөмкин була.

Планлы-командачыл яки базар икътисади системалары турында сөйләгәндә, аларны аерым рәвештә бары тик фәнни хезмәтләрдә генә табып булуын истә тоту зарур. Реаль хуҗалык тормышы, киресенчә, һәрвакыт төрле икътисади системалар элементлары кушылмасыннан гыйбарәт була.

Күпчелек алдынгы илләрнең бүгенге икътисади системасы катнаш характерда. Аларда ил күләмендәге һәм региональ икътисади проблемалар дәүләт тарафыннан хәл ителә.

Кагыйдә буларак, бүген дәүләт җәмгыятьнең икътисади тормышында ике сәбәп белән катнаша:

1) җәмгыятьнең кайбер үзенчәлекле ихтыяҗларын (армияне тәэмин итү, законнар эшләү, урамдагы хәрәкәтне оештыру, йогышлы авыруларга каршы көрәш h.б.) ул базар механизмнары нигезендә хәл итүгә караганда яхшырак канәгатьләндерә ала;

2) базар механизмнары эшчәнлегенең тискәре нәтиҗәләрен (гражданнар байлыкларында гаять зур аермалар, әйләнә-тирә мохиткә коммерция фирмалары эшчәнлеге китергән зыян) киметергә мөмкин.

Шуңа күрә XX гасыр ахыры цивилизациясендә **катнаш икътисади система** өстенлек ала.

Сергей ВИТТЕ

Россия икътисадына нигез салган шәхесләр арасында граф Сергей Юльевич Витте (1849—1915) аерым урын алып тора, ул императорлар Александр III һәм Николай II хөкүмәтләрендә төп рольләр башкара, рубльне яклаучы һәм Россияне индустрияләштерү — сәнәгать һәм транспортта яңа тармаклар төзүгә әйдәүче буларак тарихка кереп кала.

Сергей Витте эре патша чиновнигы, Кавказдагы Дәүләт мөлкәте департаменты директоры гаиләсендә туа. Сәләтле үсмер профессор булу турында хыяллана, әмма аның туганнары дворян нәселеннән чыккан кешегә бу юл лаек түгел дип таба. Аны дәрәҗәле чиновник карьерасын сайларга мәҗбүр итәләр. Ул бу юлда иң югары баскычка күтәрелә — Министрлар Кабинеты Рәисе дәрәҗәсенә ирешә.

Әмма бу юл туры гына бармый. Аның чиновниклык карьерасының беренче этабы әллә ни озакка сузылмый, чөнки элемтә юллары министры граф Бобринский төпле егетне бик тиз алга киткән тимер юллар челтәре проблемалары белән кызыксындыруга ирешә.

Сергей Витте станция башлыгы ярдәмчесе булып эшләп, транспорт икътисадын алты ай дәвамында иң башлангыч ноктасыннан ук өйрәнә. Гомумән алганда, Витте хосусый тимер юл компанияләрендә 20 ел эшли. Ул тәҗрибәле зур белгечкә әверелә, һәм аны элемтә юллары министры итеп билгеләү беркемдә дә гаҗәпләнү уятмый. Виттены 1892 елда финанс министры урынына тәкъдим итүне дә Россия сәнәгате эшлеклеләре яклап чыгалар. Финанс министрлыгы ул чорда тимер юл транспортын, сәүдә һәм сәнәгать эшчәнлеген контрольдә тота, димәк, граф Витте дәүләтнең икътисад белән идарә итүендә төп шәхескә әверелә.

Рус икмәк экспортын чикләргә омтылган Германия белән «сәүдә көрәшендә» үзенә абруйлы исем яулаганнан соң, Витте шәраб монополиясе ярдәмендә Россия бюджетын шактый ныгытуга ирешә. Акча реформасы үткәрүе һәм алтын стандартка күчерүе аның Россия икътисадын ныгытудагы аеруча зур адымы була. Бу реформага кадәр Россия рубле бик көчсез була. Салтыков-Щедрин хәтта: «Хәзер рубльгә Европада берни бирмиләр, озакламый яңакка суга башлаячаклар»,— дип яза.

Витте реформасы танылган сатирикның әлеге прогнозын кире кага: рубльнең абруе күтәрелә, ил кибетләре кулай бәягә алып булырлык чит ил товарлары белән тула. Рубльнең ныгуы һәм Витте үткәргән башка икътисади чаралар Россиягә эре чит ил кертемнәре килүгә шартлар тудыра.

Бу акчалар тиз арада илдә автомобиль, электр техникасы һ.б. кебек яңа тармаклар булдыруга мөмкинлек ача. 20 ел эчендә Россия сәнәгате өч тапкырдан да күбрәккә үсә.

Ил алдындагы әлеге зур казанышларына карамастан, «артык либераль» карашлары өчен Николай II аны отставкага җибәрә.

КАТНАШ ИКЪТИСАДИ СИСТЕМА — хосусый милеккә нигезләнгән икътисади тормышны оештыру ысулы. Монда чикләнгән ресурсларны бүлү базарлар һәм шулай ук шактый күләмдә дәүләт катнашында тормышка ашырыла.

Мондый икътисади системаның нигезен икътисади ресурсларга хосусый милек тәшкил итә, гәрчә кайбер илләрдә (Франция, Германия, Бөекбритания һ.б.) шактый эре дәүләт секторы да бар. Ана капиталлары өлешчә яки тулысынча дәүләткә караган предприятиеләр керә (мәсәлән, немец авиакомпаниясе «Люфтганза»). Әмма алар:

а) дәүләттән план алмый;

б) базар законнары буенча эшли;

в) хосусый фирмалар белән бертигез дәрәҗәдә көндәшлек итә.

Бу илләрдә төп икътисади мәсьәләләр, нигездә, базарлар тарафыннан хәл ителә. Икътисади ресурсларның шактый өлешен дә алар бүлеп бирә. Шулай да ресурсларның бер өлеше дәүләт тарафыннан, кайбер йомшак базар механизмнарын компенсацияләү максатында, командачыл механизмнар ярдәмендә үзләштерелә һәм бүлеп бирелә (2-2 рәсем). Мондый катнашуның төп идеясе шәхси уңышның һәрвакытта да бернинди тоткарлыксыз бәяләнергә тиешлеге, ә базар механизмнары тудырган гаделсезлекнең мөмкин кадәр киметелү зарурлыгыннан гыйбарәт.

Бу идеяне тормышка ашыру гаять авыр. Шуна күрә дә күп кенә илләр, **социаль көйләнүле базар (социаль базар хуҗалыгы)** төзергә омтылып, немец сәясәтчеләре — 1949 елдан алып 1963 елга кадәр ГФР канцлеры булып торган Конрад Аденауэр (1876—1967) һәм икътисад министры Людвиг Эрхард төзегән мондый базар принципларын үзләрендә дә тормышка ашыру мөмкинлеген җентекләп өйрәнәләр. Бу принциплар бик гади:

1. «Мин — граждан — бу тормышта үземә үзем юл ачачакмын, язмышым өчен җаваплылыкны үз өстемә алырга әзермен. Син — дәүләт — мин шулай эшли алырлык, гамәлләрем ирекле булырлык шартлар тудыру турында кайгырт».

2-2 рәсем.
Катнаш икътисади система элементлары
(I — базар механизмнары эшчәнлеге өлкәсе; II — командачыл механизмнар эшчәнлеге, ягъни дәүләт тарафыннан контроль өлкәсе)

2. «Гамәлләр ирегe чиксез була алмый. Алар кешенең үзе яшәгән җәмгыять алдындагы бурычлары белән тулыландырылырга тиеш».

3. «Җәмгыять бурычы — барлык халыкны яхшы тормыш белән тәэмин итү, бу максатка ирешү юлы — базар конкуренциясе аша яхшы тормышка ирешү».

СОЦИАЛЬ КӨЙЛӘНҮЛЕ БАЗАР — катнаш икътисади системаның бер төре. Мондый системада җәмгыять һәм дәүләт икътисади үсешне тәэмин итәргә генә түгел, ә хуҗалык итү ирегe, гражданнар һәм дәүләт арасында җәмгыять тормышы өчен җаваплылыкны дөрес итеп бүлү һәм гражданнар теләктәшлеге бергә үрелү принципларын тулырак тормышка ашырырга омтыла.

Димәк, мондый система нигезендә хезмәткә сәләтле һәр гражданның «Үз тормышым иминлеге, муллыгы өчен мин үзем җаваплы!» дигән анлы тормыш позициясе ята.

Ә Россиянең бүгенге икътисади системасы нинди соң? Бу сорауга җавап эзләгәндә, шуны искә алу зарур:

1) безнең илдә командачыл система нигезләре инде җимерелгән;

2) базар системасы механизмнары әле формальша гына;

3) житештерү факторлары әлегә тулысынча хосусый милеккә әверелмәде.

Якын киләчәктә Россиягә, һичшиксез, базар механизмнарын кабат торгызырга һәм, аларга таянып, катнаш икътисади система төзергә туры киләчәк. Безнең илдә мондый системаның конкрет милли моделен сайлау зарурлыгы мәсьәләсе дә бар әле. Бүгенге көндә галимнәр һәм сәясәтчеләр нәкъ шул турыда бәхәсләшәләр (бу турыда соңгы бүлектә җентеклерәк итеп сөйләнер).

Икътисади системалар төрләре, аларның унай һәм кимчелекле яклары турындагы сөйләшүне тәгәлләп, без икътисади акыллылык рецептының икенчесен төзи алабыз.

Икенче рецепт

Командачыл икътисади система барлыкка килүдән сакланырга һәм базарлар хәл итә алмаган яки уңышсыз хәл иткән икътисади мәсьәләләрне чишүдә генә дәүләтнең катнашуына юл куярга кирәк.

БҮЛЕКНЕҢ ТӨП ЭЧТӘЛЕГЕ

Икътисади системалар турында төшенчә. *Кешелекнең хуҗалык эшчәнлеге төрле рәвештә корылырга мөмкин. Бу аермалар ничек хуҗалык итүне хәл итү ысулларында һәм төп ресурсларга карата милек төрләрендә аеруча нык чагылыш таба. Кешелеккә дүрт төр икътисади система билгеле: традицион, базар, командачыл һәм катнаш.*

***Традицион икътисади система** — җир һәм капитал кабиләнең уртак милегендә булып, чикләнгән ресурслар бик озак вакытлар яшәгән традицияләр нигезендә бүленә торган система ул.*

***Базар системасы.** Саф базар системасы булганда, җәмгыятьнең икътисади тормышында барлык икътисади ресурслар да хосусый милектә тора, ә барлык карарлар да тиешле базарларда кабул ителә. Бу базарларның эшчәнлеге беркем тарафыннан чикләнми һәм көйләнми.*

***Командачыл система.** Мондый икътисади системада җитештерү факторларына хосусый милекне бетерү һәм аны дәүләт милке белән алыштыру күз алдында тотыла. Төп икътисади мәсьәләләр дәүләт идарәсе органнары тарафыннан хәл ителә һәм үтәлүе мәҗбүри булган боерыклар һәм планнар аша тормышка ашырыла. Моның өчен дәүләт җәмгыять икътисади тормышының барлык якларын көйли, шул исәптән бәяләрне һәм хезмәт хакын билгеләүне дә үз өстенә ала. Мондый системаның тискәре ягы кешеләрнең хезмәткә кызыксынуы югалуда һәм хезмәт нәтиҗәләрен җәмгыятьнең реаль ихтыяҗлары белән туры килмәгән формаль критерийлар буенча бәяләүдә чагыла.*

***Катнаш икътисади система.** Бу икътисади система күпчелек икътисади ресурсларга хосусый милекнең чикләнгән дәүләт милке белән бергә үрелүен күз алдында тота. Дәүләт планнар ярдәмендә төп икътисади мәсьәләләрне хәл итүдә катнаша, үзәкләштерү аша икътисади ресурсларның бер өлешен үз карамагында тота. Бу ресурслар базар механизмнарының кайбер йомшак якларын киметерлек итеп бүлеп бирелә.*

ФИКЕР АЛЫШУ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Дәүләтнең гаять зур яклавыннан файдаланучы «Эр Франс» француз дәүләт авиакомпаниясе рейсларына билетлар Британия хосусый авиакомпанияләренен шундый ук рейслары билетларына караганда шактый кыйбатрак. Бу нилектән шулай булырга мөмкин?
2. Бөек депрессия елларында Рузвельт алып барган икътисади сәясәт уйланырга мәҗбүр итәрлек мәгълүматка ия. Аның АКШны депрессиядән чыгару программасын үзегез эзләп табыгыз. Ул программаның төп юнәлешләрен атагыз.

Базар белән идарә итүче көчләр

БҮЛЕКТӘ КАРАЛУЧЫ МӘСЬӘЛӘЛӘР:

1. СОРАУ ХЫЯЛДАН НИ БЕЛӘН АЕРЫЛА?
2. ИКЪТИСАДНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЗАКОНЫ НӘРСӘНЕ РАСЛЫЙ?
3. КЕШЕЛӘР НИ ӨЧЕН БИЗНЕС БЕЛӘН ШӨГЫЛЬЛӘНӘ?
4. БАЗАРДА ТОВАР КҮЛӘМЕ НИДӘН БӘЙЛЕ?

Кырыктартмачы, асламчы, лотокчы, коммивояжер — сатып алучыларга төрле товарлар таратып йөрүче сәүдәгәрләрне төрле заманнарда әнә шулай атаганнар.



Базарда бәянең бик нык төшә алуын шушы графикта яхшы күрергә мөмкин. Бу очракта җәйге төзелеш сезоны тәгамләнү аркасында, АКШның ылыслы агач материаллары базарында агачка сорау кискен кимү белән бәйле булган бәя төшү күрсәтелгән.

Гадәти көндәлек тормышта һәртөрле товарларга сорау аларны тәкъдим итүгә караганда алданрак йөри.

Давид Рикардо

Шулай итеп, без түбәндәгеләрне белдек:
1) бүгенге дөньяда дәүләт һәм халыкара хокук тарафыннан төрле дәрәҗәдә көйләнүче катнаш икътисади системалар күпчелекне тәшкил итә;
2) чикләнгән ресурслар бу системаларда күбесенчә базар ярдәмендә бүлеп бирелә;
3) һәр кешенең кереме аның теге яки бу базарда сатуга нәрсә тәкъдим итә алуыннан бәйле була.

Базарлар җәмгыять тормышында шундый зур роль уйный икән, аларның ничек эшләве һәм кешеләргә икътисади мәсьәләләрне хәл итүдә ничек булышулары белән танышып үтик.

Кайсы гына базарга керсәгез дә, базар процессының асылы товарлар сату-алудан гыйбарәт булуын күрерсез. Монда төп катнашучылар булып сатучылар һәм сатып алучылар тора. Шуңа күрә базар эше закончалыкларын сатып алучылар ниятләрен һәм сатучылар теләкләрен төшенеп кенә аңлап була.

§ 5. Сорау нәрсә ул

Һәр кешегә теге яки бу әйбер кирәк. Әгәр дә ул аларны үзе җитештерә алмаса, аның өчен ул әйберләрне сатып алу кулайрак һәм шул максаттан ул базарга килә. Әлбәттә, базарда бер генә нәрсәне дә бушка алып булмау сәбәпле, аның кесәсендә акчасы булу зарур. Димәк, без базарда ниндидер ихтыяҗлар белән түгел, ә сорау (спрос) белән очрашабыз.

Бу терминны, төгәлрәк әйтсәк, «түләү сәләте булган сорау» дигән аның төгәл вариантын фәнни лексикага күренекле инглиз икътисадчысы Томас Роберт Мальтус (1766—1834) кертеп җибәрә. Ул моны кешеләрнең теге яки бу байлыкларны үзенә алу турындагы хыяллары белән бу байлыкларны реаль алу мөмкинлекләре арасында асрмачык чик уздыру өчен эшли.

Бу асрманы Мальтустан да элегрәк Адам Смит бик яхшылап тасвирлый:

«Хәтта иң ярлы кешедә дә, билгеле бер мәгънәдә, алты ат җигелгән каретага сорау булырга мөмкин; аның хәтта аны алу теләге дә булуы бар; әмма аның соравы бервакытта да реаль сорауга әверелмәячәк, чөнки бу товар нәкъ шушы кешенең теләкләрен канәгатьләндерү өчен генә базарга китерелмәячәк».

Мальтус аның бу фикеренә тагы да ачыклык кертә һәм Смитның «реаль сорау» дигәнен «түләү сәләте булган сорау» дип атый. Ул ясаган нәтиҗәләр икътисади тормышның иң мөһим кагыйдәләренең берсен формалаштырырга мөмкинлек бирә:

«Базар процесслары өчен кешеләрнең бары тик күпмедер товар сатып алырга чынлап та җитәрлек акча суммалары белән ныгытылган теләкләре генә әһәмиятле була».



3-1 рәсем.
Сатып алулар күләме һәм бәя зурлыгы бәйләнеше

Мондый мәгънәдәге сорау базардагы хәлне, төгәлрәк әйтсәк, кешеләр алырга әзер булган товарлар күләменең алар сатып алачак әйбер бәясе зурлыгы белән бәйләнешен характерлый.

3-1 рәсемендә нәкъ шушы бәйләнеш сурәтләнгән. Монда күренгәнчә, базарда бәя түбәнрәк булган саен, сатып алучы үзе теләгән товарларны күбрәк алыр иде.

СОРАУ ЗУРЛЫГЫ — сатып алучылар билгеле бер вакыт эчендә (ай, ел) билгеле бер зурлыктагы бәядән алырга әзер булган (телиләр һәм моңа мөмкинлекләре бар) натураль үлчәмдәге аерым төр товар күләме.

СОРАУ — товар базарындагы сорау зурлыгының товарларның сатуга чыгарылачак бәяләреннән билгеле бер вакыт эчендә барлыкка килгән бәйлелеге.

Мөмкин булган сорау зурлыклары турындагы мәгълүматны кәкре сызык рәвешендә күзалларга була, аны **сорау кәкресе** (кәкре сызыгы) дип атыйлар (3-2 рәсем). Ул аерым бер товар базарындагы сорауны тасвирлый, ягъни:

— товар бәясе һәм

— төрле зурлыктагы бәядән мөмкин булган сатып алу күләме арасындагы бәйлелекне күрсәтә.

Сорау кәкре сызыгы түбәндәге ике сорауга җавап табарга мөмкинлек бирә:

1) төрле зурлыктагы бәяләр булганда, сорау зурлыгы нинди булачак?

2) бәяләр беркадәр үзгәргәндә, сорау зурлыгы ничек үзгәрәчәк?

Кәкредәге һәр нокта билгеле бер бәядән әлеге товарга булган сорау зурлыгын (мөмкин булган сатып алулар күләмен) күрсәтә. Мәсәлән, 120, 750 координаталарындагы нокта сатып алучылар 750 акча берәмлеге белән күрсәтелгән бәядән 120 велосипед алырга әзер дигәнне аңлата.



3-2 рәсем.
Сорау кәкресе *(велосипедлар базары үрнәгендә)*

Сорау кәкресе базарда аерым бер вакытта мөмкин булган барлык сорау зурлыгы вариантларын күрсәтә. Алар бихисап булырга мөмкин. Шуңа күрә аерым төр товар базарындагы гомуми ситуацияне тасвирлаганда, «сорау зурлыгы» терминыннан түгел, ә «сорау» терминыннан файдалану җиңелрәк булачак.

«Сорау зурлыгы» һәм «сорау» терминнарының һәрберсе аерым бер сорауга җавап бирүен белгәндә генә, алар арасындагы аерманы ачыкларга мөмкин.

Кибет хуҗасының: «Сатып алучылар миннән бер ай эчендә 100 сум бәядән ничә товар алыр?» — дигән соравына СОРАУ ЗУРЛЫГЫ турындагы мәгълүмат җавап булачак.

Әгәр дә ул: «Аерым бер товарга төрле зурлыктагы бәяләр куелганда, бер ай эчендә сатып алучылар ничә товар сатып алыр?» — дип башкачарак итеп сораса, бу базарда сатып алучылар СОРАВЫ сыйфатламасы моңа җавап булачак.

Бәя һәм сатылган товарлар күләме арасындагы бәйлелек механизмын яхшырак аңлау өчен, 3-1 таблицасында китерелгән күрсәткечләрне карыйк (мондый таблицаларны **сорау шкаласы** дип атау кабул ителгән). Беренче баганадагы саннар велосипедлар бәясенең мөмкин булган зурлыкларын күрсәтә, ә икенчесендә сатып алучылар теге яки бу зурлыктагы бәядән алырга әзер булган велосипедлар саны теркәлгән.

3500 акча берәмлегенә тигез бәя велосипедларга ихтыяҗ булса да, сорау зурлыгы нульгә тигез булган хәлне тудыра. Сәбәп бик гади: сатып алучыларның берсе дә бу бәядән әлеге товарны алырга теләми.

Бәя бераз түбәнәйтелсә генә, сорау зурлыгы нульдән аерылып китәчәк. 3000 акча берәмлегенә тигез бәядән сатып алучылар 12 велосипедны алырга әзер. Безнең мисалда 500 акча берәмлегенә тигез бәя куелганда, сорау зурлыгы иң югары ноктада булачак.

Шунысын искәртик: бәяне, мәсәлән, 2400 дән 2000 акча берәмлегенә төшергәндә, бәяне түбәнәйтүнең һәр процентына сорауның 2,04% ка артуы күренә. Ә менә бәяне 1000 нән 750 акча берәмлегенә кадәр төшерү сатып алулар санын бәя төшүнең һәр процентына бары тик 1,46% ка гына арттыра. Башка сүзләр белән әйткәндә, сорау зурлыгы бу мисалда бәяләр үзгәрешенә төрле **сыгылмалылык** белән җавап бирә.

Таблица 3-1

Төрле бәяләр куелганда, велосипедларга карата сорау зурлыгы

Велосипед бәясе, *акча берәмлегендә*	**Мөмкин булган сатып алулар саны, *данәләрдә***
3500	0
3000	12
2400	27
2000	38
1650	50
1300	66
1000	88
750	120
500	145

Сыгылмалылык — бер үзгәрмә зурлыкның икенчесе үзгәрешенә җавап чарасы. Бу — бер үзгәрмә зурлыкның икенче үзгәрмә зурлык 1% ка үзгәргәндә ничә процентка үзгәрүен күрсәтүче сан.

$$\varepsilon_p^d = \frac{\Delta Q}{Q} : \frac{\Delta P}{P} = \frac{\Delta Q}{\Delta P} \cdot \frac{P}{Q},$$

монда ε_p^d — бәя буенча сорау сыгылмалылыгы коэффициенты, P — башлангыч бәя, Q — башлангыч сорау, ΔQ — сорауның үзгәреше, ΔP — бәя үзгәреше.

Рәсемдә дә, мисалда да бәя белән сорау зурлыгы арасындагы бәйләнеш түбәндәгечә урнашты: бәя югарырак булган саен, сатып алулар күләме азрак күзәтелде. Сатып алучылар гамәлләрендәге бу законлалык күпчелек товарлар белән дә кабатлана һәм бу кибетләргә йөргән һәр кешенең шәхси тәҗрибәсе белән дә раслана.

***СОРАУ ЗАКОНЫ:** бәяләр күтәрелү гадәттә сорау зурлыгы кимүгә, ә бәяләр төшү аның артуына китерә.*

Сорау законын белү барыбыз да истә тотарга тиешле ике нәтиҗәгә этәрә (бер акыл иясенең сүзләренә караганда, «һәркем нәрсә дә булса сатып көн итә!»):

1) бәяләр күтәрелү сатулардан килгән керемнең һәрвакыт артуына китерми;

2) үз товарына бәя билгеләгәндә, һәр коммерсант бу товар бәясе буенча гамәлдәге сорау сыгылмалылыгыннан чыгып, үзе куйган бәядән күпме керем алачагын, һичшиксез, алдан ук чамалап куярга тиеш.

Сорау формалашу законлалыклары турындагы сөйләшүне төгәлләп, сорау үзгәрүенә товарның үз бәясеннән тыш әле тагын:

— башка товарлар бәяләре;

— сатып алучыларның керемнәре дәрәҗәсе;

— сатып алучылар саны;

Ли Якокка

Ли Якокка Америка автомобиль сәнәгате тарихындагы иң мәшһүр менеджерларның берседер, мөгаен. Ул хәерче Италия эмигранты гаиләсендә туа, шулай да аның әтисе үз көче белән күтәрелеп, кабымлыклар кафесы хуҗасына әверелә һәм улына югары белем алу мөмкинлеге тудыра, ә улы исә искитмәле карьера ясап, «Форд» компаниясе президенты постына кадәр күтәрелә. Бу урында эшләп, ул гаҗәеп зур уңышларга ирешә, әмма конвейер уйлап тапкан мәшһүр Фордның дуамал оныгы, компания хуҗасы Генри Форд II тарафыннан эшеннән куыла.

Төшенкелеккә бирелмәгән Якокка банкротлык чигенә җиткән «Крайслер» эре автомобиль корпорациясе президенты постына күчә һәм аны бөлгенлектән коткарып кала.

Ли Якокка уңышларының нигезе базар таләпләрен тиз генә аңлап алып, «сорауны якасыннан эләктерүдән» гыйбарәт була. Сорауны дөрес бәяли белүгә һәм шуннан файда алуга «Форд-Мустанг» автомобиле белән булган хәл ачык мисал булып тора. Бу машина проектын эшләгәндә, Якокка үз инженерлары һәм икътисадчыларына машина 2500 доллардан да кыйбат торырга тиеш түгел дигән бурычны куя. Шулай булганда гына, күпчелек америкалыларның бу машина белән кызыксынуы туачак. Һәм ул моңа ирешә дә — машина 1964 елның 17 апрелендә 2368 доллар бәядән сатуга чыга һәм моңарчы күрелмәгән сорау кузгата.

Бу турыда Якокка үзе менә нәрсәләр язган:

«17 апрельдә «Форд» компаниясенең дилерлык пунктлары клиентлар өере белән тулды. Чикагода бер дилер залны бикләп куярга мәҗбүр булды, чөнки ишек төбендә гаять зур халык төркеме җыелган иде. Техас штатындагы Гарленд шәһәрендә унбиш сатып алучы күргәзмәгә куелган бердәнбер «Мустанг»ны үзләренә сатуларын таләп итте. Дилер аны, берәүгә дә

саттырмас өчен, машинада кунарга ниятләгән иң үҗәт кешегә сатты.

Без баштарак беренче елда 75 мең машина сатып булыр дип уйлаган идек. Аннары... аны сату планнары елына 200 меңгә кадәр җитте. Тора-бара «Мустанг»ларны җитештерүнең еллык күләме 360 мең данәгә җитте».

Түбән бәя ярдәмендә югары сорау зурлыгына ирешеп, «Форд» компаниясе сатып алучыларга индивидуаль заказлар буенча «Мустанг»ларга өстәмә кирәк-яраклар тәкъдим итә башлый. Шундый арзан машина алудан башлары күккә тигән сатып алучылар машинаны үзләре теләгән рәвешкә китергән өчен бераз гына өстәп түләргә дә риза булалар. «Прейскурант буенча 2368 доллар торган машинага клиентлар өстәмә әйберләр өчен тагын уртача 1000 доллар түлиләр!»

«Форд» компаниясе түбән бәя ярдәмендә гаять зур сорауга ирешеп бик зур табыш ала. Әгәр дә автомобильгә башта ук кыйбатрак бәя куйган булса, ул бу кадәр табыш ала алмаган булыр иде.

— сатып алучыларның нәрсәгә өстенлек бирүе (моның аларның күнекмәләре, традицияләр, реклама һ. б. йогынтысында формалаша) кебек факторларның да йогынты ясавын әйтеп үтү зарур.

Һәм, ниһаять, сорау законының ни өчен нәкъ югарыда сурәтләнгәнчә эш итүен аңлау өчен, безгә кулланучының базарда үзен рациональ (лат. *ratio* — «акыл») тотуын белү кирәк. Рациональ (акыллы) кулланучы әйберләр алу өчен аның акча суммасы чикләнгән булуын аңлый һәм, булган акчасын үзе өчен иң файдалы товарлар сатып алуга тотарга тырыша.

Шуның белән бергә, аңлап яки чамалап, товарның гомумән файдасыннан чыгып сайламый, ә бу товарның үзе өчен иң кирәк файдалы әйбер булуын истә тотып эш итә. Ә файдалылык, сатып алучыларның товарга ихтыяҗлары канәгатьләндерелгән саен, үзлексез кими бара. Чыннан да, ач кеше өчен беренче бифштексның файдасы бик зур була. Ә икенчесен инде туймас күзле кеше генә ашый. Өченчесе исә бик азларның гына тамагыннан үтәчәк, тырыш-тырыш аны авызга дыңгычлау ахырдан күңелсез нәтиҗәләргә генә китерәчәк.

Димәк, барлык өч бифштексның да абсолют файдасы бер үк булса, ә менә аның аерым кеше өчен өстәмә файдасы (предельная полезность) тамак туя барган саен кими бара. Шуна күрә кеше бер үк төрле әйберләрне бары тик аларның бәясе төшерелсә генә күп итеп алырга ризалашачак. Бу исә графиктагы сорау кәкре сызыгының түбәнгә — унга таба авышуын китереп чыгара.

§ 6. Товарларны тәкъдим итү нәрсәдән бәйле

Кешеләр үзләренә кирәк товарларны алар сатуга тәкъдим ителгәнгә күрә сатып ала алалар. Ә сатуга тәкъдим ителгән товарларның күләме нәрсәдән бәйле була соң?

Сатучыларның базардагы гамәлләрен өйрәнеп, алар тарафыннан сатуга тәкъдим ителгән товарлар санының **(тәкъдим зурлыгы)** сәүдәдә урнашкан бәяләр зурлыгыннан да бәйле булуын күрербез.

ТӘКЪДИМ ЗУРЛЫГЫ — сатучылар билгеле бер вакыт эчендә товарга урнашкан базар бәясеннән сатуга тәкъдим итәргә әзер булган (теләгән һәм тәкъдим итә алган) билгеле бер товарның натураль үлчәмдәге күләме (саны).

Гадәттә, кулланучылар тарафыннан соралучы икътисади байлыкның сату бәясе никадәр зуррак булган саен, әлеге товарны җитештерүчеләр һәм сатучылар базарга аны тагы да күбрәк күләмдә тәкъдим итәргә әзерләр. Бу әллә ни гаҗәп нәрсә түгел: сатучы үзе саткан товарлардан никадәр күбрәк керем алган саен, үз теләкләрен канәгатьләндерү өчен шулкадәр күбрәк акчасын тота һәм тормышын тагы да яхшырта ала.

3-3 рәсемендә товарлар тәкъдим итү зурлыгының аларны сатып булырлык бәя зурлыгы белән бәйләнеше күрсәтелә.

Күргәнебезчә, товарларга бәя зуррак булган саен, сатып алучылар акчасына алыштыру өчен, сатучылар шулкадәр күбрәк товар тәкъдим итәргә әзер. Башкача



3-3 рәсем.
Товарлар тәкъдим итү зурлыгы һәм бәяләр зурлыгы бәйләнеше

әйтсәк, базардагы һәр бәя зурлыгына товарларның сатучылар (җитештерүчеләр) тарафыннан куелган үз тәкъдим зурлыгы туры килә.

Тәкъдим зурлыгы, гадәттә, бәяләр зурлыгы юнәлешендә үзгәрә. Төрле зурлыктагы бәяләр куелганда мөмкин булган барлык тәкъдим зурлыгы билгеле бер товарларга карата базардагы **тәкъдимне** барлыкка китерә.

Нәкъ сорау очрагындагы кебек үк, «тәкъдим зурлыгы» һәм «тәкъдим» төшенчәләре арасындагы аерманы аларның һәрберсе билгеле бер сорауга җавап бирә алганда аңлавы җиңелрәк. Кибет хуҗасының: «Товар җитештерүчеләр миңа бер ай сату өчен X сумнан күпме товар тәкъдим итә ала?» — дигән соравына ТӘКЪДИМ ЗУРЛЫГЫ турындагы мәгълүмат җавап бирәчәк. Әгәр дә кибет хуҗасы сорауны: «Товар җитештерүчеләр миңа бер ай сату өчен билгеле бер товарга төрле зурлыктагы бәядән әлеге товарны күпме тәкъдим итә ала?» — дип башкачарак итеп бирсә, бу базардагы ТӘКЪДИМ сыйфатламасы әлеге сорауның җавабы булачак.

Димәк, тәкъдим зурлыгы бәя зурлыгы үзгәрүенә бәйле рәвештә үзгәрә икән, без **тәкъдимнең бәя буенча сыгылмалылыгы** турында әйтә алабыз.

ТӘКЪДИМ — билгеле бер чорда (ай, ел) аерым бер товарны базарда тәкъдим итү зурлыгының шушы товар сатылырга мөмкин булган бәяләр дәрәҗәсенә бәйлелеге.

ТӘКЪДИМНЕҢ БӘЯ БУЕНЧА СЫГЫЛМАЛЫЛЫГЫ — бәя бер процентка үзгәргәндә, тәкъдим зурлыгының үзгәрү колачы (% ларда).

Мондый сыгылмалылык дәрәҗәсен бәя зурлыгы үзгәргәнче һәм үзгәргәннән соңгы тәкъдим зурлыклары аермасын бәя зурлыгы үзгәрешенә (% ларда) бүлеп билгелиләр.

Тәкъдим сыгылмалылыгы күләмнәре шулай ук товарлар буенча да аерыла, һәм шуңа күрә бәяләрнең бер чамадагы үзгәреше төрле товарларга карата тәкъдимнең бертөрле генә булмаган үсешен китереп чыгарырга мөмкин.

Таблица 3-2

Төрле зурлыктагы бәяләр куелганда, велосипедларны тәкъдим итү зурлыгы

Велосипед бәясе, ***акча берәмлегендә***	**Мөмкин булган җитештерү күләме,** ***данә***
3500	130
3000	122
2400	108
2000	97
1650	85
1300	70
1000	56
750	42

Мөмкин булган тәкъдим зурлыгы турындагы мәгълүматны **тәкъдим кәкресе** (кәкре сызыгы) рәвешендә сызып күрсәтәләр. Ул аерым товар базарындагы тәкъдимне, ягъни:

— товар бәясе белән

— төрле зурлыктагы бәяләр куелганда мөмкин булган җитештерү (сатуга чыгару) күләме арасындагы бәйләнешне тасвирлый.

3-2 таблицасы күрсәткечләренә (мондый таблицаларны **тәкъдим шкалалары** дип атау кабул ителгән) нигезләнеп, тәкъдим кәкресен төзик.



3-4 рәсем.

Тәкъдим кәкресе (велосипедлар базары үрнәгендә)

Бу кәкредәге һәр нокта әлеге товарга билгеле бер бәя куелганда, аның тәкъдим зурлыгын (мөмкин булган җитештерү күләмен) күрсәтә. Мәсәлән, 70 һәм 1300 координаталары белән билгеләнгән нокта 1300 акча берәмлеге белән күрсәтелгән бәядән җитештерүчеләрнең сатуга 70 велосипед чыгарырга (тәкъдим итәргә) әзер булуын аңлата

Шулай итеп, тәкъдим кәкресе (3-4 рәсем) ике сорауга җавап табарга булыша:

1) төрле зурлыктагы бәяләр куелганда, тәкъдим зурлыгы нинди булачак?

2) бәяләр беркадәр үзгәргәндә, тәкъдим зурлыгы ничек үзгәрәчәк?

Шуңа күрә һәр җитештерүче (сатучы), эшкә тотынганда, түбәндәге сорауларга җавап эзләүдән башларга тиеш:

1) товар сатудан килгән керем бу товарны җитештерүгә (сатуны оештыруга) тотылган чыгымнарны акларлык булырмы?

2) бу товарны җитештерү (сату) аның үзенә керем китерерме һәм ул никадәр булыр?

Кагыйдә буларак, бәяләр күтәрелү сатуга тәкъдим ителүче товарлар саны артуга, ә бәяләр төшү аларның кимүенә китерә.

Җитештерүчеләрнең (сатучыларның) күпчелек товарлар базарындагы мондый закончалыклы гамәлләрен икътисадчылар **тәкъдим законы** дип атый.

***ТӘКЪДИМ ЗАКОНЫ:** бәяләр күтәрелү гадәттә тәкъдим зурлыгы артуга, ә бәяләр төшү аның кимүенә китерә.*

Товарларның тәкъдим ителешенә бәя белән беррәттән түбәндәге факторлар да йогынты ясый:

— башка товарларның бәяләре (димәк, аларны җитештерүнең файдалы яки керемле булуы);

— бу товарларны җитештерү өчен кулланылган җитештерү факторлары бәяләре;

— технология, ягъни товарны әзерләү яки хезмәт күрсәтүне оештыру ысулы.

Базарда сатып алучыларның һәм товар җитештерүчеләрнең капма-каршы булуын төшенү әллә ни кыенлык тудырмый: бәяләр күтәрелгәндә, җитештерүчеләр дә, сатучылар да базарга тагы да күбрәк товарлар чыгаруга (тәкъдим итүгә) әзер тора, ә сатып алучылар исә бәяләр күтәрелүгә сорау зурлыгы кимү белән җавап бирә.

Сорау һәм тәкъдим зурлыкларының мондый капма-каршы реакциясен сатып алучыларны һәм сатучыларны базарга алып килгән капма-каршы мәнфәгатьләре китереп чыгара.

Сатып алучылар үз кулларындагы чикләнгән акча суммасына булдыралганча күбрәк товар алырга тырышалар. Сатучылар исә, киресенчә, үзләренең чикләнгән күләмдәге товарлары өчен булдыралганча күбрәк акча каерырга телиләр.

Сатучылар һәм сатып алучыларның мондый каршылыклы мәнфәгатьләрен базарның ничек итеп яраштыруы турында без киләсе бүлектә белечәкбез.

Әмма башта тагын бер икътисади акыллылык рецептын төзик.

Өченче рецепт

Базарларда барлык сатып алучылар һәм сатучылар мәнфәгатьләре йогынтысында ирекле төстә сорау һәм тәкъдим формалашуга комачаулаучы кирталәрне юк итү зарур.

БҮЛЕКНЕҢ ТӨП ЭЧТӘЛЕГЕ

Нәрсә ул сорау. *Билгеле бер товар базарындагы сорау зурлыгы үзгәрешенең аның бәясе зурлыгы үзгәрешеннән бәйлелеге сорау дип атала. Бу гомуми закончалык сатып алучыларның билгеле бер зурлыктагы бәядән күпме товар сатып алырга әзер һәм сәләтле булуында (бу товарны сатып алу турында хыялланып кына калмыйча) чагылыш таба. Сорау зурлыгының бәя зурлыгыннан бәйлелеге икътисадның беренче законы — сорау законы белән аңлатыла: бәяләр күтәрелгәндә, сорау зурлыгы кими, ә бәяләр төшкәндә арта. Товарларга сорау аларның никадәр файдалы булуыннан һәм сайланган әйбернең бәясеннән бәйле була.*

Товарларны тәкъдим итү нәрсәдән бәйле. *Билгеле бер товар базарындагы тәкъдим зурлыгы үзгәрешенең аның бәясе зурлыгы үзгәрешеннән бәйлелеге тәкъдим дип атала. Бу гомуми закончалык сатучыларның (җитештерүчеләрнең) билгеле бер зурлыктагы бәядән базарга күпме товар тәкъдим итәргә (чыгарырга) әзер булуында чагылыш таба. Тәкъдим зурлыгының бәя зурлыгыннан бәйлелеге тәкъдим законы белән аңлатыла: бәяләр күтәрелгәндә, тәкъдим зурлыгы арта, бәяләр төшкәндә кими.*

ФИКЕР АЛЫШУ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Бөтен дөньядагы сәүдә фирмалары ни өчен бәяләрне төшереп сатулар оештыра?
2. Бөтен дөньядагы сәүдә фирмалары яңалык булган һәм сатып алучыларда кызыксыну уяткан товар базарларын ни өчен даими тестә эзли?
3. СССРның командачыл икътисадында бәяләр тотрыклылыгы ни өчен дефицит товарлар тәкъдиме артуга китерми?

Базар ничек эшли

БҮЛЕКТӘ КАРАЛУЧЫ МӘСЬӘЛӘЛӘР:

1. БАЗАРНЫ НИНДИ БӘЯ ЧИСТАРТА?
2. ДЕФИЦИТНЫҢ НАЧАРЛЫГЫ НӘРСӘДӘ?
3. САТЫП АЛУЧЫ БАЗАРЫ НӘРСӘ УЛ?



Хәзер гадәти күренешкә әверелгән әлеге чәчәкнең кайчандыр бер илне шаккатырып, теләсә нәрсәнең спекуляция предметына әверелү мөмкинлеген раславына ышанып та булмый.

Товарлар дефициты һәм әлеге фотографияләрдә күрсәтелгән чиратлар заманында әйберләр сыйфатын яхшырту һәм сәүдәне оештыру кирәк тә булмый, чөнки болай да бөтен нәрсә сатылып бетәчәк.

һәр конкрет товарның базар бәясе аның хәзер базарга тәкъдим ителгән саны һәм бу товарга аның табигый бәясен түләргә әзер булганнарның соравы арасындагы үзара бәйләнеш белән көйләнә.

Адам Смит

Базарда сатучылар һәм сатып алучыларның теләк-ниятләре бөтенләй төрле булуын без ачыкладык инде. Әмма тегеләр дә, болар да канәгать калсын өчен, аларга сөйләшеп сүз куешырга һәм товар-сату алу турында үзара килешү (сделка) төзергә кирәк. Ә мондый килешүнең төп шарты — сатучылар товарны акчага алыштырырга, ә сатып алучылар үзләре теләгән әйбер өчен түләргә әзер булган бәя зурлыгы. Базар эшчәнлеге механизмында ике як өчен дә кулай бәяне эзләү төп рольне уйнаганлыктан, без базар бәясе барлыкка килү закончалыкларын ачыклаудан башларбыз.

§ 7. Базар бәяләре формалашу

Базар бәяләре барлыкка килү механизмын җиңелрәк төшенү өчен, инде без өйрәнгән велосипедлар базары күрсәткечләреннән файдаланып, конкрет мисалдан башлыйк.

Иң элек велосипедлар базарында төрле зурлыктагы бәяләр куелганда, сорау һәм тәкъдим зурлыклары турындагы үзебездә булган барлык мәгълүматны бер таблицага туплыйк.

Күргәнебезчә, 3500 акча берәмлегенә тигез бәя куелганда, житештерүчеләр базарга 130 велосипед тәкъдим итәргә мөмкин, ә сатып алучылар исә кибет киштәсе янына килеп тә карамыйлар.

Димәк, мондый бәя базарда артык тәкъдим, яки артык товар җыелу халәте туута китерә дигән сүз (А хәрефе нәкъ шул **артыклык** халәтен аңлата да инде).

Таблица 4-1

Бәя, ***акча берәм.***	**Сорау зурлыгы,** ***данә.***	**Тәкъдим зурлыгы,** ***данә.***	**Тәкъдимнең сораудан артыграк булуы,** ***данә.***	**Базар халәте төре (А — артыклык, Д — дефицит, Т — тигезләнеш)**
3500	0	130	130	А
3000	12	122	110	А
2400	27	108	81	А
2000	38	97	59	А
1650	50	85	35	А
1300	**66**	**70**	**4**	**А**
1150	***60***	***60***	***0***	***Т***
1000	**88**	**56**	**−32**	**Д**
750	120	42	−78	Д

Бер велосипед бәясенең зурлыгы 1000—1300 акча берәмлеге диапазонына кадәр төшмичә торып, бу халәт үзгәрмәячәк.

Чыннан да, бәя 1000 акча берәмлегенә тигез булганда, безнең күрсәткечләр базарда бөтенләй капма-каршы халәт туу турында хәбәр итә: сорау тәкъдимгә караганда зуррак булып чыга. Товарлар җитмәүчелеге, дефицит халәте туа (Д хәрефе шул **дефицитны** күрсәтә дә инде).

АРТЫКЛЫК (АРТЫК ТОВАР ҖЫЕЛУ) — сатучылар базарда гамәлдә булган бәяләрдән сатып алучыларның алу мөмкинлекләренә караганда (алар бу бәядән алырга әзер түгел) күбрәк товар тәкъдим иткәндә барлыкка килгән халәт.

ДЕФИЦИТ — базарда сатып алучылар, гамәлдә булган бәяләрдән сатучыларның сатуга тәкъдим итү мөмкинлекләренә караганда (алар бу бәядән тәкъдим итәргә риза түгел), күбрәк товар алырга ниятләгәндә барлыкка килгән халәт.

Базарда товар артыклыгы да, дефицит та булмый торган халәт мөмкин микән соң?

Таблицадагы 1000 һәм 1300 акча берәмлегенә тигез бәяләр баскычына туры килгән юлларга игътибар итегез (алар хәтта башка төрле шрифт белән күрсәтелгән). 1 велосипед өчен 1000—1300 акча берәмлекләренә тигез булган бәяләр диапазонында базардагы халәт бөтенләй башка якка үзгәрә: товар артыклыгы дефицит белән алмаша.

Димәк, кайдадыр шушы диапазон эчендә товарлар артыклыгы да, дефицит та булмаслык бәя бар дигән сүз: сатуга күпме товар тәкъдим ителсә, шулкадәрле үк сатылып та бетәчәк.

Икътисадчылар мондый халәтне базар тигезләнеше дип атый: мондый шартларда сорау һәм тәкъдим бер-берсен тигезләп тора. Димәк, мондый тигезлеккә китергән бәяне дә **тигезләнешле бәя** дип, ә бу бәядән сатарга мөмкин булган товарлар күләмен тигезләнешле сатулар күләме (Т хәрефе әнә шул тигезләнешне күрсәтә дә инде) дип атау кабул ителгән.

ТИГЕЗЛӘНЕШЛЕ БӘЯ — җитештерүчеләр (сатучылар) тәкъдим итәргә риза булган һәм барлык товарларны сатып бетерергә мөмкинлек бирүче бәя.

Базар тигезләнеше формалашу белән идарә итеп буламы соң? Әлбәттә. Моның өчен бизнес эшендә күптөрле чаралардан кулланалар һәм аларның берсе — реклама.

Гәрчә реклама эшчәнлеге сатуларны үстерүче иң борынгы чараларның берсе булуына карамастан, аның асылын аңлату озак вакытлар дәвамында кызу бәхәсләр уятты, реклама — сатып алучыларны алдау һәм аларда товарның икътисади әһәмияте турында дөрес булмаган күзаллау тудыру чарасы дип каралды. Соңгы вакытларда исә реклама бары тик мәгълүмат җиткерү формасы гына һәм аның нәтиҗәләре җиткерелүче хәбәрләр характерыннан бәйле була дигән чынбарлыкка якынрак караш өстенлек алды. Һәрхәлдә, рекламаның сатып алучылар гамәлләренә йогынтысын беркем дә кире какмый.

Голландча тюльпаннар белән мавыгу

Сорауның тәкъдимне узып китүе аркасында нинди гаҗәеп хәлләр булу мөмкинлеген 1630 елда Голландиядә җәелгән «тюльпаннардан шашу» үрнәгендә күзәтергә була.

Европага шуңа кадәр 80 ел элек китерелгән һәм бай гражданнарның чәчәк түтәлләрендә мәгърур балкып утыручы әлеге чәчәкнең ни өчен кисәк кенә коточкыч сорау предметына әверелүен әле бүген дә беркем белми. Әмма факт факт булып кала — 1630 елда сорау арту аркасында тюльпан суганчаларының бәясе күтәрелә башлый, һәм бу даими күтәрелү бөтен ил игътибарын җәлеп итә.

Бу чәчәкләрнең суганчалары тотрыклы төстә кыйбатлануын күреп торган голландлар аларны тагы да матуррак алтын тәңкәләргә әйләндерү мөмкинлеген чамалап алалар.

Һәм моның өчен серле алхимия фәнен өйрәнеп торуның кирәге дә калмый. Күбрәк суганча сатып аласың да, бәя тагы да күтәрелгәч, аларны сатасың. Бу спекуляция дип аталган әллә ни катлаулы булмаган гамәл шәһәр халкының да, крестьяннарның да гомуми мавыгуына әверелә.

Нәтиҗәдә үзеннән-үзе арттырылучы сорау механизмы барлыкка килә. Чыннан да, кешеләр тюльпан суганчаларын күбрәк сораган саен, аларның бәяләре дә шулкадәр күбрәк күтәрелә. Ә бәяләр күтәрелгән саен, чәчәк спекулянтларының табышы да шулкадәр күбрәк арта. Голландлар бу эшнең уңышлы булуын һәм йоклап ятмаска, ә тизрәк һәм күбрәк суганчалар сатып алырга кирәклеген тагы да ныграк төшенә бара. Сорау шул рәвешчә бәяләрне алга куя, ә бәяләр исә сорауны арттыра.

Шул сәбәпле суганчалар бәясе һавага күтәрелә. Сакланып калган документлардан күренгәнчә, 1 суганча өчен 2500 гульден түлиләр. Ул вакытта бу суммага 2 йөк бодай, 4 йөк печән, 4 симертелгән үгез, шулкадәр үк дуңгыз, 12 эре сарык, 4 мичкә сыра, 2 мичкә акмай, 500 кг сыр, карават, костюм һәм көмеш кубок алып булган.

Шушы вакыйгалар йогынтысында сәүдәгәрләр үз складларын арзан бәягә генә сатып, ул акчага тизрәк тюльпаннар алырга ашыга. Ә акчалары җитмәгән кешеләр аларны банкирлардан һәм ростовщиклардан бурычка ала һәм «чәчәктән килгән табыш» хисабына бу бурычларыннан җиңел генә котылачакбыз дип исәпли.

Һәм кинәт базар «шартлый» — чираттагы аукционда сатарга куелган суганча үз хуҗасына 1250 гульден урынына 1000 гульден гына китерә. Бөтен ил буйлап таралган әлеге хәбәр кешеләрне куркуга сала һәм алар «кыйммәтле» суганчаларны тизрәк сатарга тотына. Әмма андый югары бәядән аларны сатып алырга теләүчеләр булмый инде.

Башкача әйтсәк, тәкъдим кисәк кенә сорауны узып китә һәм, инде белүебезчә, мондый чакта тотрыклы бәя төшә башлый. Ә Голландиядә исә тюльпан бәяләре «җимерелеп төшә» һәм әле кичә генә үзләрен бай дип хис иткән кешеләр хәерчелектә кала: аларның күбесе суганчаларны бурычка алган була, ә хәзер исә бурычны кайтару мөмкинлеге калмый!

Кызганыч ки, голландларның күңелсез тәҗрибәсе кешелекне бәяләр тирбәнеше кебек хәвефле уен хисабына тиз генә баеп китү омтылышыннан дәваламый. Дөрес, тора-бара кешеләр мондый уенның гаять камил формаларын уйлап таба һәм уңышсыз спекуляцияләр китереп чыгарган бөлү куркынычын беркадәр киметергә өйрәнә.

Сатучылар һәм сатып алучылар мәнфәгатьләрен яраштыруның базар механизмына анализ ясап, Адам Смит 1776 елда чыккан «Халыклар байлыгы табигатен һәм сәбәпләрен тикшерү» дигән мәшһүр китабында: *«Һәр кеше бары тик үзенә файда ясау турында гына уйлый, әмма ниндидер бер күренмәс кул аны башына да килеп карамаслык нәтиҗәләргә алып килә».*

Базар икътисади системасына йөзләгән миллион кешеләрнең эшчәнлеген координацияләргә һәм планлы-командачыл системаларга караганда яхшырак нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирүче «күренмәс кул» нәрсә соң ул?

Базар икътисадында төп рольне башкаручы бәяләр механизмын Адам Смит заманнарыннан ук шушы термин белән атыйлар. Барлык сатучылар һәм сатып алучылар өчен базардагы эшләр торышы һәм товарларны тәкъдим итү белән аларга сорау бәйләнеше турында төп мәгълүмат чыганагы хезмәтен нәкъ менә бәяләр башкара.

БӘЯЛӘР МЕХАНИЗМЫ — бернинди мәҗбүр итүләрсез билгеле бер карарга килгән сатып алучылар һәм сатучылар мәнфәгатьләре каршылыгы йогынтысында базар бәяләре формалашу һәм үзгәрү.

Бу мәгълүмат өч төрле булырга мөмкин:

— әгәр дә бәяләр күтәрелә икән, димәк, базарга сатып алучылар бу бәядән алырлык булганга караганда азрак товар чыга;

— әгәр дә бәяләр төшә икән, димәк, базарга сатып алучылар бу бәядән алырлык булганга караганда күбрәк товар чыга;

— әгәр дә бәяләр үзгәрешсез диярлек кала икән, димәк, базарга сатып алучылар бу бәядән сатып алырлык күләмдәге товар чыга.

Бәяләр үзгәрешенең әлеге закончалыклары 4-1 рәсемдә күрсәтелә.

Сатучыларның керемнәре күләме бәя зурлыгыннан ничек бәйле булган кебек, сатып алучыларның чыгымнары да шуннан бәйле икән, бәяләр базарда катнашучыларның үзенчәлекле «светофоры»на әверелә.

4-1 рәсем.
Икътисади үлчәүләр

Алар житештерүчеләргә һәм сатучыларга теге яки бу товарны житештерүнең һәм аны сатуның кирәген-югын хәбәр итә, урнашкан бәяләр сакланганда, күпме файда китерәчәген белдерә, сатып алучыларны, теге яки бу товарны алганда кесә ягын чамалап, төпле карарга килерлек мәгълүмат белән тәэмин итә. Шуңа күрә бәяләр системасы сатучылар һәм сатып алучыларның сату-алуы нәтижәсендә, ягъни ирекле рәвештә формалашкан базар анда катнашучыларның барысын да тигезләнеш халәте туарлык итеп эшләргә мәжбүр итә.

Тигезләнеш халәтендәге базар — сатучылар һәм сатып алучылар мәнфәгатьләре арасында мөмкин булган иң яхшы компромиссларның берсе ул.

§ 8. Эшләүче базар, яки Сәүдә эше чынлыкта ничек оештырыла

Һәр предприятие кешеләргә кирәкле әйберләрне әзерләү өчен таләп ителгән барлык житештерү ресурсларын бергә туплаганда гына эшли ала. Әмма аларны тиешле вакытта һәм тиешле күләмдә туплау мөмкин хәл микән? Шулай ук «әзерләнгән әйберләрне ничек итеп аларны алырга теләүчеләр кулына илтеп житкерергә, кемнәр өчен алар чыннан да әһәмиятле, ягъни чын байлык була?» дигән сорау да мөһимлек ягыннан калышмый.

Бу сорауларның тегесен дә, монысын да хәл итү белән менеджерлар яки эшмәкәрләр шөгыльләнә. Әмма алар моны бүген күбесенчә үзләре түгел, ә теге яки бу күләмдә сәүдә ярдәмендә башкара.

Кеше эшчәнлегенең үзенчәлекле өлкәсе булган сәүдәдән башка берниндн житештерү эшчәнлеге дә яши алмас иде. Нәкъ менә сәүдә предприятие житәкчеләренә, бердән, житештерү өчен кирәкле ресурсларны алырга, икенчедән, әзер продукцияне алырга теләүчеләргә аны сатарга мөмкинлек бирә.

Сәүдә эшчәнлеге — кеше мәнфәгатьләре, күнекмәләре, тырышлыклары салынган гаять катлаулы һәм кызыклы өлкә.

Күчмә сәүдәгәрләр сәүдә эшенең беренче профессионаллары (ягъни яшәү өчен бары тик шушы эш белән генә акча табучылар) булалар. Алар инде берничә мең ел элек үк яшиләр. Русьта, мәсәлән, мондый сәүдәгәрләр (кырыктартмачылар) инде XIX гасырда ук шәһәрдән авыллар буйлап товарлар таратып йөргән.

Алар сәүдәсенең асылы товарларны данәләп яки кечкенә генә күләмдә, әмма күп санлы сатып алучыларга житкерүдән гыйбарәт була. Сәүдә итүнең мондый борынгы формасы ваклап сату яки **ваклап сәүдә итү** (ягъни аерым-аерым, данәләп сату) дип атала.

ВАКЛАП САТУ (СӘҮДӘ ИТҮ) — куллану товарларын аз данәдә яки кечкенә күләмдә турыдан-туры сатып алучыларның үзләренә сату.

Ваклап сәүдә итү — иң борынгы гына түгел, ә иң катлаулы сәүдә эшчәнлеге ул. Ваклап сатучы сатып алучыны нәкъ менә аның товарын алырга күндерергә, өстәвенә үзен (сәүдә итүчене) канәгатьләндерерлек итеп сата белергә тиеш (бу шартларның ни белән билгеләнүе турында алдарак сөйләшербез). Нәкъ шушы хәл күренекле инглиз икътисадчысы һәм философы Джереми Бентамны «товар алу, акча алуга караганда күпкә жиңелрәк» дигән фикергә этәрә.

Күпчелек кибетләрдә (фирма кибетләреннән тыш) күптөрле товарлар сатыла. Һәм алар төрле предприятиеләрдә әзерләнә, хәтта төрле илләрдән китерелә. Кибет хуҗасы бу товарларны үз кибет киштәсендә ничек бергә туплый ала соң?

Баштарак өлеге бурычны ваклап сатучылар бик җиңел хәл итәләр: кулларына зур кәрзин тотып, базардагы коллегаларының товар киштәләрен әйләнеп чыгалар. Аларның һәрберсендә билгеле бер товарны күпләп алып, бу кәрзинне үз лавкаларына яки кибетләренә куялар һәм ваклап саталар. Тора-бара кешеләр төрле әйберләр җитештерүне үзләштергән саен, сатып алучыларны тагы да күбрәк товарлар кызыксындыра башлый, һәм ваклап сатучылар эше катлаулана. Хәзер үз кибетең яки лавкаң киштәләрендә күрергә теләгән һәр товар белән сату итүчеләрне теләсә кайсы базарда табып булмый инде.

Әлбәттә, товар әзерләүчеләрнең үзләре белән турыдан-туры килешеп булыр иде. Әмма ул очракта һәр әзерләүчегә күп санлы ваклап сатучы белән, ә һәр кибет хуҗасына бихисап товар әзерләүчеләр белән эш итәргә туры килер иде. Башкача әйтсәк, җитештерүчеләр белән сәүдәгәрләр арасында күп санлы турыдан-туры бәйләнешләр урнаша.

Мондый очракта сәүдәгәрләр товар әзерләүчеләр белән кибетләргә товар китерү турында күп санлы килешүләр (сделка) төзергә мәҗбүр булалар. 4-2 рәсемдә күренгәнчә, бары тик өч әзерләүче һәм дүрт кибет өчен генә дә шундый 12 шартнамә (договор) төзергә туры килгән.

Әмма барлык әзерләүчеләр белән мөнәсәбәтләрдә барлык кибетләр исеменнән эш итүче арадашчы хезмәтеннән файдаланганда, бу бурычны хәл итү шактый җиңелгә чыгар иде. Һәм шулай итеп, кибетләргә товар китерү бөтенләй башкача итеп тормышка ашырыла башлый.



4-2 рәсем.
Товар әзерләүчеләр белән турыдан-туры бәйләнешләр булганда сәүдәне оештыру



4-3 рәсем.
Күпләп алучы арадашчы ярдәмендә сәүдәне оештыру

Барлык әзерләүчеләрдән дә товарларны хәзер күпләп алучы сәүдәгәр сатып ала (4-3 рәсем). Хәзер инде һәр ваклап сатучыга ул үз кибетендә күрергә теләгән һәм билгеле бер җитештерүчеләр әзерләгән товарларны китереп җиткерүне оештыру аның өстенә йөкләнә. Нәтиҗәдә әзерләүчеләр белән сәүдәгәрләр арасындагы элемтәләр саны шактый кими. Мәсәлән, алда әйтеп үтелгән кадәр кибетләр һәм җитештерүчеләр өчен 12 шартнамә урынына 7 се дә бик җитә.

Әмма товар китерү турындагы шартнамәләр саны кимү күпләп сату итүче сәүдә ирешкән бердәнбер һәм иң мөһим нәтиҗә түгел. Иң әһәмиятлесе шунда ки, ул башка илләрдән яки зур илнең (мәсәлән, Россия кебек) регионнарыннан сатуга китерелгән күп санлы товарларны сатуны җиңеләйтергә һәм тизләтергә мөмкинлек бирде.

Шул ук файда ясау нияте товар җитештерүчеләрне дә күпләп сатучылар белән бәйләнешкә керергә мәҗбүр итте. Алар да товар җитештерүгә киткән акчаларын ничек булса да тизрәк кайтарырга тырышалар. Шулай итеп кенә алар товарларның алдагы партиясен җитештерү өчен кирәкле нәрсәләрне сатып ала алалар. Һәм шушы бурычны хәл итү өчен, җитештерүчеләр үз продукцияләрен күпләп сатып

алучыларга ташламалар белән җибәрергә дә ризалашалар. Ә инде соңгы сатып алучыларга бу товарларны ничек сату турында күпләп сату итүче сәүдәгәрләр үзләре кайгыртырга тиеш була.

Нәтиҗәдә тегеләре дә, болары да ота: әзерләүчеләр товар җитештерүгә тотылган акчаларын тизрәк кайтарып үз керемнәрен алалар (гәрчә күпләп сатып алучыларга ташламалар хисабына ул керем бераз кимесә дә). Ә күпләп сатып алучылар әзерләүчеләргә түләгәнгә караганда товарны югарырак бәядән сатып, үзләренә табыш ясыйлар, бу аларның үз керемнәре була.

Сәүдәгәрләр белән товар җитештерүчеләр элемтәләрен нәкъ шулай оештыру, сәнәгать массакүләм җитештерү стадиясенә кергән вакытта, барлык илләр өчен дә иң кулай гына түгел, ә бердәнбер мөмкин юл иде.

Шуның белән бергә, массакүләм һәм шулай ук башка төрле җитештерү, гомумән, теләсә кайсы коммерция эшчәнлеге фирма барлык кирәкле ресурсларны (хезмәт, капитал, җир, эшмәкәрлек сәләтләрен) бергә туплый алганда гына мөмкин була. Фирма аларны каян ала соң?

Җавап бик гади: болар барысы җитештерү факторлары базарларында алына. Мондый базарлар Россия тормышында гаять зур роль уйный, һәм аларның үсеш мәсьәләләре тирәсендә бизнесменнар һәм сәясәтчеләрнең кайнар бәхәсләре күзәтелә. Бу бәхәсләрнең асылын һәм гади гражданнар тормышы өчен аларның мәгънәсен аңлау өчен, безгә базарлар һәм башка җитештерү ресурсларының, һәм иң элек капитал базарының эшчәнлек итү мәсьәләләрен тикшереп үтү зарур.

Һәр коммерция эшчәнлеген оештыру өчен кирәкле төп ресурсларга җиһазлар, биналар, корылмалар кирә. Болар кеше кулы белән тудырыла һәм **физик капитал** дип атала.

XX гасыр ахырына таба «физик капитал» термины универсаль билгеләмә буларак беркадәр катлаулана. Эш шунда ки, ул капитал элементларының матди (әйбер буларак) табигатен күз алдында тота. Шуның белән бергә, фән-техника прогрессы нәтиҗәсендә коммерция эшчәнлеге өчен җитештерү капиталының яңа төре — **матди булмаган (җисми булмаган) капиталның** әһәмияте арта бара.

ФИЗИК КАПИТАЛ — технологияләр ярдәмендә табигый матдәләрне кешеләргә файдалы байлыкларга әйләндерү өчен кулланылучы биналар, корылмалар, машиналар, сугару системалары.

МАТДИ (ҖИСМИ) БУЛМАГАН КАПИТАЛ — әйберләр (байлыклар) җитештерү һәм аларны сату өчен озак вакытлар дәвамында файдаланылучы белемнәр, сәләтләр һәм мәгълүматлар (мәсәлән, патентлар, лицензияләр, авторлык хокуклары, кешеләрнең осталык һәм сәләтләре, сәүдә маркалары).

Әмма бүгенге көнгә кадәр кешеләргә кирәкле әйберләрне җитештерүдә төп рольне уйнаганлыктан, игътибарыбызны әлегә бары тик физик капитал белән чикләрбез.

Табигый ки, һәр фирманың үзенә генә хас физик капитал элементлары була. Әйтик, Робинзон Крузоны фирма сыйфатында карасак (бу бик хаклы адым булыр, чөнки ул үз утравы базарында бердәнбер товар җитештерүче була, ул

4-4 рәсем.
Робинзон Крузо физик капитал дип күзаллаган нәрсәләр

товарларны аннан бердәнбер «сатып алучы» да Робинзон Крузо үзе була), аның өчен капитал нәрсә була соң? Җавап аермачык: ул үзенә азык табуда, торак коруда, кием әзерләүдә кулланган барлык кораллар. Робинзон утрауда үзе генә яшәгәнлектән (Җомга килгәнче), капиталны ул бик гади кораллар ясап, үзе әзерли.

Дөрес, 4-4 рәсеменнән күренгәнчә, мондый үз кулы белән ясалган капитал ярдәмендә сыйфатлы эшләнмәләр әзерләп булмый (ул агачтан кисеп ясаган көпчәк камиллектән ерак тора). Сыйфатны бары тик Робинзонның төшенә дә кермәгән камил капитал ярдәмендә генә күтәреп булыр иде.

Әмма күрше утрауда шундый корал житештерәләр һәм безнең сәяхәтче анда үзе ясаган көймәдә барып житә ала дип күз алдына китерик. Бу очракта ул шундук бер мәсьәлә алдында калыр иде: бу коралны ничек сатып алырга, аны алганда ни белән түләргә?

Димәк, Робинзонга да барлык фирмалар хәл итә торган түбәндәге мәсьәләне чишәргә туры килә дигән сүз: физик капиталны алу өчен кирәкле акча капиталын ничек табарга?

Бу мәсьәләне хәл итү юлларын эзләү кешелекне, ахыр чиктә, коммерция эшчәнлеге өчен кирәкле акча средстволары сатып алына торган үзенчәлекле базар төзүгә этәрә. Бу базар акча капиталы базары, яки **финанс базары** дип атала.

Үз эшчәнлекләрен җәелдерү өчен әлегә акчасы житмәгәннәр шушы капитал базарында сатып алучылар булалар. Аларга коммерция фирмалары, коммерция белән шөгыльләнмәүче фирмалар һәм хәтта хөкүмәт тә карый. Ә бу базарда кем сату итә соң?

Бу рольне **саклык акча** хуҗалары арадашчылар аша башкара. Ә арадашчылар булып банклар һәм акча средстволары белән эш итү буенча махсуслашкан башка фирмалар чыгыш ясый.

ФИНАНС БАЗАРЫ — фирмалар эшчәнлеген оештыру өчен зарур финанс ресурслары сатыла торган базар.

САКЛЫК АКЧАЛАР — агымдагы кулланылыш белән бәйле бөтен чыгымнарны да түләгәннән соң калган керемнең бер өлеше.

КОММЕРЦИЯ БЕЛӘН ШӨГЫЛЬЛӘНМӘҮЧЕ ОЕШМА — эшчәнлегенең төп максаты табыш алуга кайтып калмаган юридик зат, әгәр дә аның табышы барлыкка килсә, ул әлеге оешма вәкилләре арасында бүленми, ә аның эшчәнлеген үстерүгә тотыла.

Бу терминнын билгеләмәсеннән үк күренгәнчә, керемнәре булган затларда гына саклык акча тупланырга мөмкин икән. Димәк, барлык саклык акчалар да, ахыр чиктә, гаиләләрнеке була дигән сүз (кайбер бик сирәк очракларда гына дәүләттә дә саклык акча тупланырга мөмкин. Мәсәлән, Россиядә дәүләтнең саклык акчалары Стабильләштерү фонды формасында 2005 елның 1 гыйнварына 522,3 млрд сум тәшкил итте).

Гаиләләр, фирма яки дәүләт, киләчәктә кулллануларын арттыру яки килеп чыгарга мөмкин булган проблемаларны (мәсәлән, гаилә әгъзаларының берсенә кыйбатлы операция кирәк була яки нефтькә дөньякүләм бәяләр төшеп китү аркасында дәүләтнең керемнәре кими) хәл итү өчен саклык акча калдырып, агымдагы куллануны чиклиләр.

Саклык **акча туплауга һәвәслек** төрле гаиләләрдә төрлечә була. Бу түбәндәгеләрдән бәйле:

1) гаиләдә ирешелгән муллык дәрәҗәсеннән (алар туплаган барлык төр мөлкәт күләменнән);

2) килгән акча керемнәре зурлыгы һәм аларның яшәү минимумы белән чагыштырмасыннан (алар никадәр якынрак булган саен, гаиләнең бераз гына булса да акча туплау мөмкинлеге дә кими);

3) гаилә әгъзаларының тормышка карашларыннан һәм тәрбиясеннән (бары тик «бүгенге көн белән генә яшәүче» һәм «киләчәкләрен әзерләүче» кешеләр һәрвакыт булган; бер үк зурлыктагы керемнәре булса да, икенчеләре күбрәк акча саклап калачак).

Алдынгы илләрдә гаилә икътисады товарлар өчен ваклап түләүгә (рассрочка), кредитка таяна. Мондый очракта сатып алучы сатучыдан яки банктан акча алып тора һәм аны килешенгән вакыт дәвамында кире кайтара, шулай ук бурычка биреп торган акча өчен процентлар да түли. Мәсәлән, **ипотека ссудасы** гадәттә 30 ел вакытка бирелә.

ИПОТЕКА ССУДАСЫ, ипотека кредиты — күчемсез милекне закладка салу шарты белән банк тарафыннан озак срокка бирелә торган акча ссудасы.

ССУДА — заем шартнамәсендә катнашучы бер якның кире кайтару, кагыйдә буларак, процентлата кайтару шарты белән икенче якка акча яки матди кыйммәтләр биреп торуы.

КРЕДИТ — кире кайтару (гадәттә процентлата түләү) шарты белән акчалата яки әйберләтә бирелгән ссуда.

Мондый сату акча ссудасы аналогы буларак карала, һәм сатып алучыдан банк кредитындагы кебек үк түләү алына. Нәтиҗәдә сатып алучы ярлыкта күрсәтелгән бәягә караганда товар өчен күбрәк түли, анын каравы шундук кулына ала. Нәтиҗәдә «яшерен туплау» килеп чыга, чөнки ваклап түләү шарты белән алынган товарлар өчен түләүләр россиялеләрнең саклык счетларындагы взносларга (түләмнәргә) тиң була, әмма АКШ һәм башка илләрнең статистикасы аларны чыгымнар буларак теркемли. Ваклап түләү шарты белән товар һәм торак алган америкалылар гаиләләренең бүгенге көндәге бурычлары 3 трлн долларга җитә һәм гаилә керемнәренең еллык суммасын 1,2 тапкырга узып китә.

Гаилә икътисадының бу моделе бик кырыс. Товар өчен чираттагы взносны вакытында түләмәсәң, аны синнән алып китәргә һәм инде түләгән акчаларыңны кире кайтармаска мөмкиннәр. Бу товар үз торагың булган очракта да шушындый ук хәл күзәтелә. Взносларын вакытында түләмәгән өчен һәр ел саен 2,5 млн америкалыны йортларыннан чыгаралар. Шуңа күрә ваклап сату шарты белән товар алган гаиләләр иң элек мөлкәт өчен взносларын түлиләр, аннан соң гына азык-төлек алуга һәм агымдагы кирәк-яракка тоталар.

Ваклап түләү шарты белән товарлар сатып алу шундый кырыс нәтиҗәләргә китерә икән, ни өчен кешеләр аннан файдаланалар соң? Файда монда ике яклы.

Беренчесе — тормыш муллыгына тизрәк ирешү, ниятләгән баскычка күтәрелү өчен кирәкле вакытның кыскаруы. Кеше гомер буе арендага алган фатирда яшәп, картайган көнендә генә җитәрлек акча туплап лаек торак алырга тиеш түгел. Киресенчә, ул яшьлек елларында ук яхшы яңа фатирга яки үз йортына керә һәм шуннан соң гына аның бәясен ваклап түли, шул ук вакытта уңайлы торагында яшәп хозурлана. Әмма ваклап түләү шарты белән товар һәм торак сатулар кеше тормышының бөтен структурасын үзгәртә (4-5 рәсем): бурычлар түләү чоры белән туры килсә дә, рәхәт тормыш вакыты арта.

Икенче файда исә вакытлар үткән саен кыйммәтләре арта гына барган товарлар алганда күзәтелә. Мондый категориягә торак, җир участоклары, кыйммәтле кәгазьләр, сәнгать әсәрләре һ.б. керә. Инфляция һәм ресурсларның чикләнгәнлеге шартларында («абруйлы» урамның бер участогында ике йорт төзеп булмый) мондый товарларның базар бәясе шактый күтәрелергә мөмкин, димәк, мондый мөлкәте булган гаиләләрнең байлыгы да арта дигән сүз.

Әмма гаиләләр ничек кенә һәм нәрсә өчен генә дип акча тупласалар да, саклык акча барлыкка килү белән, алар алдында түбәндәге сорау калка: бу акчалар нindидер чыгымнар өчен кирәк булганчы, алар белән ничек уңышлырак итеп эш итәргә соң?



4-5 рәсем.
Торак һәм товарларны ваклап сату шарты белән сатуны оештырганда, кеше тормышының икътисади структурасы үзгәрү

Башта ук әйтеп куйыйк: тупланган акчаларны реаль акча формасында һәм өйдә саклау — иң файдасыз юл. Бу очракта андый акчаларның хуҗасы бәяләр үскән очракта аларны югалта һәм процентка акча биреп торып үз байлыгын тагы да арттыру мөмкинлегеннән колак кага.

Шуңа күрә саклык акча ияләре бу акчаларның бәясе төшмәслек, ә артырлык итеп аларны «эшкә җигүче»ләрне эзли. Саклык акча ияләре һәм үз бизнесларын үстерү өчен акчага мохтаҗ коммерсантларны берләштерү вазифасын акча капиталы базары башкара да инде. Аның булышлыгы белән саклык акчаларны **инвестицияләүләр** өчен файдаланалар.

ИНВЕСТИЦИЯЛӘҮ — керем алу максатыннан нинди дә булса берәр эшкә, эш башлауга озак вакытка капитал (средстволар) салу.

Акча хуҗалары инвестицияләүнең төрле формаларын тәкъдим иткәндә һәм ул инвестицияләр

1) файда китерерлек;

2) ышанычлылык кебек ике сыйфатка ия булганда гына, илнең икътисади механизмы яхшы эшли дип исәпләп була.

Әгәр дә илдә саклык акчаларны капитал итеп салырлык бернәрсә дә булмаса, аларны туплауның һәм күбрәк акча эшләргә тырышуның мәгънәсе калмый. Бу җитештерүчәнлектә, хезмәтнең сыйфатында, һәм гомумән җәмгыятьнең әхлакый ягында тискәре чагылыш таба: арткан хезмәт хакларын мәгънәле итеп файдалана алмагач, нәрсәгә дип яхшырак эшләргә тырышырга соң?

Әгәр дә кешеләр үз хезмәт хакларын арттыру һәм аның бер өлешен саклык акча итеп туплау өчен күбрәк эшләүнең мәгънәсе юклыгын күрсәләр, ил икътисады үз үсешенең төп моторыннан — кешеләрнең кызыксынуыннан һәм инициативасыннан коры кала.

Өстәвенә, кешеләр акча тупламаса, инвестицияләр өчен кулланылучы ирекле акча средстволары бик нык кими һәм икътисад «инвестиция ачлыгы» кичерә башлый. Ә гамәлдәге предприятиеләрнең эшләве һәм яңартылуы, иң мөһиме — яңа заманча җитештерү оешмалары төзү инвестицияләрсез тормышка ашырыла алмас иде. «Инвестиция ачлыгы»на дучар булган илдә бөтен җитештерү өлкәсе хәлсезләнә, ә аның товарлары кирәксез нәрсәгә әверелә.

1990 елларда Россия икътисады нәкъ әнә шундый проблемалар алдында кала. Икътисадның бик тиз искерә барган җитештерү базасы бик зур инвестицияләр суммаларын таләп итә, ә россиялеләр үз акчаларын ил сәнәгатен үстерүгә салырга куркалар, чөнки бу инвестицияләрнең табыш китерәчәгенә, ышанычлылыгына шикләнеп карыйлар.

Башкача әйтсәк, саклык акчалар формалашуның һәм аларның, ахыр чиктә, фирмаларның физик капиталына әверелүенең уңай барган процессы җимерелә. Бу процессны 4-6 рәсемендәгечә итеп күзалларга мөмкин.

Әлеге рәсемнән күренгәнчә, гаиләләр керемнәреннән алып фирма капиталына кадәр илтүче юл бик озын һәм катлаулы. Һәм илдә алдынгы финанс капиталы базары булганда һәм уңышлы эшләгәндә генә, бу юл да уңышлы узачак.

Базар тибындагы алдынгы икътисади системалы илләрдә (АКШ, Япония, Көнбатыш Европа илләре һ.б.) финанс капиталы базары күп гасырлар дәвамында формалашкан бик катлаулы структураны тәшкил итә. Бу структура саклык акча



4-6 рәсем.
Гаилә керемнәрен инвестицияләргә салу процессы

хуҗаларының һәм бу саклык акчаларны инвестицияләр итеп алырга теләүче коммерция фирмаларының кайвакыт шактый каршылыклы мәнфәгатьләрен уңышлы рәвештә килештерү, яраштыру зарурлыгыннан туа.

Финанс капиталы базарының бик нык гадиләштерелгән вариантын 4-7 рәсемендә күрсәтелгәнчә күзалларга мөмкин.

Бу базарда фирма ике типтагы акча средстволары алырга мөмкин:

1) заем капиталы (кредит);

2) шәхси капитал.

Заем капиталыннан (кредиттан) файдалану срогы төрле — берничә көннән алып берничә елга кадәр булырга мөмкин, әмма барлык очракларда да фирма акча хуҗасына (кредиторга) аннан алган бөтен сумманы кайтарырга һәм аның акчасыннан файдаланган өчен өстәп (процент) түләргә тиеш була.

Үзкапитал (собственный капитал), киресенчә, фирмага чиксез срокка бирелә, ә кайчакларда инвестицияләр хуҗасының үзе салган кертемнәр (вкладлар) өчен күпме алырга теләве дә күрсәтелми. Бу төр капиталның атамасы ук шушы юл белән алынган акчаларның фирма милеге булып әверелүен, ә инвесторның бу фирма милектәшенә (совладелец) әйләнүен белдерә.

Акцияләр базары һәм облигацияләр базары рәсемдә гомуми рамка эченә алынган, чөнки алар бергәләп *фонд базарын* барлыкка китерәләр (аны тагын кыйммәтле кәгазьләр базары дип тә атыйлар, чөнки монда кыйммәтле кәгазьләрне саталар һәм сатып алалар. Кыйммәтле кәгазьләр — теге яки бу фирманың бер өлеш милегенә хокук турындагы документлар алар).



4-7 рәсем.
Финанс капиталы базары корылышы

ОБЛИГАЦИЯ — кыйммәтле кәгазь ул. Аның хуҗасы бу облигацияне чыгарган фирмага яки дәүләткә беркадәр сумма биреп тора һәм билгеле бер вакыттан соң үз акчасын премия белән бергә кире кайтару хокукына ия була; әлеге премия күләме шулай ук облигацияне сатканда ук билгеләнә.

АКЦИЯ — кыйммәтле кәгазь ул. Аны алган кешенең әлеге кәгазьне чыгарган акционерлык җәмгыяте капиталында өлеше була, бу акция аңа әлеге җәмгыятьнең бер өлеш керемен алу хокукы бирә.

Кредит базарыннан һәм облигацияләр базарыннан бары тик заем капиталын гына алып була. Ә акцияләр базары — фирма үзкапитал ала торган чыганак ул.

Акция инвестиция товары буларак (ягъни киләчәктә керем китерер өчен алынган товар буларак) кайбер мөһим сыйфатларга ия:

1) әлеге акция хуҗасының бу кыйммәтле кәгазьне чыгарган фирма мөлкәтендә өлеше барлыгын һәм аның эшчәнлеге белән идарә итүдә катнашу хокукын раслый (әгәр дә инвестор гадәти акция алган булса). Бу хокуклар фирманың кыйммәтле кәгазен сатып алучыга ул түләгән акчалар өчен алмашка бирелә;

2) компания бөлсә, кыйммәтле кәгазьләр хуҗасы бары тик аларны сатып алганда түләгән акчасын гына югалта һәм бернинди дә ризасызлык белдерә алмый;

3) әгәр дә компания яшәүдән туктаса, аның мөлкәтен саткач килгән керемнән кыйммәтле кәгазь хуҗасына (мәсәлән, акцияләре булган кешегә — акционерга) фирма капиталында аның өлешенә тиң булган сумма кире кайтарыла;

4) эшкә алынган акчаларны югалту куркынычын компенсацияләү сыйфатында акционерга фирманың киләчәктә алачак табышының (акционерлар акчасын файдаланып, капиталын арттыруга ирешкәннән соң килгән кеременең) бер өлешен алу хокукы бирелә. Табыштан алып акционерларга бирелә торган мондый түләүләрне гадәттә **дивидендлар** (лат. *dividendus* — бүленергә тиешле) дип атыйлар.

ДИВИДЕНД — саф табыш суммасының акционерлык җәмгыяте акционерлары арасында алар хуҗа булган акцияләр санына карап бүленә торган өлеше.

Күпчелек акцияләр гадәти кыйммәтле кәгазьләр — **гадәти акцияләр** — рәвешендә чыгарыла.

Мондый акцияләр буенча килгән дивиденд күләме фирмага реаль килгән саф табыш (дәүләткә салымнар түләгәннән соң калган табыш) зурлыгыннан бәйле була. Димәк, фирманың табышы күбрәк булган саен, акционерлар шулхәтле күбрәк дивиденд ала дигән сүз. Әмма табыш аз икән, гомуми җыелыш карары нигезендә, гадәти акцияләр буенча дивидендлар бөтенләй түләнмәскә дә мөмкин — фирма шулай эшли ала.

Саклык акчалары булган кайберәүләр мондый билгесез перспективаны бик үк өнәп бетермиләр. Мондый инвесторлардан да акчаларын алуга ирешү өчен, эшмәкәрләр кыйммәтле кәгазьләрнең **өстенлекле акцияләр** дигән формасын уйлап табалар. Мондый акцияләр буенча дивидендлар зурлыгы алдан ук төгәл билгеләнеп

куела. Ул, акция бәясеннән яки компаниянең саф табышыннан (салымнардан тыш гомуми табыштан) чыгып, процентларда күрсәтелә. Мәсәлән, «Сургутнефтегаз» нефть компаниясе өстенлекле акция хуҗаларына барысына бергә еллык 10 % тан да ким булмаган саф табыш бирергә ышандыра (ә 2000 елда бу компаниянең саф табышы 1 млрд доллардан да артып китә).

ӨСТЕНЛЕКЛЕ АКЦИЯ — аңа ия булган затка, корпорация дивидендларын һәм корпорация ябылган очракта аның мөлкәтен бүлгәндә, гадәти акцияләр хуҗаларына караганда өстенлекләр бирүче акция. Мондый акция хуҗасы, гадәттә, фирма эшчәнлеге турында карарлар чыгарганда тавыш бирү хокукына ия булмый, әмма акционерлык җәмгыяте билгеле бер вакыт эчендә алган табыш дәрәҗәсенә карамастан, төгәл билгеләнгән дивидендларны ала.

Шунысын да истән чыгармаска кирәк: акционер дивидендлар гына түгел, ә үз кулындагы кәгазьләрнең бәяләре үсү хисабына да үзенә файда ясый ала. Әгәр дә ул эшен уңышлы алып баручы фирма акцияләрен алса, шундый үсешкә ирешә. Мондый фирма мөлкәтенең гомуми бәясе арта икән, анда акционер хуҗа булган бер өлеш мөлкәтнең бәясе дә үсә.

Шул ук вакытта, монда фирма мөлкәтенең бухгалтерлар билгеләгән бәясе турында түгел, ә фирманың базар бәясе турында сүз баруын аңлау зарур. Ә ул бәя, иң элек, фирма мөлкәтен алуга күпме акча тотылудан түгел, ә фирма киләчәктә үз хуҗаларына күпме зурлыктагы табыш китерә алачагыннан бәйле була.

Әгәр дә фирма эшләрен уңышлы алып барса һәм зур табыш алса, аның акцияләренең базар бәясе (аны, гадәттә, **акцияләр курсы** дип атыйлар) бу акцияләргә хуҗа булу хокукы өчен акционерлар кайчандыр түләгән номиналь суммадан күпкә артып китәргә мөмкин. Шуңа күрә акцияләр тоту бик табышлы эш була ала.

АКЦИЯЛӘР КУРСЫ — акцияләрне кыйммәтле кәгазьләр базарында ирекле төстә кабат сатканда урнашкан базар бәясе.

Мәсәлән, IBM кебек мәшһүр Америка компьютер фирмасының акцияләр курсы 33 ел эчендә 156 тапкыр үсте, ә аларга ия булган акционерлар кайчандыр бу кыйммәтле кәгазьне алганда түләгән һәр долларга 38 доллар дивиденд алды.

Фонд базарында чынлыкта акцияләр белән ике төрле килешү (сделка) күзәтелә:

1) *акцияләрне беренчел урнаштыру* (*эмиссия*); бу төр килешүләр фирмаларга өстәмә үзкапитал китерә;

2) *кыйммәтле кәгазьләрнең икенчел әйләнеше*; бу төр килешүләр кыйммәтле кәгазьләргә ия булганнарга һәм саклык акча хуҗаларына төрле фирмаларның элегрәк чыгарылган акцияләрен ирекле төстә сатарга яки сатып алырга мөмкинлек бирә.

Акцияләрнең барлык эмиссиясе ярдәмендә капитал җәлеп итү җиңел түгел. Яңа фирманы әле беркем дә белми, берәү дә үз акчасын аңа бирергә ашкынып тормый, чөнки аларны югалту куркынычы бик зур. Яңа предприятие уңышсызлыкка

дучар булып, керемсез калса, акцияләрне дә сатып булмаячак, димәк, тотылган акчаларны да кире кайтарып булмаячак. Менә ни өчен яңа төзелгән күпчелек фирмалар акцияләр аша акча җәлеп итә алмыйлар да инде.

Алар индивидуаль (хосусый) предприятие яки ширкәт фирмасында уңышка ирешкәч кенә, ул чыганакны җәлеп итә алачаклар.

Югарыда әйтеп үтелгәннәрдән чыгып, икътисади акыллылыкның тагын бер рецептын төзи алабыз.

Дүртенче рецепт

Базар механизмнары эшләвенә тоткарлыклар тудырырга, мәсәлән, бәяләрне «өшетергә» ярамый, чөнки бу гына базарда тигезләнеш урнаштыра алмаячак һәм анда бик озак вакытка сузылган товарлар дефициты яки артыклыгы халәте урнашачак.

БҮЛЕКНЕҢ ТӨП ЭЧТӘЛЕГЕ

Базар бәяләре формалашу. *Базарда сәүдә итү барышында сатучылар һәм сатып алучылар мәнфәгатьләрен үзара килештерү тигезләнешле бәя рәвешендәге компромисс формалашуга китерә. Мондый бәяләр вакытында җитештерүчеләр (сатучылар) сатуга тәкъдим итәргә (чыгарырга) риза булган кадәр барлык товарларны сатып бетереп була. Мондый товарлар күләме тигезләнешле сату күләме дип атала. Базарның тигезләнеш халәтеннән читкә тайпылуы — дефицит яки товарлар артыклыгы халәте сатучыларга да сатып алучыларга да файдалы түгел. Товар артыклыгы — сатучылар өчен, ә дефицит сатып алучылар өчен авыр. Базар тигезләнеш халәтенә ирешсә, сатучылар һәм сатып алучыларның мәнфәгатьләре берберсе белән бик уңай яраша.*

Эшләүче базар, яки Сәүдә эше чынлыкта ничек оештырыла. *Фирмалар оештыру һәм аларның үсеше физик һәм матди булмаган капитал алуны таләп итә. Моның өчен фирмаларга акча капиталы кирәк. Фирмалар аны капитал базарыннан җәлеп итә. Саклык акча хуҗалары, ягъни агымдагы хаҗәтләргә кирәкле чыгымнан артыграк керемнәре булган һәм куллануларын киләчәктә шактый арттыру максатында бүген азрак чыгымнар тотарга сәләтле гаиләләр бу базарда сатучылар буларак чыгыш ясый. Бу максатларга ирешү өчен, саклык акчасы булганнар вакытлар узу белән аларның бәяләре төшмәслек, ә киресенчә, шактый артырлык итеп куллану мөмкинлекләрен эзли. Саклык акча хуҗаларына бу мәсьәләне хәл итүдә финанс капиталы булыша, аның ярдәмендә алар үзләренең саклык акчаларын коммерция фирмаларына вакытлыча түләүле файдалануга биреп торалар. Капитал базары составына акча капиталын сату-алу шартлары белән аерылучы төрле секторлар керә. Кредит базары, акцияләр базары һәм фирмаларның бурыч*

йөкләмәләре (иң элек облигацияләр базары) шундый иң мөһим секторлар рәтеннән. Моннан тыш, Россия капитал базарында дәүләт тә зур роль уйный. Ул предприятиеләргә ярдәм итү, аларны банкротлыктан саклап калу һәм үсешләрендә булышу өчен аларга акча кертемнәре сала. Капитал базарында фирмалар төрле характердагы акча средстволары алырга мөмкин: мәсәлән, заем капиталы яки үзкапитал. Заем средстволарын фирмалар вакытлыча файдалануга ала һәм аннары файдаланган өчен хуҗаларына өстәп кире кайтара. Үзкапитал фирмалар карамагына чикләнмәгән вакытка тапшырыла, ә аның элекке хуҗалары фирмаларның милектәшләренә әверелә һәм алар мөлкәтенең, шулай ук кеременең бер өлешенә хокуклы була. Үзкапитал алуның төп чарасы төрле типтагы акцияләр чыгарудан (эмиссия) һәм сатудан гыйбарәт. Акция ияләре аларны эмитент-фирмага кайтара алмый, әмма кыйммәтле кәгазьләр, ягъни фонд базарында сата ала. Бу базардагы акцияләр бәясе фирма киләчәктә үз хуҗаларына китерә алырлык керемнәр көтелү белән билгеләнә.

ФИКЕР АЛЫШУ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Базарда ни өчен күбрәк мәгълүматлы булган зат ота?
2. Россия фирмалары, товарларын түбәнрәк бәядән сатып, дөнья товар базарларына чыкмакчы була. Мондый сәясәт нәтиҗәләрен әлеге базарлардагы тәкъдим кәкреләре рәвешендә ничек сызып күрсәтергә мөмкин?
3. Сезнең, мөгаен, «бәяләрнең сезонлы тирбәлеше» дигән гыйбарәне ишеткәнегез бардыр. Аның мәгънәсен ничек аңлыйсыз?

Акча дөньясы

БҮЛЕКТӘ КАРАЛУЧЫ МӘСЬӘЛӘЛӘР:

1. КЕШЕЛӘР НИ ӨЧЕН АКЧА УЙЛАП ТАПКАН?
2. НӘРСӘЛӘР АКЧА БУЛА АЛА?
3. ХӘЗИНӘ ЯШЕРҮ НИ ӨЧЕН ФАЙДА КИТЕРМИ?

Кызык ки, элек-электән тәңкәләр үзенчәлекле һәйкәлләр ролен дә башкарган,— туган илендә чыгарылган тәңкәләрдә үз йөзен төшерү ниятеннән тыелып калган идарәчене тарих битләрендә табуы бик кыен. Бу өч рус тәңкәсе моның җитди дәлиле булып тора.



№ 4119 20s

THIS Indented Bill of Twenty Shillings due from the Massachusetts Colony to the Possessor shall be in value equal to money & shall be accordingly accepted by the Treasurer and Receivers subordinate to him in all Publick payments and for any Stock at any time in the Treasury. Boston in New-England February the third 1690. By Order of the General Court

Яңа Англиядә Массачусетс колониясендә 1690 елда чыгарылган акча билеты

Кешеләрне хәтта мәхәббәт тә
акча асылы турында акыл
сату кадәр шаштырмаган.

Уильям Ю. Гладстон,
Бөекбритания премьер-министры
(1809—1898)

Базар икътисады механизмы турында сөйләсәк тә, без моңа кадәр акча турында, аның роле болай да аңлашыла инде дип уйлап, бөтенләй диярлек сүз алып бармадык. Һәм, чыннан да, акча — безгә сабый чактан ук, беренче акча кәгазеннән үк мәгълүм икътисади механизм.

Әмма күпчелек халык акча дөньясы турында бик аз белә. Бу гаҗәп тә түгел: әлеге дөнья цивилизациянең иң катлаулы икътисади механизмын гәүдәләндерә. Аның барлык законнары бары тик профессионалларга — галимнәргә, банкирларга, финансистларга гына мәгълүм. Әмма үкенечле хаталар ясамас өчен, акча дөньясы законнары турында беркадәр күзаллаулар һәр кеше өчен кирәк.

§ 9. Акча барлыкка килү сәбәпләре һәм аның формалары

Акча — кеше акылы уйлап тапкан иң бөек казанышларның берсе. Табигать дөньясында аның аналоглары юк.

Җирнең иң ерак почмагындагы иң артта калган цивилизацияләр дә үз акчаларын ясаганнар. Барлык алыш-биреш эталоны дип саналган акча роле һәрвакытта да иң күп соралган (кирәк булган) һәм бу максатлар өчен иң кулай булган товарга йөкләнгән.

Тарихчылар тапкан дәлилләр раславынча, дөнья халыкларында акча ролен тоз, мамык тукымалар, бакыр беләзекләр, алтын ком, атлар, кабырчыклар, хәтта кипкән балык кебек иң төрле товарлар башкарган.

Мәсәлән, XV гасыр Исландиясендә түләү чарасы булып кипкән балык хезмәт иткән, һәм шуңа күрә дә шул замандагы бәяләр белешмәсе (прейскурант) түбәндәге рәвештә булган: дага өчен — 1 балык; 1 пар хатын-кыз башмагы өчен — 3 балык; 1 мичкә шәраб өчен — 100 балык; 1 мичкә атланмай өчен — 120 балык.

Борынгы заманнардан ук акчаның кешеләр тормышында нинди зур роль башкаруын түбәндәге кызыклы факт раслый. Эцталь Альпы бозлыкларында археологлар яхшы хәлдә сакланган 5 мең еллык кеше мәете тапканнар. Кар буранында һәлак булган бронза дәвере кешесе кулында бакыр пластинаны — үзендә булган иң кадерле нәрсәне кысып тоткан. Нәкъ шундый бакыр пластиналар шул заманда акча ролен башкарган.

Базар эшендә катнашучыларның барысы өчен дә әһәмиятле булган һәм һәр килешүне үзе аша үткәрергә мөмкинлек биргән универсаль акча товарын кешелек бик озак эзләгән. Күп гасырлар дәвамында иң уңай акча товары дип затлы металлар — алтын һәм көмешне санаганнар, чөнки аларның берничә өстенлеге булган:

— сирәк очрау — алтын һәм көмешне аларга булган ихтыяҗга караганда күп тапкыр кимрәк чыгарганга күрә, затлы металларның кадере бик зур була һәм алар бик күп башка товарларны алмаштыру эквиваленты хезмәтен башкара алган һәм бу бик уңайлы булган;

— югары ликвидлылык — затлы металлар базарда аз тәкъдим ителгәнлектән (аз чыгарылганлыктан), ә аларга булган сорау (ихтыяж) зур булганлыктан, акчаларны бетерү, ягъни аларны башка товарга алмашу мөмкинлеге һәрвакыт булган;

— портативлылык — бик сирәк очрау һәм шул сәбәпле кыйммәте югары булу аркасында, тәңкәләрне затлы металлардан бик кечкенә һәм җиңел массалы, әмма зур кыйммәтле итеп ясаганнар;

— аеручанлык — алтын һәм көмешне кешеләр бик тиз танып алганнар, бу металлардан сугылган тәңкәләрнең чынлыгын тикшереп карау юлларын табу авыр булмаган;

— бүленүчәнлек — сирәк очрау һәм югары ликвидлылык сыйфаты хас булганлыктан, төрле кыйммәткә ия булган төрле авырлыктагы тәңкәләр ясау әллә ни авырлык тудырмаган һәм бу исәп-хисап эшләрен дә җиңеләйткән;

— бертөрлелек — кешеләр затлы металларны кушылмалардан чистартуны бик тиз үзләштерәләр, һәм шуңа күрә тәңкәләрнең бердәй микъдардагы металлдан эшләнүен тәэмин итүгә ирешәләр һәм, димәк, аларның кыйммәте дә бер үк төрле була. Алай гына да түгел, әгәр дә алтын коелманы өлешләргә киссәләр, кирәк булган очракта бу алтын кисәкләрен, металлның кыйммәтенә зыян салмыйча, янадан кушып куярга мөмкин.

Менә ни өчен коелма һәм тәңкә хәлендәге алтын һәм көмеш дөньяның күпчелек илләрендә акча системасының нигезен тәшкил итә һәм бик озак вакытлар дәвамында «алтын», «көмеш» һәм «акча» сүзләре синонимнар була.

Әмма тора-бара затлы металларның акча әйләнешендә иң яхшы нигез булмавы ачыклана бара, чөнки аларның җитди кимчелекләре бар: эре акча суммаларын күчереп йөртү һәм саклау бик зур чыгымнар таләп итә.

Моңа кадәр әле сүз товар акчалар, ягъни башка максатларда кулланыла алса да, акча вазифасын да башкарырлык үзенчәлекле товар турында сүз барды. Алар урынына акча дөньясына товар акчаларның алмашлары — башта товар акчаларның символлары, билгеләре булып хезмәт иткән төрле документлар үтеп керә. Кемнең дә булса товар акча рәвешендәге беркадәр сумманы саклау өчен урнаштыруы һәм аны кире ала алуы турындагы дәүләт һәм банк белешмә язулары (расписка) нәкъ әнә шундый беренчел символик акчалар булган да инде. Мондый белешмә язуларын (һәм алар белән бәйле товар акча алуга хокукны) бер хуҗадан икенчесенә тапшыру мөмкинлеге тугач та, акча әйләнешенең дөньядагы яңа тәртибе, төгәлрәк әйтсәк, товар акчаларны уңайлырак булган символик акчалар белән этеп чыгару процессы башлана.

СИМВОЛИК АКЧАЛАР — түләү чаралары алар (вак акча һәм кәгазь акча). Боларның бәясе һәм акча буларак түләү сәләте аларны әзерләүгә киткән чыгымнарны яки башка максатларга файдалангандагы кыйммәтен узып китә.

Тәңкә белән гасырлар аша

Акча сугу йортларында (монетный двор) бүген чыгарыла торган тәңкәләр — акчаларның иң борынгы төре алар: Борынгы Грециядә тәңкәләрне б. э. к. VIII—VII гасырларда ук суга башлыйлар. Римда беренче акча сугу йорты Юнона-Монета храмы каршында төзелә. Һәм «монета» (тәңкә) дигән термин әнә шуның белән бәйләнгән дә инде. Тәңкәләрне әзерләү өчен, гадәттә, ышкылуга чыдам махсус коелма кулланыла, чөнки тәңкәләр бик тиз кулдан кулга күчеп йөри, ә йомшак металл бер ел да хезмәт итә алмас иде.

Тәңкәләр тарихы бик чуар һәм төрле. Әмма аның аша кызыл җеп булып узучы бер үзлек аерым игътибарга лаек: кешелек, гомумән, акчаның һәм аерым алганда тәңкәнең бәя символы булуын төшенә. Тәңкәне әзерләүгә анда күрсәтелгән бәядә торырлык металл тотылмый. Әлеге аксиома бөтен дөньядагы монархларга «тәңкәләрне бозу» белән шөгыльләнергә мөмкинлек биргән. Номиналга караганда металы арзанрак булган тәңкәләр коюны элекке заманнарда әнә шулай дип атаганнар.

Мәсәлән, Петр I үзе идарә иткән елларда сумның (рубльнең) бәясен ике тапкырга киметә, шул ук вакытта 1 сумлык тәңкә коюга киткән көмеш күләмен дә шулкадәр үк кыскарта.

Дөрес, Петр I, үз әтисенең «тәңкә бозу»дагы кыланмышларын истә тотып, акчалар белән артык сак эш итә. Аның әтисе, патша Алексей Михайлович, 1656 елда казнаны тутыру максатында, барлык көмеш акчаларны да әйләнештән алырга һәм алар урынына шул ук номиналдагы бакыр акчалар куярга боера. Бу — 100 сумлык тәңкәне бары тик 2 сум торырлык бакыр кисәгеннән әзерләп була дигәнне аңлата.

Алексей Михайловичның акча экспериментлары 1662 елның 25 июле восстаниесе белән тәгәлләнә. Тарихка Бакыр бунты

Тәңкәләр тарихы әлеге тәңкәләр басылган ил тарихын гәүдәләндерә. Мәсәлән, Борынгы Италиянең сәяси конфликтлары б. э. к. I гасырда ана бүрене егып салган үгез сурәте төшерелгән Оск тәңкәсен сугуга этәргеч бирә.

атамасы белән кереп калган бу восстаниене бастыру бик канкойгыч рәвеш ала — 1 меңнән артык кеше үтерелә, асыла, Мәскәү елгасында батырыла. Шуңа да карамастан, бәясе төшкән бакыр акчалар бер елдан соң әйләнештән алына.

Алтын һәм көмеш тәңкәләр XX гасырда да әле барлык илләрдә әйләнештә йөри. Россиядә, мәсәлән, революциягә кадәр 5, 10, 15 сумлык номиналлы тәңкәләр (империал), шулай ук 7 сум 50 тиенлек тәңкәләр (ярымимпериал) сугыла. Һәрхәлдә, әле бүген дә алтын тәңкәләр сугыла, әмма алар бик аз. Мондый тәңкәләр ирекле әйләнештә йөрү өчен чыгарылмый — аларны коллекционерлар һәм үз акчаларын алтын тәңкәләрдә саклауны кулайрак күргән кешеләр сатып ала. Шул сәбәпле Көньяк Африка Республикасында (КАР) сугылучы «Крюгерранд» дигән алтын тәңкәнең номиналы (сугылган бәясе) да күрсәтелми: аның бәясе сорау һәм тәкъдим чагыштырмасы белән билгеләнә.

Кәгазь акчалар яңа акча әйләнеше коралы булып әверелә. Алар беренче тапкыр IX гасырда Кытайда әйләнешкә кертелә. Ә инде Юань династиясе идарә иткән чорда (1271—1368) алар күпләп басыла башлый һәм Кытайдагы акча әйләнешенең төп чарасы булып әверелә. Хәер, «чын акчалар»ның, ягъни затлы металлардан сугылган тәңкәләрнең алмашлары башка илләрдә дә киң кулланыла. Мондый түләү билгеләренең номиналы патша мөһере яки сәүдәгәрнең, банкирның имзасы һәм шәхси мөһере белән раслана. Мәсәлән, Русьта моның өчен штемпельле күн кисәкләре кулланалар, ә Кытайда император Хубилай XIII гасырда акчаны тут агачы кайрысыннан «сугарга» боера һәм аларга император мөһере басыла.

Көнбатыш цивилизация илләрендә күпләп кәгазь акча чыгару эшендә беренчелек Төньяк Америка Штатлары (хәзерге Америка Кушма Штатларының элгәресе) кулында була: 1690 елда мондый акча билгеләрен Массачусетс штаты баса башлый. Американлыларның әлеге тәҗрибәсен беренчеләрдән булып Франция үзләштерә: 1716—1720 елларда икътисадчы һәм банкир Джон Ло Король банкы банкнотларын бастыра башлый. Безнең илдә беренче кәгазь акчалар (ассигнацияләр) 1769 елда, Екатерина II патшалык иткән чорда әйләнешкә кертелә. Алар без бүген кулланган кәгазь акчалардан бик нык аерылган һәм банк йөкләмә кәгазьләреннән гыйбарәт булган.

Мондый банк билетлары банкир тарафыннан язылган. Шушы билетны аңа тотып килгән кешегә теләсә кайсы вакытта банкир әлеге документта күрсәтелгән акча суммасын чыгарып бирергә тиеш булган. Банк никадәр бай һәм абруе никадәр югары булган саен, аның банк билетлары да шулкадәр күбрәк ышаныч уяткан һәм сәүдәгәрләр белән гражданнар исәп-хисапларында, алтынны һәм көмешне алмаштырып, алар шулкадәр күбрәк кулланылган.

Әйтергә кирәк, акчаның яңа төре буларак банкнотлар куллануны кертү әллә ни куаныч уятмаган. Киресенчә, 1725 елда ук күренекле инглиз философы, тарихчы һәм икътисадчы Дэвид Юм 12 млн фунт стерлинг торырлык кәгазь акчаны юк итәргә өндәгән, бу шул чакта Англиядә әйләнештә йөргән 40% акча массасын тәшкил иткән. Аның фикеренчә, кәгазь («начар») акчалардан шундый юл белән котылу корольлеккә затлы металлар («яхшы акчалар») агымын китерер иде.

Кәгазь акчаларны тәнкыйтьләү игътибарсыз калмаган. Киләчәктә күпчелек илләр үзәк банклар төзи башлагач, банкнотлар чыгару хокукы бары тик аларга гына бирелгән. Сәбәп бик гади: бу банкнотларны иң югары ышанычлылык белән тәэмин иткән, **акча эмиссиясенә** юл калдырмаган.

АКЧА ЭМИССИЯСЕ — әйләнешкә акча знаклары (билгеләре) чыгару.

Беренче бөтендөнья сугышы заманнарыннан бирле үзәк банклар банкнотлары акчалата түләүнең төп чарасы булып әверелә, ягъни **кулдагы акча средстволарының** төп формасына әйләнә. Махсус дәүләт оешмалары — акча сугу йортлары чыгарган вак акча да алар рәтеннән йөри.

Кулдагы акчалар белән беррәттән кешеләр **кулда булмаган акча средстволарын** (акчалата булмаган акча әйләнеше) да файдалана. Алар:

Русьта нинди акчалар булган

Борынгы Ипатьев елъязмасындагы түбәндәге юлларның мәгънәсен аңларга тырышып карагыз: князь Ярослав в 1080 г. «начаша скот брати: от мужа по 4 куна, а от старосты по 10 гривен, а от бояр по 80 гривен; приведоша варяги и вдаша им скот, и совокупи Ярослав многи». Беренче карашка бик серле фраза. Кайберәүләр монда борынгы заманда алмашу чарасы итеп терлекләр кулланылуына ишарә күрә. Бик мөмкин. Һәрхәлдә, XI гасырда бу термин архаизмга әверелә, чөнки Русьта инде дүрт гасыр дәвамында әйләнештә көмеш һәм мех йөри, ә аннан соң берничә йөз елга кун системасы ныгып урнаша, бу системада төп берәмлек булып куница, ягъни сусар мехы, ә ваграк берәмлек булып тиен мехы йөри (татарча акча берәмлеге булып йөргән «тиен» сүзе әнә шуннан — *тәрҗ. искәрмәсе*). 25 кун — 1 гривнага, ә 50 кун гривнакунга тигез булган.

Хәер, Ипатьев елъязмасындагы «скот» сүзе нәкъ менә акча мәгънәсен аңлата дигән фаразны борынгы рус телендәге «скотница» сүзенең хәзинәләр, ягъни патша казнасын саклау урынын белдерүе раслый.

Бик борынгы заманнардан ук Русь, ә соңрак Мәскәү дәүләте, үз җирендә металлар чыгарылмау сәбәпле, аларны коелмалар, тәңкәләр һәм эшләнмәләр рәвешендә башка халыклардан сәүдә аша алганнар һәм сәүдә әйләнешендә мехлар белән беррәттән чит ил тәңкәләреннән (монета) дә файдаланганнар. Русьта күбесенчә гарәп акча билгеләре алтын динарлар, көмеш дирһәмнәр һәм бакыр фельслар әйләнештә йөргән. Әгәр дә исәп-хисаплар өчен вак акча җитмәсә, тәңкәләрне кисәкләргә бүлгәннәр. Кайчакта мондый хәлне истә тотып, тәңкәнең икенче ягында аны ике яки дүрт кисәккә бүлү мөмкинлеге бирүче сызыклар төшерелгән.

Көнчыгыш белән кайнаган сәүдә бераз сүрелә төшкәч һәм Русьны монголлар яулап алгач, Русь акча системасы зур үзгәрешләр кичергән һәм аның төньяк-көнчыгышында түләү чарасы буларак тәңкә («деньга») киң кулланыла башлаган. Рус телендә барлык сатып алулар өчен түләнә торган товарның (деньги) гомуми атамасы да әлеге сүз белән бәйләнгән.

Руслар үз акчаларын XIV гасыр ахырында, Дмитрий Донской заманнарында суга башлаганнар. Әмма Петр I заманнарында да әле Себер халыкларыннан казнага җыела торган ясакны элеккечә мехлата алганнар, чөнки аларны рәхәтләнеп сатып җибәреп булган, патша үз түрәләренә дә мех белән түләгән (моның белән ике як та бик риза булган).

1) кулдагы акчалар кебек үк акча берәмлекләрендә гәүдәләнгән;

2) махсус коммерция оешмаларында — банкларда сакланган;

3) махсус китапларда яки компьютерның магнитлы йөрткечләрендәге (носительләрендәге) язмаларны үзгәртү юлы белән исәп-хисап ясауда файдаланылган суммаларны гәүдәләндерәләр.

КУЛДАГЫ АКЧА СРЕДСТВОЛАРЫ (НАЛИЧНЫЕ) — кәгазь акчалар һәм вак акча (тәңкәләр).

КУЛДА БУЛМАГАН АКЧА СРЕДСТВОЛАРЫ (БЕЗНАЛИЧНЫЕ) — гражданнар, фирмалар һәм оешмаларның банклардагы счетларында саклануч һәм банклардагы кемнең күпме акча средствосы булуы турындагы язмаларны үзгәртү юлы белән исәп-хисап ясау өчен кулланылучы суммалар.

5-1 рәсем.
Хәзерге акча системаларының төп элементлары

Шуны истә тотып, хәзерге акча системасы төзелешен 5-1 рәсемендәгечә күзалларга мөмкин.

Хәзерге акча формалары барлыкка килү тарихы белән танышкач, кешеләрнең ни өчен акча уйлап табулары турындагы сорауга әйләнеп кайтыйк.

Акча иң элек алмашуны җиңеләйтү өчен кирәк булган. Ә алмашу кешелекнең иң борынгы шөгыле булганлыктан, акча системасының тамырлары да чал тарих тирәнлегенә китә.

Акча барлыкка килү турында күренекле тарихчы Фернан Бродель бик шәп фикер әйткән: *«Товар алмашу килеп чыккач та, акча кыштырдавы ишетелә башлый»*,— ди ул.

Гәрчә акчаны кешелек товар алмашуны җиңеләйтү һәм тизләтү өчен уйлап тапкан булса да, вакытлар узу белән, акча башка функцияләрне дә үти башлаган.

§ 10. Хәзерге икътисадта акча функцияләре

Хәзерге икътисадта акча өч төп вазифаны башкара (5-2 рәсем):
— алмашу чарасы;
— исәпләү (исәп-хисап) чарасы;
— саклау (туплау) чарасы.



5-2 рәсем.
Икътисадта акча функцияләре

Кайбер икътисадчылар карашынча, әлеге рәтне, акчаның тагын ике функциясен өстәп, тагы да киңәйтергә кирәк. Әмма ничек кенә булмасын, акча — мөһим икътисади бурычны, төгәлрәк әйтсәк, кешеләрнең товар һәм хезмәт күрсәтүләр алмашу өлкәсендәге тырышлыкларын координацияләү бурычын хәл итә.

Кайчандыр бер акыл иясе «акча — сәүдә тәгәрмәче тәгәри торган юл ул» дигән. Башка акыл иясе акчаларны дөньядагы сәүдә өлкәсендә аралаша торган универсаль тел белән чагыштырган. Һәм аларның икесе дә хаклы.

Акчаларны сәүдә товар алмашуны җиңеләйтү өчен уйлап таба. Бары тик партнерларның икесендә дә бер-берсенә кирәкле әйбер булганда гына, акча катнашыннан башка турыдан-туры алмашу башкарылырга мөмкин.

Чыннан да, көтүче башмакларга алыштыру өчен базарга сарык тиреләре алып килгән дип күз алдына китерегез; итекче исә башмакларын тукымага алмаштырырга исәпли. Аларның һәрберсе үзе теләгән әйбергә алыштыру өчен үз товарын тәкъдим итеп карый, әмма икенче як аның товары белән кызыксынмый, һәм алмашу барып чыкмый.

Нәкъ менә шушы хәл алмашуның без күреп үткән формасын бик җайсыз итә. Аны **бартер** дип атыйлар. Бартер вакытында товар алмашуда катнашкан һәр як үзенә кирәкле әйбере булган һәм аның товарын алырга әзер торган партнерны табарга тиеш була. Алмашу нияте белән җитештерелгән әйберләр никадәр күбрәк булган саен, мондый принциплар буенча алмашу да шулкадәр кыенлаша бара.

БАРТЕР — бер товарларны яки хезмәт күрсәтүләрне башкаларына акча кулланмыйча гына турыдан-туры алмашу.

Югарыда сурәтләнгән хәлдә калган алмашу яклары (көтүче, итекче) әлеге тупиктан әгәр дә аларның берсе ике катлы алмашу ясарга кирәклекне төшенсә генә чыга алачак. Һәм моны беренчеләрдән булып көтүче чамалап алган дип күз алдына китерегез. Ул очракта ул үз кулындагы тиреләрне үзенә кирәк булмаган товарга — тукымага алмаштыра. Аның каравы, шул тукымага, итекчедә алмаштырып (аңа бит тукыма кирәк иде), ниһаять, үзенә кирәкле башмакларны алуга ирешә. Димәк, бу базарда тукыма үз өстенә акча (яки, башкача әйтсәк, акча-товар) ролен ала. Һәм шулай итеп, алмашуда катнашучыларның үзара туры килмәгән алмашу ниятләрен һәм мөмкинлекләрен җайлап чыгуга ирешелә.

Башкача әйтсәк, акча базарга килүчеләрнең алмашу ниятләрен килештерүчегә әверелә.

Нәтиҗәдә ике гамәлне вакыт һәм пространствода бүлү кебек гаҗәеп мөмкинлек туа. Ул гамәлләр түбәндәгедән гыйбарәт: үзеңдә булган товарларны сату һәм әле алырга гына теләгән товарларны сатып алу. Хәзер инде бартердагы кебек турыдан-туры алмашуны эзләп торуның кирәге калмый. Үз товарыңны акчага сатып җибәрү дә җитә һәм, шул акчаңны тотып, үзеңә кирәк әйберне сатучыны эзләп табасы гына кала.

Бу исә сәүдәдә катнашучылар арасындагы товар алмашуны, яки икътисадчылар әйткәнчә, товар «әйләнешен» шактый җиңеләйтә һәм тизләтә.

Шуннан чыгып, без **«акчаның»** беренче билгеләмәсен төзи алабыз:

Акча — һәртөрле башка товарлар һәм хезмәт күрсәтүләргә алмашка барлык кешеләр тарафыннан кабул ителүче махсус товар ул.



5-3 рәсем.
Товар алмашын оештыру:
а) акча-товарны (тукыманы) кулланмыйча *(пунктирлы уклар сәүдәдә катнашучыларның канәгатьләндерелмәгән ихтыяҗларын күрсәтә);*

б) акча-товарны (тукыманы) кулланып (*тукыма, көтүче кулы аша узып, сәүдә итүчеләрне бер җепкә бәйли, һәм аларның һәрберсе теләгәнен алуга ирешә. Ике яклы уклар сорау һәм тәкъдимне белдерә*).

Акча барлык сатып алучылар һәм сатучыларны җинел генә килештерә торган әнә шул универсаль тел хезмәтен башкара. Акча белән бөтенесе дә тәртиптә икән, «акча телендәге сәүдә сөйләшүе» бернинди проблемасыз бара. Әгәр дә инде акча дөньясында эшләр бозылып китсә, сәүдәне «бизгәк тота» башлый, тора-бара бөтен икътисад «авыруга» әйләнә.

Акчаның икенче функциясе аермачык күренеп тормаса да, мөһимлеге ягыннан калышмый. Әлеге функция исәпләү (исәп-хисап) чарасы булудан гыйбарәт.

5-3 рәсемендә күрсәтелгән бартер сәүдәсе механизмында, ниһаять, бердәм товар уйлап табалар, сәүдәдә катнашучылар үз теләкләрен һәм тәкъдимнәрен әлеге бердәм товар аша исәплиләр.

Чынбарлык тормышта да шушы ук хәл күзәтелә. Әмма монда берничә акча-товар була, сәүдәдә катнашучылар алмашуга тәкъдим иткән әйберләрен алар аша исәплиләр.

Мәсәлән, 1991 ел ахырында Россиядәге икътисади реформалар алдыннан товар дефициты шулкадәр көчәя ки, гадәти акчалар бөтенләй файдасызга әйләнеп кала — сәүдәнең иң күп өлеше бартер нигезендә алып барыла башлый. Һәм шул вакытта яңа акча-товарлар (автомобильләр, агач материаллары, корыч, бензин, ит) барлыкка килә, аларга алыштырып, кирәк булган бар нәрсәне сатып алу мөмкинлеге туа.

Әлеге акча-товарларны бер-берсенә алмаштыру турында «Коммерсантъ» газетасы төзегән таблица түбәндәгечә тасвирлана (5-1 табл.).

Таблица 5-1

Бартер товарлары								
	1	2	3	4	5	6	7	8
1. Автомобиль ГАЗ-2410 *(1 данәгә)*		1,7	1940	820	460	120	35	515
2. Автомобиль КамАЗ *(1 данәгә)*	0,6		1150	485	270	72	20	305
3. Цемент М-400 *(1 тоннага)*	0,0005	0,0009		0,4	0,2	0,06	0,02	0,3
4. Агач *(0,6 куб. м га)*	0,001	0,002	2,5		0,6	0,15	0,04	
5. Бензин А-76 *(1 тоннага)*	0,002	0,004	4,2	1,8		0,26	0,07	1,1
6. Корыч уголок *(1 тоннага)*	0,008	0,014	16	6,8	3,8		0,28	4,2
7. Суытып катырылган ит *(1 тоннага)*	0,03	0,05	57	24,4	13,6	3,6		15,3
8. Кызыл кирпеч *(1 мең данәгә)*	0,002	0,003	3,3	1,7	0,9	0,24	0,07	

Шулай итеп, 1 т бензинга 4,2 т цемент, яки 70 кг ит, яисә 1100 данә кызыл кирпеч алып булган.

Әгәр дә бердәм акча-товар юк икән, фирма хуҗасы үзенә табыш китерүче товарлар җитештерүгә ресурслар алу өчен тотасы чыгымнарын нәрсә ярдәмендә исәпләячәк соң? Чөнки ресурсларының бер өлешен ул кирпечкә, икенче өлешен — цементка, ә өченчесен кер юу порошогына алыштырган инде. Һәм үз чиратында фирмасы әзерләгән товарларны ул җиңел автомобильләргә һәм суыткыргеч торбаларга алыштыра. Шулай булгач, фирма хуҗасы эшенең никадәр файдалы булуын ничек аңларга соң?

Әгәр чыгымнар да, сатудан килгән төшем (выручка) дә акчада гәүдәләнә икән, төшемнәр суммасыннан гомуми чыгымнар суммасын алып ташласаң, фирманың табышы бармы, юкмы икәнлеген бик тиз ачыклап була.

Табыш булган очракта, хуҗа кулында фирмасын үстерү һәм үзенең шәхси кирәк-яраклары өчен акча кала. Әгәр дә чыгымнар керемнән арта икән, хуҗага тиз арада үз фирмасы эшен яхшырту чараларын күрү кирәк.

Хәзер инде без акчаның билгеләмәсен киңрәк итеп төзи алабыз.

Акча — һәртөрле башка товарлар һәм хезмәт күрсәтүләргә алмашка барлык кешеләр тарафыннан кабул ителүче, алмашу һәм исәп-хисап өчен барлык товарларны да үзара чагыштырып бәяләргә мөмкинлек бирүче махсус товар ул.

Акчаның башка функцияләре белән чагыштырганда саклау яки хәзинә туплау чарасы функциясе турында, мөгаен, аеруча күп язылгандыр. Хәтерлисезме, Пушкинның «Скупой рыцарь» әсәрендә:

Деньги? — Деньги
Всегда, во всякий возраст нам пригодны;
Но юноша ищет в них слуг проворных
И не жалея шлет туда, сюда.
Старик же видит в них друзей надежных
И бережет их как зеницу ока.

Саклау чарасы буларак акчаларның гаҗәеп бер сыйфаты бар: алар үз хуҗаларына тормыш муллыгы китерү сәләтен күп еллар буена саклап кала. Бу мәгънәдә акчалар «консервлаган куллану» кебек аңлашыла. Бу «консервлар»ны тупларга һәм аларның хуҗасы теләгән вакытта гына файдаланырга мөмкин.

Пушкин герое (Скупой рыцарь), хәзинәләр тутырылган сандыкларын караганда, нәкъ шул турыда уйлый да:

Лишь захочу — воздвигнутся чертоги;
В великолепные мои сады
Сбегутся Нимфы резвою толпою;
И Музы дань свою мне принесут...

Әлбәттә, акча хәзинәләрнең бердәнбер формасы түгел. Бүтән төрле кыйммәтләр дә бу рольне дәгъвалый. Алар — күчемсез милек (җир участоклары яки йортлар), сәнгать әсәрләре, антиквариат, ювелир эшләнмәләр, маркалар яки тәңкәләр коллекциясе һәм хәтта шәраб базлары.

Барлык бу **активларны** кирәк булганда башка төрле байлыкларга алмаштыру өчен файдаланып була.

Акчалата булмаган активларны шулай итеп файдалану өчен, аларның хуҗасы бу активларны үзенә кирәк әйберләргә алмаштыру чарасын табарга, яки аларны акчага әйләндерергә тиеш. Соңгысына бары тик активларны ликвидацияләү (сату) юлы белән генә ирешеп була.

Әгәр дә активлар акча формасында сакланса, хәл тагын да җиңеләя. Чөнки кирәк әйберләр алу өчен, акчаны бернинди арадаш операцияләрсез, ягъни турыдан-туры файдаланып була. Башка активлар белән чагыштырганда акчаның бер өстенлеге бар: алар абсолют **ликвид** була.

АКТИВЛАР — милек хокукында аерым бер кешенеке, фирманыкы яки дәүләтнеке булып исәпләнүче байлыклар.

ЛИКВИДЛЫК — теге яки бу активлар хуҗасының аларны нинди җиңеллек белән акчага әйләндерүен аңлата.

Чыннан да, йортны, җир участогын яки картинаны сату (мөлкәтне ликвидацияләү) өчен вакыт һәм тырышлык таләп ителә. Алай гына да түгел, аларны

саткач күпме акча киләсен алдан белеп тә булмый. Мәсәлән, бөек рәссамнар картиналарын сатучы мәшһүр «Sotbis» фирмасы аукционнары нәтиҗәләрен беркем дә алдан белә алмый. Кайчакларда рәсемне сатудан бөтенләй алып куярга мәҗбүр булалар: алар өчен хәтта иң минималь, башлангыч бәяне бирүче дә табылмый. Димәк, барлык акчалата булмаган хәзинәләр дә ликвидлык ягыннан акчадан калыша.

Әмма акчаны саклау чарасы итеп куллану мөмкинлеге хәзерге керемнәрне киләчәктә кулланырга дип туплап кую яки кыйммәтле әйбер сатып алырга өкренләп акча җыю өчен генә мөһим түгел. Әгәр дә кешеләр акчаны туплау чарасы дип танымаса, алар алмашу чарасы булып хезмәт итә алмас иде.

Чынлыкта сатылган товарлары өчен сатучы акча алган вакыттан соң ул үзе нәрсә дә булса сатып алганчы күпмедер вакыт үтәчәк. Әгәр дә шушы вакыт эчендә акчалар үз кыйммәтләрен, ягъни яңа әйбер алганда түләү сәләтен саклый алмаса, аларны беркем дә матди байлыкларга яки хезмәт күрсәтүләргә алмаштырырга риза булмаячак. Товар үзенең кыйммәтен һәм саклау чарасы булырлык ролен саклауга никадәр азрак сәләтле булган саен, аның акча-товарга әйләнү мөмкинлеге дә шулкадәр ким була.

Мәгълүм ки, Советлар Россиясендәге хәрби коммунизм заманнарында акча хуҗалыгы җимерелеп, кәгазь акчалар саклау (туплау) чарасы буларак хезмәт итү сәләтен югалткач, кешеләр озак вакытлар саклап булырлык һәм кыйммәтләрен югалтмый торган товарларны саклау чарасы итеп куллана. Тоз һәм шырпы шундый товарлардан була.

Әмма хәтта илнең акча системасында хәлләр уңай булып, әйләнештәге барлык акчалар бөтен халык тарафыннан әйләнеш чарасы һәм саклау чарасы дип танылса да, бу әле байлыкларны акча формасында саклау иң дөрес адым дигән сүз түгел. Эш шунда ки, акча туплау аның хуҗасы өчен кайбер югалтулар китерергә мөмкин. Моның ике сәбәбе бар:

1) керем алу мөмкинлеген ычкындыру. Акчаларны коммерция операцияләренә салсаң, алар керем китергән булыр иде;

2) инфляция аркасында акчаның бәясе төшү (бу хакта 6 бүлектә сөйләнәчәк).

Шекспир үз персонажларының берсе әйткән сүзләрдә шушы югалтуларның беренчесен искә алган да инде:

Зарытый клад ржавеет и гниет,
Лишь в обороте золото растет!

Шуңа күрә хәзинәләрне саклау формасын табу — катлаулы икътисади мәсьәлә, һәм аны чын икътисадчыларга да, аз гына байлык туплый алган гади гражданнарга да чишәргә туры килә.

Бу мәсьәләне хәл итүдә җәмгыятьнең финанс институтлары зур роль уйный. Алар милек ияләре туплаган акча средстволарын бизнес үстерүгә яки куллану товарларын алуга өстәмә средстволарда мохтаҗлык кичергән заемчыларга бирә. Бүген дөньяда финанс институтларының бик күп төрләре эшли, әмма банклар (алар турында 6 бүлектә сөйләнер), төрле саклык оешмалары, фонд биржалары, шулай ук страхование һәм инвестиция компанияләре алар арасында иң әһәмиятле урынны алып тора.

Шулай итеп, без акчага тагын бер аеруча тулы билгеләмә төзи алабыз:

АКЧА — махсус товар, ул —

1) барлык кешеләр тарафыннан һәртөрле башка товарлар һәм хезмәт күрсәтүләргә алмаштырып кабул итеп алына;

2) алмашу һәм исәп-хисап өчен барлык товарларны да үзара чагыштырып бәяләргә мөмкинлек бирә;

3) агымдагы керемнәрнең бер өлешен саклау һәм туплау мөмкинлеге бирә.

Акча дөньясы белән танышуны без икътисади акыллылыкның тагын бер рецепты белән тәгәллибез.

Бишенче рецепт

Илнең икътисади тормышы бартер җәелә алмаслык һәм акчаны аның төрле функцияләрендә файдаланырга беркем дә комачау итмәслек итеп оештырылырга тиеш.

БҮЛЕКНЕҢ ТӨП ЭЧТӘЛЕГЕ

Акча барлыкка килү сәбәпләре һәм аның формалары. *Акчаны кешелек иң элек алмашуны җиңеләйтү өчен уйлап тапкан. Баштарак акча ролен бөтенләй бүтән төрле байлыклар башкарган, акчаның хәзерге формалары соңрак барлыкка килгән. Алмашу, товарларның базардагы кыйммәтен исәпләү, саклау (туплау) чарасы функцияләрен башкару сәләте — акчаның сыйфаты әнә шулардан гыйбарәт.*

Бүгенге икътисадта акча функцияләре. *Акчалар сәүдәне җиңеләйтә.Чөнки аларны теләсә кайсы товарга алмашып була. Бу сәүдә эшен универсаль итәргә һәм товарлар сату факты белән шуннан кергән акчаны башка товар сатып алуда куллануны вакыт ягыннан бер-берсеннән аерырга мөмкинлек бирә. Хәзерге акча формалары барлыкка килү товар әйләнешен тоткарлаучы һәм күптөрле чагыштырма бәяләр таләп итүче бартерның уңайсыз булуы белән бәйләнгән. Акчалар бәяләр механизмы эшләвен гадиләштерергә ярдәм итәләр һәм җәмгыятьнең барлык хуҗалык тормышын җиңеләйтәләр. Моннан тыш, акчалар барлык товарларның кыйммәтен бердәм үлчәү системасында гәүдәләндерергә, аларны контроль һәм идарә эшләрендә истә тотарга мөмкинлек бирә. Акчалар хәзинәләрне иң ликвид формада тупларга ярдәм итә. Әмма байлыкларны акча формасында гына саклау кайбер югалтуларга китерергә мөмкин. Бу югалтулар туплаган акчаны коммерция операцияләренә салмыйча алынмый калган керемнәрдә гәүдәләнергә мөмкин. Моннан тыш, саклык акчалар инфляция аркасында да зыян күрергә мөмкин.*

ФИКЕР АЛЫШУ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Ни өчен алтын һәм көмеш төп акча-товар булганнар, ә тагы да ныграк һәм кыйммәтрәк бриллиантларга бу роль тапшырылмаган?
2. Кайчандыр Совет Россиясе АКШтан тракторлар алганда Эрмитажда сакланган кайбер рәсем сәнгате җәүһәрләрен сатып түләгән. Мәдәният хәзинәләреннән шул максатта файдалану дөрес адыммы?
3. XVI гасырда ук Британия финансисты сэр Томас Грэшем акча дөньясындагы тенденцияне түбәндәгечә тасвирлый: «Начар акчалар һәрвакытта да көндәлек әйләнештән яхшыларын этеп чыгара». Ул монда нәрсәне истә тоткан?

АЛТЫНЧЫ БҮЛЕК

Банк системасы

БҮЛЕКТӘ КАРАЛУЧЫ МӘСЬӘЛӘЛӘР:

1. КЕШЕЛӘР БАНКЛАРНЫ НИ ӨЧЕН УЙЛАП ТАПКАН?
2. БАНКЛАР КРЕДИТЛАРНЫ НИЧЕК БИРӘ?
3. НИ ӨЧЕН БАНКЛАР – ТӨП АКЧА ЯСАУЧЫЛАР?
4. ИЛГӘ ҮЗӘК БАНК НИ ӨЧЕН КИРӘК?

«Акчаны — өстәлгә!» өндәмәсе уен биналарында яки талаучылар дөньясында уйлап табылмаган. Ул кешелеккә мәгълүм булган иң беренче банклар эшен оештыруның нигезен тәшкил иткән.

Купчелек бай кешеләр элек-электән законлы хуҗасыннан тыш беркем дә файдалана алмаслык акча булдыру турында хыялланганнар.

Банкир — үзәк фигура.
Ул үз иннәрендә бөтен дөньяны күтәреп тора.

Герберт Н. Кэссон

Җәмгыятьнең акча системасы төзелеше турында бербөтен күзаллау барлыкка килсен өчен, безгә акча әйләнешен үзләре аша үткәрүче банклар һәм алга киткән икътисади механизмлы һәр илдә банклар барлыкка китергән система белән танышу зарур.

§ 11. Банклар барлыкка килү сәбәпләре һәм аларның төрләре

Банклар — кешеләр уйлап тапкан бик борынгы икътисади корылма. Беренче банклар инде б. э. к. үк Борынгы Көнчыгышта VII—VI гасырларда, кешеләрнең тормышы байлык тупларлык дәрәҗәгә житкәч барлыкка килә. Шуннан соң эстафетаны Борынгы Греция дәвам итә. Монда иң абруйлы храмнар сугыш вакытларында сакларга дип акча ала башлыйлар, чөнки сугышучы яклар беркайчан да изге урыннарны талауга бармыйлар.

Әмма борынгы банкларның саклау урыннарында хәзинә капчыклары ята башлау белән, җирле эшмәкәрләрнең (сәүдәгәрләр һәм һөнәрчеләр) карашлары да шул якка төбәлә. Алар башында бу хәзинәләрне үз эшләрен киңәйтү өчен кулланырга алып торып булмас микән дигән бик эшлекле сорау туа. Әлбәттә инде, түләү хакына.

Әнә шул рәвештә икътисадта катнашучы ике мөһим якның — саклык хәзинәләр хуҗасының һәм үз эшчәнлеген җәелдерү өчен капиталга мохтаҗ коммерсантның — мәнфәгатьләре бергә кисешә. Банклар барлыкка килү әнә шуның белән бәйләнгән дә инде (6-1 рәсем).

6-1 рәсем.
Банклар барлыкка килүгә этәргән икътисади мәнфәгатьләр

«Акчаны — өстәлгә!» — банкирларның иң борынгы девизы

Акчаны — өстәлгә!» өндәмәсе уен биналарында яки талаучылар дөньясында уйлап табылмаган. Ул кешелеккә мәгълүм иң беренче банкларның эшен оештыруның нигезен тәшкил иткән. Акча алмаштыру контораларының эше һәм храмнарда башка төрле банк хезмәтләрен күрсәтү традициясе бик борынгы заманнарга барып тоташа, һәм моңа бөтен кеше дә күнегә. Христианнарның изге китапларында Иисус Христосның түбәндәге адымы юкка гына тасвирланмый (Матвей Евангелиесы, 21 бүлек):

«Иисус Ходай храмына килеп керде һәм шунда сату итүчеләрнең һәм сатып алучыларның барысын да куып чыгарды, акча алыштыручыларның өстәлләрен һәм күгәрчен сатучыларның урындыкларын аударды».

Чыннан да, әле Борынгы Вавилонда һәм Борынгы Грециядә каһиннәр (жрецлар) һәм храмнар бергәлекләре банк операцияләре белән шөгыльләнеп, җәмгатьчелекнең акчасын ышанычлы итеп саклау һәм аларны коммерция эшләре өчен яки шәхси кирәк-яракка алып тору ихтыяҗын канәгатьләндерәләр. Бу ихтыяҗның никадәр җитди һәм гомумтанылган булуын түбәндәге факт бик ачык күрсәтә: Аполлон храмының акча саклау урыны (Грециянең Европа өлешенә хезмәт күрсәтә) илкүләм изге урын дип исәпләнә һәм мәңге дошманлыкта яшәгән грек дәүләтләренең бер генә армиясе дә бу акчаларга кул суза алмый.

Акчаларны саклауга кабул итү һәм бихисап грек дәүләтләренең акчаларын алмаштыру операцияләрен башкару урыны өстәл була, ул грекча «трапеза» дип атала; шул сәбәпле теге заманнарда банкирларны трапезитлар дип атыйлар. Рим банкирларын (менсарийларны) шулай ук өстәл хөрмәтенә (латинча «менса» — өстәл) атаганнар. Һәм, ниһаять, безгә килеп кергән «банкир» сүзе дә үзенең килеп чыгышы белән урта гасырлар Италиясендә «банка» дип аталган гап-гади көнкүреш предметына бурычлы.

Төрле илләрнең акчаларын алыштырудан, акча саклаудан һәм ссудалар бирүдән башлап җибәргән банклар тора-бара үзләренең хезмәт күрсәтү өлкәсен тагы да җәелдерәләр һәм шуның белән иң элек сәүдә үсешенә ярдәм итәләр. Флоренциядәге банкир йорты — Медичи гаиләсенең тарихы урта йөзләр Европасында банкларның нинди куәтле көчкә әверелүе турында хәбәр итә.

Медичи банкы XV гасырда Европадагы иң эре банкларның берсенә әверелә, бу аларга 300 ел дәвамында Флоренция шәһәр-дәүләтенең идарәчеләре булып торырга һәм герцог титулы алырга мөмкинлек бирә. Үз икътисади мәнфәгатьләрен яклау өчен, Медичилар герцоглык белән генә чикләнеп калмыйлар. Үзләренә мәгълүм ышанычлы схема буенча эш итеп, алар башта Рим папасы тәхете каршында банк төзиләр, ә аннары бу тәхеткә үз гаиләләренең ике кешесен күтәрүгә ирешәләр.

Медичилар фән һәм сәнгать алдында баш иючеләр буларак та мәгълүм: нәкъ менә алар ярдәмендә Флоренция дөньяның иң гүзәл шәһәренә әверелә. Һәм моның да икътисади тамырлары бар. Мондый эшчәнлек белән Медичилар үзләренең «банкирлык гөнаһларын» юарга тырышалар. Эш шунда ки, ул заманнарда банк проценты чиркәү тарафыннан билгеле бер вакытлы салым (бу очракта — заемга алган акчалардан файдалану вакыты) дип каралган. Ә вакыт исә, чиркәү атакайлары фикеренчә, Алла эше. Димәк, банкирлар Алла хисабына байыйлар һәм шуңа күрә гөнаһ кылалар.

Бүген, бәхеткә каршы, банкирларга заемчылардан процент алган өчен акланып торасы юк (гәрчә мөселман илләрендә бу — әле бүгенге көндә дә тыелган гамәл, андагы банклар үзләренә файданы башка юллар белән таба. Мәсәлән, заемчы-фирманың киләчәктә аласы табышында катнаша). Нәтиҗәдә банк оешмалары базар тибындагы икътисадларда үзәк урынны алалар. Алай гына да түгел, бүген банкларны еш кына һәр илдәге «бишенче хакимият» дип атыйлар (беренче дүртесен парламент, хөкүмәт, суд һәм пресса дип карасак).

Димәк, банклар икътисадта дүрт төп функция башкаралар дигән сүз:

1) исәп-хисап функциясе — товар һәм хезмәт күрсәтүләрне сатучылар һәм сатып алучыларның (хәтта болар төрле илләрдә булсалар да) үзара исәп-хисабын оештыралар;

2) депозит функциясе — саклык акча хуҗаларына ирекле акчаларын вакытлыча банкка урнаштырып тору һәм шуның өчен өстәмә керем алу мөмкинлеге бирәләр;

3) кредит функциясе — фирмаларга, хуҗабикәләргә һәм хөкүмәткә аларның теге яки бу проблемаларын хәл итүгә кирәкле акча средстволарын арттырып түләү шарты белән биреп тору;

4) товар һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләүләрне тизләтү һәм җиңеләйтү максатында акчаның яңа формаларын булдыру (мәсәлән, чек кенәгәләре. Андагы чек счетының хуҗа имзасы төшерелгән битләре, кәгазь акчалар кебек үк, кулдан кулга тапшырыла ала һәм аның белән банкка барып, чекта күрсәтелгән сумманы алырга була).

Моннан тыш, банклар клиентларга башка төрле хезмәтләр дә күрсәтә. Мәсәлән, саклык акчалар белән эш итәргә булыша, фирмаларга үз акцияләрен һәм облигацияләрен сатуны оештыруда ярдәм итә, валюта сату-алу базарын төзи, кыйммәтле әйберләрне саклау өчен сейфлар бирә («сейфинг» хезмәте күрсәтә) һ.б.

Шулай итеп, банклар ил гражданнары өчен күмәк «туплагыч» («копилка») ролен башкара. Алар үз гарантияләрен биреп (ышандырып) гражданнарның саклык акчаларын үзләрендә туплыйлар. Алай булмаганда, гражданнар бу акчаларын өйдә саклап ятарлар яки ышанычнамә (расписка) белән кемгәдер бурычка биреп торырлар иде (элек шулай булган).

Әмма банклар «туплагыч» кына түгел, алар акчаларны артырга һәм хуҗаларына табыш китерергә мәҗбүр итә. Шуның белән бергә, саклык акча хуҗаларына үз средстволарын коммерция эшенә урнаштыру белән шөгыльләнеп торасы да юк — алар өчен моны банклар эшли.

Саклык акча хуҗаларына керем китерүне банклар беренче карашка бик гади икътисади механизм нигезендә тәэмин итәләр. Аның асылы түбәндәгедән гыйбарәт: банклар гражданнарның саклык акчаларын дәүләткә һәм коммерция фирмаларына (әгәр дә боларга эшчәнлекләре өчен акчалары җитмәсә) бурычка биреп тора. Мондый бурычка биреп тору кредит белән тәэмин итү (латинча *creditum* — «ссуда», «бурыч») дип атала.

Әлбәттә, бурычка биреп тору заемчылардан әлеге кредиттан файдаланган өчен түләү алу хисабына тормышка ашырыла. Бу түләүнең күпчелек өлеше саклык акча хуҗаларына процентлы керем түләүгә китә. Ә бер өлеше, аны маржа (инглизчәдән *margin* — «чик») диләр, банкларга кала һәм керемне тәшкил итә. Димәк, банк кредиты бәясе, заемчы күзлегеннән караганда, түбәндәге структурадан гыйбарәт була (6-2 рәсем):



6-2 рәсем.
Кредит бәясе структурасы

Үзләренең озак тарихы дәвамында банклар бик зур үсеш һәм камилләшү юлын уза. Нәтиҗәдә банк оешмаларының күптөрле формалары барлыкка килә. Шуның белән бергә, төрле илләрнең банк системалары еш кына үз төзелешләре буенча үзгә булалар. Банкларның төп төрләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

— **эмиссия** банклары;

— **коммерция** (депозит) банклары.

Моннан тыш, Россиядә тагын:

— **инвестиция** (кыйммәтле кәгазьләр белән операцияләр) банклары;

— **саклык** банклары;

— **махсус** банклар (тышкы сәүдә, ипотека, авыл хуҗалыгы банклары) да бар.

КОММЕРЦИЯ БАНКЫ — 1) депозитлар кабул итү; 2) ссудалар бирү; 3) исәп-хисап эшләрен оештыру; 4) кыйммәтле кәгазьләр сату һәм алу эшчәнлеген алып баручы финанс оешмасы.

ЭМИССИЯ БАНКЫ — илнең акча берәмлекләрен чыгару (эмиссия) һәм шул илдә акча әйләнешен көйләү хокукына ия булган банк.

6-3 рәсемдә дөньяның алдынгы илләрендәге хәзерге заман банк системалары моделе күрсәтелгән.

6-3 рәсем.
Хәзерге заман милли банк системалары структурасы

Кагыйдә буларак, эмиссия банклары яки бер (дәүләт, үзәк банкы), яки берничә була, алар бу функцияне дәүләт исеменнән алып бара. Россиядә дәүләткә карауны Россия Үзәк банкы гына эмиссия банкы була ала. Ул хосусый затларга һәм фирмаларга хезмәт күрсәтми, дәүләт һәм коммерция банклары белән генә эш алып бара (Россия Үзәк банкы эшчәнлеге белән танышa башлагач, без бу хакта җентеклерәк итеп сөйләрбез).

Барлык башка банклар коммерция банклары рәтенә кертеп карала. Алар тулысынча хосусый булырга яки дәүләт аларда милектәш булып торырга мөмкин (мәсәлән, Россия саклык банкы — хосусый акционерлык коммерция банкы, әмма аның акцияләренең иң эре пакеты дәүләт кулында).

Формалары буенча банклар:

— хосусый-индивидуаль;
— акционерлык;
— кооператив;
— муниципаль;
— федераль;
— катнаш милек;
— вак дәүләт банкларына бүлеп карала (МБРР, ЕБРР һ.б.).

Хәзер без коммерция фирмасының **банк** дигән төренә тулы билгеләмә бирә алабыз.

БАНК — 1) депозитлар кабул иту; 2) ссудалар бирү; 3) исәп-хисап эшләрен оештыру; 4) кыйммәтле кәгазьләрне сату һәм алу эшчәнлеген башкаручы финанс оешмасы.

§ 12. Кредит белән тәэмин итү принциплары

Кредит белән тәэмин итүнең акча средстволарын вакытлыча һәм түләү шарты белән файдалануга биреп тору икәнлеген без ачыкладык инде. Әмма бу гади генә билгеләмәдә банкир эшен иң катлаулы һөнәргә әйләндерүче дөнья кадәр проблема яшеренгән. Кредит бирүнең үз кагыйдәләре һәм нормалары бар, әмма без монда аның иң мөһим принциплары һәм иң киң таралган формалары белән генә танышырбыз.

Әгәр дә бу принципларны бик кыска гына итеп тезсәк, алар түбәндәгечә булыр:

— срoклы булу;
— түләүле булу;
— кире кайтаручанлык;
— гарантиялелек;
— максатчанлык.

Срoклылык. Банкның үзен оештыручылар салган акчаның һәм аннан соң банк алган табыш хисабына тупланган акчаның бер өлеше (кечкенә өлеше) генә аның милке була.

Әмма банклар кредит бирү өчен үз средстволарын гына түгел, ә сакларга салучылар акчаларын да файдаланалар. Мәсәлән, 1995 елда күпчелек иң эре Россия банкларының үз акчалары «эшләүче» акчаларның гомуми суммасында, кагыйдә буларак, бары тик 13—26% ны гына тәшкил итә.

Шулай итеп, кредит бирү өчен төп чыганак булып акча кертүчеләрнең **депозитлары** кала.

Депозитлар ике төрле була:

1) **таләп ителгәнгә кадәрге депозитлар (агымдагы счетлар)** — акча кертүче үз акчасын теләсә кайсы вакытта килеп ала;

2) **срокл ы депозитлар** — акча кертүче үз акчасын билгеле бер вакыт үтмичә сорап алмаска вәгъдә бирә.

Шулай булгач, банк та үз карамагына тапшырылган акчаларны билгеле бер вакытка гына әйләнешкә кертә ала һәм ул вакыт акча кертүче рөхсәт иткән вакыттан артырга тиеш түгел. Шуңа күрә кредитлар һәрвакыт билгеле бер вакытка гына бирелә. Әгәр дә бурычка алучы акчаны **кредит шартнамәсендә** күрсәтелгән датада кире кайтармаса, банк аннан акчасын яки мөлкәтен суд аша тартып ала, яки кредитны каплау вакытын бозган өчен штраф ала башлый.

***ДЕПОЗИТЛАР** — акча хуҗаларының банкка вакытлыча саклау өчен тапшырылган барлык төр акча средстволары. Шулай ук алар банкка бу акчаларны кемнәргәдер кредитка бирү хокукын да бирәләр.*

***КРЕДИТ ШАРТНАМӘСЕ** — банк һәм аннан акча алып торучы (заемчы) арасында төзелгән, ике якның да бурыч һәм хокукларын, барыннан да элек кредит белән тәэмин итү срогын, аннан файдаланган өчен түләүне һәм банкка акчаны кире кайтару гарантияләрен билгеләүче килешү.*

Түләүле булу. Әлбәттә, кешеләр, акчаларын ышанычлы итеп саклау өчен, элек-электән банк хезмәтеннән файдаланганнар. Халыкара кулланышка кергән һәм инглиз телендә «банкларда кыйммәтле әйберләрне саклау өчен хезмәт итүче» дигән мәгънәне белдерүче «сейф» сүзенә «куркынычсыз, ышанычлы» дигән тагын бер мәгънә юкка гына хас түгел.

Шуңа күрә дә банклар акчаны вакытлыча файдалануга бары тик моның өчен түләү шарты белән генә бирөп торалар, бу «кредит проценты» дип атала. Бу түләү, гадәттә, кредит суммасына карата процентларда һәм заем средстволарын 1 ел файдаланганнан чыгып исәпләнә.

Димәк, әгәр дә сез банктан ярты елга 10 млн сум акчаны елга 10 % исәбеннән алсагыз, сез 10 млн сум × (1 + 0,1 : 2) = 10 × 1,05 =10,5 млн сум акча кире кайтарырга тиеш буласыз.

Башкача әйтсәк, кредиттан файдаланган өчен банкка түләү 0,5 млн сум тәшкил итәчәк.

Кредит өчен процент күләме капитал базары эшчәнлегенең гомуми закончалыклары белән билгеләнә (бу турыда 7 бүлектә сөйләнде инде). Шуңа күрә бары тик шунысын гына искә төшерик: тагы да күбрәк вакытка алган ссудалар өчен процент күләме (ставкасы) тагы да югарырак булачак: чөнки мондый ссудаларны шундый ук озак сроклы депозитлар белән тәэмин итәргә туры килә. Шуның белән бергә, озак вакытка салынган озак сроклы депозитлар буенча, акча салучылар (вкладчики) үз керемнәрен дә югарырак процентттан исәпләүләрен

таләп итәләр, һәм банклар да акчалы булу өчен моның белән килешергә мәҗбүр булалар.

Мәсәлән, 2004 елның декабрендә «Импэксбанк» үз акчаларын аңа салырга әзер булган россиялеләргә керемнең түбәндәге вариантларын тәкъдим итә:

Кертем (вклад) срогы	Процент күләме (ставкасы)
181 көн	11,0
271 көн	11,4
12 ай	11,5
18 ай	11,7
24 ай	12,0

Әлбәттә, үзләренә җәлеп ителгән озак сроклы средстволарның мондый югары кыйммәтен барлык банклар да заемчылар җилкәсенә өя (әле шуның өстенә без алда әйтеп үткән маржаны — үз керемен формалаштыру өчен өстәмә түләүне дә билгели). Шулай итеп, 2004 елның декабрендә заемчы «Импэксбанк»тан рубльләрдә (сумнарда) исәпләнүче кредитны елга 12 % тан кимрәк итеп ала алмый.

КРЕДИТ КАЙТАРУ СӘЛӘТЕ — заемчының (акча алып торучының) кредит шартнамәсе буенча үз йөкләмәләрен вакытында үти алуы, ягъни төп заем суммасын кире кайтару һәм аның буенча процентлар түләү мөмкинлеге булу.

Кире кайтаручанлык. Кредит бирүнең бу принципы катлаулы түгел: кредиттан файдалануның вакыты бар һәм ул тиешле вакытта кайтарылырга тиеш. Әмма банкның үзе өчен бу принципны саклау заемчыларны бәяләү, төгәлрәк әйтсәк, аларның **кредит кайтару сәләтен** билгеләү кебек бик четерекле эш башкаруын таләп итә.

Заемчының кредит кайтару сәләтен бәяләү өчен, банклар аларның матди хәлләре һәм коммерция операцияләре турындагы икътисади мәгълүматка махсус анализ үткәрәләр. Мәсәлән, танылган Америка агентлыгы «Дан энд Брэдстрит» кредиторлар өчен заемчы коммерция оешмасы турында йөзләгән параметр буенча мәгълүматлар туплый. Алар арасында хәтта бу фирмаларның җитәкчеләре биографиясендәге кара таплар һәм аларның тискәре гадәтләре хакындагы четерекле мәгълүматлар да була. Болар барысы закон кысаларында эшләнә, һәм һәр кызыксынган зат үзе турында агентлык хәбәр иткән мәгълүматны соратып алырга, әгәр дә ул дөрес булмаса, аны суд аша кире кагырга мөмкин.

Гарантиялелек. Белүебезчә, банклар күбесенчә акча салучылар ышанып тапшырган акчаны бурычка биреп тора. Бу акчаларны югалтулардан саклау өчен, банклар заемчының кире кайтару сәләтен тикшерү белән беррәттән, саклануның тагын бер юлын уйлап тапканнар. Алар заемчыдан саткан очракта, аның кредитын кире кайтаруны тәэмин итәрлек милке булу турындагы дәлилләр китерүен, яки хәтта аны **залогка** салуын таләп итәләр.

ЗАЛОГ — заемчының (бурычка акча алучының) үз бурычын кайтара алмау очрагын истә тотып, аның тарафыннан банк контроленә яки карамагына сатарга рөхсәт итеп тапшырылган милке.

Мәсәлән, коммерция фирмасы үз кибете өчен товарлар алырга дип банктан ссуда сорый. Бу очракта банк әлеге товарларның ссуда буенча залог буларак теркәлүен һәм хәтта аның хезмәткәрләре контроле астына тапшырылуын таләп итә ала. Әгәр дә фирма бурычын вакытында түли алмаса, банк аның бу товарларын үзенә алырга һәм, түләргә сәләтсез заемчы аркасында килеп чыккан югалтуларын каплау өчен, аларны мөстәкыйль рәвештә үзе сатарга мөмкин. Һәрхәлдә, кредит һәрвакыт залогны сатудан алыначак керемгә караганда азрак суммада бирелә. Монда товарларның начар сатылып, аларның бәяләрен төшерү ихтималы истә тотыла.

Мәсәлән, торак алырга кредит (ипотека кредитлары) биреп, Россия банклары заемчы кредит хисабына алган фатирны үзләренә алу хокукын шартнамәдә искәртәләр. Шулай итеп, банк залогка салынган фатирны яна хуҗага сатып җибәрергә һәм акча салучыларның беренче эшлексез заемчыга кредит итеп бирелгән акчаларын кире кайтарырга мөмкин.

§ 13. Илнең кредит-акча системасын көйләүдә Үзәк банкның роле

Дөньяның күпчелек илләрендәге баш (эмиссия) банк хәзер 5 төп функцияне башкара:

1) дәүләт таләбе белән акча чыгара (эмиссия);

2) «банклар банкы» буларак эшли, ягъни коммерция банкларының акча резервларын саклый һәм аларга кирәк булганда ссудалар бирә (соңгы инстанция кредиторы), шулай ук дәүләт исеменнән алар эшчәнлегенә күзәтчелек итә;

3) хөкүмәт банкиры ролен башкара, чөнки фонд базарында ул сату итә, дәүләтнең кыйммәтле кәгазьләрен (дәүләт облигацияләрен) урнаштыра, аеруча зарур очракларда хөкүмәткә кредитлар бирә, хөкүмәт һәм дәүләтнеке булган барлык оешмалар өчен исәп-хисап операцияләре алып бара, дәүләт казначылыгының акча операцияләрен алып бара, дәүләт резервларын кыйммәтле металларда һәм ирекле конверсияләнүче валютада саклый;

4) илнең коммерция банкларына үзара һәм клиентлары таләпләре буенча алып барылган операцияләрдә исәп-хисап эшләрен тормышка ашыруда булышып, илдә акчалата булмаган (безналичный) акча әйләнешенең төп оештыручысына әверелә;

5) акча-кредит операцияләрен көйли һәм илдәге коммерция банкларының ничек итеп законнарны үтәвенә күзәтчелек итә.

ДӘҮЛӘТ КАЗНАЧЫЛЫГЫ — дәүләт идарәсе тармаклары (ведомстволар) тарафыннан сарыф ителүче чыгымнарны түләүне оештыручы һәм дәүләт керемен кабул итүче акча средстволарын кабул итүче дәүләт оешмасы.

Россия Федерациясе Үзәк банкы эшчәнлегенең төп максатлары да нәкъ шулар белән бәйләнгән (6-4 рәсем). Безнең милли банк:

1) рубльне (сумны) сакларга һәм ныклыгын тәэмин итәргә;

2) илнең банк системасын үстерергә һәм ныгытырга;

3) түләү системасының нәтиҗәле һәм тоткарлыксыз эшләвен тәэмин итәргә тиеш.

6-4 рәсем.
Россия Үзәк банкы эшчәнлегенең төп бурычлары

Билгеләп үтик: һәр илдәге үзәк (дәүләт) банклар гражданнарга, фирмаларга хезмәт күрсәтмәсә дә, алар үзләре коммерция эшчәнлеге җәелдерәләр һәм хәтта табыш та алалар. Бу Үзәк банкның процентлы керем алуы хисабына мөмкин була. Керемне ул түбәндәге юллар белән ала:

1) ул үз средстволарын коммерция банкларына кредитка биреп тора;

2) үз илләренең алтын валюталары резервларын чит хөкүмәтләрнең кыйммәтле кәгазьләренә салып, кыйммәтле кәгазьләр белән сату-алу операцияләре үткәрәләр;

3) валюта базарында валюта сатып алалар һәм саталар.

Үзәк банк икътисад белән идарә итүче дәүләт аппаратының бер кисәген тәшкил итә. Шул ук вакытта законнар (шулай ук Россия законнары да) аның башкарма хакимияттән бәйсезлеген (ҮБ рәисе ил премьер-министрына буйсынмый) һәм закон чыгару хакимияте белән ил президенты алдында гына җавап тотуын нигезли.

Үзәк банк дәүләтнең икътисадны көйләү буенча кайбер функцияләрен башкара. Бу өлкәдә аның төп бурычлары түбәндәгеләр:

1) коммерция банклары оешуын һәм эшчәнлеген контрольдә тоту. Әлеге контроль банк системасы тотрыклылыгын тәэмин итүдән һәм банкларны артык хәтәр операцияләрдән саклап калудан гыйбарәт;

2) милли һәм чит ил валюталары белән акча операцияләре кагыйдәләрен билгеләү. Безнең илдә чит ил валютасын сатып алу һәм сату кагыйдәләрен һәм аны хуҗалык эшчәнлегендә файдалану чикләрен Россия ҮБ билгели;

3) коммерция банкларының кредитлар бирү күләмен көйләү;

4) илдәге инфляция темпларын тиешле күләмдә киметү чараларын үткәрү.

Без инфляция турында берничә тапкыр искә төшердек. Нәрсә соң ул? Бу термин беренче тапкыр Төньяк Америкада узган гражданнар сугышы вакытында (1861—1865) кәгазь акча әйләнеше арту процессын билгеләү өчен кулланыла.

ИНФЛЯЦИЯ — акча берәмлегенең телә̆сә нинди рәвештә бәясе төшү, ягъни сәбәпләре нинди булуга карамастан, икътисадта даими төстә бәяләр үсеше.

Илнең инфляция сукмагына килеп керүе сатыла торган товарларның барысына да берьюлы бәяләр артуны аңлатмый. Аларның кайберләренә, мәсәлән, сорау аз булган яки базарда әле сатыла гына башлаган товарларга бәя хәтта төшәргә дә мөмкин. Шулай да инфляция вакытында күпчелек товарларның бәяләре арта һәм **акчаның сатып алу сәләте** кими.

Инфляциянең берничә сәбәбе бар һәм инфляция үзе дә төрле була.

Сорау инфляциясе булганда, кешеләр, коммерция фирмалары һәм хөкүмәт, кайбер сәбәпләр аркасында, илдә җитештерелгән товарларга караганда күбрәк акча тоталар. Башкача әйтсәк, сорау товарларны тәкъдим итүгә караганда күбрәк булып чыга, ә бу исә котылгысыз рәвештә бәяләр артуга китерә, бу очракта бәяләрнең гомуми зурлыгы артуга, ягъни инфляциягә китерә. Икътисадчылар бу ситуацияне: «Бик күп акча бик аз товарны аулый»,— дигән тасвирлама белән сурәтлиләр.

Сорау инфляциясе безнең илдә дә мәгълүм. Ул монда планлы-командачыл система яшәгән зур бер период дәвамында саклана. Әмма аның чагылышы үзенчәлекле була. Гәрчә барлык бәяләр дә катгый рәвештә дәүләт тарафыннан билгеләнсә дә, артык акчалар турыдан-туры товарлар кыйбатлануга китерми. Һәм монда инфляция канәгатьләндерелмәгән сорау артуга этәрә.

Чыгымнар инфляциясе дә җиңелләрдән түгел. Бу вакытта бәяләр куллану товарлары җитештерү өчен сатып алыначак ресурслар кыйммәтләнүгә карап арта. Мондый «бәяләр — чыгымнар» спирален «ваклап сату — хезмәт хакы» бәйләнеше мисалында күрергә мөмкин.

Әгәр дә ваклап сату бәяләре арта икән, хезмәт хакының сатып алу сәләте кими һәм хезмәткәрләр басымы астында аны күтәрергә туры килә. Чыгымнарның болай артуын бәяләрне арттыру хисабына капларга кирәк була. Нәтиҗәдә бәяләр арту үзен этәргеч рәвеш ала һәм аның тизлеге һаман арта бара.

Хезмәт җитештерүчәнлегенә караганда тизрәк үскән хезмәт хакы белән беррәттән, ресурслар саклагыч җитештерү технологияләрен кертү темпларыннан тизрәк баручы материаллар һәм энергия кыйбатлану да еш кына чыгымнар инфляциясе сәбәбе булып әверелә.

Барлык бу проблемалар ил **гиперинфляция** сукмагына килеп кергәч, тагы да җитдирәк рәвеш ала.

XX гасырда гиперинфляция кичергән илләр арасында булган Германиядә 20 нче елларда бәяләр сәгатенә 10% ка арта, ә Боливиядә 80 нче елларда бәяләрнең гомуми күләме бер елга 80 тапкыр арта!

XX гасырның инфляция тәҗрибәсе күрсәткәнчә, гиперинфляция сукмагына килеп кергән илне гаять авыр социаль һәм сәяси бәлаләр көтә.

Гиперинфляция икътисадны үзеннән-үзе юкка чыгармый. Ил мондый халәттә дә берникадәр вакыт яши ала. Әмма ул икътисадның бүтенге уңышлы эшчәнлеге һәм киләчәктәге үсеше өчен зарур булган мөһим механизмнарны какшата. Бу очракта без сәүдә итү, акча туплау һәм аларны икътисад үсешенә салу (инвестицияләү) механизмнарын күз алдында тотабыз.

Эш шунда ки, гиперинфляция вакытында бернинди сәүдә килешүләре дә бәяләр үсешен куып җитә алмый. Товар сатылган арада, аның киләчәк партиясен алуга (җитештерүгә) киткән чыгымнар шулкадәр арта ки, кергән төшемнәр (выручка) аларны капларга җитми инде. Бәясе төшкән акчаларга ул товарларны сату түгел, ә турыдан-туры башка товарларга алыштыру файдалырак була бара. Уңай гына барган сәүдәгә үз кимчелекләре белән бартер алмашка килә.

Аңлаешлы сәбәпләр аркасында, саклык акчалар да «үлә» бара. Әмма кешеләр һәм фирмалар саклык акча тупламыйлар, ә барлык керемнәрен, шундук юкка чыгаралар икән, үзләре өчен һәм җитештерү өчен кирәкле кыйммәтле товарлар сатып алуга кирәкле эре суммалар туплый алмаячаклар. Димәк, яңа предприятиеләр төзү яки эшләүче заводларда иске һәм тузган эш коралларын яңага алыштыру мөмкинлеге калмый дигән сүз.

Шуңа күрә зур инфляция, аеруча гиперинфляция вакытында предприятиеләр һәм коммерция оешмалары үзләренең озак сроклы һәм эре проектларын тормышка ашыру өчен акча таба алмыйлар. Аларга озак вакытлы бурычны яки бөтенләй бирмиләр (1992—2000 елларда Россия банклары өч айдан да артык вакытка акча биреп тормыйлар), яки акча биреп торган өчен түләп булмаслык зур суммалардагы процентлар таләп итәләр.

Шул сәбәпле предприятиеләр һәм фирмалар хезмәт коралларын һәм җиһазларын яхшы хәлдә саклау һәм яңарту, шулай ук яңа продукция үзләштерү яки үз эшчәнлекләре колачын киңәйтү мөмкинлегеннән коры калалар. Сәүдә һәм җитештерүнең җимерелүе дәвам итә.

Ил икътисадның алга үсеше нигезен юкка чыгарып, үз киләчәген «ашап бетерә». Өстәвенә инфляция бик авыр социаль нәтиҗәләргә китерә, ягъни күпчелек халыкның яшәү шартларына тискәре йогынты ясый. Без инде инфляциянең керемнәр һәм саклык акчаларга йогынтысы турында сөйләгән идек, әмма һәр ил гражданы өчен дә инфляция зур бәла булып әверелә, чөнки:

— инфляция кешеләрнең хезмәт эшчәнлеге белән кызыксынуын киметә, чөнки бәяләр хезмәт хакына караганда тизрәк арта, һәм аласы керемнәрнең бәясе төшә бара — аларга бик аз әйбер генә сатып алып була;

— инфляция шартларында керемнәр дифференциациясе проблемасы көчәя, чөнки хәллерәк гражданнар — бизнес хуҗалары — үз керемнәрен арттыруда инфляция темпларыннан бер дә калышмый, ә кайбер очракларда аны уздырып та җибәрә, ә ярлырак гражданнарның керемнәре инфляциягә караганда акрынрак үсә, ә бу хәл бай һәм ярлы гражданнар арасындагы каршылыкларны кискенләштерә һәм илнең сәяси тотрыклылыгына яный.

Инфляциянең әлеге нәтиҗәләре җәмгыятьтәге гомуми социаль-икътисади тотрыксызлыкны тагын да кискенләштерә.

90 нчы елларның беренче яртысында Россиядә нәкъ шундый вазгыять урнаша. Ил авыр инвестицион ачлык хәлендә кала. Сәнәгатьне һәм икътисадның башка өлкәләрен коткару өчен, инфляцияне тиз арада шактый киметергә һәм инвестицияләрне яңарту шартларын тудырырга кирәк була.

Россия хөкүмәтенә моның өчен ике ел таләп итеЛә (1994 ел ахырыннан алып 1996 елның җәенә кадәр). Хәлбуки, хәтта 2004 елда да инфляцияне 12% тан да киметү мөмкин булмый. Инфляцияне актив төстә киметү еш кына житештерүнең кимүе һәм башка авыр икътисади нәтиҗәләр белән үрелеп бару аркасында, Россиядәге инфляциягә каршы сәясәт, аерым алганда, банк системасының дәвамлы кризисына китерә.

Бәяләр арту һәм акча агымы шартларында эшләргә өйрәнгән күп кенә банкларның, кими баручы инфляция шартларына яраклаша алмыйча, «көймәләре комга терәлә». Алар үз йөкләмәләре буенча түли алмыйлар һәм бөләләр, шулай итеп, күп кенә гаиләләрне һәм фирмаларны саклык акчаларыннан коры калдыралар.

ҮБ инфляцияне акрынайту бурычын ничек хәл итә соң? Ул иң элек базардан вакытлыча артык акчаларны «суыртырга» һәм шулай итеп, бәяләр үсешен акрынайтырга тырыша. Моның ничек эшләнүе 6-5 рәсемендә күрсәтелгән.

6-5 рәсем.
Россия ҮБның инфляциягә каршы көрәш ысуллары

Беренче ысулны ҮБ илнең валюта базарында чит ил валютасын күбрәк сата башлап гамәлгә ашыра. Чит ил валютасын фирмалар һәм гражданнарга сату өчен алган банк аларны рубльләргә сатып ала һәм икътисадта рубльләр азая, сорау кими һәм бәяләр арту акрыная төшә.

Икенче ысул беренчесенә охшаган: ҮБ, кирәк чакта хөкүмәт белән килешеп, банкларга дәүләтнең керемле кыйммәтле кәгазьләрен сатуны арттыра һәм шуның белән икътисадтагы рубль массасы кыскаруга этәргеч ясый.

Өченче ысул вакытында ҮБ коммерция банкларына аларның вакытлыча ирекле акча средстволарын үзендәге депозитларга салырга тәкъдим итә һәм бу депозитлар буенча элеккегә караганда күбрәк керем вәгъдә итә. Бу очракта банклар акчаларын ҮБда урнаштыралар һәм аларның кредит бирү мөмкинлекләре кими, димәк, әйләнештәге акча массасы азая һәм бәяләр арту акрыная төшә. ҮБ исә, банклардан акча алып, аларның бер өлешен хәрәкәтсез калдыра, ә икенче өлешен бурычка бирә, әмма бик зур процентлар куя һәм аны түләргә ашкынып торучылар «арзан» акчалар биргәндәгегә караганда әллә ни күп булмый.

Һәм, ниһаять, ҮБның инфляциягә каршы көрәш ысулларыннан дүртенчесе — административ ысул. Бу ысулны кулланганда ҮБ коммерция банкларыннан алар җыйган акча средстволарының бер өлешен ҮБның махсус резерв счетларына салуларын таләп итә, моңа аның законлы хокукы бар. Әлеге механизм илдәге бөтен банк системасының ышанычлылыгын күтәрергә, банкларны банкротлыктан саклап калырга, димәк, аңа акча салучыларның акчаларын югалту куркынычын бетерергә мөмкинлек бирә. Әмма резервлар бәясе зурлыгын инде закон билгеләми, бу эш ҮБ карамагына тапшырыла. Шуңа күрә дә инфляция тизләнгәндә, ҮБ коммерция банклары җыйган акчаларның күбрәк өлешен үзендә резерв итеп салуларын таләп итә. Нәтиҗәдә әйләнештәге акча массасы кими һәм инфляция акрыная.

Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, без икътисади акыллылык рецептының алтынчысын төзи алабыз.

Алтынчы рецепт

Һәр ил, бер яктан, бартер үсешен китереп чыгармас өчен һәм, икенче яктан, инфляция үсешен тоткарлау өчен, үз банк системасын һәм акча әйләнешен катгый контрольдә тотарга тиеш.

БҮЛЕКНЕҢ ТӨП ЭЧТӘЛЕГЕ

Банклар барлыкка килү сәбәпләре. *Банклар бик борынгы заманнарда ук үзенчәлекле хезмәт күрсәтүләр буенча махсуслашкан фирмалар кебек барлыкка килгән. Әлеге хезмәт күрсәтүләр туплаган акчаларны саклаудан һәм кредитлар бирүдән гыйбарәт. Вакытлар узу белән, банклар ил эчендә һәм дөнья базарында сатыла һәм сатып алына торган товарлар өчен исәп-хисапны оештыру белән бәйләнешле эшчәнлекне дә үзләштерә. Һәм бу түләүләрне тизләтергә һәм аларның ышанычлылыгын арттырырга мөмкинлек бирә, ә бу исә сәүдә үсешенә һәм дөнья икътисадына уңай йогынты ясый. Үз хезмәтләре өчен*

банклар маржа дип аталган түләү ала. Маржа банкның үз чыгымнарын каплый һәм аның табыш алуын тәэмин итә. Банк клиентлары маржаны түләргә ризалашалар, чөнки банклар эшчәнлеге трансакция чыгымнарын һәм акчаны бурычка биреп тору хәтәрен киметә.

Кредит белән тәэмин итү принциплары. *Кредит бирү банклар эшчәнлегенең мөһим бер төрен тәшкил итә. Кредит бирүне тормышка ашырып, банклар мондый кредитның сроклылыгын, түләүле булуын, кире кайтарылуын һәм гарантияләлеген тәэмин итәргә тырыша. Кредитның вакыты банкка акча туплаучылардан алынган депозит вакытыннан бәйле була. Кредит өчен түләү зурлыгы капитал базарында акча ресурсларының бәяләре формалашуның гомуми принциплары белән билгеләнә. Кредитның кире кайтарылуы законнар һәм аларның үтәлешен контрольдә тотучы органнар ярдәмендә тормышка ашырыла. Кредитның гарантияләлеге банкларның заемчылардан аның кредитын кире кайтаруны тәэмин итәргә яки хәтта мөлкәтләрен банкка залог итеп тапшырырга таләп итүдә чагыла.*

Илнең кредит-акча системасын көйләүдә Үзәк банкның роле. *Һәр илнең Үзәк банкы — милли банк системасын контрольдә тотучы, акча әйләнешен көйләүче һәм дәүләт ихтыяҗларына хезмәт итүче дәүләт органы ул. Үзәк банк фирмалар яки гражданнар белән операцияләр алып бармый, ә ил эчендәге һәм чит илләрдәге банклар белән эш итә. Һәр Үзәк банкның төп бурычы инфляциягә каршы көрәштән гыйбарәт. Ул бу көрәшне төрле ысуллар белән тормышка ашыра. Аның берсе коммерция банкларыннан алар җыйган акча средстволарының резерв зурлыгын үзгәртүләрен таләп итүдән гыйбарәт: инфляция тизләнгәндә, бу таләпләр илдәге акча массасын кысу өчен тагын да көчәя. Инфляция кимегәндә, икътисад үз үсешен тизләтергә кредитларны күбрәк ала алсын өчен, резерв таләпләре дә кими.*

ФИКЕР АЛЫШУ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Ни өчен һәр ил үз милли банк системасын үстерү һәм ныгыту өчен кайгыртырга тиеш?
2. Ни өчен Россиядә бүген чек кенәгәләреннән беркем дә файдаланмый диярлек?
3. Ни өчен илдәге икътисади һәм сәяси тотрыклылык кредит базарында акча тәкъдим итүнең артуына һәм шуның белән аның икътисади үсешен инвестицияләү мөмкинлекләре киңәюгә китерә?

Җ И Д Е Н Ч Е Б Ү Л Е К

Кеше хезмәт базарында

БҮЛЕКТӘ КАРАЛУЧЫ МӘСЬӘЛӘЛӘР:

1. ФИРМАГА КҮПМЕ ХЕЗМӘТКӘР ЯЛЛАУ ФАЙДАЛЫ?
2. ХЕЗМӘТ ХАКЫ НӘРСӘДӘН БӘЙЛЕ?
3. КЕШЕЛӘР ЭШ УРЫННАРЫН НИ ӨЧЕН АЛЫШТЫРА?

Теге яки бу эш төре никадәр ялыктыргыч һәм кешедән никадәр күбрәк көч таләп иткән саен, кешеләр аның өчен шулкадәр күбрәк хезмәт хакы сорыйлар.

Кешенең бәясе — аның хезмәт хакы.

Инглиз мәкале

Базар эшенең гомуми механизмнары белән танышкач, без хәзер аларның аерым бер базарлар эшчәнлегендәге чагылышын өйрәнә алабыз. Мондый танышуны төп җитештерү ресурсларының (факторларының) берсе булган хезмәт базарыннан башлыйк.

§ 14. Хезмәт базарының икътисади табигате

Беренче бүлектә әйтеп үтелгәнчә, хезмәт базарында кешеләрнең акыл һәм физик сәләтләрен файдалану белән бәйле хезмәт күрсәтүләрне, шулай ук икътисади байлыклар җитештерү өчен кирәкле күнекмәләрен һәм тәҗрибәләрен саталар һәм сатып алалар. Һәр илнең икътисадында **хезмәт базарының** роле гаять зур, чөнки теләсә кайсы илнең күпчелек халкы үз хезмәтләрен сату хисабына керем ала.

Шулай итеп, хезмәт базары, үз хезмәтләрен сатарга теләүче кешеләр белән үз эшчәнлекләрен тормышка ашыру өчен, ул хезмәтләрне сатып алырга теләүче оешмаларны берләштерә. Соңгыларын, гадәттә, «эш бирүчеләр» яки «яллаучылар» дигән терминнар белән атыйлар.

***ХЕЗМӘТ БАЗАРЫ** — үз хезмәтләрен фирмаларга сатарга әзер булган кешеләр белән аларның бу хезмәтләренә хезмәт хакы һ.б. түләргә риза булган фирмалар арасындагы икътисади һәм юридик үзара мөнәсәбәтләр бәйләнеше ул.*

Хезмәт базарындагы сатучылар даирәсе гаять күптөрле. Анда җир астыннан күмер чыгару өчен ялланучы шахтер да, илнең иң шәп залларында концертлар үткәрү турында шартнамә төзүче рок-җырчы да, заказчыга кирәкле тәҗрибәләр үткәрү өчен акча алучы галим дә, аерым эшчәнлек өлкәсе белән җитәкчелек иткән өчен дәүләттән хезмәт хакы алучы министр да бар.

Аларның барысы да, хезмәт базарында эш урыны табарга өмет итеп, үз хезмәтләрен тәкъдим итәләр һәм аларның бу хезмәтләре өчен түләрләр дип ышаналар. Әмма аларның төрлесе төрле уңышка ирешә: кемдер бик җиңел генә эш урыны таба, ә кемдер айлар буе эшсез азаплана, кемдер хезмәте өчен рәхәтләнеп яшәрлек керем ала, ә кемгәдер гаиләсенә тартып-сузып кына җитәрлек хезмәт хакы түлиләр. Хезмәт базары эшен анализлап, без мондый аермаларның сәбәпләрен ачыкларга тырышырбыз.

Иң элек монда сатылучы товарның хезмәт булуын билгеләп үтик:

1) ул бик күптөрле була (официант күрсәткән хезмәт белән банкир күрсәткән хезмәт бик нык аерыла);

2) хезмәт бервакытта да кешеләрдән аерым була алмый.

Бу хезмәт базары эшчәнлегенә берничә төп үзенчәлек хас булуын күрсәтә:

1) сорау монда гомумән хезмәткә карата түгел, ә аерым төрдәге һәм катлаулылыктагы хезмәткә карата туа (мәсәлән, гомумән шофер хезмәтенә карата түгел, ә билгеле бер квалификация һәм тәҗрибәгә ия булган автобус йөртүчеләр хезмәтенә карата);

2) гомуммилли хезмәт базары белән беррәттән жирле хезмәт базарлары да эшли (мәсәлән, Иваново өлкәсе хезмәт базары яки Краснодар крае хезмәт базары). Аларда бер үк төрле хезмәткә карата сорау һәм тәкъдим чагыштырмасы бик нык аерылырга мөмкин;

3) хезмәтләр тәкъдиме кешеләрнең башка квалификация үзләштереп, профессияләрен алыштыру мөмкинлекләренә карап та үзгәрергә мөмкин.

Хезмәт базарындагы вакыйгалар үсеше анда сатучы буларак чыгыш ясаучы хезмәткә сәләтле халыкның (яки башкача әйтсәк, икътисади актив халыкның) үзен ничек тотуы белән бәйләнгән. Хезмәткә сәләтле халык дигәндә, хезмәт яшендә булып, үз хезмәтләрен сата алучы һәм сатарга теләүче кешеләрне күз алдында тоталар.

Мәсәлән, һәр илнең хезмәткә сәләтле халкы мобильлеге никадәр зуррак булган саен, хезмәт базары да шулкадәр жинелрәк жайга салына һәм шулкадәр яхшырак та үсә. Мобильлек ике төрле була:

1) профессиональ;

2) территориаль.

Хезмәт ияләренең *профессиональ мобильлеге* дигәндә, кешенең гомере буена төрле профессияләр үзләштерү һәм башка эшләргә өйрәнү сәләте күз алдында тотыла. Әлбәттә, кеше мондый адымга нәрсәдер мәжбүр иткәндә яки үзе өчен керемле булганда гына бара. Сәнәгатьләре алга киткән илләрдә хәтта югары белемле кешеләрнең дә профессияләрен алыштыру очраклары шактый күзәтелә. Алар янадан студент эскәмиясенә утыралар һәм яхшырак хезмәт шартлары хас булган яңа һөнәрләр үзләштерәләр. Бүгенге Россиядә дә энә шундый хәл күзәтелә. Мәсәлән, 1992—1993 елларда бездә бухгалтерлык курслары күбәеп китте. Фәнни-тикшеренү институтларының, төрле дәүләт конторaларының, конструкторлык бюроларының бихисап хезмәткәрләре янадан укырга дип шул курсларга агылды.

Хезмәткә сәләтле халыкның *территориаль мобильлеге* дигәндә, кешеләрнең эш алу өчен яшәү урыннарын алыштырырга әзер һәм сәләтле булуын күз алдында тоталар.

Мәсәлән, Америка эшчеләре һәм хезмәткәрләре үз гомерләрендә 10 тапкыр (һәм аннан да күбрәк) эш урыннарын алыштыралар, шуның аркасында бер урында эшләү вакыты бу илдә уртача 3,6 елга гына кала.

Эш монда америкалыларның тиктормас холкында гына түгел. Дөньяның һәрбер илендә күпчелек яллы хезмәткәрләр, үзләренең шушы ук эше өчен күбрәк түләнә торган урын эзләп, «як-якка карaналар».

Мондый акыл белән уйлап эш итү барлык ил халыкларына, хәтта гомер буена ялланып эшләү традицияләрендә тәрбияләнгән һәм хезмәт хаклары эш стажыннан турыдан-туры бәйле булган японнарга да хас. Менә әле күптән түгел генә Япониядә эш куллары житешми башлады һәм башка фирмаларда югарырак хезмәт хакы алу мөмкинлеге туды. Һәм Кояш Чыгышы Илендә яшәүчеләр нәкъ америкалылар кебек адымга барды. 1989 елда 3 млн япон кешесе иске эш урынын ташлый, ә сорашулар күрсәткәнчә, 20 дән алып 29 яшькәчә булган 41% ир-ат эш урынын алыштыру нияте булуын белдерә.

Инде хезмәт базарында нәрсә сатылуы һәм сатучыларның үз-үзләрен тотышындагы үзенчәлекләр белән танышкач, хезмәт базарының ничек эшләве һәм анда хезмәткә базар бәясе — **хезмәт хакы ставкасы** ничек формалашу мәсьәләсенә күчик.

Иң элек шуңа игътибар итик: хезмәт базары ул — беренчел сорау базары түгел (мондые белән без товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр базарында очрашабыз), ә **өстәмә сорау** базары.

ХЕЗМӘТ ХАКЫ — хезмәткәргә билгеле бер вакыт эчендә (сәгать, смена, ай) куелган хезмәте яки билгеле бер күләмдәге эшне башкаруы өчен зарур булган (мәсәлән, бер детальне әзерләү өчен) хезмәтенә түләнә торган акча суммасы.

ӨСТӘМӘ СОРАУ ЯКИ ҖИТЕШТЕРҮ СОРАВЫ — товарлар җитештерүдә һәм хезмәт күрсәтүләрне оештыруда җитештерү факторларын куллану зарурлыгы аркасында аларга карата барлыкка килгән сорау.

Эш шунда ки, хәтта иң квалификацияле хезмәткәрнең дә (мәсәлән, токарь яки парикмахерның) хезмәткә сәләте тик торганнан гына беркемгә дә кирәк түгел. Аны турыдан-туры файдаланып булмый. Хезмәт вакыты һәм һәртөрле эш күнекмәләре базарда соралучы товар җитештерү һәм хезмәт күрсәтүләрне оештыру өчен кирәк булганда гына, базарны кызыксындырырлык товарга әвереләчәк! Башкача әйтсәк, токарьның хезмәткә сәләте хезмәт базарында аңа сорау булган очракта гына сатылачак. Иң оста парикмахер да кешеләр ул күрсәткән хезмәт өчен түләргә әзер булган очракта гына хезмәт урынына ия булачак.

Шуңа күрә дә эш ала алырлык (үз вакытларын һәм күнекмәләрен сата алырлык) хезмәткәрләр саны турыдан-туры икътисадтагы хәлләр торышыннан бәйле була. 7-1 рәсемендә нәкъ шушылар сурәтләнгән дә.

Рәсемнән күренгәнчә, базардагы хәл «Сорау-1» кәкре сызыгы белән билгеләнсә, хезмәттә мәшгульлек 9 шартлы хезмәткәрдән гыйбарәт булачак («Сатулар күләме» дигән сызык астында сурәтләнгән фигуралар). Әгәр дә инде товарларга сорау артса (сорауны күрсәтүче кәкре сызык уң якка югарыга таба «Сорау-2» торышына кадәр күчсә), товарларны күбрәк сатып булачак. Аларны чыгару өчен дә күбрәк



7-1 рәсем.
Товар базарлары һәм мәшгульлек арасындагы бәйләнеш

хезмәткәр кирәк булачак. Нәтиҗәдә тагын 4 шартлы хезмәткәр эш алачак һәм гомуми мәшгульлек 13 кешегә житәчәк.

Бу рәсемдә күрсәтелгән башка 9 шартлы хезмәткәр өчен эш булмаячак. Аларның вакытын һәм күнекмәләрен файдаланып житештерелгән товарлар күләме базарда соралмаячак. Димәк, аларның хезмәт мөмкинлекләре җәмгыятькә кирәк түгел дигән сүз (бу — эшсезлекнең төп сәбәбе, моның турында без алдарак сүз алып барырбыз).

Хезмәт базарындагы өстәмә сорау андагы хәлнең товар базарындагы эшләр торышыннан бәйлелеген китереп чыгара, ягъни андагы (хезмәт базарындагы) базар сәүдәсе үсешенең кысаларын билгели.

Хәзер инде бу базарда тәкъдим ничек формалашу белән танышып үтик. Тәкъдим дигәндә, без төрле факторлар йогынтысында теге яки бу эшкә тотынырга әзер торган кешеләрне (кешеләр санын) күз алдында тотарбыз (чөнки хезмәт базары чынлыкта аерым профессияләрнең күп санлы хезмәт базарыннан тора). Икътисадчылар тикшеренүләре һәм тормыш тәжрибәсе күрсәткәнчә, бу факторларның иң мөһимнәре 7-2 рәсемендә сурәтләнгән.

Хезмәт ул — кешелек яшәешенең төп шарты. Аннан башка тормыш итеп булмый. Әмма моны аңлау хезмәтне кешеләрнең физиологик ихтыяжына әвереледерми, гәрчә кайчакларда эш тә шатлык китерергә (бу аеруча ижади профессияләргә хас күренеш) яки югары бәяләнгән иҗтимагый абруйлы итәргә мөмкин (бу фактор иҗтимагый һәм сәяси эшчәнлек өлкәсендә күзәтелә).

Шулай да күпчелек кешеләр хезмәт бары тик керем китергәнгә һәм, иң мөһиме, тормыш итүгә кирәкле чараларны алу мөмкинлеге биргәнгә генә хезмәт

7-2 рәсем.
Хезмәт базарында тәкъдим формалаштыру факторлары

эшчәнлеге алып баралар. Моннан хезмәт өчен алырга мөмкин булган түләү хезмәт эшчәнлегенә этәрүче төп кызыксындыручы чара дигән нәтиҗә чыгарабыз. Хезмәт хакы алыр өчен үз көчеңне һәм вакытыңны сарыф итү зарурлыгы кешене рәхәтлекләрдән баш тартып эшкә ялланырга этәрә. Түләү никадәр югарырак булган саен, кеше бу хезмәткә шулкадәр теләбрәк алына.

Әмма моны белеп кенә, без кешеләрнең хезмәт базарындагы гамәлләре логикасын тулаем аңлый алмабыз. Моның өчен безгә кешеләрдә хезмәткә салкын караш барлыкка килү сәбәбен төшенү зарур.

Искә төшерик: икътисадта һәр сайлап алуның үз бәясе бар. Эшкә барганда, без сайлап алуыбыз өчен нинди бәя түлибез соң? Бу бәя үз күңелебезгә хуш килгән шөгыль өчен файдалана алырлык буш вакытыбызны хәзер эшләү өчен сарыф итүгә мәҗбүр булу белән исәпләнә.

Кешеләрнең хезмәт белән кызыксынуын йомшарта торган тагын бер фактор — түләү өчен башкарылырга тиешле вазифаларның **авырлыгы**. Теге яки бу эш төре никадәр ялыктыргыч булган саен, кешенең көчен дә шулкадәр күп ала, һәм кешеләр аның өчен шулкадәр үк күбрәк түләүләрен таләп итә.

Ниһаять, куйган көчеңә түләнсен өчен, уңышлы башкарылырга тиешле вазифаларның катлаулылыгы да хезмәтне тәкъдим итүгә йогынты ясый.

Хезмәтнең күп төрләрен башкару өчен моңа сәләтең булу һәм озак уку таләп ителә. Әмма мондый сәләтләр бар кешегә дә бирелмәгән һәм һөнәр алу өчен озак уку шарты белән бар кеше дә риза түгел, алар азрак уку-өйрәнүне таләп иткән эшчәнлек төрләрен кулайрак күрәләр.

Эшләргәме әллә юкмы, әгәр дә эшләсәң, нинди профессия сайларга? Шушыларны хәл иткәндә, кешеләр үзләрен гомумән хезмәттән яки аерым төр профессиональ эшчәнлек белән шөгыльләнүдән биздерүче факторларны бу хезмәт эшчәнлеге китерәчәк керем белән чагыштыралар.

Боларны белгәч, без хезмәт базарындагы тәкъдим законын төзи алабыз:

Эш бирүчеләр аерым хезмәт төре өчен никадәр күбрәк түләргә әзер булса, шулкадәр күбрәк кеше аны башкарырга әзер торачак.

Әлбәттә, бу закон түбәндәге шартларда нәкъ шулай чагылыш табачак. Әйтик, мәшһүр опера җырчыларының хезмәт хаклары гаять югары, әмма алар иртәгә театр ишеге төбенә ялгыз партияләр башкарырга теләүчеләр чираты тезелер дип бер дә борчылмыйлар. Андый җырлау сәләте һәм осталыгы бик аз кешеләргә генә бирелгән, һәм бу хәл хезмәт хакын күтәрүне үзгәртә алмый.

§ 15. Хезмәт хакы ни ул һәм нәрсәдән бәйле

Хезмәт базарында сорау һәм тәкъдимнең үзара йогынтысы базар процессларының гомуми закончалыкларына буйсына. Нәкъ шушы закончалыклар йогынтысында тигезләнешле хезмәт бәясе — аерым һөнәр ияләренең хезмәт хакы ставкасы туа.

Урнашкан хезмәт хакы ставкасы зурлыгына риза булып, теге яки бу эш төре белән шөгыльләнергә әзер кешеләр саны белән эш бирүчеләр тәкъдим итәргә әзер торган эш урыннары саны туры килсә генә, хезмәт хакы ставкасы хезмәтнең тигезләнешле бәясенә әверелә. 7-3 рәсеме нәкъ шуны күрсәтә дә инде.



7-3 рәсем.
Хезмәт базарында хезмәткә түләү зурлыгы формалашу

Товар бәяләре кебек үк, базарда формалашкан хезмәт хакы ставкасы да бик үзгәрүчән. Алай гына да түгел, аерым профессия хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү зурлыгы үзгәргән кебек, аларның кайсы тармакта яки илнең кайсы төбәгендә яшәвенә карап түләү чагыштырмалары да үзгәрә. Бу нәрсә белән бәйле соң?

Без кешеләрнең ихтыяҗлары (КИ) бик күптөрле һәм үзгәрүчән булуын ачыкладык. Шушы хәл генә дә товар базарларындагы хәлне бик нык тотрыксызландыра. Моннан тыш, башка факторлар да бар: фән һәм техника прогрессы, аерым илләр икътисадының бертигез дәрәҗәдә үсмәве, һава торышындагы көтелмәгән хәлләр һ.б.

Болар барысы төрле товарлар җитештерү колачын даими үзгәртеп тору зарурлыгын китереп чыгара. Озак сатылмый ятучы товарлар чыгаручы предприятиеләрдә күп кенә хезмәткәрләрнең кирәге калмый. Киресенчә, дефицит товарлар чыгаручылар исә өстәмә эшче кулларга һәм белгечләргә мохтаҗлык кичерә.

Бу проблеманы нәкъ әнә шул эшче көчләр мобильлегенә таянып хәл итәргә мөмкин: ул җитештерүне кыскарткан предприятиеләрдәге хезмәткәрләрнең базарга кирәк товарлар чыгаруны арттыра баручы предприятиеләргә күчү мөмкинлеген ача. Хезмәткәрләрне бер эштән икенчесенә күчерү бәяләр механизмы ярдәмендә тормышка ашырыла. Бәяләр механизмы дефицит товарлар кыйбатлануга китерә, димәк, аларны әзерләү дә табыш китерәчәк дигән сүз. Югары табышлылык исә өстәмә хезмәткәрләргә тагы да югарырак хезмәт хакы тәкъдим итәргә мөмкинлек бирә (хезмәткә булган сорауны күрсәтүче кәкре сызык уң якка югарыга таба күчә).

7-4 рәсемендә күренгәнчә, хезмәткә сорау арту хезмәте булганнар санын күбәйтү һәм шулай ук хезмәт хакы (Х) күләмен үстерү мөмкинлеген ача (Х-1 зурлыгыннан Х-2 зурлыгына кадәр).



7-4 рәсем.
Товар дефициты барлыкка килү аркасында хезмәт ресурсларына сорау артканда, хезмәт базарындагы хәлнең үзгәрүе

Башка фирмада шундый ук эш өчен югарырак хезмәт хакы тәкъдим ителүен белгәч, кешеләр эштән китәләр һәм үз эш вакытларын, күнекмәләрен юмартрак сатып алучыга саталар. Эшлеләр (мәшгульләр) саны арту дефицит продукция чыгаруны тизләтергә мөмкинлек бирә, һәм бу базар тора-бара көйләнә.

Кирәк булмаган продукция житештерүче фирмалар исә мәшгульлек колачын һәм тулаем бөтен эшчәнлекләрен кыскартырга мәҗбүр булалар. Нәтиҗәдә аларның артык товарлары таралып бетә һәм базар эше жайга салына.

Төрле һөнәр һәм тармаклар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү зурлыгы ничек формалаша соң?

Теге яки бу предприятиедә житештерелүче товарлар базарында урнашкан хәл бу процессның нигезен тәшкил итә. Шундый ук хезмәт базарындагы сорау һәм тәкъдимнең туры килүе дә шуның белән бәйләнгән һәм бу хезмәт хакын билгели.

Шуңа күрә дә эшләре уңышлы барган һәм авырлыклар кичергән фирмаларның түләүләрендәге һәм хезмәт шартларындагы аермалар хезмәт базарының мәҗбүри элементына әверелә.

Әмма әгәр дә хезмәт хакы базардагы хәлнең мондый кыска вакытлы үзгәрешләре белән генә билгеләнә икән, ахыр чиктә, бөтен профессияләр һәм тармакларда аның зурлыгы кадрларның югары хезмәт хакы артыннан куып бер предприятиедән икенчесенә агылуы аркасында бер үк төрле булыр иде. Моны тоташ савытлардагы су күләме белән чагыштырырга мөмкин. Чөнки бөтен тармаклар да шул савытлар кебек гомуммилли хезмәт базары аша үзара тоташа.

Әмма физика законнары хезмәт базарында тулысынча эшләми: тармаклар һәм профессияләр арасында, кагыйдә буларак, хезмәткә түләүнең тотрыклы аермалары да яши. Алдынгы үсешле хезмәт базарындагы мондый аермаларның колачын 7-1 таблицасына таянып күзалларга мөмкин.

Таблица 7-1

АКШ икътисады тармаклары буенча хезмәткә түләү зурлыклары (долл./сәг)

Юридик һ. б. хезмәтләр	65,6
Финанс һәм страховкалау	63,7
Казылмалар чыгару сәнәгате	59,7
Мәгълүмати хезмәтләр күрсәтү	57,2
Күпләп сәүдә итү	48,8
Эшкәртү сәнәгате	43,0
Төзелеш	38,4
Дәүләт идарәсе	36,5
Транспорт һәм склад хуҗалыгы	36,2
Күчемсез милек белән сәүдә итү һ. б. операцияләр	32,9
Медицина һәм социаль хезмәтләр	32,8
Мәгариф	32,1
Сәнгать, күңел ачу, ял	25,3
Шәһәр идарәсе һәм техник хезмәтләр	24,4
Ваклап сәүдә итү	22,7
Авыл, урман хуҗалыклары, аучылык, балыкчылык	20,2
Кунакханәләр эше һәм җәмәгать туклануы	13,7

Хезмәткә түләүдәге аермалар төп биш фактор белән билгеләнә:

1) **хезмәтнең катлаулылыгы** белән. Хезмәт вазифалары никадәр катлаулырак булган саен, аларга шулкадәр озаграк әзерләнергә, өйрәнергә кирәк. Кешеләр моңа ризалашсыннар өчен, бу хезмәттә алар куйган өстәмә көч югарырак хезмәт хакы белән компенсацияләнергә тиеш. Дөньяның күпчелек алдынгы илләрендә югары белемле кешеләргә, кагыйдә буларак, мондый белем таләп ителмәгән эшләрдә эшләүчеләргә караганда күбрәк түләнә.

Бу шулай булырга тиеш тә, чөнки белемле кешеләр хезмәт базарына күбрәк белем һәм күнекмәләр белән киләләр һәм бу аларны эшкә алучылар өчен аеруча әһәмиятле эшләр башкарырга мөмкинлек бирә. Шушы күзлектән чыгып караганда, яхшырак белем алу кешенең кызыксынучанлыгын канәгатьләндерү буларак түгел, ә үзенең — **кешенең капиталын** арттыру һәм киләчәктә хезмәтен сату өчен керемлерәк шартлар тудыру хакына куелган көче итеп карала;

2) **хезмәтнең авырлыгы** белән. Кайбер эшчеләргә инженерларга караганда күбрәк түләнә. Аларның хезмәт хаклары белгечлек буенча белем алуга куйган көчләрен генә түгел, ә кайбер төр житештерү өлкәсендәге хезмәтнең аеруча авыр булуын да истә тотып түләнергә тиеш. Шуңа күрә дә металлургия һәм химия өлкәсендә эшләүче эшчеләрнең, шулай ук шахтерларның хезмәт хаклары, гадәттә, шактый югары була;

3) **талантларның аз булуы** белән. Мәшһүр спортчыларның, рок-музыкантларның, опера жырчыларынын һәм кино йолдызларының хезмәт хаклары дөнья

күләмендә бик югары була. Мондый кешеләрнең һәрберсе, сирәк очрый торган табигый сәләтләре аркасында, хезмәт базарында «гаҗәеп товар» буларак карала. Мондый товарны «алырга» теләүче тамашачылар саны бик күп. Башкача әйтсәк, мондый «товар» сорау бик зур булса да, аның тәкъдим ителүе бик чикле. Димәк, аның таланты бәясе, ягъни аның хезмәтенә түләү дә күкләргә җитә;

4) теге яки бу эшнең **хәтәрлелек дәрәҗәсе** белән. Җәмгыятькә кирәкле эш никадәр хәтәррәк булган саен, аны башкарырга ризалашкан кешеләр шулкадәр күбрәк хезмәт хакы сорый. Бу хәл, мәсәлән, шахтерлар, очучы-сынаучылар, космонавтлар, эшмәкәрләр һәм биржа операцияләре белгечләренә түләүләрдә аермачык күренә: аларның кайберләре үз сәламәтлекләрен һәм тормышларын, ә башкалары исә килешүләргә (сделкага) салган зур суммадагы акчаларын куркыныч астына куя;

5) **дәүләтнең социаль сәясәте** белән.

Әгәр дә илнең икътисади механизмнары жайга салынган икән, хезмәт базары массакүләм профессия кешеләренә түләүдә җитди аермалар килеп чыгуга юл куймый. Мәсәлән, АКШта икътисад тармаклары буенча хезмәткә түләүдәге аерма якынча 4,8 тапкыр чамасында була.

Уңай эшләүче хезмәт базары һәм аңа хезмәт күрсәтү системалары (мәгариф һәм торак сәүдәсе) булмаган икътисадтагы хәлләр алай ук куандырырлык булмый. Монда эшче көчләрнең мобильлеге бик нык кими, ә бу исә, башка факторлар белән үрелеп, хезмәткә түләү күләмендәге икътисадтан бәйле булмаган бик зур аермаларга, ягъни хезмәт хакының чиктән тыш дифференциацияләнүенә китерә.

7-5 рәсемендә Россия икътисадында 2004 елның уртасында килеп туган нәкъ шул хәл сурәтләнгән.



Рис. 7-5.
Россия икътисады тармаклары буенча хезмәт хакы күләмнәре
(2004 ел, ноябрь, ил буенча уртача зурлыгы — 7046 сум)

Күргәнебезчә, монда хезмәткә түләү күләмнәрендәге аерма АКШка караганда күбрәк һәм ул 7,34 не тәшкил итә. Игътибар итик: хезмәт хакы күләме буенча алдынгы урыннарны ягулык сәнәгате, банклар, электр энергетикасы һәм транспорт алып тора. Банклардан тыш (монда аеруча югары керемнәрнең сәбәпләре акча массасы инфляциясе үсешеннән килгән керемнәргә никадәр якын тору белән бәйләнгән), хезмәткә түләү буенча өч лидер конкуренция иң аз булган тармакларга карый һәм андагы фирмалар сатып алучыларга югары бәяләрне бик җиңел генә тага ала.

Гомумән алганда, Россиядә хезмәт хакы күләменә базар факторлары, төгәлрәк әйтсәк, аерым профессия хезмәткәрләренә булган сорау һәм тәкъдим тирбәлеше күбрәк йогынты ясый (табл. 7-2). Мәсәлән, җитештерүче персоналның кискен җитмәүчелеге аркасында, предприятиеләр эшкә яшь белгечләрне өйрәнчек итеп ала башлыйлар һәм аларны эш барышында өйрәтәләр. Димәк, җитештерүдә белгечләргә куелган таләпләр тиешлегә караганда бераз түбәнрәк була. Әмма хәзер үк инде компанияләр мондый һөнәр ияләренә аларның хезмәт базарындагы чын хакларына караганда күбрәк хезмәт хакы түләргә әзер торалар.

Таблица 7-2

Россия белгечләренең 2003 елдагы хезмәт хакы, АКШ долл.

Белгечләр	*2003 ел*
Генераль директор	2000–8000
Сатулар буенча директор	1000–6000
Финанс директоры	1000–5000
Маркетинг директоры	1500–5000
Коммерция директоры	1000–4000
Реклама директоры	1000–4000
Персонал директоры	800–3000
IT хезмәте җитәкчесе	1500–3000
Бренд-менеджер	800–2500
Баш бухгалтер	800–2500
Программист	500–2500
PR-менеджер	800–2500
Финанс аналитигы	700–2200
Проект менеджеры	1000–2000
Юрист	500–2000
IT белгече	500–2000
Баш технолог	800–2000
Логистик	500–1800
Җитештерү башлыгы	800–1800

Персонал менеджеры	400–1500
Маркетинг менеджеры	500–1200
Система администраторы	500–1200
Инженер	400–1200
Сатулар менеджеры	400–1000
Секретарь-референт	250–1000
Реклама менеджеры	300–1000
Бухгалтер	200–800
Мерчендайзер	200–450

Чыганак: «Известия», кадрлар агентлыгы мәгълүматлары буенча (http://www.finiz.ru/cfin/tmpl-art/id_art-738708).

Гәрчә без хезмәткә түләү турында сөйләгәндә шул ук «хезмәт хакы» терминын кулллансак та, чынбарлыкта кешеләрнең хезмәтләре өчен түләүнең күптөрле юллары бар. Шул сәбәпле яллы хезмәткәрнең кереме берничә элементтан торырга мөмкин.

Аларның иң беренчесе — *төп хезмәт хакы.* Әгәр дә хезмәткәр эшкә алу турындагы шартнамәдә күрсәтелгән хезмәт вазифаларын тулысынча үтәгән очракта аңа шушы хезмәт хакы гарантияләнә. Әгәр дә хезмәткәргә бер сәбәпсез төп хезмәт хакы түләнмәсә, ул үзен эшкә алучыны судка бирә ала.

***ТӨП ХЕЗМӘТ ХАКЫ** — хезмәткәр эшкә яллаучыдан үз вазифаларын: а) хезмәтнең стандарт шартларында; б) стандарт күләмдә һәм стандарт сыйфат белән үтәгән өчен ала торган акча суммасы.*

Хезмәтнең стандарт шартлары иң элек хезмәткәрнең үз эш урынында һәм эш көнендә үткәрергә тиешле сәгатьләр саны белән билгеләнә. Гадәти эш көне тәмамланганнан соң да эшләгән очракта өстәмә түләү каралган. Әлеге түләү күләме закон белән көйләнә.

Хезмәт хакы турында сөйләгәндә, бу сүзнең тирәнрәк мәгънәсен төшенү зарур. Гади генә итеп әйткәндә, аны нәрсә өчен түлиләр соң?

Монда үзеннән-үзе шундый җавап кетелә — кеше үз хезмәт вазифаларын үтәп, күпмедер вакыт дәвамында эшләгән өчен. Әмма бу җавап бик үк төгәл түгел. Кешегә күпмедер вакыт эшләгән өчен түгел, ә үзен эшкә яллаучыга шул вакыт эчендә китергән файда өчен түлиләр. Шуңа күрә дә хезмәт хакының катгый югары чиге бар. Гадиләштереп әйткәндә, бу чик хезмәт нәтиҗәсен сатудан килгән төшем (выручка) һәм ул хезмәтне алу белән бәйле чыгымнар аермасына тигез була. Башка сүз белән әйтсәк, үз яллаучысы өчен хезмәткәр бер ай эчендә җитештергән товарны 600 сумга сатып булса, хезмәткәрнең хезмәт хакы шушы суммадан да арта алмый (чынлыкта исә аннан ким булырга тиеш һәм шулай була да, чөнки бер генә товар да хезмәт чыгымнары белән генә тудырылмый).

Яллы хезмәткәр хезмәт хакыннан башка да өстәмә керем алырга мөмкин. Мондый өстәмә керемнәрнең иң киң таралган төре булып премия яки *бонус* (латинчадан — *bonus* — яхшы) санала.

Гадәттә, хезмәткәргә фирма өчен аеруча мөһим эшләр үтәгәч яки фирма эшчәнлеген оештыру алымнарын яхшырту турында тәкъдимнәр керткәч, премия бирелә. Предприятиенең даими хезмәткәрләренә шулай ук ел ахырында яки бәйрәмнәр хөрмәтенә дә премия тапшыралар.

Кайбер оешмаларда (аеруча сәүдә өлкәсендә) хезмәткәр төп хезмәт хакыннан тыш *комиссион түләүләр* дә ала. Гадәттә, автомобильләр, йортлар, станоклар һ.б. сату белән шөгыльләнүчеләрнең тырыш хезмәтен шулай бәялиләр. Төп хезмәт хакына мондый өстәмә түләүнең күләме хезмәткәр сатып җибәргән товар бәясенең процентларында билгеләнә. Әйтик, фатирлар сату белән шөгыльләнүче фирма үз хезмәткәрләре өчен комиссион түләүләр ставкасын 3% күләмендә билгеләде ди. Ул чакта клиент белән 35 мең долларлык шартнамә төзегән хезмәткәр 1050 доллар күләмендәге комиссион түләү алачак.

Ниһаять, күп кенә фирмалар хезмәткәрләре үз хезмәт вазифаларын яхшырак башкарсын өчен, аларны *акчалата булмаган ташламалар* белән дә кызыксындыралар, болар чынлыкта төп хезмәт хакына өстәмә түләүгә тиң була. Аларга хезмәт автомобиленнән, кәрәзле телефоннан бушлай файдалану хокукы һ.б. керә. Еш кына фирмалар үз хезмәткәрләренә һәм аларның гаилә әгъзаларына кыйммәтле клиникалардагы медицина страхованиесен дә түлиләр.

Әмма яллап эшләүчеләрнең төп хезмәт хакы һәрвакытта да төп керем чыганагы булып кала. Аның күләме фирманың үз хезмәткәрләреннән закон белән билгеләнгән эш көне дәвамында күпме күләмдәге һәм нинди сыйфаттагы эш башкаруын таләп итүеннән бәйле була. Әмма хезмәт нәтиҗәсенең күләменә һәм сыйфатына карата әлеге таләпләр төрлечә куелырга мөмкин.

Алар, мәсәлән, хезмәткәр көн дәвамында җитештерергә тиешле билгеле бер сыйфаттагы эшләнмәләрнең күләмендә чагылыш табарга мөмкин. Әгәр дә шулай икән, без монда **эш башыннан (исәбеннән) түләнә торган хезмәт хакы** турында сүз баруын күрербез.

Эш башыннан түләнә торган хезмәт хакы булганда, эш бирүче үз хезмәткәренә түбәндәге шартларны куя:

1) эш көне дәвамында ул җитештерергә тиешле продукциянең тиешле күләмдә булуын;

2) һәр данә продукция өчен (шул исәптән, әгәр дә эшкә алучы норманы арттырып үтәү белән кызыксынса, көнлек нормадан тыш җитештерелгән продукция өчен дә) күпме акча түләнәчәген күрсәтә.

Әмма һәр хезмәткә дә эш башыннан түләп булмый. Әйтик, укытучылар, табиблар, галимнәр һ.б. белгечләрнең хезмәт хакын болай түләү мөмкинлеге юк. Алар өчен вакыт схемасы нигезендә түләү каралган. Бу очракта эш бирүче үзенә эшкә ялланган һәр хезмәткәргә түбәндәге шартларны җиткерә:

1) ул һәр көн ничә сәгать эшләргә тиешлекне күрсәтә;

2) һәр сәгать өчен аңа күпме акча биреләчәген җиткерә.

Кайвакыт хезмәткәрнең эш вакытын төгәл исәпләү авыр яки максатка ярашлы булмаган очракларда, эш вакытыннан түләү атнага яки айга билгеләнгән төгәл күрсәтелгән акчалата түләү рәвешен ала. Мондый түләүне **оклад** дип атыйлар.

Хезмәт белән беренче танышуыбызны тәгәлләп, без икътисади акыллылыкның тагын бер рецептын төзербез.

Җиденче рецепт

Ил байлыгы артуын тәэмин итү өчен, гражданнарның хезмәт төрен ирекле сайлау хокукын якларга, әгәр дә товар базарлары таләп итсә, аларга яңа эш урыннары эзләүдә һәм башка белгечлекләр үзләштерүдә ярдәм итәргә кирәк.

БҮЛЕКНЕҢ ТӨП ЭЧТӘЛЕГЕ

Хезмәт базарының икътисади табигате. *Хезмәт базары җитештерү ресурслары базарлары арасында иң мөһим урынны алып тора. Бу базар һәр ил халкының хезмәткә сәләтле күпчелек өлешен тәшкил итүче ялланып эшләүчеләргә үз вакытларын һәм хезмәт күнекмәләрен эш бирүчеләргә (фирма һәм оешма хуҗаларына) сатарга һәм шуның өчен үз гаиләләрен туендырырлык керем алырга мөмкинлек бирә. Икенче яктан карасак, бу базар эш бирүчеләргә хезмәткәрләр алларга мөмкинлек тудыра, ә бу исә һәртөрле хуҗалык эшчәнлеген тормышка ашыруның мәҗбүри шарты булып тора.*

Хезмәт базарындагы сорау нәрсәдән бәйле була. *Хезмәт базарындагы сорау товарлар һәм хезмәт күрсәтүләргә булган сорауга бәйле рәвештә барлыкка килә, бу товарларны җитештерү һәм хезмәт күрсәтүләрне оештыру өчен, эш бирүче хезмәткәрләр алларга тиеш була һәм ул өстәмә сорауны тәшкил итә дә. Шуңа күрә дә хезмәт базарындагы һәм аерым профессияләр базарындагы сорау зурлыгы илдәге икътисади вазгыятьтән һәм аерым төр товарларга карата сорауның никадәр канәгатьләндерелүеннән бәйле була.*

Хезмәт базарында тәкъдим формалаштыру факторлары. *Хезмәтне тәкъдим итү хезмәт хакы зурлыгы йогынтысында, шулай ук хезмәтнең никадәр абруйлы булуы һәм ул китергән күңел канәгатьлегенә карап арта. Хезмәтнең авырлыгы, катлаулылыгы, һәм кешеләрнең буш вакытка ихтыяҗлары булу тәкъдимнең кимүенә китерә.*

Хезмәт базарында хезмәт хакы формалашу. *Барлык базар бәяләре кебек үк, хезмәт хакы эш бирүчеләр тарафыннан килгән сорау белән яллы хезмәткәрләрнең үз хезмәтләрен тәкъдим итүләре йогынтысында формалаша. Хезмәт хакындагы тотрыклылыктан тайпылышлар төрле товар базарларындагы вазгыять үзгәреше, шул исәптән иң яхшы хезмәт шартлары тәкъдим ителгән яңа тармаклар барлыкка килү аркасында килеп чыга.*

Хезмәткә түләү күләмнәрендәге даими аермаларның сәбәпләре. *Базар шартлары йогынтысында хезмәт хакының кыска вакытлы тирбәлешләренә хезмәт хакы дифференциациясенең озак сроклы*

факторлары да тәэсир итә. Бу иң мөһим факторларга аерым профессияләрнең катлаулылыгы һәм авырлыгы; талантларның аз булуы; әлеге һөнәр белән шөгыльләнгәндәге хәтәрлек дәрәҗәсе керә.

ФИКЕР АЛЫШУ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Халык мәкале «Бәхет акчада түгел» ди. Әгәр дә бу мәкаль барлык кешеләр эшчәнлегендә дә нигез итеп алынса, кешелек икътисады ничек үсәр иде икән? Әгәр дә кешеләрне күпме хезмәт хакы алулары бөтенләй кызыксындырмый икән, дөньяда хезмәт базары ничек эшләр иде?
2. «Хезмәткә түләү зурлыгы профессиянең дәрәҗәлелегенә капма-каршы бәйлелектә тора» дигән фикер дөресме һәм ни өчен?
3. Күп кенә алга киткән илләрдә университет профессорлары коммерция фирмаларының җитәкче персоналына караганда кимрәк хезмәт хакы ала. Шуңа да карамастан әле бер генә университетның да профессорлар җитмәү аркасында ябылганы юк. Ни өчен профессорлар коммерция фирмаларына эшкә китми?

Хезмәт базарының социаль проблемалары

БҮЛЕКТӘ КАРАЛУЧЫ МӘСЬӘЛӘЛӘР:

1. КЕШЕЛӘР ПРОФСОЮЗЛАРНЫ НИ ӨЧЕН УЙЛАП ТАПКАН?
2. ЯШӘҮ МИНИМУМЫ НӘРСӘ УЛ?
3. УҢЫШТА НИЧЕК КАТНАШЫП БУЛА?

Сугыш елларында кертелеп, 1947 елда юк ителгән карточкалар системасы СССРның күпчелек халкы өчен дефицитка һәм табып булмаслык хәлгә җиткән кайбер төп туклану продуктларына карата 1991 елда яңадан кертелде. Бу фотографиядә 1947 елдагы ипи карточкалары һәм 1991 елда бирелгән шикәр талоннары күрсәтелгән.

Заманча, ирекле һәм демократик милләтнең
бер сыйфаты — ирекле һәм бәйсез профсоюзлар.

Франклин Д. Рузвельт,
АКШның 32 нче президенты

Алдагы бүлектә без хезмәтнең базар бәясе — хезмәт хакы формалашуның гомуми закончалыклары белән танышкан идек. Алар күп яктан башка товар һәм ресурс базарларында чагылыш тапкан закончалыкларга охшаш. Әмма хезмәт базарының хезмәт хакына йогынты ясаучы үзенә генә хас үзенчәлекләре дә бар.

§ 16. Профсоюзлар һәм хезмәт конфликтлары

Хезмәт базарының башка базарлардан төп аермасы — сатучылар (яллы хезмәткәрләр) белән сатып алучылар (эш бирүчеләр, яллаучылар) арасындагы мөнәсәбәтләрнең аерым характерда булуы. Аны хезмәт базарының социаль-сәяси характеры диләр.

Бу базарда катнашучылар гасырлар буена үзара дошманлашып яшәгәннәр. Еш кына кан коюларга, атуларга ук барып җиткән бу көрәш әлегә кадәр тынмый. Шулай да XX гасыр үзе белән бик күп яналыклар алып килә һәм күп кенә илләрдә хезмәт мөнәсәбәтләрен тынычрак юлга чыгара.

Эш шунда ки, эш бирүчеләр элек-электән хезмәт хакы билгеләгәндә аны мөмкин кадәр түбәнрәк баскычта тотуны төп кагыйдә итеп санаганнар.

Үз чиратында яллы эшчеләр бөтенләй капма-каршы фикердә тора һәм иң югары хезмәт хакы таләп итә. Бу көрәштә һәр як «көрәш хәрәкәтләре» алып баруның үз ысулларын таба.

XIX гасырда—XX гасыр башында эш бирүчеләр түбәндәге ысуллардан киң файдалана:

1) **«кара исемлек» төзү.** Хезмәт хакын арттыру һәм эш шартларын яхшырту өчен аеруча актив көрәшүчеләрне эштән куып кына калмыйлар, аларны бер генә эшмәкәр дә эшкә алмаслык махсус исемлеккә теркиләр. Россиядә бу «бүре билеты алу» дип аталган;

2) **локаут** (ингл. *lock-out* — «кемнеңдер алдында ишекне ябып кую»). Локаут вакытында, хезмәт хакын арттыру турындагы таләпләргә җавап итеп, эш бирүчеләр предприятиеләрне берничә атнага ябып куялар. Әлбәттә, аларның керемнәре югала, аның каравы «фетнәчеләрне» ачлык чигенә җиткерәләр;

3) **штрейкбрехерлар яллау** (нем. «штрейкбрехер» сүзенең турыдан-туры тәрҗемәсе «забастовканы өзүче»). Әгәр дә хезмәткәрләр хезмәт хакын түләүләрен таләп итеп эштән туктаса, фирма хуҗалары элекке түләүгә дә ризалашкан вакытлыча хезмәткәрләрне яллый;

4) **«сары эт» контрактлары** (аларны америкалылар шулай атый). Әлеге юлны сайлаган фирмалар, югарырак хезмәт хакы өчен көрәш максатында, беркем белән дә берләшмәскә вәгъдә итүче шәхси хезмәт шартнамәсе (контракт) төзегән кешене генә эшкә алалар. Әгәр дә ул контрактны бозса, аны шунда ук эштән куалар һәм бер генә суд та аны якларга риза булмаган.

Эшчеләргә каршы әлеге һәм башка чаралар, шул исәптән законнарны, полицияне һәм хәтта армияне эшкә җигү, эшче көчен сату-алу шартлары белән эшчеләрне килешергә мәҗбүр итүгә һәм эшче көче бәясен бөтенләй минимумга кадәр калдырырга юнәлдерелә.

Әлбәттә, яллы эшчеләр хезмәткә бәяне күтәрү өчен көрәш чараларын тагы да арттыралар һәм камилләштерәләр.

Яллы хезмәткәрләр стратегиясе түбәндәге көрәш алымнарыннан гыйбарәт була:

— **забастовкалар (стачкалар)** — эш бирүчеләр баш күтәрүчеләрнең хезмәт хакын арттыру яки хезмәт шартларын яхшырту турындагы таләпләрен канәгатьләндергәнгә кадәр эшне туктатып тору;

— **кагыйдәләр буенча эшләү** (Италия эшчеләре уйлап тапканга күрә, бу алымны «италиялеләр забастовкасы» дип атаганнар) — яллы эшчеләр чын-чынлап эшне туктатмыйлар, ә аны катгый күрсәтмәләр буенча һәм акрын итеп (яки кыска вакытлы тукталышлар белән) башкаралар. Ә бу исә хезмәт җитештерүчәнлеген һәм эшмәкәрләрнең табышын бик нык киметә;

— **сәяси партияләр төзү**. «Хезмәт партияләре» (Бөекбританиядәге әйдәп баручы сәяси партияләрнең берсе булган лейбористлар партиясе әнә шулай тәрҗемә ителә) дәүләт карарларын парламент юлы белән яллы хезмәткәрләр файдасына хәл итәргә мөмкинлек бирә. Алар хезмәт хакы минимумын билгеләүдән, хезмәт куркынычсызлыгын тәэмин итүче гомуммәҗбүри таләпләр кертүдән һ.б. гыйбарәт;

— **профсоюзлар оештыру** — бу оешмалар эшмәкәрләр белән алып барган сөйләшүләрдә яллы эшчеләр мәнфәгатьләрен кайгырта.

Эшче көчләр базарында көрәшнең бу алымнарын кулланып инде берничә гасыр буена сәүдә бара. Эшчеләр күбрәк хезмәт хакы таләп итеп забастовкага чыга, ә эшмәкәрләр локаут белән җавап бирә. Эшчеләр профсоюзлар төзи, ә эшмәкәрләр алар эшчәнлеген суд аша тыярга тырыша. Эшчеләр үз партияләрен төзи, ә эшмәкәрләр үз сәяси оешмаларын төзү белән җавап бирә.

Бүгенге көндә хәтта иң демократик илләрдә дә хезмәт базарындагы көрәш аеруча кискен формалар алырга мөмкин.

Мәсәлән, АКШ авиадиспетчерлары забастовка игълан иткәч, президент Рональд Рейган, транспортта забастовкаларны тыючы законнарга таянып (хәрәкәт куркынычсызлыгына һәм пассажирлар гомеренә куркыныч янау сәбәпле), авиадиспетчерлар профсоюзына коточкыч зур штрафлар салып, аларны куып тарата. Аннары баш күтәрүчеләр каршылыгын тәмам сындыру өчен, ул, гадәти аэропортларда хәрби диспетчерларны эшләргә мәҗбүр итеп, штрейкбрехерлык тактикасын куллана.

Бүген дөньяның алдынгы илләрендә профсоюзлар хәрәкәте кимүгә таба бара. Моның төп сәбәпләре арасында түбәндәгеләр бар:

1) *хезмәт эшчәнлеге характеры үзгәрү* (предприятиеләрне кечерәйтү, милектәш хезмәткәрләр катнашында яңа төр фирмалар барлыкка килү);

2) *җәмгыятьтәге муллыкның үсеше.* Бу исә мондый илләрдәге яллы хезмәткәрләргә моңарчы фабрика хуҗаларының төшенә дә кермәгән тормыш шартларын тәэмин итәргә мөмкинлек бирә.

Тормыш күрсәткәнчә, ил баерак булган, андагы муллык дәрәҗәсе күтәрелгән саен, хезмәт базарындагы мөнәсәбәтләр дә шулкадәр тыныч корыла. забастовкалар

да сирәгрәк һәм кыскарак була. Әмма икътисади вазгыять начар булган, хезмәт базары тотрыксызлыгы күзәтелгән, гражданнарның тормыш хәлләре яхшырмый, ә киресенчә артка тәгәрәгән илләрдә (бүгенге көндә Россиядә шундый хәл күзәтелә) профсоюзлар роле саклана, һәм шуңа күрә бу оешмаларның хезмәт базарына ничек йогынты ясавына игътибарлырак булырга кирәк.

Профсоюзларның борчу-мәшәкатьләре үз әгъзалары һөнәренең үзенчәлекләре белән аерылгысыз бәйләнештә тора, шуңа күрә дә, мәсәлән, рәссам-графиклар хәл итә торган мәсьәләләр шахтерлар профсоюзы җитәкчеләре кайгырткан мәсьәләләрдән шактый аерыла. Әмма барлык һөнәри берләшмәләрнең дә уртак бурычлары бар.

Аларның иң мөһимнәрен түбәндәгеләр тәшкил итә:

— **хезмәт шартларын яхшырту һәм аның куркынычсызлыгын тәэмин итү.**

Монда, гадәттә, профсоюзларның хезмәттәге санитария-гигиена шартларын яхшыртуга юнәлдерелгән эшчәнлеге турында сүз бара (мәсәлән, цехлардагы көчле тавышны һәм тузанны киметү). Профсоюзлар шулай ук хатын-кызларга һәм яшүсмерләргә (аеруча йөкле һәм кечкенә балалары булган хатын-кызларга) ташламалы хезмәт шартлары булдыру турында да кайгырта (аерым алганда, хезмәт көнен кыскарту).

Ниһаять, профсоюзлар кайгырткан тагын бер мәсьәлә хезмәткәрләрнең җитештерүдә тормышына янаган хәтәрләрне яки травмалар алу куркынычын киметүдән гыйбарәт. Күпчелек алдынгы илләрдә хезмәт шартларын көйләүче һәм җитештерүдәге бәла-казаларны киметүне тәэмин итүче махсус законнар һәм нормалар нәкъ менә профсоюзлар басымы астында кабул ителде.

Әмма икътисад дөньясында һәрбер нәрсәнең үз бәясе бар. Эш бирүче хезмәт шартларын яхшыртуга никадәр күбрәк акча тотарга тиеш булган саен, һәр эшче аңа шулкадәр кыйбаткарак төшә һәм ул аларны эшкә шулкадәр азрак санда яллый ала;

— **хезмәт хакын күтәрү.**

Хезмәт базары турында алдагы бүлектә өйрәнгәннәребезне искә төшерсәк, бу мәсьәләне:

1) хезмәткә сорауны арттыру өчен;

2) хезмәтне тәкъдим итүне киметү өчен шартлар тудырып хәл итеп булачагын төшенергә мөмкин.

Әлбәттә, хезмәткә сорауны арттыру профсоюзлар өчен шактый катлаулы эш: аларның хезмәт базарына сорау җибәрүче товар базарларына йогынты ясау мөмкинлеге юк. Монда профсоюзларның илгә чит ил товарларын кертүне чикләү өчен тырышуы турында сүз бара. Мондый товарларның илдә сатылуы үз фирмаларыбыз продукциясенә сорауны киметә, димәк, илебез гражданнары хезмәтенә бүген сорау да кими дигән сүз. Импорт товарларга сорау кимегәч, эчке хезмәт базарында хезмәткәрләр саны һәм хезмәт хакы арту өчен шартлар туачак.

Шуның белән бергә, профсоюзларның мондый позициясе эчке базардагы конкуренция йомшаруга һәм илдә җитештерелгән продукция сыйфатын яхшырту белән кызыксынмауга этәрә. Продукция конкуренциягә сәләтсез була башлый. Аны читкә чыгару мөмкинлекләре кими, шулай булгач, аны әзерләргә кирәкле хезмәткә карата сорау да кими дигән сүз. Моннан тыш, бер илнең импорт товарларны чикләвенә каршы башка дәүләтләр, гадәттә, шундый ук чаралар белән

җавап кайтаралар. Нәтиҗәдә илнең барлык товарлары экспорты өчен мөмкинлекләр кими, ә бу исә башка илләргә товар чыгару юнәлешендә эшләүче фирмалар һәм тармаклар хезмәткәрләре өчен хезмәт базарындагы шартларның начар якка үзгәрүенә китерә.

Хезмәтне тәкъдим итүне чикләү мәсьәләсенә кагылсак, профсоюзлар, моңа ирешү өчен, эш бирүчеләр белән үз әгъзаларын гына эшкә алу турында килешәләр. Урта гасырларда ук осталар гильдияләрендә (цехларда) кулланыла башлаган әлеге тактика чит илләрдә бик киң таралса да, Россиядә бөтенләй диярлек кулланылмый.

Бу исә, мәсәлән, Россия актерларына АКШта эш эзләргә комачаулый, чөнки театр һәм киностудия хуҗалары аларга рольне Америка актерлары гильдиясенең аерым рөхсәте белән генә тәкъдим итә ала.

Хезмәт базарында сорауны арттыру яки тәкъдимне чикләү юлы белән хезмәт хакын арттыру мөмкинлекләренең чикле булуын аңлап, профсоюзлар бу мәсьәләне хәл итүнең башка юлына басым ясады. Алар, хезмәт һәм түләү шартларын хәл иткәндә, үзләренең барлык әгъзаларының бердәнбер вәкиле буларак чыгыш ясый башлады.

Бу бурыч эш бирүчеләр белән бергәләп сөйләшүләр алып бару юлы аша хәл ителә. Профсоюзлар логикасы гади: яки аның барлык әгъзалары да югарырак хезмәт хакы алачак, яки забастовка башланачак.

§ 17. Хезмәт хакы формалашуның социаль факторлары

Хезмәт базарына әһәмиятле бер үзенчәлек хас: анда бәяләр кимүнең чиге бар. Чыннан да, әгәр ниндидер товар сатылмыйча ята икән, аның хуҗасы (житештерүчесе яки сәүдә итүче) товар сатылганга кадәр бәяне төшерәчәк. Бу аңа табыш китермәсә дә, аны җитештерүгә тоткан чыгымнарны капларга мөмкинлек бирәчәк.

Хезмәт белән хәлләр башкачарак тора: аның бәясенең — хезмәт хакы ставкасының — объектив бәя төшү чиге бар. Бу чик илдә урнашкан бәяләр буенча минималь кирәк-ярак «кәрзин»ен алу өчен түләргә тиешле сумма белән билгеләнә. Мондый «кәрзин»гә кешегә җан асрау өчен, һичшиксез, кирәкле әйберләр генә керә. Әлеге «кәрзин»нең бәясе **«яшәү минимумы»** дип атала.

ЯШӘҮ МИНИМУМЫ — кешенең туклану өчен физиологик нормалардан түбән булмаган күләмдә азык-төлек алуы, шулай ук аның киемгә, аяк киеменә, торакка, транспорт хезмәтенә, санитария-гигиена предметларына ихтыяҗын минималь күләмдә канәгатьләндерүе өчен кирәкле акча суммасы.

Яшәү минимумы зурлыгын билгеләүне түбәндә әйтеп үтелгән кайбер сәбәпләр гаять катлауландыра:

1) яшәү минимумы «кәрзин»енә нәрсәләр керергә тиешлек турында төрле карашлар яши (иң элек эш бирүчеләр һәм профсоюзларда);

2) «кәрзин»гә кертелгән әйберләрне куллануның минималь күләмен билгеләүдә бердәм фикергә килү җиңел түгел;

3) төрле регионнардагы бәяләрнең төрле булуы яшәү минимумындагы территориаль төрлелекләргә сәбәп була. Мәсәлән, товар ташуга киткән югары транспорт чыгымнары аркасында, Ерак Көнчыгыштагы һәм Россия көньягындагы бәяләр илнең үзәк өлкәләренә караганда шактый югарырак була.

Шуңа күрә төрле илләрдә яшәү минимумы зурлыгын билгеләүгә төрлечә якын киләләр. Россиядә әлегә төрле әйберләрне минималь нормаларда куллануга нигезләнгән якын килү өстенлек итә.

Шушы нигездә яшәү минимумы зурлыгын билгеләгәндә, туклану буенча белгечләр кешегә ачлы-туклы яшәүдән авырмас өчен кирәкле азык күләмен исәпләп чыгаралар.

Мәсәлән, Россиядә азык-төлек куллануның еллык нормасы түбәндәге дәрәҗәдә билгеләнә (җәяләр эчендә — көнлек норма):

ипи	— 134 кг (370 г);
бәрәңге	— 123 кг (340 г);
ит	— 27,5 кг (80 г);
яшелчәләр	— 93,4 кг;
җиләк-җимешләр	— 19 кг;
шикәр һәм кондитер ризыклары	— 20 кг;
балык	— 12 кг;
сөт ризыклары	— 218 кг;
йомырка	— 172 данә.

Башка белгечләр азык-төлектән тыш товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрне куллануның минималь күләмен билгели. Аннан соң бу куллануның натуралата нормалары гамәлдәге бәяләргә тапкырлана һәм шулай итеп, яшәү минимумының акчалата зурлыгы исәпләп чыгарыла.

Яшәү минимумы хәзерге хезмәт базарында минималь хезмәт хакы ставкасын исәпләп чыгарганда нигез итеп алына.

Мәсәлән, «Предприятиеләр һәм эшмәкәрлек эшчәнлеге турында» Россия Законының 26 нчы статьясы: «Предприятие, үзенең милек төрләре һәм оештыру-хокукый формалары нинди булуга карамастан, закон белән каралган минималь хезмәт хакын, хезмәт шартларын һәм хезмәткәрләрне социаль-яклау шартларын тәэмин итәргә тиеш»,— дип билгели. Әгәр дә предприятие минималь хезмәт хакын түли алмый икән, ул банкрот дип игълан ителә һәм аны закон буенча ябарга тиешләр.

Иң гади эшне башкаручы квалификациясез хезмәткәрләргә түләнгән минималь хезмәт хакы, норма буенча, яшәү минимумыннан бераз югары булырга тиеш, ягъни хезмәткә түләү 8-1 рәсемендә күрсәтелгәнчә корылырга тиеш.

Хезмәт базарындагы сәүдә чынлыкта ничек бара соң, сату-алу килешүләре монда ничек теркәлә?

XX гасыр әлеге базарда сәүдә операцияләрен теркәүнең төп ике механизмын иң алдынгы рәткә чыгарды:

1) **хезмәт контрактлары** һәм
2) **коллектив шартнамәләр** (килешүләр).

8-1 рәсем.
Хезмәт хакы системасының төзелеше

ХЕЗМӘТ КОНТРАКТЫ — эш бирүче белән эшкә ялланучы арасында хезмәтнең эчтәлеге, аның шартлары, шулай ук аңа түләү күләме һәм үзара башка йөкләмә-бурычлар турында аерым сөйләшүләр нәтиҗәсендә ирешелә торган килешү.

Бүгенге көндә, индивидуаль контрактлардан тыш, коллектив шартнамәләр дә бик еш кулланыла. Мондый шартнамә —

1) эш бирүчеләр һәм әлеге предприятиедәге яллы хезмәткәрләрнең кайбер төркемнәре мәнфәгатьләрен кайгыртучы оешма арасында төзелгән һәм

2) бу төркем хезмәткәрләрнен хезмәтен оештыру һәм түләүнең бердәм принципларын билгеләүче документ ул.

Коллектив шартнамә фирма персоналының хезмәт шартларына кагылышлы бихисап мәсьәләләрне колачлый, аларны көйли һәм хәл итә. Мондый шартнамә, билгеле бер мәгънәдә, фирмадагы хезмәт мөнәсәбәтләрен коручы закон буларак та карала. Яхшы итеп төзелгән шартнамә шулкадәр киң колачлы мәсьәләләрне хәл итә ки, хәтта аны фирманың «хезмәт конституциясе» дип тә атап булыр иде.

Күрсәтмәлелек өчен 1988 елның июлендә япон-америка автомобиль компаниясе «New United Motor Manufacturing» җитәкчеләре һәм профсоюз арасында төзелгән коллектив шартнамәне карап үтик.

Шулай итеп, бу шартнамә:

1) аңа кул куйган якларның җаваплылыгын искәртә һәм йөкләмәләрен билгели. Әлеге яклар, *компанияне үстерү хисабына, хезмәткәрләрнең һәм алар гаиләләренең тормышларын яхшырту һәм аларга ярдәм итү кебек уртак максатка ирешү өчен, бер команда булып берләшеп эшләргә, иң түбән бәяле, әмма дөнья күләмендә иң шәп автомобиль төзергә йөкләмә алалар;*

2) компания җитәкчеләренең профсоюз алдындагы йөкләмәләрен, профсоюз һәм хезмәткәрләрнең компания алдындагы йөкләмәләрен билгели. Алар арасында *«компания принциплары һәм фәлсәфәсе кушканча эшләүне; бер-берсенең индивидуаль хокукларын хөрмәт итүне; үз-үзеңне тиешенчә тоту һәм эшкә йөрү кагыйдәләрен үтәүне»* таләп иткәннәре дә бар;

3) хезмәт белән тәэмин итүне искәртә: *«Кырыс икътисади зарурлык мәҗбүр итмәсә, компания хезмәткәрләрен эштән җибәрмәскә ризалаша. Кемне дә булса эштән җибәргәнче, компания бу мәсьәләне хәл итү өчен кайбер чаралар (мәсәлән, администрациянең хезмәт хакын кыскарту) күреп карарга сүз бирә»;*

4) хезмәт конфликтларын һәм бәхәсләрен хәл итү юлларын билгели;

5) хезмәткәрләрне компаниянең бер тармагыннан икенчесенә, бер сменадан икенчесенә күчерү тәртибен билгели;

6) хезмәтне бригада тәртибендә оештыру концепциясен билгели;

7) хезмәт хакы күләмен һәм инфляция аркасында тормышның һаман да кыйммәтләнә баруын истә тотып, өстәмә түләүләр тәртибен билгели;

8) эш вакыты озынлыгын һәм хезмәткәрләрне эш вакытыннан тыш хезмәткә җәлеп итү тәртибен билгели;

9) бәйрәм көннәре санын һәм чираттагы ял (отпуск) озынлыгын билгели;

10) күмәк страхование (иминиятләштерү), сәламәтлекне, пенсияләр белән тәэмин итүне страховкалау, саклык акчалар туплау программасын һәм резерв фонд формалаштыру тәртибен билгели;

11) хезмәт куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын билгели;

12) шартнамә гамәлдә булган вакытта стачкалар һәм локаутлар тыелуын искәртә.

Коллектив шартнамә бер предприятие өчен генә төзелергә мөмкин, ул шулай ук тулы бер тармак, территория хезмәткәрләренең яки аерым бер профессия вәкилләренең хезмәт шартларын, ялын һәм социаль яклау мәсьәләләрен дә хәл итәргә мөмкин. Мондый шартнамәләрне, гадәттә, тармак буенча (региональ, профессиональ) хезмәт килешүләре дип атыйлар.

Хезмәт базарын мондый көйләүнең иң югары формасын **генераль килешү** тәшкил итә.

ГЕНЕРАЛЬ КИЛЕШҮ — хөкүмәт, эш бирүче һәм профсоюз берләшмәләре арасындагы сөйләшүләр нәтиҗәсендә кабул ителгән, бөтен ил буенча эш көчләрен сату-алу шартлары үзгәрешенең гомуми юнәлешләрен билгеләүче документ.

Россиядә беренче тапкыр мондый Генераль килешү 1992 елда төзелә һәм түбәндәге бүлекләргә тупланган 52 пункттан гыйбарәт була:

1. Икътисад һәм реформалар үткәрү өлкәсендәге чаралар.
2. Халыкны хезмәт белән тәэмин итүгә, хезмәт базарын үстерүгә булышу.
3. Тормыш дәрәҗәсен көйләү һәм социаль гарантияләрне тәэмин итү.
4. Хезмәт шартлары тудыру һәм хезмәт иминлеген саклау, экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү.
5. Хезмәт һәм социаль партнерлык мөнәсәбәтләрен хокукый яктан тәэмин итү.
6. Генераль килешүне тормышка ашыру механизмы.

Башка сүз белән әйткәндә, мондый документ эш бирүчеләр һәм яллы хезмәткәрләр арасындагы барлык үзара йогынты юнәлешләренең нигезен тәшкил итә. Әгәр дә яклар килешү буенча барлык йөкләмәләрен чыннан да үтиләр икән, ил өчен бу күп яктан отышлы гына булачак.

Нәкъ менә шундый хезмәттәшлек ГФР, Япония һәм Испания кебек илләрнең икътисад үсешенә һәм гражданнарның тормыш шартларын яхшыртуга этәрүче төп алшарт булып әверелә.

Әлбәттә, хезмәт базарында сатучылар һәм сатып алучылар мәнфәгатьләре арасындагы каршылыкларны бернинди килешүләр дә тулысынча юкка чыгара алмый. Әмма бу базарда катнашучылар, нәкъ башка базарлардагы кебек үк, компромисс эзләргә һәм аны табарга тырышалар.

Сәбәбе бик яхшы аңлашыла: ни эш бирүчеләр, ни яллы хезмәткәрләр берберсеннән башка яши алмый. Эш бирүчеләр ялланып эшләүчеләрдән башка үз эшчәнлекләрен оештыра алмый, димәк, керемсез кала дигән сүз. Ялланып эшләүчеләргә дә эш бирүчеләр булмаса, хәерчелек янар иде.

Хезмәт базары эшчәнлеге һәм хезмәткәрләргә түләү үзенчәлекләре турында сөйләгәндә, кешенең яллану турында документка кул куюыннан соң, хезмәт базарыннан вакытлыча китсә дә, икътисади мөнәсәбәтләр өлкәсеннән китмәвенә игътибар итү зарур. Бары тик проблемаларның характеры гына үзгәрә: ялланган кешенең югары сыйфатлы итеп һәм житештерүчән эшчәнлегенә ничек ирешергә — эшкә яллаучының төп проблемасы әнә шуннан гыйбарәт була. Ә эшкә ялланган кеше гамәлдәге хезмәт хакы системасы кысаларында үз хезмәте өчен ничек итеп күбрәк түләү алу турында кайгырта.

Яллы хезмәткәрләрне икътисади кызыксындыру, өметләндерү алымнары кулланып, бу мәнфәгатьләрне үзара килештереп була. Кешелек мондый кызыксындыруның күптөрле юлларын уйлап тапкан һәм алар турында җентекләп сөйләү бик күп вакытны алыр иде. Шуңа күрә аларның иң мөһимнәрен генә искә алып үтик:

— хезмәт активлыгын хезмәт хакы аша бәяләү;

— «уңышта катнашу»;

— пенсияне турыдан-туры хезмәт хакыннан бәйле итеп формалаштыру.

Хезмәт хакы. Хезмәт хакының иң традицион формалары — вакыт исәбеннән түләнә торган хезмәт хакы һәм эш башыннан (исәбеннән) түләнүче хезмәт хакы (болар турында 7 бүлектә сөйләнә).

ЗАКОН КУШКАНЧА

Россиядә коллектив шартнамәләр һәм килешүләр беркетү тәртибе 1992 елның мартында кабул ителгән «Коллектив шартнамәләр һәм килешүләр» турындагы Закон белән билгеләнә.

Бу законда түбәндәгеләр беркетелә:

— коллектив шартнамәләр һәм килешүләр шартлары алар колачлаган предприятиеләр өчен мәҗбүри;

— коллектив шартнамәләр яки килешүләрдән аермалы булган һәм хезмәткәрләрнең хәлен начарлау ягына боручы шартларны индивидуаль хезмәт контрактларына кертү тыела;

— коллектив килешүләр яки шартнамәләргә кул куйган яклар үз өсләренә йөкләмәләрне иркле төстә алалар;

— эш бирүчеләр, башкарма хакимият органнары яки сәяси партияләр төзегән яки финанслаган теләсә кайсы оешма эшкә ялланучылар исәбеннән сөйләшүләр алып бара алмый, бу тыела;

— хезмәткәрләр исеменнән сөйләшүләрне профсоюзлар алып бара ала, әгәр дә алар берничә булса, закон тарафыннан танылган профсоюзлар вәкилләре алып барырга мөмкин;

— яклар килешә алмаган очракта, законга каршы килмәсә, забастовкалар үткәрү рөхсәт ителә;

— коллектив шартнамәдә хезмәт хакы һәм күләме, аңа инфляцияне искә алып төзәтмәләр кертү, эшләү һәм эштән җибәрү шартлары, эш вакыты һәм ял озынлыгы мәсьәләләре буенча яллы хезмәткәрләрнең һәм эш бирүчеләрнең үзара йөкләмәләре күрсәтелә.

Бүгенге көндә, хезмәт хакының шактый өлеше фирма уңышлары һәм керемнәреннән турыдан-туры бәйле булган вакытта, алга киткән илләрдә хезмәткә түләү күләмен билгеләүнең яңа юллары тарала башлады. Хезмәткә түләүнең бу яңа формалары фирма җитәкчеләренең хезмәткәрне предприятие уңышы белән ныграк кызыксындырырга тырышуы белән бәйләнгән.

«Уңышта катнашу». Ялланган хезмәткәрләрне хезмәт белән кызыксындыруның заманча ысуллары нигезендә яткан төп фикерне әнә шулай дип формалаштырырга була.

Психологлар фикеренчә, күпчелек кешеләр өчен муллыкның арта баруы гына җитми. Кеше предприятие белән идарә итүдә актив катнашырга, үзен милектәш итеп тоярга, үз фикеренә колак салуларын һәм әйләнә-тирәдәгеләрнең хөрмәтен казанырга тели. Хезмәт мөнәсәбәтләренең шушындый психологик төсмерләре хезмәт җитештерүчәнлеген һәм продукция сыйфатын күтәрүнең мөһим этәргечен тәшкил итә. Дөньяның алга киткән күпчелек илләре предприятиеләренең җитәкчеләре һәм эшмәкәрләре әлеге ысулны тиз арада куллана башлыйлар. Бу юлда Япония барысын да уздырып җибәрә. Әмма бүген башка илләр дә «уңышта катнашу» системасын кертүдә Кояш чыгышы иленнән калмаска тырышалар. Бүгенге көндә хезмәткәрләрнең компания табышын бүлүдә катнашуын тәэмин итүче ысуллар аеруча киң таралыш ала. Әмма кызыксындыруның тагы да камилрәк формалары барлыкка килде. Алар яллы хезмәткәрләрнең үзләре эшләгән предприятиедә милектәшкә әверелүенә нигезләнгән. Күп кенә илләрдә эшчеләргә милектәш булырга мөмкинлек биргән предприятиеләр өчен закон тарафыннан ташламалар тудырыла. Мәсәлән, «Крайслер» автомобиль компаниясенең һәр эшчесе бу компаниянең 6 мең долларлык капиталына ия. Данлыклы компьютер фирмасы «Майкрософт»ның иң яхшы программистлары билгән милек өлеше миллионлаган долларлар белән исәпләнә. Аларның «үз» фирмалары өчен шулкадәр тырышып эшләвенә бер дә гаҗәпләнәсе юк. Һәм бу, уңышлы сәүдә сәясәте белән беррәттән, әлеге компанияне дөньякүләм программалаштыру базарында алдынгы урыннарга чыгарды!

Гомумән алганда, АКШ та тулысынча яки өлешчә үз хезмәткәрләре милегендә булган (ИСОП системасы) предприятиеләрдә хәзер инде 12 миллионнан артык кеше эшли. «Уңышта катнашу» системасы аша кызыксындыру ысуллары Россиядә дә уңышлы гына кулланыла башлады.

Пенсия белән кызыксындыру. Һәр кешегә дә картлык киләчәк һәм аның хезмәткә сәләтле еллары да чикле. Күпчелек илләрдә хатын-кызлар 60 яшьтән соң, ә ирләр 65 яшьтән соң тулы хезмәт йөген күтәрә алмый дип исәпләнә. Һәм монда аларның нәрсә хисабына яшәргә тиешлеге турындагы сорау калка.

Моны, әлбәттә, һәр кешенең үз эше дип исәпләп, кеше үз картлыгы өчен үзе тупласын дип котылырга да мөмкин. Әмма мондый гакыллы гамәл бар кешегә дә хас түгел. Кешеләрнең картлык көннәрендә дә яшәү чаралары булсын өчен, күпчелек илләр пенсия белән тәэмин итү системасыннан файдаланалар. Аларда каралганча, кеше пенсия яшенә җиткәч **хезмәт пенсиясе** алырга хаклы.

ХЕЗМӘТ ПЕНСИЯСЕ — гражданга законда билгеләнгән яшькә җиткәч, инвалидлыкка дучар булгач, туендыручысын югалткач, шулай ук тиешле еллар эшләгәннән соң (выслуга лет) бирелә торган даими акчалата түләүләр.

Вадим ТУМАНОВ

Россиянең яңа эшмәкәрләре арасында иң якты фигураларның берсе булган Вадим Туманов — гаять авыр, әмма гаҗәеп язмышлы кеше.

Туманов 1928 елда туа. Диңгезче булырга ниятләп, ул штурманнар мәктәбен тәмамлый, әмма аның диңгезче карьерасы тормышка ашмый кала. 1948 елда, әле 20 генә яшь булганда, аны «Советка каршы пропаганда һәм агитация өчен» дип, ә чынлыкта исә Сергей Есенин шигырьләренә һәм Александр Вертинский җырларына мәхәббәте өчен кулга алалар һәм 8 елга лагерьларга хөкем итәләр. Гаделсез хөкем белән ризалашмыйча, ул 8 тапкыр лагерьлардан качмакчы була. Бары тик Сталин үлгәннән соң гына, аны гаепсез дип танып иреккә чыгаралар.

Тау осталары курсларын тәмамлап, Туманов яңа тормыш башлап җибәрә, торабара ил күләмендә танылган «Печора» алтын чыгару артелен ача. Әлеге артельдә шул чорларда СССР өчен бөтенләй яңа хезмәт төрләре һәм түләү формалары кертә, артельдә эшләүче һәр кешедә оешманың гомуми уңышы белән кызыксыну уята. Хезмәт мөнәсәбәтләренең мондый моделе хезмәт хакын артельдә бүлү кебек борынгы рус принцибына нигезләнә. Әлеге модель хәзерге Көнбатышның «уңышта катнашу» моделенә бик якын тора. Туманов артелендә һәр кеше хезмәтнең уртак нәтиҗәсен яхшыртудан аңа да файда килүен тоя, әлеге нәтиҗә үсешендә аның да өлеше булуын аңлый.

Шулай итеп, артель предприятиедә тагы да югарырак җитештерүчәнлеккә ирешә. Гади старательләр алтын чыгаручы эре предприятиеләр директорларына караганда да күбрәк хезмәт хакы ала. Тумановка кешеләр агыла. Ул мәшһүр актер һәм җырчы Владимир Высоцкийның дусты була. Высоцкий аңа багышлап җырлар яза. Әмма Тумановка аның хөр фикерен һәм артелендәге югары хезмәт җитештерүчәнлеген гафу итә алмыйлар. Бу дәүләт предприятиеләренең никадәр начар эшләвен аермачык күрсәтә. 1987 елда уйдырма бер сәбәп белән «Печора» артелен тараталар. Әмма Тумановның хезмәт мөнәсәбәтләрен оештыру моделе шулкадәр нәтиҗәле була һәм кешеләр күңеленә хуш килә, аны бөтенләй эзсез юк итә алмыйлар. Һәм озакламый «Печора» хәрабәләре өстендә яңа фирмалар корыла башлый, алар, мәсәлән, Россиядәге иң авыр мәсьәлә — юллар төзелеше эшенә керешә һәм уңыш казана.

Туманов үзе дә төшенкелеккә бирешми — инде өченче тапкыр бөтенесен яңадан башлап, «Туманов и К°» дигән акционерлык җәмгыятен төзи. Бу җәмгыять 1992 елның җәендә Себердә алтын чыгару хокукы алуга ирешә.

Әмма пенсия бары тик кешегә йөз белән борылган бурычларны гына хәл итми. Кешелек гакылы хәерче картлык алдында куркуны әллә кайчан инде бик яхшы эшләү стимулына әверелдерде. Шушы максатлардан чыгып, пенсияләр механизмы төзелә, һәм андый хезмәт пенсиясенең күләме турыдан-туры хезмәт хакы күләменнән һәм эшләгән вакыт озынлыгыннан бәйле була.

Россиядә пенсия законнарында каралган тәртип буенча, пенсия алу өчен, һичшиксез, 25 ел эшләү мәҗбүри (ә балалы хатыннарга — 20 ел). Әгәр дә кеше үз гомерендә күбрәк ел эшләсә, пенсиясе күләме аның базис зурлыгына карата артыграк була. Әлеге базис зурлык кеше алган хезмәт хакының процентларында билгеләнә. Күпчелек алга киткән илләрдә пенсияләр күләме кеше пенсиягә киткәнче алган хезмәт хакының 50—80% ын тәшкил итә. Димәк, кеше никадәр яхшырак эшләсә, ул картлык көнендә шулкадәр яхшырак яши.

Пенсия хосусый фирмалар яки дәүләт тарафыннан төзелгән махсус фондлардан алып түләнә. Россиядә соңгы вариант кабул ителгән, шуңа күрә пенсияләр бердәм Россия фондыннан алып түләнә.

Бу фондка акчалар предприятиеләр түләгән взнослар хисабына туплана һәм социаль страхованиегә чигерелгән акчаларның бер өлешен тәшкил итә. Безнең илдә дәүләт Пенсия фонды белән беррәттән күптән түгел дәүләтнеке булмаган пенсия фондлары (*рус.* НПФ) эшли башлады.

Алар картлык өчен өстәмә пенсиягә акча тупларга булышалар, һәм аларга взнослар кертү — һәркемнең үз эше.

Хезмәт хакын формалаштыру механизмнары турындагы сөйләшүне төгәлләп, икътисади акыллылыкның түбәндәге рецептын тәзибез.

Сигезенче рецепт

Гражданнарның тормыш шартларын яхшырту өчен, хезмәт базарында конфликтлар килеп чыгуга юл куймаска, эш бирүчеләр һәм яллы хезмәткәрләр арасында ирешелгән компромиссларны хупларга, минималь хезмәт хакының яшәү минимумыннан да түбән төшүен булдырмаска кирәк.

БҮЛЕКНЕҢ ТӨП ЭЧТӘЛЕГЕ

Профсоюзлар һәм хезмәт конфликтлары. *Хезмәткә базар бәясе формалашканда, гадәттә, эш бирүчеләр һәм яллы хезмәткәрләр арасында каршылыклар килеп чыга. Әлеге каршылыклар вакытында яклар үз ихтыярларын тагу өчен төрле ысуллардан файдалана. Ялланып эшләүчеләр мәнфәгатьләрен яклауның төп ысулы профсоюзлар төзүдән гыйбарәт, алар үз составларына керүче кешеләр исеменнән сөйләшүләр алып бара. Профсоюзлар, гадәттә, үз әгъзаларының хезмәт шартларын яхшырту, хезмәт куркынычсызлыгын күтәрү, шулай ук аларның хезмәт хакын арттыру өчен тырышалар. Бу хәл профсоюз әгъзалары эшен күңелгә ятышлырак һәм керемлерәк итә, әмма шул ук вакытта эш белән тәэмин ителүнең икътисади чикләрен тарайта һәм, әгәр дә бәядә табыш зурлыгы кимемәсә, сатып алучылар өчен товар бәясе артуга китерә.*

Хезмәт хакы формалашуның социаль факторлары. *Хезмәт хакы яшәү минимумыннан да түбәнрәк күләмдә исәпләнмәскә тиеш. Кешегә яшәү өчен иң кирәкле товар һәм хезмәт күрсәтүләрнең иң аз җыелмасын яшәү минимумы дип атыйлар. Минималь хезмәт хакы закон чыгаручы хакимият органнары тарафыннан билгеләнә һәм үзгәртелә, иң тәҗрибәсез, квалификациясез хезмәткәрләр эшенә түләү өчен кулланыла. Хезмәт базарында сату-алу килешүләрен формалаштыру хезмәт контрактлары һәм коллектив шартнамәләр төзү аша тормышка ашырыла. Коллектив шартнамәләр үз чиратында предприятие, тармак яки ил күләмендә төзелергә мөмкин. Соңгы очракта алар генераль килешү дип атала. Хезмәткә түләү контракт яки коллектив шартнамә белән билгеләнә. Боларга өстәмә рәвештә, эш бирүчеләр хезмәткәрләрнең хезмәт активлыгын һәм хезмәтләре сыйфатын яхшыртканнары өчен түләүнең яңа ысулларын да кулланалар. Хезмәт хакына өстәп түләүләр мондый кызыксындыруның иң мөһим ысулларыннан санала. «Уңышта катнашу» (хезмәткәрләрне фирманың милектәшләренә әверелдерү) һәм пенсия белән тәэмин ителү (кешенең картлык көнендәге тормышы аның гомер буе ничек эшләвеннән бәйле була) әнә шундый кызыксындыру юлларына керә.*

ФИКЕР АЛЫШУ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Бүген Россиянең күп кенә предприятиеләрендә һәм коммерция фирмаларында профсоюзлар юк. Илнең хезмәт базарын бу нинди нәтиҗәләргә китерергә мөмкин?
2. Әгәр дә ил профсоюзларының җитәкчеләре «Россия товарларын сатып ал — эшсез калмассың!» дигән өндәмә астында безгә импорт товарлар кертүне киметү кампаниясе башлап җибәрсә, аларны күпчелек ватандашларыбыз яклар микән?
3. Пенсия фондына мәҗбүри күчермәләр хезмәткәрләрнең хезмәт хакын киметә. Мондый күчермәләрдән баш тартып, картлык көненә акча туплауны һәр кешенең үз ирегенә кую кирәкме?

Эшсезлекнең икътисади проблемалары

БҮЛЕКТӘ КАРАЛУЧЫ МӘСЬӘЛӘЛӘР:

1. ЭШСЕЗЛЕК НИ ӨЧЕН КИЛЕП ЧЫГА?
2. ЭШЛӘМӘҮЧЕ ҺӘР КЕШЕ ЭШСЕЗМЕ?
3. ХЕЗМӘТ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТЕЛҮНЕ НИЧЕК АРТТЫРЫРГА?

Кешене эшсез дип тану критерийлары закон яки хөкүмәт документлары белән билгеләнә һәм һәр илнең үзенә генә хас критерийлары була.

> Сез үзегез эшсез икән, эшсезлек дәрәҗәсе 100% ка тигез була.
>
> *Аноним*

§ 18. Эшсезлекнең сәбәпләре һәм төрләре

Билгеле бер эшчәнлек төре белән шөгыльләнүче хезмәткәрләр саны һәм аларның хезмәт хакы ни белән билгеләнә? Әлеге сораулар микроикътисад өлкәсенә карый. Хезмәт базары эшчәнлеге закончалыкларын өйрәнү аларга җавап табарга булышачак.

Әмма хезмәт эшчәнлеге **эшсезлек** проблемасы белән бәйләнгән. Әлеге термин илдә урнашкан хезмәткә түләү күләменә риза булып актив төстә эшләргә әзер торучы, әмма эш таба алмаучы кешеләр булуын белдерә.

***ЭШСЕЗЛЕК** — илдә урнашкан хезмәткә түләү күләменә риза булып эшкә ялланырга сәләтле һәм теләүче, әмма үз белгечлекләре буенча эш таба алмаучы яки бөтенләй эшкә урнаша алмаучы кешеләр булу.*

Эшсезлекне гомумикътисади проблемаларга кертәләр, чөнки:

1) аны илкүләм икътисад процесслары китереп чыгара;

2) ул үзе дә бөтен ил хуҗалыгына йогынты ясый.

Дөньяда эшсезлекнең теге яки бу төре булмаган илне табу мөмкин түгел. Россия дә шулар рәтенә керә. Эшсезлек куркынычы ялланып эшләүче һәр хезмәткәрне сагалый, һәм аның каян янавын, никадәр дәвамлы булачагын һәм аңа каршы ничек көрәшергә кирәклеген күзаллау зарур.

Эшсезлек проблемаларын анализлау өчен, иң элек кемнең эшсез дип исәпләнүен төгәл билгеләргә кирәк. Кешене эшсез дип тану критерийлары закон яки хөкүмәт документлары белән билгеләнә һәм төрле илләрдә алар бераз аермалы булырга мөмкин. Әмма, кагыйдә буларак, барлык билгеләмәләрдә дә берничә сыйфат кабатлана. Болар:

— *хезмәткә сәләтле яшьтә* булу, ягъни кеше закон ялланып эшләргә рөхсәт иткән минималь яшьтән (15 яшь) өлкәнрәк, әмма картлык буенча пенсия билгеләнгән яшьтән кечерәк булырга тиеш. Димәк, хезмәткә сәләтле яшькә кадәр булган яшүсмерләр яки 60 яшьтән олырак ирләр һәм 55 яшьтән өлкәнрәк хатын-кызлар (Россиядә), эшләргә теләп, эш таба алмасалар да, эшсезләр дип санала алмыйлар;

— кешенең билгеле бер вакыт дәвамында (мәсәлән, ай буе) *даими хезмәт хакы чыганагы булмау;*

— *кешенең эш табу омтылышы дәлиле* (мәсәлән, аның мәшгульлек хезмәтенә мөрәҗәгать итүе һәм әлеге хезмәт вәкилләре җибәргән эш бирүчеләргә баруы).

Эшсезлек дәрәҗәсе	=	Эшсезләр саны / Эшче көчләр саны	=	Эшсезләр саны / (Эшле гражданнар саны + Эшсезләр саны)

Шушы сыйфатларга ия булган кеше генә, чыннан да, эшсез дип исәпләнә һәм илдәге *гомуми эшсезлек дәрәҗәсен,* ягъни илдәге барлык эшче көче санындагы эшсезләр өлешен билгеләгәндә исәпкә алына.

Боларга нәтиҗә ясап, без **«эшче көчләр»** (икътисади актив халык) терминына төгәлрәк билгеләмә бирә алабыз.

ИКЪТИСАДИ АКТИВ ХАЛЫК (эшче көчләр) — илдә эшле булган яки эшле була алган хезмәткә сәләтле яшьтәге гражданнарның гомуми саны.

Эшсезлек — иң алга киткән илләр өчен дә иң авыр проблемаларның берсе. Эшсезлек мәсьәләсенең аеруча җитдилеген кайбер сәбәпләр китереп чыгара.

Беренчедән, кеше — үзенчәлекле икътисади ресурс төре ул. Әгәр дә аны икътисадта хәзер файдаланмасаң, аны алдагы көннәр өчен саклап яки «суыткычка куеп торып» булмый. Югалган эш вакыты кире кайтарылмый һәм эшсезлек аркасында бүген житештерелмичә калган әйберләр киләчәктә дә эшләнмәячәк.

Икенчедән, кеше эшләмәсә дә кулланудан туктамый һәм аңа барыбер үз гаиләсен туендырырга туры киләчәк. Шуңа күрә җәмгыять эшсезләрне ач үлемнән яки начар юлга басудан саклап калу юлларын эзләргә мәҗбүр. Әмма бу максатка юлланган акчалар яңа әйберләр җитештерүгә тотылмый, димәк, илнең барлык гражданнары тормышын яхшыртуга илтми дигән сүз.

Өченчедән, эшсезлек арту эчке базарда товарларга сорауны киметә. Хезмәт хакы алмаган кешеләр җан асрарлык кына аз күләмдәге әйберләргә риза булып яшәргә мәҗбүрләр. Шулай итеп, илнең эчке базарында товар сату кыенлаша («базар кысыла»). Эшсезлек үсеше илдәге икътисади проблемаларны кискенләштерә һәм хезмәт белән тәэмин ителүнең кимүенә этәргеч ясый. Бу котылгысыз боҗра гаять куркыныч: һәр әйләнеш саен аны чишеп җибәрү тагы да кыенлаша бара.

Дүртенчедән, эшсезлек илдәге сәяси вазгыятьне кискенләштерә. Мондый хәл үз гаиләләрен җиту тормышта яшәтә алу мөмкинлегеннән коры калган һәм көн арты көн эш эзләп интеккән кешеләрнең ачулары көчәю аркасында туа.

Бишенчедән, эшсезлек арту җинаятьләр саны күбәюгә дә китерә, чөнки кешеләр кирәк әйберләрне үзләштерү өчен шундый начар юлга басарга мөмкин.

Эшсезлек — дөньякүләм күренеш: Берләшкән Милләтләр Оешмасы мәгълүматлары буенча, дөньядагы эшсезләр саны 800 миллионга житкән.

Эшсезлек төрләре бик күп, аларны китереп чыгара торган сәбәпләр дә күптөрле. Бүген икътисадчылар тулаем эшсезлек турында сөйләмәскә тырышалар, ә аның үзенчәлекле төрләрен аерып күрсәтүне кулайрак күрәләр:

— фрикцион эшсезлек;
— структур эшсезлек;
— циклды эшсезлек;
— сезонлы эшсезлек.

Фрикцион эшсезлек хәтта икътисади яктан гөрләп үсүче илләрдә дә бар. Аның сәбәбе шунда ки, үз предприятиесеннән эштән җибәрелгән яки аннан үз ихтыяры белән киткән кешегә яңа эш урыны табу өчен күпмедер вакыт таләп ителә. Әлеге эш аны эшчәнлек төре буенча да, түләү дәрәҗәсе буенча һәм еш кына башка яклардан да канәгатьләндерергә тиеш була.

Өстәвенә хезмәт базарында әле беренче тапкыр гына эш эзләүче эшсезләр дә була (яшьләр, балаларын үстереп җиткергән хатын-кызлар һ. б). Мондый «яңалар» фрикцион эшсезлек дәрәҗәсен билгеләгәндә шулай ук исәпкә кертелә.

Икътисад фәне фрикцион эшсезлекне гадәти хәл дип кабул итә һәм аның өчен хәвефләнү кирәк түгел дип исәпли. Алай гына да түгел, фрикцион эшсезлек — тиешенчә эшләүче икътисадта котылгысыз күренеш, чөнки анда кешеләрнең эш урыны эзләү иреге чагылыш таба.

Фрикцион эшсезлек артуга ни этәрә икән соң?

Монда берничә төп сәбәпне аерып күрсәтергә кирәк:

1) кешеләрнең аерым бер фирмада аларны канәгатьләндерерлек хезмәт хакы булган эш табу мөмкинлеге турында мәгълүматлары булмау;

2) объектив төстә эшче көченең мобильлеген киметүче факторлар. Мәсәлән, кеше үз шәһәрендә эш тапмый, ә андый эш булган шәһәргә ул күчә алмый һәм пропискасы юк. Россия өчен әнә шушындый хәл хас, бу аны тискәре яктан, әйтик, АКШ хезмәт базарыннан аерып тора. Америка хезмәткәрләре, торак базары алга китү, прописка яки теркәлү мәҗбүрияте булмау һәм шулай ук уңайлы социаль һәм мәдәни шартлар аркасында, бер шәһәрдән икенчесенә бик җиңел күчеп йөри алалар;

3) яшәү рәвеше һәм милли характер үзенчәлекләре. Фрикцион эшсезлек социаль-мәдәни сәбәпләр аркасында гомер буе бер генә торак пунктта яшәүне кулай күргән, ягъни түбән мобильлек белән аерылып торган илләрдә югары була. Мондый яшәү рәвеше булганда (россиялеләрнең күбесе шулай яши), регионнар арасында эшче көчләр күчеше кими.

Структур эшсезлек бер һөнәр хезмәткәрләренә сорауны киметеп, икенчеләренә арттыручы техник прогресс нәтиҗәсендә барлыкка килә. Башкача әйтсәк, структур эшсезлек төрле профессия хезмәт базарларында эшче көчләргә сорау һәм тәкъдим структурасындагы аермалар аркасында эшкә урнашып булмаудан килеп чыга.

Мондый эшсезлек фрикцион эшсезлеккә караганда күп тапкыр авыррак. Структур эшсезлек вакытында күп кенә кешеләргә яңа профессияләр үзләштерергә туры киләчәк һәм элекке профессияләрендә алган кадәр керемне киләчәктә дә ала алырлармы, юкмы анысы да билгеле түгел.

Структур эшсезлектән котылып булмый. Мондый хәл техник прогрессның туктаусыз яңа товарлар, технологияләр тудыруы белән бәйләнгән (аларга, мәсәлән, персональ компьютерлар, лазер дисклар һ.б. карый). Нәтиҗәдә эшче көчләргә булган сорау бик нык үзгәрә, кайбер профессия кешеләре элекке санда ук кирәк булмый һәм алар эшсезләр рәтен тулыландыра.

Мәсәлән, Россиягә күп санлы персональ компьютерлар кертү зур ЭВМнардан баш тартуга китерә, алар белән эшләүче күп санлы программистларның кирәге калмый. Компьютерлар белән бергә чит илдән яңа буын программалы продуктлар да үтеп керде, алар машина белән арадашчы-программисттан башка да аралашу мөмкинлеге тудырды. Иске мәктәп программистлары, эшләрен саклап калу яки яңа эш табу өчен, тиз арада яңадан укырга, яңа программалаштыру телләрен һәм яңа программа пакетларын үзләштерергә мәҗбүр булдылар.

Сорау структурасындагы үзгәрешләр аеруча арта бара. Мәсәлән, Россиядә бик күп еллар дәвамында инженерлар әзерләүче вузлар саны артканнан-арта барды, ә бүгенге хезмәт базары бөтенләй башка һөнәр белгечләрен таләп итә. Мәсәлән, 2001 елның апрелендә Мәскәү һәм Санкт-Петербург хезмәт базарларында, «Форум карьер» («The Career Forum») газетасы мәгълүматларына караганда, түбәндәге һөнәр ияләре таләп ителә:

региональ маркетинг тикшеренүләре өчен өлкән координатор;
сәүдә маркасы менеджеры;
реклама һәм маркетинг менеджеры;
салым аналитигы;
баш бухгалтер;
компьютерда проектлаштыру системаларын белүче проектлаштыручы инженер;
фармацевтика компанияләренең сәүдә вәкиле;
бизнес үсеше консультанты;
проект менеджеры;
өлкән финанс аналитигы;
телекоммуникация системалары аналитигы;
маркетинг мәгълүматларын җыю белән идарә итүче менеджер.

Бу белгечләргә сорау әле бүген дә саклана.

Гаять авыр булган структур эшсезлек, башка белгечлекләре булып та эш эзләүче кешеләр саныннан ирекле эш урыннары саны калышмаган очракта, илне әллә ни дулкынландырмаска да мөмкин. Әгәр дә инде эш урыннары эшсезләргә караганда азрак икән, ул чакта хәлләр бик хөрти. Бу исә илдә эшсезлекнең иң авыр циклы формасы башлануны белдерә.

Циклы эшсезлек гомуми икътисади үсешләре кимегән илләргә хас. Мондый очракта кризис күренешләре аерым тармакларда гына түгел, ә барлык товар базарларында күзәтелә. Илнең күпчелек фирмалары кыенлык кичерә, шуңа күрә бер үк вакытта һәм бөтен җирләрдә дә массакүләм эштән җибәрүләр башлана. Шулай итеп, ирекле эш урыннары эшсезләр санына караганда азрак булып чыга.

Кайчакларда эшсезләр категориясенә (бик үк дөрес булмаса да) **сезонлы хезмәткәрләрне** кертәләр. Алар кайбер эшчәнлек төрләре белән елның билгеле бер фасылларында гына шөгыльләнеп булганга күрә эшсез кала. Моның иң ачык мисалы — авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре. Алар күбесенчә уңыш җыйганда гына мәшгуль булып, башка вакытларда очраклы хезмәт хаклары белән көн күрә.

9-1 рәсем.
Эшсезлек төрләре барлыкка килү шартлары

Сезонлы эшсезлек — күп кенә һөнәр ияләренә, мәсәлән, курортларда ял итүчеләргә хезмәт күрсәтүчеләргә таныш күренеш. Мондый эшсезлек, әлбәттә, кайбер проблемаларны китереп чыгара, әмма анда берниндн дә яман нәрсә юк: яңа сезон җитү белән эш тә кире кайта. Алай гына да түгел, сезонлы эшсезләр эшсез дигән билгеләмәгә бик үк туры да килеп бетмиләр, чөнки алар даими эш урыны эзләү белән әллә ни шөгыльләнмиләр: аларның кайберләренә мондый яшәү рәвеше бик ошый, ә башкаларының тиешле квалификациясе яки аңа ирешү теләге булмый.

Эшсезлек төрләре арасындагы аерманы 9-1 рәсемен күреп аңларга һәм истә калдырырга мөмкин.

Россия икътисады өчен хәзер структур эшсезлек хас, аңа шулай ук циклы һәм фрикцион эшсезлек тә өстәлә. Бу 90 нчы еллар башыннан алып үткәрелүче дәүләт сәясәте (хосусыйлаштыру һәм структур үзгәртеп кору) һәм шулай ук икътисад эшчәнлеге шартлары белән бәйләнгән.

Безнең илдә аеруча үзенчәлекле күренеш — **тулы булмаган эшлелек** тә күзәтелә.

ТУЛЫ БУЛМАГАН ЭШЛЕЛЕК — кеше рәсми рәвештә эшле булып саналып та, мәҗбүри ялда булу аркасында, хезмәт хакы алмый, яки тулы эш көне эшләмәгәнгә күрә, тиешле хезмәт хакының бер өлешен генә ала торган ситуация.

Тулы булмаган эшлелекнең Россиядә иң киң таралган төрләре түбәндәгеләр:

— хезмәткәрләрне түләнми торган ялга җибәрү;

— кыска эш көне яки кыска эш атнасы кертү.

Мондый хәлдә калган кешеләр эш белән тәэмин итү хезмәтләрендә исәптә тормыйлар һәм эшсезлек буенча ярдәм алмыйлар. Икътисад фәнендәге критерийлар буенча караганда, аларны эшсезләр дип атап булмый. Әмма хезмәт активлыгы һәм хезмәт хаклары буенча алар теркәлгән эшсезләргә караганда авыррак хәлдә калалар.

Россиядәге хәзерге тулы булмаган эшлелекнең тамырлары командачыл система заманнарына барып тоташа. Беренче бишьеллык заманнарында икътисадның экстенсив үсеше һәм Конституциядә хезмәткә хокукның законлы төстә беркетелүе эшсезлекнең юкка чыгуына китерде, әмма предприятиеләрдә хезмәткәрләр саны артык күп иде.

СССРда халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә (моны хезмәт базары дип атап булмый) барган процессларның асылын төшенү өчен, монда күзәтелгән **монопсония** дигән хәлнең ни булуын аңлатып үтү кирәк. Ә монопсонист булып дәүләт тора, барлык эш урыннары да аңа карый, хезмәт хакы күләмен дә ул билгели.

ЗАКОН КУШКАНЧА

Россиядә эшче көчләр базары 1991 елның апрелендә кабул ителгән «РСФСРда халыкның хезмәт белән тәэмин ителеше турындагы» Закон белән көйләнә.

Бу закон түбәндәгеләрне билгели:

— һәр граждан үзенең җитештерү һәм иҗади хезмәткә сәләтен ирекле рәвештә, үзе теләгәнчә файдаланырга хокуклы, шуңа күрә аны беркем дә берничек тә хезмәткә мәҗбүр итә яки эшләмәгәне өчен җәзага тарта алмый;

— эше һәм хезмәт хакы булмаган, үзе өчен кулай эшне эзләү максатында эш белән тәэмин итү оешмасында теркәлгән һәм мондый эш урыны табылган очракта эшли башларга әзер торган граждан эшсез дип исәпләнә;

— тәкъдим ителгән эш кеше ризалыгыннан башка яшәү урыны үзгәртүне таләп итсә, ә кетеләчәк хезмәт хакы элекке эш урынындагы уртача хезмәт хакыннан кимрәк булса, мондый эш аның өчен кулай дип исәпләнергә тиеш түгел;

— Россия гражданнары чит илләрдә эшләргә һәм анда эш эзләргә хокуклы;

— эшсезләргә ярдәм итү максатында Халыкны хезмәт белән тәэмин итүче дәүләт фонды төзелә. Барлык эш бирүчеләр бу айдагы хезмәт хакы түләргә тотылган гомуми сумманың 1%ы күләмендә әлеге оешмага ай саен акча күчерергә тиеш;

— эшсезләр эшсезлек буенча пособие алырга хокуклы. Аның күләме аларның соңгы эш урынындагы түләүнең бер өлешен тәшкил итәргә, әмма минималь хезмәт хакыннан түбән булмаска тиеш; беренче тапкыр эш эзләүче яшьләр өчен дә пособие билгеләнә;

— эшсезлек буенча пособие эш югалткан вакыттан башлап 12 айдан да артык түләнми;

— Халыкны хезмәт белән тәэмин итү буенча дәүләт комитеты хезмәтләре эш эзләргә ярдәм итәләр.

МОНОПСОНИЯ — базарда товарларны бер генә сатып алучы (монопсонист) булганда һәм ул үзенең шушы өстенлегеннән файдаланып, сатучыларга товарларны алу шартларын, барыннан да элек, аларга бәяләрне көчләп тага алганда була торган ситуация.

§ 19. Эшсезлекне ничек киметергә мөмкин

Эшсезлекнең күптөрле булуы әлеге бурычны гаять катлауландыра. «Эшсезлектән бердәм дару» булмаганлыктан, һәр илдә әлеге мәсьәләне хәл итүнең төрле юлларын кулланалар.

Фрикцион эшсезлек күләме түбәндәге юллар белән киметелергә мөмкин:

1) хезмәт базарын мәгълүмати тәэмин итүне яхшырту. Барлык илләрдә дә бу вазифаны эшкә урнаштыру оешмалары (хезмәт биржалары) башкара. Болар эш бирүчеләрдән аларда булган вакансияләр турында мәгълүмат җыялар һәм аны эшсезләргә житкерәләр;

2) эшче көчләр мобильлеген киметүче факторларны бетерү. Моның өчен иң элек: а) нык үскән торак базары булдырырга; б) торак төзелеше колачын җәелдерергә һәм в) бер торак пункттан икенчесенә күчүне чикләүче административ киртәләрне юк итәргә кирәк.

Структур эшсезлекне аеруча яңа һөнәргә өйрәтү һәм яңа белгечлек үзләштерү программалары ярдәмендә киметергә мөмкин.

Циклы эшсезлеккә каршы көрәшү исә барысына караганда да авыррак. Бу бурычны хәл итү өчен күптөрле чаралар кулланырга туры килә.

Аларның кайберләре белән танышып үтик.

Товарларга сорау арттыру шартларын тудыру. Хезмәт базарында сорауның өстәмә (производный) төшенчә булуын һәм товарлар, хезмәт күрсәтүләр базарларындагы вазгыятьтән бәйлелеген инде ачыклаган идек. Димәк, товар базарларының соравы артып, аны канәгатьләндерү өчен өстәмә хезмәткәрләр ялларга туры килсә генә, эшсезлек кимеп, мәшгульлек артачак.

Күпчелек Россия сәясәтчеләренең түбәндәге схеманы тормышка ашыру өчен икътисадка өстән акча «бөркү» турындагы өндәмәләре әнә шуның белән бәйләнгән дә: гражданнарның керемнәрен күтәрү → товарларга сорау арту → соралган товарларны житештерүнең үсүе → бу товарларны житештерүче предприятиеләрдә эш белән тәэмин ителүнең артуы.

Эшсезлеккә каршы көрәшүче әлеге схеманың инфляция сикерешe кебек житди кимчелеге дә бар. Чөнки товарлар житештерүне арттыру өчен вакыт кирәк, ә өстәмә акча базарга кичекмәстән шунда ук агылачак. Нәтиҗәдә сорау артачак һәм элеккечә калган тәкъдим аркасында, кичекмәстән бәяләр күтәреләчәк. Шуңа күрә сорауны арттыру өчен түбәндәге чаралар кулайрак дип исәпләнә:

— *экспорт үсешенә булышу.* Бу ил предприятиеләрендә житештерү күләмнәре үсүгә һәм, димәк, алардагы эш белән тәэмин ителүнең артуына китерергә мөмкин;

— *продукциянең конкуренциягә сәләтен күтәрү максатында, предприятиеләрне реконструкцияләүгә инвестицияләр бирү һәм моны хуплау*. Шулай булганда, предприятиеләр базарда үз өлешләрен арттыра, җитештерү һәм эш белән тәэмин итү колачын киңәйтә алачак;

— *чит илләрнең Россия икътисадын инвестицияләвен хуплау*. Шундый инвестицияләр ярдәмендә яңа җитештерү предприятиеләре ачыла, яки гамәлдәгеләр үзгәртеп корыла. Нәтиҗәдә җитештерү һәм россиялеләрнең хезмәт белән тәэмин ителеше арта.

Хезмәтне тәкъдим итүне киметү өчен шартлар тудыру. Мәгълүм ки, эш урыннарын дәгъва итүче кешеләр саны никадәр азрак булган саен, бу эш урыннары да шул ук санда булуга карамастан, эш табу шулкадәр җиңелрәк булачак. Әлеге эш урыннарын дәгъвалаучылар санын киметергә, алай гына да түгел, эшсезләр өчен өстәмә вакансияләр дә булдырырга мөмкин.

Мәсәлән, әлегә пенсия яшенә җитмәгән хезмәткәрләргә вакытыннан элек пенсиягә китү мөмкинлеге бу эштә күпмедер җиңеллек тудыра. Россиядә, мәсәлән, союзкүләм идарә органнарын бетергәндә, анда эшләүче ир-атларга 57—58 яшьтән, ә хатын-кызларга 53—54 яшьтән пенсиягә китү мөмкинлеге бирделәр. Болай булмаганда, аларга эш эзләргә туры килер иде. Бу яшьтә эшкә урнашу гаять авыр булганлыктан, алар эшсезләр рәтен тулыландырыр иде. Вакытыннан элек бирелгән пенсия мондый хәлне булдырмый калырга ярдәм итте.

Шулай да бу алым бик сирәк очракларда гына кулланыла ала, чөнки ул пенсия түләүләренең шактый артуына китерер иде.

Үз эшен ачуга этәрүче шартлар тудыру. Мондый программаларның мәгънәсе кешеләргә, алар эшкә яллана алмаган очракта да үз-үзләрен һәм гаиләләрен карап-тәрбияләп тора алсын өчен, үз эшләрен ачуга ярдәм итүдән гыйбарәт.

Бу программаларның эчтәлеге гаять күптөрле булырга мөмкин. Мәсәлән, кайбер илләрдә башлангыч эшмәкәрләр өчен махсус «бизнес-инкубаторлар» оештыралар. Мондый «инкубатор»лар, гадәттә, биналар комплексыннан гыйбарәт була. Аларда яңа фирмаларга билгеле бервакыт дәвамында бүлмәләрдән, элемтә хезмәтеннән һәм коммерция эшчәнлегенең төрле аспектлары буенча белгечләр консультацияләреннән бушлай файдалану мөмкинлеге тудыралар. Аякка басып, табыш ала башлагач, фирма үзеннән соң килүчеләргә юл биреп, инкубатордан китә.

Россиядә үз эшен ачуга ярдәм итүне дәүләт үз кулына алды. Шушы максатларда Кече эшмәкәрлекне яклау программасы кабул ителде һәм әлеге программаны тормышка ашыру белән шөгыльләнүче дәүләт органнары төзелде. Аларның максаты илебезнең яңа эшмәкәрләренә уңышлы итеп эшли башларга һәм, ким дигәндә, үз гаиләләрен тәэмин итәргә, ә иң яхшысы бизнесмен сыйфатлары булмаган һәм ялланып кына эшли алган, әмма хәзер эшсез калганнар өчен яңа эш урыннары булдырырга ярдәм итүдән гыйбарәт.

Яшь хезмәткәрләргә ярдәм программасын гамәлгә ашыру. Эшсезлек бигрәк тә олы яшьтәгеләр (җитештерү сәләтләре кимү һәм сәламәтлекләре какшау аркасында, аларны беркем дә эшкә алырга теләми) һәм бик яшьләр (аларны, квалификацияләре түбән булу һәм тәҗрибәсезлекләре аркасында, эшкә алмаска тырышалар) өчен аяныч.

Яшьләргә ярдәм йөзеннән төрле алымнар кулланылырга мөмкин:

— яшьләрне эш белән тәэмин итүчеләрне икътисади яктан кызыксындыру (мәсәлән, штатларында килешенгән күләмдә яшь хезмәткәрләр тотучы фирмаларга күпмедер күләмдә салым ташламалары бирелә);

— яшьләргә эш тәкъдим итүче махсус фирмалар төзү;

— яшьләр өчен эшкә урнашу мөмкинлеге зур булган һөнәрләргә өйрәтү үзәкләре төзү.

Эшсезлекне киметү программалары исемлеген әле тагы да дәвам итеп булыр иде — төрле илләрдә аларның күп төрләре уйлап табылган. Әмма әлеге программаларның берсе дә циклы эшсезлекне тулысынча бетерә яки шактый киметә алмый. Мондый нәтиҗәгә бары тик илдәге гомуми икътисади хәлне яхшырткач, ягъни эшсезлек буенча пособиегә ялыручыларне сорау үсә башлаган товарлар җитештерүгә җәлеп итү файда китерә башлагач кына ирешеп булачак. Россия өчен вакыйгаларның әнә шундый агышы мөһим дә, чөнки шул очракта гына барлык регионнардагы эшсезләр саны фрикцион һәм структур эшсезлеккә тиң дәрәҗәгә төшәчәк.

Эшсезлек проблемаларын өйрәнеп, икътисад фәне фрикцион һәм структур эшсезлек — нормаль күренеш һәм ул ил үсешенә куркыныч тудырмый дигән нәтиҗәгә килә. Алай гына да түгел, эшсезлекнең әлеге төрләреннән башка үсеш бармый да. Әгәр барлык хезмәткәрләрнең дә эш урыннары булса, ничек итеп яңа фирмалар төзеп, яки базарда күп соралган товарлар җитештерүне арттырып булыр иде соң?

Өстәвенә, эшсезлек булгач, кешеләр үз эш урыннарын югалтудан курка һәм тагы да җитештерүчәнрәк һәм сыйфатлырак итеп эшли. Әлеге позициядән караганда, эшсезлекне яхшырак эшләүгә этәргеч, стимул диярга мөмкин (Борынгы Римда туган «стимулус» сүзе белән йөк ишәкләре тизрәк барсын өчен аркаларына төртә торган очлы таякны атаганнар). Менә ни өчен күпчелек алга киткән илләрдә, тулы эшлелекне, фрикцион һәм структур эшсезлек яшәп тә, бары тик циклы эшсезлек бетерелү генә дип аңлыйлар. Башкача әйткәндә, бу илдәге эшсезлек үзенең **гадәти нормасына** туры килә торган халәт була.

Шулай итеп, тулы эшлелек дәрәҗәсе түбәндәге тигезләмә белән күрсәтелә:

Тулы эшлелек = Эшче көч × (1 — Эшсезлекнең гадәти нормасы)

Һәр илдә үзенә генә хас эшсезлекнең гадәти нормасы урнаша һәм аны билгеләүче бердәм күрсәткеч юк. Мәсәлән, 70 нче еллар уртасында Америка икътисадчылары үз илләре өчен әлеге норма 4% тәшкил итә дип исәпләделәр. Ә 80 нче еллар уртасында әлеге күрсәткеч 6,5—7,0% ка кадәр күтәрелә.

Россиядә эшсезлекнең гадәти нормасы чама белән хезмәт яшендәге халык санының 3—3,5%ын тәшкил итә. Шуның белән бергә, статистика мәгълүматлары буенча 2004 елның маенда эшсезлек дәрәҗәсе (икътисади актив халык санына карата процентларда) Россиядә 7,2% ка җитә. Бу күрсәткеч Япониягә (4,6%), Бөекбританиягә (4,8%) һәм АКШка (5,6%) караганда югарырак, Канада белән бертигез, ә Франциядәгедән (9,8%) яки Германиядәгедән (11,5%) кимрәк.

Россиядә эшсезлекне киметүдә халыкның эш белән тәэмин ителешенә булышучы дәүләт сәясәте зур роль уйный. Аның буенча түбәндәгеләр күз алдында тотыла:

1) РФның барлык гражданнары өчен, аларның милләтенә, җенесенә, яшенә, социаль чыгышына, сәяси карашларына һәм дингә мөнәсәбәтенә бәйсез рәвештә, ирекле хезмәт һәм хезмәтне үзе сайлап алу хокукын тормышка ашыруда тигез мөмкинлекләр тудыру;

2) гражданнарның закон кысаларында тормышка ашырылган хезмәт һәм эшмәкәрлек башлангычларын яклау, аларның җитештерү һәм иҗади хезмәткә сәләтләрен үстерүдә ярдәм итү;

3) социаль яклауга аеруча мохтаҗ булган һәм эш табуда кыенлыклар кичергән гражданнарны (мәсәлән, инвалидларны; ирегеннән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгәннәрне; беренче тапкыр эш эзләүче 18 яшькәчә булган үсмерләрне, яки пенсия яшенә җитеп килүчеләрне) эш белән тәэмин итүгә булышучы махсус чаралар үткәрү;

4) социаль яклауга аеруча мохтаҗ булган һәм эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче гражданнар өчен эш урыннарын саклаучы һәм яңаларын булдыручы эш бирүчеләрне хуплау, яклау.

Хәзер без икътисади акыллылыкның тагын бер рецептын тәзи алабыз.

Тугызынчы рецепт

Гражданнарның хәерчеләнүен кисәтү һәм илдә социаль тынычлык урнаштыру өчен, эшсезлекнең гадәти югарылыктан күтәрелмәвенә ирешү һәм эшсезләргә эш табуда ярдәм системасын булдыру зарур.

БҮЛЕКНЕҢ ТӨП ЭЧТӘЛЕГЕ

Эшсезлек сәбәпләре һәм төрләре. *Эшсезлек дигәндә, илдә урнашкан хезмәткә түләү күләменә риза булып эшләргә теләүче, әмма эш таба алмаучы кешеләр булуны аңлыйлар. Эшсезлек һәрбер икътисади системада күзәтелә, әмма аның формалары гына төрле була. Эшсезлек дәрәҗәсе илдәге гомуми эшче көчләр санында эшсезләр өлешен исәпләп чыгару белән бәйләнә. Гадәттә, эшсезлекне фрикцион, структур, циклы һәм сезонлы төрләргә бүлеп карыйлар. Циклы эшсезлек аеруча кыен проблемалар китереп чыгара. Эш эзләүчеләрнең гомуми санында эшсезлек төрләренең чагыштырмасы илдәге гомумикътисади вазгыятьтән һәм яңа эш урыннары эзләү механизмнары үсешеннән бәйле була. Эшсезлекнең икътисади һәм социаль яктан тискәре аспектлары булуга карамастан, аны тулысынча бетерү мөмкин түгел һәм моның кирәге дә юк. Билгеле бер күләмдәге эшсезлек ил өчен хәтта файдалы да. Ул товар базарларындагы хәл үзгәргәндә җитештерү структурасын тизрәк үзгәртү мөмкинлеген тәэмин итә. Эшсезлекнең мондый кулай дәрәҗәсен эшсезлекнең гадәти нормасы дип атау кабул ителгән. Ул илдәге тотрыклы икътисади үсеш чорында урнашкан күпьеллык фрикцион һәм структур эшсезлек дәрәҗәсенә туры килә.*

Эшсезлекне ничек киметеп була. *Эшсезлекне киметү өчен, товарларга сорауны арттыруга юнәлдерелгән алымнар кулланырга мөмкин. Әнә шулай итеп, яхшы сатылучы товарлар җитештерүче предприятиеләрдә эш белән тәэмин ителүне үстерүче шартлар тудырыла. Моннан тыш та, эшсезләрнең барысына яки аерым төркемнәренә (иң элек өлкән яшьтәгеләргә, яшьләргә, хатын-кызларга, инвалидларга) турыдан-туры ярдәм итү программалары да кулланылырга мөмкин. Гадәттә, мондый программалар хезмәт базарында күп соралган һөнәрләр үзләштерүдә, вак гаилә фирмалары төзүдә, күбесенчә яшьләргә яки инвалидларга һ.б. эш бирүче предприятиеләр оештыруда ярдәм күрсәтәләр.*

ФИКЕР АЛЫШУ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Бүген Россиядә яшерен эшсезлек ачыктан-ачык күренешкә әверелде, һәм кешеләр эшсезләр сыйфатында теркәлергә мәҗбүр булды. Бик күпләр моны бик авыр кабул итә һәм бу хәлгә калуларыннан кимсенә. Яшерен эшсезлеккә кире кайту кешелеклерәк булыр идеме?
2. Россия хөкүмәте ни өчен төньяк районнарда урнашкан артык чыгымлы һәм өметсез предприятиеләрдә эшләүче кешеләрне аннан күчереп утырту программасын башламый?

УНЫНЧЫ БҮЛЕК

Фирма нәрсә ул һәм базарда ничек эшли

БҮЛЕКТӘ КАРАЛУЧЫ МӘСЬӘЛӘЛӘР:

1. ФИРМА КАЙЧАН ЯШӘҮ ХОКУКЫ АЛА?
2. «НОРМАЛЬ ТАБЫШ» НӘРСӘ УЛ?
3. ЧЫГЫМНАР БЕЛӘН ИДАРӘ ИТЕП БУЛАМЫ?
4. КОНКУРЕНЦИЯНЕҢ (КӨНДӘШЛЕКНЕҢ) НИНДИ ТӨРЛӘРЕ БУЛА?
5. ЭШМӘКӘРЛЕК (ЯКИ ЭШКУАРЛЫК) ТАЛАНТЫ НӘРСӘ УЛ?

Бу борынгы рәсемдә дөньядагы тәүге акционерлык фирмаларының берсе — атаклы Ост-Индия компаниясе бинасы сурәтләнгән.

Бизнес — уен, дөньядагы иң бөек уен ул,
әмма ничек уйнарга кирәклеген белсәң генә!

Томас Дж. Уотсон

§ 20. Фирмалар ни өчен төзелә

Базар икътисады дөньясында теләсә кайсы кешенең тормышы төрле фирмалар белән даими үзара бәйләнештә булуга бәйле. Фирмалар кешеләрне эшкә ала, товар җитештерә һәм хезмәт күрсәтә. Ниһаять, фирмалар эшчәнлеге без яши торган табигый тирәлеккә дә йогынты ясый.

Фирманың сату өчен төрле байлыклар җитештерүче оешма булуын ачыкладык инде без. Төгәлрәк итеп әйткәндә, фирма — түбәндәге сыйфатларга ия оешма:

1) ул товарлар җитештерү һәм хезмәт күрсәтү өчен оештырыла;

2) җитештерү факторларын сатып яки арендага ала һәм аларны байлыклар җитештерү процессында берләштерә;

3) үз товарларын яки хезмәт күрсәтү төрләрен аерым сатып алучыларга, башка фирмаларга яки оешмаларга сата;

4) аның хуҗасы (яки хуҗалары) товарлар сатудан яки хезмәт күрсәтүләрдән табыш рәвешендә керем алырга тели.

Хуҗалык оешмасы шушы сыйфатларга ия икән, ул, нәрсә белән шөгыльләнсә дә (очкычлар җитештерү, бакча йортлары төзү яки чәчәкләр сату һ. б.), **фирма** була.

ФИРМА — төрле байлыклар булдыру һәм аларны сату, шуның нигезендә табыш алу максатында җитештерү факторларын сатып яки арендага алучы коммерция оешмасы.

«Фирмалар ни өчен төзелә?» дигән сорауга җавап аны бирүченең кем (сатып алучы, эшмәкәр яки икътисадчы) булуыннан тора.

Сатып алучы карашынча, фирмалар базарга (сатуга) сорала торган байлыклар чыгару өчен кирәк. Димәк, сорау булмаган әйберләр җитештерүче фирманың эшчәнлеге, сатып алучы карашынча, мәгънәсезлек. Товарны сату һәм табыш алу мөмкинлеге булмаса, фирманың эшчәнлеге аның хуҗасы өчен дә мәгънәсен югалта.

Эшмәкәр карашынча, фирма табыш рәвешендә керем яки башка төрле файда (шул исәптән яхшы эшли торган бизнес төзү максатын иҗади, уңышлы хәл итә алудан канәгатьләнү хисе кичерү һ.б.) алу өчен кирәк. Бу хакта Россиянең күренекле эшмәкәре, еллык сату күләме 75 млн доллар булган «Глория Джинс» компаниясе хуҗасы һәм җитәкчесе Владимир Мельников менә нәрсә ди: «Эшмәкәр, хосусый милекчедән аермалы буларак, бизнесны үз хезмәтенең нәтиҗәсен күрүне күздә тотып оештырмый,— бу мөмкин дә түгел. Ул эшне оештыра, һәм, чираттагы һәр этап тәгәлләнгән саен, аның офыклары киңәя бара. Эшмәкәр һәрчак үсешкә омтыла — бу аның табигый халәте. Хосусый милек иясе үзенең мөлкәтен югалтудан

куркып эш итә. Ә эшмәкәр, аны югалтмау гына түгел, үсешкә ирешә дә белә. Аның мөлкәте юк; бернәрсә дә аныкы түгел — барысы да вакытлыча. Менеджер исә — өченче буын, ул «ничек» эшләргә кирәклеген белә. Эшмәкәр «кайда» барырга икәнен белә һәм үз тирәсенә «ничек» эшләргә кирәклеген белүчеләрне җыя».

***ЭШМӘКӘР** — үз акчасына яки бурычка алган (заем) акчага тәвәккәлләп, җитештерү ресурсларын берләштереп, сатудан табыш бирәчәк байлыклар тудыру өчен фирма төзүче кеше.*

Әлеге бурычны һәрбер эшмәкәр дә уңышлы хәл итә алмый. Эшмәкәрлек башлангычларының күпчелеге (80 %ка якыны) уңышсызлыкка очрый. Һәм ул кешеләр баеп алмау гына түгел, үзләренең фирманы оештыруга тоткан акчаларын тулысынча (яисә тулысынча диярлек) югалталар.

Уңышка ирешү өчен, эшмәкәр булу теләге генә җитми — эшмәкәрлек таланты да кирәк. Ул талант теләсә кайсы фирма алдына килеп басачак түбәндәге бурычларны уңышлы хәл итә белүдән тора:

1) нинди товар җитештерергә яки нинди хезмәт күрсәтүләр белән шөгыльләнергә;
2) аларны нинди күләмдә җитештерергә яки башкарырга;
3) җитештерү өчен нинди технологиядән файдаланырга;
4) җитештерү өчен нинди җитештерү факторларын (ресурсларын) һәм күпме җәлеп итәргә;
5) персоналның эшен һәм җитештерү процессын ничек яхшырак итеп оештырырга;
6) кешеләр җитештерүчәнрәк эшләсен өчен, аларның хезмәтенә күпме түләргә;
7) товарларны базарга (сатуга) ничек чыгарырга;
8) товарларны сатуга нинди бәядән куярга һ.б.

Әгәр фирма хуҗасы һәм ялланган идарәчеләр (менеджерлар) әлеге мәсьәләләрне уңышлы хәл итәләр икән, фирманың товар сатудан алган кереме чыгымнарны капларга гына түгел, хуҗаларны табышлы итәргә дә җитә.

Хосусый яки дәүләт фирмасы булуга карамастан, базар икътисадындагы фирма эшчәнлегенең мантыйгы әнә шундый. Командачыл системада хосусый фирмалар юк, бары тик дәүләт предприятиеләре генә бар; алар эшчәнлегенең барлык яклары Госплан яки министрлыклар йөкләмәләре белән билгеләнә. Әлеге йөкләмәләрне үтәү предприятиенең төп максатына әверелә. Шуларны уңышлы үтәгән өчен, предприятие җитәкчеләрен дә, хезмәткәрләрне дә бүләклиләр, ә табыш алу мәсьәләсе икенче планда кала.

Әмма нәкъ менә табыш алу предприятие үсеше һәм тулаем ил икътисады өчен табигый чыганак булып хезмәт итә. Әгәр дә предприятиеләр табышсыз эшли икән, илнең хуҗалыгы үз үсешен тәэмин итү өчен кирәкле акчадан мәхрүм була, һәм аны бернәрсә белән дә тәэмин ителмәгән «буш» акчалар белән алмаштырырга туры килә. Бу исә котылгысыз рәвештә инфляциягә китерә.

Икътисадчы карашынча, җитештерү факторларын берләштерү җитештерү бурычларын, аерым кешегә караганда, нәтиҗәлерәк хәл итәргә мөмкинлек тудыра; фирмалар шунлыктан барлыкка килә. Бу шуның белән бәйле: фирма кысаларында җитештерүне арттыруның барлык факторларын эшкә җигәргә була. Алар түбәндәгеләр:

10-1 рәсем.
Россия законнары буенча фирмаларның төрләре

1) җитештерүнең техник дәрәҗәсен күтәрү;
2) идарә итүне, җитештерү һәм хезмәтне оештыруны камилләштерү;
3) товарлар җитештерү күләмен һәм структурасын җитештерүчәнлекнең артуына китерүче товарлар файдасына үзгәртү;
4) персоналны хезмәт эшчәнлегенең камилрәк ысулларына өйрәтү.

Кайбер байлыкларны эре предприятиеләр төзергә һәм алардан файдаланырга сәләтле фирмалар гына җитештерә ала. Мәсәлән, очкычлар, корабльләр, автомобильләр кебек катлаулы продукция җитештерүне фирмалардан башка — шәхси җитештерү һәм базар сәүдәсе нигезендә генә — оештыруны күз алдына да китереп булмый.

Шулай итеп, фирмалар:
1) кешеләр өчен кирәкле байлыклар булдыруда җитештерү факторларын рациональ берләштерү;
2) фирма хуҗаларына табыш китерү өчен оештырыла.

Законнар Россиядә коммерция оешмаларының күп төрләрен төзергә рөхсәт бирә. Аларның төп төрләре, шулай ук катнашучылар һәм кертемчеләр (акча салучылар) даирәсе 10-1 рәсемендә күрсәтелгән. Алардан башка, Россия Федерациясендә җитештерү кооперативлары һәм дәүләт яки муниципаль (җирле идарәгә караган) унитар предприятиеләр төзергә дә мөмкин. Һәм, ниһаять, кайбер эшчәнлек өлкәләрендә коммерция белән шөгыльләнмәүче оешмалар (мәсәлән, куллланучылар кооперативлары, хәйрия һәм башка фондлар, җәмәгать һәм дин оешмалары) төзү рөхсәт ителә. Коммерция оешмаларының аерым төрләрен кыскача тасвирлап үтик.

Хуҗалык итүне оештыруның иң гади, борынгы һәм киң таралган төре — шәхси (хосусый) фирма. Россия законнарында ул хәзер **юридик зат барлыкка китермәүче эшмәкәр** дип атала.

Шундый фирманы төзүче — аның бердәнбер һәм тулы хокуклы хуҗасы. Аңа беркем дә аның нәрсә эшләргә тиешлеге турында күрсәтмә бирә алмый, һәм ул үзенең **саф табышын** беркем белән дә бүлешергә бурычлы түгел.

***САФ ТАБЫШ** — табышның салымнарны һәм башка мәҗбүри түләүләрне башкарганнан соң хуҗалык итүче оешма карамагында кала торган өлеше.*

Шәхси фирмалар гадәттә зур булмыйлар; алар эре бизнес төзү өчен кирәкле күләмдә акча тупларга сәләтле түгел. Андый фирмалар барыннан да бигрәк сәүдә һәм хезмәт күрсәтү өлкәләрендә эш итәләр — анда фирманың капиталы чагыштырмача зур булмаска да мөмкин.

Шәхси фирмаларның күбесе кыска гомерле. Чөнки андый фирмага табышның бер өлешен үсешкә бүлеп бирү аеруча кыен. Һәм моны еш кына хуҗаның керменә әверелергә, аның гаиләсенә ким дигәндә яшәү минимумын тәэмин итәргә тиешле табыш исәбенә эшләргә туры килә. Ә керем аз булса, хуҗа гаиләсен тоту өчен акчаны эш өчен билгеләнгән күләмнән ала; бу исә бик тиз банкротлыкка китерә. Менә ни өчен күпләп төзелүче шәхси фирмалар бер-ике ел эшләгәннән соң ябылалар.

Эре коммерция предприятиеләре төзү өчен акча җитмәү проблемасын хәл итү һәм шулай ук фирма белән идарә итүне вазифаларны бүлешү юлы белән яхшырту өчен эшмәкәрләр тагын бер хуҗалык оешмасын үзләштерделәр: ул — *тулы ширкәт һәм ышанулы (коммандит) ширкәт* рәвешендәге **хуҗалык ширкәте**.

Тулы ширкәттә катнашучылар:

— ширкәт исеменнән эшмәкәрлек белән шөгыльләнәләр;

— ширкәт карамагында булган милек өчен (вазифаларына карап) җаваплы булалар;

— ширкәт эшчәнлеге белән гомуми килешү буенча идарә итәләр;

— табышны һәм күргән зыянны ширкәтнең гомуми капиталына керткән өлешләренә бәрабәр итеп бүләләр.

Ышанулы ширкәттә кайбер катнашучы-кертемчеләр (коммандитистлар) үзләре керткән сумма күләмендә зыян күрергә мөмкин, алар эшмәкәрлектә һәм аның белән идарә итүдә катнашмыйлар.

Хуҗалык ширкәтләре һәм шәхси фирмалар озак вакытлар дәвамында коммерция оешмаларының төп формасы булып тордылар. Сонрак исә җитештерүне үстерү бурычы эре фирмалар төзүне таләп итә башлый, һәм элекке формалар кысаларында алар өчен кирәкле акчаны туплау нык кыенлаша. Һәм эшмәкәрләр чираттагы адымны ясыйлар: алар (*ачык* һәм *ябык*), **чикләнгән яки өстәмә җаваплылыклы акционерлык җәмгыятьләре** оештыралар.

Хуҗалык оешмасының мондый формасы устав һәм билгеле бер минимумнан ким булмаган устав капиталларын берләштерүдән гыйбарәт. Катнашучылар милекне юридик зат карамагына тапшыралар; алар кертемнәре күләмендә зыян күрергә мөмкин.

Акционерлык компанияләре барлыкка килү кешелекнең икътисади алгарышында зур әһәмияткә ия була, мөмкинлекләрне нык киңәйтә. Гаять зур акционерлык җәмгыятьләреннән башка, XIX—XX гасырларда кешеләрнең яшәү рәвешен үзгәрт-

кән машина төзелеше, химия сәнәгате, һава транспорты һ.б. кебек тармакларны төзү мөмкин булмас иде.

Шул рәвешле, фирмаларның һәр төренең дә уңай һәм кимчелекле яклары бар. Алар 10-1 таблицасында туплап күрсәтелгән.

Таблица 10-1

Фирманың төре	*Уңай яклары*	*Кимчелекле яклары*
Шәхси фирма	1. Төзергә җиңел. 2. Тикшереп торырга уңайлы. 3. Эшчәнлек итү ирегенә ия. 4. Дәүләт тарафыннан чагыштырмача азрак көйләнә.	1. Фирманы киңәйтү өчен чыганаклар табу читен. 2. Фирманың тотрыклылыгы аз. 3. Хуҗа фирма белән идарә итү эшен тулысынча үзе алып барырга тиеш.
Ширкәт	1. Төзергә җиңел. 2. Идарә итү эшен бүлешеп башкарырга мөмкин. 3. Фирманы үстерү өчен кирәкле зур сумманы шәхси фирмага караганда җыюы җиңелрәк. 4. Дәүләт көйләве бик үк катгый түгел.	1. Партнерлар арасында каршылыклар булуы ихтимал. 2. Партнерларның берсе эштән китү (яки үлү) очрагында фирма документларын яңадан эшләргә туры килә. 3. Тулы иптәшләр милек белән җаваплы. 4. Зур проектлар өчен акча туплау бик читен.
Акционерлык җәмгыяте (корпорация, компания)	1. Акцияләр сату юлы белән гаять зур капитал җыярга була. 2. Акционерларның җаваплылыгы бик аз. 3. Хуҗалар алмашынганда фирманың тотрыклылыгы бик зур. 4. Һөнәри әзерлекле менеджерлар яллау мөмкинлеге бар.	1. Кем дә булса бик күп акцияләр сатып алса, фирманы контрольдә тотып булмый. 2. Акционерлар белән эшләү күп көч таләп итә (акционерлар реестрын алып барырга, дивидендлар түләүне оештырырга кирәк һ.б.). 3. Фирма хуҗаларына икеләтә (фирма табышына һәм шәхси керемнәрдән саф табышка) салым салына.

Төрле төр фирмаларның барлыкка килү һәм эшләү сәбәпләре 10-2 рәсемендә күренә. Анда хуҗалык (коммерция) оешмаларының барлык төрләре ике үзәккә мөнәсәбәттә урнаштырылган. Беренчесе — аерым кешенең фирма эшчәнлегенә йогынты ясау мөмкинлеге. Икенчесе — фирманы үстерү өчен акча җәлеп итү мөмкинлекләре.

Шәхси эшмәкәргә эшчәнлек итү ирегенен җаваплылыгы чикләнгән ширкәт бирә. Әмма андый фирманың акча җәлеп итү мөмкинлекләре бик аз.



10-2 рәсем.
Төрле төр фирмалар арасындагы икътисади аерымлыклар

Хуҗалык оешмасы нинди фирмада төзелсә дә, моның өчен тәвәккәллек кирәк. Фирма үзенең хуҗаларын баетырга да, шулай ук аларны бөтен туплаган акчаларыннан гына түгел, эшләрне алып барганда туган нерв киеренкелеге аркасында сәламәтлекләреннән дә мәхрүм итәргә мөмкин. Фирма — аның хуҗаларының шәхси эше, әмма аның уңышына җәмгыять тулаем алганда битараф түгел. Теләсә кайсы илдә фирмаларның тотрыклы булуы һәм «чәчәк атуы»ннан күп нәрсә (базарның тәэмин ителүе, товарларга бәяләр дәрәҗәсе, эш табу мөмкинлекләре һ.б.) тора.

КЕШЕЛЕКНЕҢ ИКЪТИСАДИ ТАРИХЫ СӘХИФӘЛӘРЕ

Гаилә табыныннан — «сәүдәгәр-авантюрачылар»га

Эшмәкәрләр берлегенең бер формасы буларак, ширкәтләр барыннан да элек сәүдә өлкәсендә барлыкка киләләр. Бу табигый, чөнки сәүдә — коммерция эшчәнлегенең иң борынгы төре; хәлбуки ул зур чыгымнар һәм тәвәккәллек таләп итә. Борынгы Рим дәүләтендә үк бөтен Урта диңгез бассейнында эшчәнлек итүче коммерция ширкәтләре барлыкка килә. Б. э. к. XI—X гасырларда «диңгез ширкәтләре» яки «чын (хак) ширкәтләр» чәчәк ата. Аларны сәүдә юлы оештыру өчен, гадәттә, ике сәүдәгәр төзи торган була: берсе чыгымнарны каплау өчен кирәкле акчаның бер өлешен генә бирә, әмма аның урынына шәхсән үзе су буйлап күп айлык һәм җиңел булмаган юлга чыга. Икенчесе акчаның төп өлешен бирә, әмма үзе коры җирдә, куркынычсыз урында кала.

«Диңгез ширкәтләре»нең уңай тәҗрибәсе шундый ук «фирма»ларның авыл җирләрендә дә барлыкка килүенә этәрә. Аларда, гадәттә, бер гаилә әгъзалары берләшә, һәм алар барысын да: хезмәтне, капиталны, икмәкне бергәләп табалар һәм бүлешәләр, күргән зыянны да бергәләп күтәрәләр. Нәкъ менә шундый гаилә бергәлекләре соңрак «компания» дип йөртелә башлый, ул итальянча «кум» («бергә») һәм «панис» («икмәк») дигән сүзләрдән ясалган. Башкача әйткәндә, «компания» — «икмәкне бүлешүчеләр бергәлеге» ул.

Кайбер компанияләр, өстәмә акча һәм югары квалификацияле хезмәткәрләр җәлеп итү өчен, үз әгъзалары арасына чит кешеләрне дә ала башладылар. Андый компанияләр бигрәк тә тиз үсә.

XVI гасырдан гаилә компанияләрен акчалы хуҗаларга тынычрак тормыш тәэмин итүче коммандит ширкәтләр кысрыклый, һәм алар әкренләп икътисад аренасыннан югала башлый. «Коммандитис (компаньон)

беркайчан да һәм бер сәбәп белән дә ширкәтнең бурычлары һәм вазифалары өчен үзе аңа керткән суммадан да артыграк җаваплы булып санала алмый».

Хезмәттәшлекнең иң кулай һәм хәвефсез формасын эзләүдә Италия сәүдәгәрләре зур уңышларга ирешәләр. Алар XIV гасырда ук Урта диңгездә йөзүче сәүдә корабларын сатылырлык өлешләргә бүлә башлыйлар. Соңрак исә акча җәлеп итүнең шул ук ысулыннан тау сәнәгатендә дә файдаланалар: көмеш һәм бакыр рудникларын өлешләргә бүләләр. Ә Франциянең Тулуза шәһәрендә ул вакытта шактый әһәмиятле предприятие булып саналган тегермәннәрне өлешләргә бүләләр. Тегермән өлешенә ия кеше, йорт яки җир участогы саткан кебек, аны теләсә кемгә сата алган.

Акционерлык җәмгыятьләренең «туган елы» дип рәсми рәвештә 1695 ел исәпләнә: көзге мануфактурасы эшләрендә катнашуның кыйммәтле кәгазь — акция — рәвешендәге өлешен сату беренче тапкыр теркәлә.

Эшмәкәрлекнең акционерлык формасы Англиядә бигрәк тә тиз үсә: аны «сәүдәгәр-авантюрачылар» берләшмәләре күтәреп ала (алар постау, ефәк, бәрхет белән сәүдә итәләр). Шушы җитди сәүдәгәрләр диңгездә йөк ташуга нигезләнгән кыю («авантюралы») сәүдә алып баралар.

Шундый гадәти булмаган исемле «сәүдәгәр-авантюрачылар» берләшмәләре катгый кодекс белән яшиләр. Ул кодекс (кагыйдәләр җыелмасы) сәүдәгәрләргә бер-берсенә — «туганым», ә аларның хатыннарына «апам», «сеңлем» дип эндәшергә куша. «Туганнар» һәм «апа», «сеңелләр» бергәләп чиркәүгә һәм кеше күмәргә йөрергә тиеш булалар. Аларга үзләрен начар тоту, сүгенү сүзләре куллану, исергәнче эчү һәм кешеләр алдында оятсыз хәлдә күренү тыела. Бәхәсләшү, бербереңне мәсхәрәләү, дуэльләр шулай ук катгый рәвештә тыела. Моның сәбәбе аңлашыла да — яхшы абруйлы булу кешеләрдә ышаныч тудыра һәм эшләрне яхшырак алып барырга мөмкинлек бирә.

Шундый тыгыз хезмәттәшлек һәм эшләрне алып баруның бердәм принциплары «сәүдәгәр-авантюрачылар»га акчаны берләштерүнең акционерлык механизмын җиңел үзләштерергә булыша. Башка илләрдәге эшлекле кешеләр дә алардан үрнәк алып эш итә башлый.

Мәсәлән, Россиядә бизнес алып бару һәм шәхси тормышны оештыру кагыйдәләрен берләштерүнең алда бәян ителгәнгә охшаш модельләрен староверлар мәхәлләләрендә күрергә мөмкин,— алар ил икътисады үсешендә зур әһәмияткә ия булганнар. Россиянең иң атаклы эшмәкәрләре: Рябушинскийлар, Морозовлар, Солдатенковлар, Лавенишниковлар һәм Третьяковлар — барысы да староверлар мәхәлләләрендә әгъза булып торганнар; аларда кешеләр бергәләп дога уку гына түгел, бизнеста да бер-берсенә ярдәм иткәннәр. Староверларның акционерлык җәмгыятьләре булмаган, әмма, башка юл белән булса да, капиталларны берләштергәннәр.

Эш шунда: Россия империясенең рәсми хакимияте, староверларны дошман санап, аларның үз йолалары буенча башкарылган никахларын танымый, һәм андый гаиләләрдәге балалар законсыз туган булып исәпләнә; димәк, алар үз әти-әниләре милкенең варислары була алмыйлар. Шуңа күрә бай староверлар (иске йола тарафдарлары) үз васыятьнамәләрендә милекләрен мәхәллә карамагына күчерү турында язалар, ә мәхәллә әлеге милек белән идарә итүне үлгәннәрнең балаларына тапшыра. Әгәр дә үлүченең балалары булмаса, аның милке мәхәлләгә кала; ул исә аны мәхәлләнең яшь әгъзаларына бизнесны үстерү максатында ссуда бирү өчен файдалана.

Моннан тыш, старовер сәүдәгәрләр, үз товарларын кая да булса илтү, саклау һәм сату өчен, диндәш арадашчыларның киң челтәреннән файдалана алганнар. Кирәк булганда, старовер мәхәлләсе әгъзасы булган постоялый двор тотучыларга, сәүдә агентларына, артель ямщикларына мөрәҗәгать итә алганнар; аларны катгый дисциплина һәм буйсынучанлык берләштергән. Эшлекле диндәш партнерларның мондый мөнасәбәтләр дөньясы Россиядә бизнес үсешенә нык ярдәм иткән.

Голицын Ю. Этика предпринимательства//Русский предприниматель. — 2001. Нояб.

§ 21. Фирма эшчәнлегенең икътисади нигезләре

Табышка ничек ирешелә; ни сәбәпле кайбер фирмалар байый, ә икенчеләре бөлә?

Фирма эшчәнлеге, хуҗалар табыш рәвешендә керем алганда гына, үзен аклый. Ә табыш — товар сатудан кергән акчаның аны житештерү һәм сатуны оештыруга киткән чыгымнар суммасыннан артып китүе ул.

Әмма бу билгеләмә бик үк төгәл түгел, чөнки **гомуми чыгымнарның** зурлыгын төрлечә исәпләргә мөмкин. Теләсә кайсы фирма үз эшчәнлегендә ике төрле ресурстан файдалана:

— тышкы ресурслардан;

— эчке ресурслардан.

ГОМУМИ ЧЫГЫМНАР — билгеле бер күләмдә продукция җитештерүне оештыру өчен, фирма файдаланган яки файдаланачак ресурсларның тулы күләмен алуга тотылган чыгымнар.

Тышкы ресурсларга фирма башка коммерция оешмаларыннан яки гражданнардан сатып ала торган барлык нәрсәләр (материаллар, детальләр, энергия, эшче көче һ.б.) керә. Алар билгеле бер күләмдә продукция житештерү өчен тотыла, ә алдагы партияне җитештерү өчен аларны тагын алырга кирәк. Мәсәлән, хезмәт хакы бер айга исәпләнә, һәм ул ялланган хезмәткәрләргә шушы вакыт эчендә җитештергән продукция яки хезмәт күрсәтү күләме өчен түләнә. Яңа ай килеп җитә, һәм хезмәт иткән өчен яңадан түләргә кирәк.

Эчке ресурслар — фирманың үз карамагындагы һәм аның тарафыннан үз эшчәнлеген оештыру өчен файдаланыла торган нәрсәләр. Мондый ресурсларның иң әһәмиятлеләре — биналар, җиһаз, җир, фирма хуҗасының аны төзүгә киткән акчасы.

Болар барысы да чикләнгән күләмдә, шуңа күрә аларның үз кыйммәте бар. Ул кыйммәт ресурсларны әлеге фирма эшчәнлегенә юнәлтү файдасына ясалган сайлау бәясенә тигез.

Мисал өчен, фирма хуҗасының шәхси акчалары һәм эшмәкәрлек хезмәте күрсәтү кебек эчке ресурсларны карап үтик.

Беренче карашка алар бушлай кебек: аларны беркемнән дә сатып аласы юк бит. Әмма ул акчаларны һәм фирма эшчәнлегенә бирелгән көчне аның хуҗасы башка максатларга юнәлтә һәм шуның белән нәрсә дә булса эшләп таба алыр иде. Мәсәлән, ул акчаны банкка сала, ә үзенең сәләтләрен, башка бер фирмага эшкә урнашып, хезмәт хакына сата ала.

Әмма ул бу ресурсларын үз фирмасына бирде (салды), ди. Сүз дә юк, мондый адым эшмәкәрлек талантын, тупланган акчасын башкача кулланып алырга мөмкин булган керемнән ким булмаган табышка ирешкән очракта гына икътисади яктан файдалы була.

Мондый керемне «нормаль керем» дип атыйлар һәм ул түбәндәгеләр өчен җитәрлек булырга тиеш:

— эшкә тотылган акчаны һәм куелган көчне кайтару;

— фирма эшләре белән алга таба да шөгыльләнүгә кызыксынуны саклау;

— киләчәктә дә фирманы үстерү, аның конкурентлык сәләтен саклау өчен җитәрлек акча керту.

Әгәр эшмәкәр нормаль табыш алмый икән, ул йә үзе бу эшне ташлый һәм ялланып эшли башлый, йә фирма көчсезләнә һәм конкурентлар аны базардан кысрыклап чыгаралар.

Болар бар да фирманың эчке (үз) ресурсларының башка төрләре өчен дә дөрес. Мәсәлән, фирма карамагындагы һәм аның эшчәнлегендә файдаланыла торган бинаны кемгә дә булса арендага биреп торырга һәм аннан аренда өчен түләү алырга мөмкин булыр иде. Димәк, бинадан үз ихтыяҗларың өчен файдаланганда, мөмкин булган аренда өчен түләүдән күбрәк күләмдә керем алырга кирәк.

Тышкы ресурслардан альтернатив файдаланудан алынмаган керемнәр фирманың табышын, тышкы (сатып алына торган) ресурсларга чыгымнар кебек үк киметә. Бу исә фирма өчен барлык эчке ресурсларның да кыйммәтле булуын белдерә һәм шуңа күрә аның чыгымнарының гомуми күләме:

— тышкы (ачык билгеле) һәм

— эчке (ачык билгеле булмаган) чыгымнар суммасыннан тора (10-3 рәсем).

Башкача әйткәндә, икътисад фәне раславынча, фирманың гомуми чыгымнарына фирма туплаган һәм җитештерүне оештыру өчен файдаланган (фирманың үз милкен дә кертеп) барлык төр ресурсларны алуга чыгымнар һәм аның хуҗасының эшмәкәрлек таланты да керә.

Шундый мәгънәдәге гомуми чыгымнар **икътисади чыгымнар** дип атала. «Икътисади» сүзе бу очракта чыгымнарны икътисадчылар, бухгалтерлар һәм дәүләт салым хезмәтенең төрлечә аңлавы белән бәйле.

Бухгалтерлар да, салым хезмәтләре дә фирманың эчке (ачык билгеле булмаган) чыгымнарын исәпкә алмыйлар. Алар чынлыкта гамәлгә ашырылган чыгымнарны гына саныйлар.

10-3 рәсем.
Фирмалар чыгымнарының төп төрләре

Бухгалтерлар һәм салым инспекторлары фикеренчә, милекченең нормаль табышы — керем, ә керемгә салым булырга тиеш. Шулай итеп, милекченең нормаль табышын да, башка ачык билгеле булмаган чыгымнарын да бухгалтерлар һәм салым хезмәте «чыгымнар» дип танымый; «фирманың чыгымнары» дигәндә, алар чынлыкта гамәлгә ашырылган һәм бухгалтерия документларында теркәлгән чыгымнарны гына күздә тоталар (**«бухгалтерлык чыгымнары»**).

ИКЪТИСАДИ ЧЫГЫМНАР — фирманың товарлар җитештерүгә һәм хезмәт күрсәтүләргә гомуми чыгымнары (товарлар җитештерү һәм сатуны оештыруга турыдан-туры, шулай ук альтернатив чыгымнарны, ягъни фирманың ресурсларын башка төр эшчәнлек вариантларына файдаланмау сәбәпле алынмаган файданы да кертеп).

БУХГАЛТЕРЛЫК ЧЫГЫМНАРЫ — билгеле бер вакыт эчендә фирма товарлар җитештерүгә һәм хезмәт күрсәтүләргә тоткан тышкы (ачык билгеле) чыгымнарның гомуми суммасы.

Фирма чыгымнарының гомуми суммасына ике төрле караш булганлыктан, табыш зурлыгын да төшем (сатудан кергән акча) һәм тоткан чыгымнар арасындагы аерма буларак төрлечә аңлаталар.

Төшемнән икътисади чыгымнарны чигерсәк, килеп чыккан зурлык икътисади табыш дип аталырга тиеш. Әгәр дә төшемнән бухгалтерлык чыгымнарын гына чигерсәк, бухгалтерлык табышы килеп чыга.

Боларны тигезләмәләр рәвешендә язарга мөмкин:

Фирманың икътисади табышы	=	Төшем	–	Тышкы чыгымнар	–	Эчке чыгымнар

Фирманың бухгалтерлык табышы	=	Төшем	–	Тышкы чыгымнар

Хәзер без бухгалтерлар һәм икътисадчыларның товарлар сатудан кергән акчага төрле караштa булуларын 10-4 рәсемендә күрсәтелгәнчә күз алдына китерә алабыз.

Фирмаларның чыгымнар белән ничек идарә итүен, нинди икътисади законча-лыкларны истә тотарга кирәк булуын яхшырак аңлау өчен, фирмаларның нинди чыгымнары булырга мөмкин икәнлеген карап үтик. Чыгымнар (башкача әйткәндә, акча тоту, сарыф итү) белән танышуны тышкы чыгымнарның ничек барлыкка килүен, аларның **расход** һәм түләүләрдән нәрсә белән аерылуын ачыклаудан башлыйк.

Фирма станок яки бер вагон металл алырга булды, ди. Моңа ирешү өчен расход чыгарырга, ягъни шул ресурсларны алу өчен килешенгән суммада акча сарыф итәргә кирәк була.

10-4 рәсем.
Бухгалтерлар һәм икътисадчыларның чыгымнарны һәм фирма табышын аңлауларындагы аерымлыклар

Чыгымнар = Сатып алына торган җитештерү ресурсларының саны × Сатып алына торган җитештерү ресурсларының бәясе

Фирма өчен кирәкле ресурсны алу турында шартнамәгә кул кую — ул әле расход гамәлгә ашырылды дигән сүз түгел. Акча товарны сатучыга тапшырылганнан соң гына, расход фирма өчен чынбарлыкка әверелә.

Кулда булган акчаны түләү яки акчаны банк аша күчерү **түләү** дип атала. Ресурсларны алу һәм түләү төрле вакытта башкарылырга мөмкин. Сәүдә эшләрендә еш кына: «Бүген сатып ал — иртәгә түләрсең!» дигән принцип буенча эш итәләр; шулай сатып алучыны товарны алырга күндерү җиңелрәк.

Ресурслар алу (хәтта аның өчен түләү дә) ул әле ресурсларның, чынлап та, фирма ихтыяҗларына файдаланылуы дигән сүз түгел. Алар складка җибәрелеп, **запас** булып ятарга да мөмкин.

Ресурслар, чынлап та, фирма тарафыннан товарлар җитештерүгә яки хезмәт күрсәтүләргә тотыла башлагач кына, чыгымнар зурлыгы формалаша башлый. Шул рәвешле, чыгымнар товар җитештерү яисә фирманың башка төр эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдаланылган ресурслар күләменең әлеге ресурс берәмлеге бәясе тапкырчыгышына тигез.

Фирма чыгымнарының (файдаланыла торган ресурсларның төренә карап) төрлечә формалашуына игътибар итик.

Мәсәлән, материаллардан файдалану чыгымнарын һәм җитештерү биналарын файдалану белән бәйле чыгымнарны чагыштырып карыйк.

Материаллар, биналар кебек ресурслардан башка фирма җитештерүне оештыра алмый. Аерма шунда гына: материаллар, әзер продукциягә әверелгәндә, тышкы күренешләрен үзгәртәләр (бер өлеше калдыкка чыга), ә җитештерү цехлары

эшләп чыгарылган әйберләрнең чираттагы партиясен алып киткәч тә, үз урыннарында үзгәрешсез калалар.

Күбрәк берәмлек продукция житештерүгә күбрәк материал сарыф ителә. Әйтик, автомобиль эшләп чыгару өчен 1,2 т металл китсә, 10 автомобиль житештерү өчен — 12 т, ә 100 автомобильгә 120 т металл кирәк була.

Хәзер шушы автомобильләр житештерелә торган цехка һәм андагы жиһазларга игътибар итик. Алар 1 тәүлеккә 100 автомобиль житештерүгә исәпләп төзелгән, дип уйлыйк. Ә сорау кимү нәтижәсендә, анда 100 түгел, ә 90 автомобиль житештерелә башласа да, аңа карап цехның зурлыгы да, жиһазлар күләме дә үзгәрми.

Житештерү күләме үзгәргәндә, житештерү ресурсларыннан файдалану күләме үзгәрү икътисадчыларны барлык төр чыгымнарны ике категориягә бүләргә мәжбүр иткән:

1) даими чыгымнар;
2) үзгәрмә чыгымнар.

Даими чыгымнарга, мәсәлән, бина өчен аренда түләве, жиһазларны көйләп-карап торуга киткән чыгымнар, элегрәк алынган ссудаларны түләү, шулай ук һәртөрле административ һәм өстәмә расходлар керә.

Үзгәрмә чыгымнар — фирманың материаллар, энергия, комплектлаучы эшләнмәләр алуга, хезмәт хакы түләүгә киткән чыгымнары. Алар товар житештерү күләменең һәртөрле тирбәлешләренә бәйле рәвештә үзгәреләр (житештерү күләме артканда — арталар, кыскарса — кимиләр).

Чыгымнар үзгәрү закончалыкларындагы аерма һәм аларның гомуми структурасы 10-5 рәсемендә ачык күренә.



10-5 рәсем.
Гомуми чыгымнар структурасы һәм житештерү күләме үзгәргәндә даими һәм үзгәрмә чыгымнар суммасы үзгәрү

Матвей КУЗНЕЦОВ

Фарфор һәм керәч әйберләр эшләп чыгаручы «Матвей Кузнецов ширкәте» дигән атаклы Россия фирмасы тарихы күпләп җитештерү өстенлекләреннән уңышлы файдалану үрнәге булып тора.

Әлеге фирма Россиядә 1810 елда барлыкка килә. Башта аның бөтен җитештерү куәте ике горннан (фарфорны яндырып эшкәртү учагы) гыйбарәт була. Фирма Россиянең яңа тип махсус белемле (Ригадагы коммерция училищесын тәмамлаган) эшмәкәре Матвей Сидорович Кузнецов (1846—?) җитәкчелек иткәндә чәчәк ата башлый. Ул XIX—XX гасырлар чигендә туган күпләп җитештерү закончалыкларын яхшы белә: продукцияне арзанайту өчен, төп игътибарны эшләнмәләрнең югары сәнгати дәрәҗәдә булуына һәм аларны күпләп эшләп чыгаруга бирә.

Әле хәзер дә уңышлы эшләп килүче Дулев заводы күпләп җитештерү барышында фирма предприятиеләре масштабларының тиз үсүенә үрнәк булып тора. 1884 елда анда 1 мең эшче хезмәт иткән.

XX гасыр башына аларның саны — 2335, ә 1913 елга 3199 кешегә җиткән (Русский торгово-промышленный мир.— М., 1993). Предприятие иң яңа, шул заман өчен иң җитештерүчән товарларны күпләп эшләп чыгару техникасы (мәсәлән, «Фор» дип аталган француз фирмасының калын чәшкеләр формалаштыручы автоматы) белән җиһазландырылган була.

Болай эшләү «Кузнецов фарфоры»н киң катлам сатып алучылар — авыл кешеләре («Шәһәрнекеләрдән ким түгел!») һәм фарфорны уртача бәягә сатып алган, бик үк бай булмаган шәһәр кешеләре дә («Дворяннарныкы кебек үк диярлек!») — файдалана алырлык иткән.

Шундый акыллы сәүдә һәм сәнгати сәясәт «Матвей Кузнецов ширкәте»н Россиянең иң яхшы һәм иң зур фирмаларының берсенә әверелдерә: ширкәт илдә җитештерелә торган фарфорның өчтән икесен эшләп чыгара һәм үз эшләнмәләренә Россия гербын куярга хокуклы була.

Ә Матвей Кузнецов үзе бик нык баеп китү генә түгел, иң мөхтәрәм кешегә әверелә: ул күп кенә Россия һәм чит илләр орденнары, шул исәптән Франциянең «Шәрәфле легион» ордены белән бүләкләнә, аңа «Император хәзрәтләре сараен тәэмин итүче» дигән дәрәҗә бирелә.

Графиктан күренгәнчә (10-5 рәсем), эшләп чыгарыла торган продукция күләме арту белән даими чыгымнар суммасы артмый (бу очракта продукция 20 яки 40 берәмлек эшләп чыгарылса да, ул 15 млн сумга тигез).

Ә менә үзгәрмә чыгымнарның гомуми суммасы эшләп чыгару күләме арткан саен үсә бара. 20 берәмлек продукция эшләү өчен 19 млн сум үзгәрмә чыгым кирәк булса, 40 берәмлек өчен ул 30 млн сум булыр.

Шулай ук житештерүгә гомуми чыгымнар да арта. Фирмада 20 берәмлек продукция эшләүгә гомуми чыгымнар 34 млн сум тәшкил итсә (даими чыгымнар 15 млн сум + үзгәрмә чыгымнар 19 млн сум), 40 берәмлек эшләү өчен 45 млн сум (даими чыгымнар 15 млн сум + үзгәрмә чыгымнар 30 млн сум) кирәк булачак.

Шундый тәфсилле анализ ясаганда гына фирманың:

1) базарга (сатуга) чыгарыла торган үз товарларына бәяне һәм

2) товарлар житештерү яки хезмәт күрсәтүләр күләмен ничек билгеләвен анларга була.

***МАРЖИНАЛЬ (ЧИК) ЧЫГЫМНАР** — эшләп чыгарыла торган һәр өстәмә берәмлек продукциягә реаль чыгымнар суммасы.*

Житештерү масштабларын арттыру һәрвакыт маржиналь (ингл. *margin* — «чик») чыгымнарны җентекләп нигезләүне һәм исәпләүне таләп итә. Өстәмә товар берәмлеген житештерүгә чик чыгымнар сату бәясенә (сатудан маржиналь керемгә) тигез яки аннан зуррак булмасмы? Маржиналь чыгымнар әнә шуны ачыкларга ярдәм итә. Әгәр дә шулай була калса, фирманың өстәмә берәмлек товарны сатудан табышы нульгә тигез булыр яки зыян китерер; бу исә бизнес белән шөгыльләнү максатына каршы килә.

Теләсә кайсы фирма эшчәнлегенең нәтиҗәләре аның чыгымнарына гына түгел, ул үз товарларын сата торган базар төренә дә нык бәйле. Монда базарлар арасында аларда сатыла торган товарларга хас үзенчәлекләр аермасы түгел, ә аларны сатуда урнашкан конкурентлык шартлары аермасы күздә тотыла.

Үз товары белән базарга чыгучы фирма күбесенчә үз товарларын сатарга теләүче башка фирмалар (конкурентлар) белән очраша. Базарда товар сатып алучыларның ресурслары (барыннан да бигрәк акчалары) чикләнгән булу сәбәпле, әлеге фирмалар бер-берсе белән ярышырга мәжбүр.

Әмма бу «ярыш» төрле төс алырга мөмкин. Һәр фирма, үз коммерция (сәүдә итү) сәясәтен эшләү өчен, үзе базарда очрашачак конкуренциянең төрен белергә тиеш. Конкуренциянең төре сатып алучылар өчен дә әһәмиятле; ул аларның мәнфәгатьләренә кагыла.

Гадәттә, конкуренцияне (конкурентлы базарны) түбәндәге төрләргә бүләләр:

1) камилләшкән (саф) конкуренция базары;

2) монополиячел конкуренция базары;

3) олигополиячел базар;

4) монополия базары.

Камилләшкән (саф) конкуренция базары. Сатып алучыларның игътибарын һәм акчаларын «яулау» өчен көрәштә күп санлы бертөрле товар житештерүчеләр очраша. Һәм аларның берсе дә үзе өчен файдалы сату шартларын башкаларга көчләп тагарлык базар өлешен контрольдә тота алмый.

Мәсәлән, авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүче яки хезмәт күрсәтү өлкәсендәге вак фирмалар үзара шулай конкурентлык итә.

Мондый конкуренциядә базар тигезләнешенә сатучылар һәм сатып алучыларның күпләп килешүләре нәтиҗәсендә ирешелә; алар үз ихтыярларын бер-берсенә көчләп тага алмыйлар һәм, бердәй тигез дәрәҗәдә, базар бәясе (базар тигезләнеше бәясе) рәвешендәге компромисс эзлиләр.

Шундый хәлдә базар механизмнарының яхшы яклары да, кимчелекләре дә ачык күренә. III, IV бүлекләрдәге базар төзелеше, сорау һәм тәкъдимнең үзара тәэсир итешүе турындагы өлешләр нәкъ менә камилләшкән конкуренция базарын төгәл тасвирлыйлар.

Монополиячел конкуренция базары. Икътисадчылар әйтүенчә, монополиячел конкуренция түбәндәге шартлар булганда барлыкка килә:

1) базарда үзара конкурентлык итүче фирмалар күп;

2) бер үк ихтыяжны канәгатьләндерү өчен әлеге фирмалар бер-берсеннән аерылып торган товарлар тәкъдим итәләр;

3) һәрбер фирма үзе сата торган товар бәясен берникадәр үзгәртә ала;

4) базардагы фирмалар яңа фирмаларга анда керү юлын яба алмыйлар.

Шундый товар сату базарларына азык-төлек, кием-салым, йорт җиһазлары һ.б. базарлар керә.

ЗАКОН КУШКАНЧА

Җитештерү һәм хезмәт күрсәтү даирәсендә авторлык хокукларын саклау өчен Россия Федерациясе Югары Советы 1992 елның 14 маенда **«Товар билгеләре, хезмәт күрсәтү билгеләре һәм товарлар барлыкка килү урыннарының исемнәре турында»** махсус Закон кабул итте.

Законда билгеләнгәнчә:

1) товар билгесе ул — граждан яки сәүдә оешмасы товарын яки хезмәт күрсәтүен башка җитештерүчеләрнең шундый ук товарларыннан аеручы тамга;

2) товар билгесенең хуҗасы гына аннан файдалана ала һәм башка беркемнең дә хуҗаның рөхсәтеннән башка аннан файдаланырга хакы юк;

3) товар билгеләре Россия Федерациясе Дәүләт патент ведомствосы тарафыннан теркәлә;

4) товар билгеләреннән файдалануга бәйле (алардан законсыз файдалануны да кертеп) бәхәсләрне суд, арбитраж суды яки третейский суд (битараф як хөкеме) карый;

5) үзенеке булмаган товар билгесеннән файдаланган кеше яки оешма зыян күрүчеләрнең чыгымнарын кайтарырга, ә калган табышны хакимиятнең җирле органнарына тапшырырга тиеш.

Мәсәлән, төрле фирмаларның пальтолары сатып алучыларның бер үк ихтыяҗын канәгатьләндерә: салкыннан саклануны тәэмин итә. Әмма пальтолар эшләп чыгаручы һәрбер фирма сатып алучыга материалы, тегелеше, бизәлеше, төсләре белән аерылып торучы товарлар тәкъдим итә. Пальтоның аерым бер төрен билгеле бер фирма гына чыгара һәм ул үз продукциясе үзенчәлекләренә автор хокукларына ия була.

Мондый базарда һәрбер фирманың монополиячел хакимлеге — бары тик товарның аерым бер төрен җитештерү һәм аны мөстәкыйль рәвештә билгеләнгән бәя белән базарга (сатуга) чыгаруда гына. Фирма бер төр товарлар базарына контрольлек итә һәм базар бәясен көчләп тага алмый.

КЕШЕЛЕКНЕҢ ИКЪТИСАДИ ТАРИХЫ СӘХИФӘЛӘРЕ

Тоз һәм шәраб — дәүләтнең нигезе

Иң беренче монополияләр патша һәм императорларныкы булган. Алар тарихка «дәүләт монополияләре» исеме белән кереп калганнар һәм аның мәгънәсенә төгәл туры килә торган булганнар. Дәүләт товарның (гадәттә, киң куллану товарының — тәмәке, шәраб, тоз, шырпы) бердәнбер тулы хокуклы сатучысы дип игълан ителгән. Чын дәүләт монополияләре XVII гасырда гына барлыкка килгәннәр. Әмма, тарихчылар фикеренчә, аларның тамырлары борынгырак һәм урта гасырларда «Алла тарафыннан бүләк ителгән» судан, җир асты һәм җир өсте байлыкларыннан, урманнардан файдалану хокукына ия булган феодалларга барып тоташа. Моннан табигый рәвештә, мәсәлән, тоз табуга монополия барлыкка килә; ә аннан тоз монополиясенә — «дәүләт кешеләренең» генә тоз белән сату итүгә хокуклы булуына — бер адым.

Россиядә, мәсәлән, тоз монополиясе Петр I указы белән 1705 елда кертелә һәм 1862 елга кадәр (бер ярым гасырдан артык) яши. Шәраб монополиясе Россиядә тагын да озынрак гомерле була: ул XVII гасырда барлыкка килә. Шуннан бирле рус телендә «монополька» сүзе кулланыла, ул «шәраб сату урыны» дигәнне белдерә. «Монополька»лар 1992 елда гына, дәүләт исерткеч эчемлекләр җитештергән өчен гражданнарны эзәрлекләүдән туктагач кына бетерелә.

Дәүләт монополияләренең шулкадәр яшәүгә сәләтле булуы гаҗәп түгел. Алар «монополь» товарларны нык күтәренке бәяләргә сатучы дәүләтнең төп керем чыганакларының берсе булып торалар. Мәсәлән, аракы җитештерүгә чыгымнар революциягә кадәрге Россиядә бер елга 200 млн сум тәшкил итсә, халык аның өчен 900 млн сум түләгән. 700 млн сум аерма патша хөкүмәтенең монополь табышы булган һәм аның бөтен чыгымнарының 30 процентын капларга җиткән.

Тарихта шундый бер вакыйганың булуы билгеле: Россия икътисадының атаклы реформаторы граф Сергей Витте Россия империясе бюджетында акча җитмәүчелекнең зур булуын белеп ала, һәм тиз арада йөз илле шәраб заводы төзетә, ә шул заводларны... Финанс министрлыгы карамагына кертә; шулай итеп, шәраб сатудан килгән керем турыдан-туры дәүләт казнасына элләгә. Җиде дистә ел дәвам иткән СССРда коммунизм төзелеше чорында да шәраб-аракы монополиясе бюджетны тәэмин итүдә зур әһәмияткә ия була.

Конкуренциянең мондый төре бигрәк тә киң таралган. Ул түбәндәге шартлар булган тармакларда барлыкка килә:

1) житештерүне оештыру өчен аеруча зур предприятиеләр төзү һәм зур капитал кертү кирәк түгел;

2) билгеле бер ихтыяжны канәгатьләндерүче күп төрдәге товарлар барлыкка китерү мөмкинлеге бар;

3) аерым бер фирманың аның тарафыннан барлыкка китерелгән товарны үзе генә эшләп чыгаруга хокукларын авторлык хокуклары һәм товар билгесенә хокук (патентлар) белән якларга мөмкин. Житештерүче хокукларын закон шулай яклаганда, башка фирмалар үз продукцияләрен шул исем һәм патент белән якланган продукциянеке кебек үк сыйфатлы итеп чыгара алмый.

Олигополия базары. Мондый төр базарга үзара көндәшлек итүче аз санлы зур фирмаларның бертөрле яки охшаш товарлар житештерүе хас. Һәрбер фирма үз товарларының сату бәяләрен сизелерлек үзгәртә ала.

Олигополия гадәттә технология үзе зур предприятиеләр төзү зарурлыгын китереп чыгарган тармакларда барлыкка килә. Икътисади яктан рациональ житештерү масштабы базар ихтыяжларын канәгатьләндерүче берничә фирмага тигез була.

Мәсәлән, АКШта автомобильләр базары нинди генә зур булмасын, аның ихтыяжларын дистәләрчә еллар буена фирмаларның «зур өчлеге»: «Форд», «Дженерал моторс» һәм «Крайслер» фирмалары тәэмин итеп килде. Гадәттә, авыр җиһазлар, нефть химиясе продукциясе житештерүче, халыкара йөк ташуны һава юллары белән гамәлгә ашыручы һ. б. базарлар олигополь (берничә фирма хакимлек итүле) була.

Россиядә жиңел автомобильләр базары структурасы кызыклы. СССР чорында, планлаштыру органнары билгеләгәнчә, анда 4 кенә төп житештерүче: «ВАЗ» («Жигули»лар житештерүче), «АЗЛК» («Москвич»лар эшләп чыгаручы), «ГАЗ» («Волга» автомобильләре эшләүче) һәм «ЗАЗ» («Запорожец»лар житештерүче) булган. Ул вакытта дәүләт чит ил фирмалары автомобильләрен эчке базарда сату өчен алмый, автомобильләр белән сәүдә итүче хосусый фирмалар булмый, базарны тулысынча алда атап үтелгән житештерүчеләр бүлешә. Аларның һәрберсе үз автомобильләренә бәяне үзләре билгели диярлек.

Илдәге суыткычлар һәм телевизорлар сату базарларында шуна охшаш хәл туа.

Монополия базары. Мондый төр базарда сатып алучы өчен иң начар шартлар тудырыла (искә төшерик: «монополия» грекча «монос» — «бер» һәм «полео» — «сатам» дигән сүзләрдән ясалган, һәм ул базарда билгеле бер төр товарны бер генә сатучы булуны белдерә).

Саф монополиядә сатып алучының сатулашу мөмкинлеге бик аз, чөнки альтернатив житештерүче (сатучы) юк. Шуна күрә монополистның гадәти сәүдә планы (уе) — сатып алучыга күтәренке бәяләрне көчләп тагу.

Монополия базарында бәяләрне күтәрү мөмкинлеге бик зур; сатучы бәяләрне үзе билгели һәм шул бәяләрдән сатып алырга мәжбүр итә. Моннан тыш, монополистка үз продукциясен камилләштерергә дә, аны житештерү һәм сатуның кулайрак ысулларын эзләргә дә кирәк түгел. Шуңлыктан базарларның монополияләшү дәрәжәсе арту һәрвакыт житди проблемалар тудыра.

Төрле төр базарлар арасындагы аермаларны 10-2 таблицасыннан, ә төрле төрдәге конкуренция булган базарларда сатучы һәм сатып алучыларның бәяләр формалашуга йогынты ясау дәрәҗәсен 10-6 рәсеменән анларга һәм истә калдырырга була.

Рәсемнән күренгәнчә, сатып алучы һәм сатучыларның мөмкинлекләре саф (камилләшкән) конкуренция базарында гына тигез. Калган барлык башка төрдәге базарларда сатучылар йогынтысы сатып алучылар йогынтысыннан зуррак; саф монополиядә ул иң югары ноктага житә.

Алга киткән илләрнең күбесендә дәүләт базарда монополия күренешләренә каршы көрәшә. Россия Федерациясендә монополиягә каршы дәүләт көйләвенең үзәген монополист фирмаларның сатып алучыларга үз бәяләрен көчләп тагуны чикләве һәм конкуренцияне яклау тәшкил итә. Бу бигрәк тә **табигый монополияләргә** мөнәсәбәттә әһәмиятле.

Таблица 10-2

Конкурентлык итүче базар төрләре арасындагы аермалар

Базар төре	Конкурентлы ситуация тасвирламасы				
	Тармакта фирмалар саны	**Товар төрләре**	**Базарга керүдә каршылыклар**	**Фирманың үз товарларына бәя билгеләү мөмкинлеге**	**Шундый базарларда эшләүче тармакларга мисаллар**
Камилләшкән конкуренция	Зур	Бертөрле эшләнмәләр	Юк	Бөтенләй юк	Авыл хуҗалыгы, көнкүреш хезмәте
Монополиячел конкуренция	Зур	Охшаш файдаланудагы төрле эшләнмәләр	Бар, әмма аларны узарга була	Бераз бар	Азык-төлек, җиңел сәнәгать товарлары, йорт җиһазлары җитештерү
Олигополия	Күп түгел	Бертөрле яки күптөрле эшләнмәләр	Бар, һәм аларны узуы кыен	Зур	Автомобильләр җитештерү, һава юлы белән йөкләр ташу
Монополия	Бер	Алыштыручысы булмаган товар	Бар, һәм аларны узуы кыен яки мөмкин түгел	Бик зур	Электр энергиясе җитештерү, тимер юл белән йөкләр ташу

10-6 рәсем.
Базарны төрлечә оештырганда сатып алучылар һәм сатучыларның бәяләргә йогынты ясау мөмкинлекләре

ТАБИГЫЙ МОНОПОЛИЯ — объектив (табигый яки техник) сәбәпләр аркасында товар җитештерү яки хезмәт күрсәтү бер фирмада тупланган һәм җәмгыять өчен отышлы булган тармак.

Эш шунда: кайбер очракларда монополия (объектив сәбәпләр аркасында) зарур була.

Мәсәлән, бер шәһәрдә ике канализация, фатирларга газ һәм электр энергиясе бирүче ике челтәр төзү икътисади яктан отышлы түгел. Бер үк шәһәрдә көндәшлек итүче ике телефон фирмасы кабельләре сузарга тырышу да һәрвакытта да файда китерми.

Аеруча зур масштаблы табигый монополияләр, гадәттә, энергетикага һәм транспортка карый. Әлеге тармакларда бер зур монополист фирма урынына кечерәк берничә фирма төзү җитештерүгә чыгымнарның артуына һәм нәтиҗәдә бәяләрнең түбәнәюенә түгел, ә күтәрелүенә китерергә мөмкин. Ә бу, аңлашылганча, җәмгыять мәнфәгатьләренә туры килми.

§ 22. Эшмәкәр һәм фирма төзү. Отышлы бизнес оештыру шартлары

Алдарак без фирма төзү һәм аның эшчәнлек алып бару мантыйгы турында сөйләдек. Ә хәзер шушы процесска якыннанрак — фирма төзүче эшмәкәр күзлегеннән карыйк. Бу анализ баштан ук төгәл булсын өчен, **эшмәкәр** сүзенә билгеләмә бирик.

ЭШМӘКӘР — үз акчасына яки бурычка алган заем акчага тәвәккәлләп, җитештерү ресурсларын берләштереп, сатудан табыш бирәчәк байлыклар тудыру өчен фирма төзүче кеше.

Барыннан да бигрәк нинди кешеләр эшмәкәр булып китә? Тикшеренүләр күрсәткәнчә, мондый тормыш юлын түбәндәге үзенчәлекләр белән аерылып торучы кешеләр сайлый:

— үз тормышын үзе кору теләге;
— уртача тәвәккәллеккә һәвәслек;
— үзенең уңышка ирешү сәләтенә ышаныч;
— үзе куйган хезмәтнең нәтиҗәләрен кичекмәстән күрү теләге;
— энергиялелек;
— киләчәккә юл табу;
— башка кешеләрнең эшен оештыра белү;
— ирешелгән уңышны акчага күчереп исәпләргә һәвәслек.

Эшмәкәрлеккә карата төрле фикерләр бар, мәсәлән:

1. Уникаль фикер-идея тапкан эшмәкәрләр генә уңышка ирешә.
2. Эшмәкәрлек катлаулы эш түгел.
3. Эшмәкәрлек — тәвәккәллек сорый торган уен ул.
4. Эшмәкәрлек кече бизнеста гына була.

Әлеге мифлар тулысынча уйдырма, ялган. Байтак уңышлы эшләүче фирмаларны оештыручы эшмәкәрләр бүтәннәр эшли торган эшне башкачарак итеп гамәлгә ашыралар. Шул ук вакытта эшмәкәрлек шактый катлаулы шөгыль: фирманы оештыручыга маркетинг, менеджмент өлкәләрендә гаять күптөрле мәсьәләләрне хәл итәргә туры килә (алар турында сонрак сөйләрбез). «Бу тәвәккәллек сорый торган уен» гына дип әйтү дә («Җай чыгармы-чыкмасмы...») ярамастыр. Күп нәрсә эшмәкәрнең идарә итү квалификациясеннән, яшь фирмаларның күпчелеген юкка чыгаручы еш очратырга мөмкин булган ялгышлардан котылу осталыгыннан тора. Һәм эшмәкәрлек кече бизнес белән генә чикләнми. Мәсәлән, Бөекбританиянең иң бай кешеләреннән берсе «Virgin Airlines» авиакомпаниясе һәм башка күп предприятиеләр (аларның исемнәрендә «Virgin» сүзе булган) хуҗасы, сэр Ричард Брэнсон, гомере буена гадәти эшмәкәр буларак эш-гамәл кылып, бик зур бизнес-империя төзүгә ирешә.

Дөньяда тупланган гаять зур эшмәкәрлек тәҗрибәсе күрсәткәнчә, бу — уен гына түгел, ә катлаулы һөнәри эшчәнлек. Шуны аңлап җиткермәү — яшь фирмаларның юкка чыгуына китерә торган 9 ялгышның төп сәбәбе. Ул ялгышлар түбәндәгеләр:

1) менеджментта белемле (компетентлы) булмау;
2) тәҗрибә булмау;
3) финанслар белән начар идарә итү;
4) ерак киләчәккә үсеш планын эшли белмәү;
5) фирма үсешен контрольдә тотмау;
6) фирманың урнашу урыны уңышлы булмау;
7) ресурслар һәм әзер продукция запасларын начар контрольдә тоту;
8) бәяләр билгеләүнең дөрес булмавы;
9) фирма хуҗасы агымдагы идарә итүне ялланган менеджерларга тапшырганда эшмәкәрлек этабыннан даими менеджмент этабына күчә белмәү.

Әлеге ялгышуларның җитдилеген мондый факт та дәлилли: Америка статистикасы мәгълүматларына караганда, яңа төзелгән фирмаларның 24 %ы төзелүдән соң ике ел үтүгә яшәүдән туктый, фирмаларның 54 %ы беренче 4 елда ябыла,

ə 63 %ы төзелүләренең җиде еллыгына җитә алмый. Шуны булдырмау өчен эшмәкәр:

— үз бизнесының барлык нечкәлекләрен белергә;

— яхшылап уйланган бизнес-план төзергә;

— финанс ресурслары белән оста идарә итәргә;

— үз фирмасының финанс отчетларын анализлау күнекмәләренә ия булырга;

— фирма персоналы белән нәтиҗәле идарә итәргә өйрәнергә тиеш була.

Эшмәкәр җитәрлек дәрәҗәдә акыллы булса да, әлеге ялгышуларны булдырмый калуны һәм бизнесны уңышлы үстерүне җинел эш дип булмый. Эш шунда: һәрбер эшмәкәр керемнәренең тотрыклы булмавы, бизнесны югалту ихтималы, нормалаштырылмаган эш көне һәм хезмәтнең киеренкелеге, бизнес җитәрлек дәрәҗәдә зурайганчы керемнәрнең түбән, эшнең тынгысыз, борчулы булуы, фирманың барлык эшләре өчен җаваплылык белән очраша.

Билгеле, фирма милекчеләре һәм менеджерларының бердәнбер булмаса да, төп максаты — бизнесның уңышлы үсүен тәэмин итү һәм шуның нигезендә шәхсән баю. Ә моңа ничек ирешергә соң? Эш практикасын анализлау күрсәтүенчә, мондый хезмәтнең уңышлы булуы:

1) сатулар һәм активларның үсүеннән;

2) дәүләтнең ярдәм күрсәтүеннән тора (10-7 рәсем).



10-7 рәсем.
Фирманың чагыштырма урынын һәм аның отышлылыгын хәл итүче факторлар



10-8 рәсем.
Табышлы сату һәм активлар үсүен тәэмин итүче факторлар

Башта ук шуны әйтеп үтик: чынлыкта фирманың эшчәнлеге шушы фирма өчен билгеле бер минимумнан да ким булмаган табыш китсә генә отышлы була. Шулай ук активларның үсеше дә алар табышлы продукция җитештерүне турыдан-туры яки башка рәвештә арттыру мөмкинлеге бирсәләр генә нәтиҗәле дип санала.

Сатуның артуын һәм активларның үсүен нәрсә тәэмин итә? Ул ике фактор йогынтысында (10–8 рәсем) мөмкин була:

1) нәтиҗәле менеджмент;

2) нәтиҗәле инвестицияләр кертү.

Бу — шартлы рәвештә шулай. Нәтиҗәле менеджменттан башка нәтиҗәле инвестицияләр (бизнесны үстерүгә акча средстволары кертү) була алмый. «Нәтиҗәле менеджмент» төшенчәсен фирманы үстерүгә кертелә торган акча средстволарын ике үзара бәйләнешле шартның үтәлеше:

1) фирма продукциясенең конкурентлык сәләтен арттыру;

2) фирманың базар кыйммәтен күтәрү мөмкинлеге бирә торган менеджмент дип аңларга кирәк (10-9 рәсем).

Алда әйтеп үтелгән шартларның һәр икесе дә хәзер Россия фирмалары өчен бик мөһим, әмма еш кына моның шулай икәнлеген менеджерлар аңлап бетерми, һәм ул шартлар аларның реаль эш-хәрәкәт итү программаларына сирәк кертелә. Нәкъ менә шул сәбәпле күп кенә Россия фирмалары (бигрәк тә сәнәгатьтә) кыенлыклар кичерә — аларны илдәге базардан чит ил конкурентлары кысрыклый, чөнки соңгылар югары конкурентлык сәләтенә ия, отышлы бизнес оештыру кагыйдәләрен яхшырак үзләштергән.

10-9 рәсем.
Коммерция фирмасы эшчәнлегенә инвестицияләр кертүне нәтиҗәле итү шартлары

Конкурентлык сәләтен арттыру — чит илләрдән товар кертүгә каршы көрәш нәтиҗәсе булудан бигрәк, яхшылап уйланган маркетинг стратегиясен сайлап алудан һәм аны гамәлгә ашырудан килеп чыга (10-10 рәсем).

***ФИРМАНЫҢ БАЗАР БӘЯСЕ** — фирма тарафыннан чыгарылган акцияләрнең суммар бәясе (бәяләре расланган кыйммәтле кәгазьләр тотучы ачык акционерлык җәмгыятьләре өчен) яки фирма икенче бер яңа хуҗага сатылырга мөмкин булган сумма.*

10-10 рәсем.
Фирманың нәтиҗәле маркетинг стратегиясен эшләү нигезләре

10–10 рәсемендә күрсәтелгәнчә, андый стратегияне эшләү фирма менеджерларыннан түбәндәге дүрт төп элементны даими анализлауны таләп итә:

1) фирманың базардагы урыны: ягъни булачак сатып алучылар аның товарларын ничек кабул итәләр (алар товарларның техник яктан камил, сыйфатлы һәм ышанычлы булуын көтәләр);

2) базар ихтыяҗлары: ягъни кулланучылар базарда хәзер нинди таләпләр куялар һәм якын киләчәктә аларның нинди теләкләрен тормышка ашырырга мөмкин;

3) чыгымнарны киметү мөмкинлекләре: фирма, товарларны конкурентларга караганда түбәнрәк бәяләр белән сатып, җитештерү чыгымнарын тизрәк һәм күбрәк киметә аламы;

4) төрле продукция җитештерү мөмкинлекләре: фирма үз товарларының (конкурентларныкы белән чагыштырганда) сыйфатлары буенча аерылып торырдай, бәяләре шундый ук яки югарырак булса да, сатып алучыларны җәлеп итәрдәй төрләрен эшләп чыгара аламы.

Мондый анализ — теләсә нинди маркетинг эшчәнлегенең иң гади нигезе. Россиядәге күп кенә предприятиеләрнең менеджерлары әлеге сорауларга җавап эзләмәгәнгә күрә генә ул хакта искәртергә туры килә. Андый битарафлык еш кына бик уңышсыз маркетинг стратегияләре эшләүгә һәм бәяләр турында мәгънәсез карарлар кабул итүгә, ә кайбер очракларда предприятиеләрнең эшләүдән туктавына китерә.

Бизнесның отышка өмете булсын өчен, эшмәкәргә түбәндәге сорауларга дөрес җавап табарга кирәк:

— Сатып алучыларга, аларның игътибарын җәлеп итү өчен, нинди товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр тәкъдим итәргә була?

— Сатып алучылар безгә мөрәҗәгать итсен өчен, товарлар җитештерүне һәм хезмәт күрсәтүләрне ничек оештырырга, сыйфатны ничек күтәрергә һәм чыгымнарны, сату бәяләрен ничек киметергә?

— Сатып алучылар игътибар итсен һәм сатып алырга теләсен өчен, товарларны һәм хезмәт күрсәтүләрне ничек рекламаларга?

— Фирманы оештыру һәм товарларның беренче партияләрен җитештерүне оештыруга барлык чыгымнарны каплау өчен акчаны каян алырга?

Алдагы өч сораута җавапны эшмәкәр:

1) җитештерү менеджментында;
2) маркетингта;
3) финанс менеджментында (10–11 рәсем);
4) бухгалтер исәп-хисабында;
5) мәгълүмат технологияләрендә эзләргә тиеш була.

МЕНЕДЖМЕНТ — фирманың агымдагы һәм перспективадагы эшчәнлеген нәтиҗәле оештыру кагыйдәләре җыелмасы.

Җитештерү **менеджменты** — фирманың үз товарларын эшләп чыгару һәм сатуны оештыру өчен күпме һәм нинди хезмәткәрләр һәм башка ресурслардан файдаланырга, моны ничек итеп аз чыгымнар белән (тиешле сыйфатны саклаган хәлдә) башкарырга тиешлеге турындагы сорауларны хәл итү ул.



10-11 рәсем.
Бизнесны уңышлы үстерү өчен, эшмәкәр кабул итәргә тиешле карарларның төп төрләре

Андый сорауларны, гадәттә, менеджмент принциплары нигезендә хәл итәләр. Аларга, менеджментны барлыкка китерүчеләрнең берсе Анри Файоль фикеренчә, түбәндәгеләр керә:

1) *хезмәт бүленеше.* Бу — табигый күренеш. Аның максаты — шул ук чыгымнар белән, җитештерүнең күләмен һәм сыйфатын арттыру. Моңа исә игътибар һәм эш-гамәлләр юнәлтелгән максатларның санын киметү исәбенә ирешелә. Хезмәт бүленеше техник эшләрдә генә кулланылмый. Аның нәтиҗәсе — эш вазифаларын махсуслаштыру һәм хакимлекне бүлешү;

2) *хакимият* (тулы вәкаләтле) һәм *җаваплылык.* Вәкаләтләр — әмер бирү хокукы, ә җаваплылык — санкцияләр (бүләкләүләр, шелтә бирүләр); вәкаләтләр булганда җаваплылык та барлыкка килә;

3) *дисциплина.* Бу,— нигездә, буйсыну, тырышлык, эшчәнлек, үз-үзеңне тоту манерасы, хәрәкәт. Дисциплина оешма һәм аның хезмәткәрләре арасында ирешелгән килешүләрне үтәү һәм ихтирам итүдән башка була алмый;

4) *бер кешенең генә күрсәтмәләр бирүе (бер җитәкче).* Нинди дә булса эш-гамәл турында хезмәткәргә ике боерыкны бер җитәкче генә бирә ала;

5) *җитәкчелек, юнәлеш бердәмлеге.* Бер максатка юнәлтелгән бер җитәкче һәм бер программа. Бер максат кысаларындагы һәрбер төркем бердәм план нигезендә берләшергә, аларның бер җитәкчесе генә булырга тиеш;

6) *хосусый, шәхси мәнфәгатьләрне гомуми (уртак) мәнфәгатьләргә буйсындыру.* Бер хезмәткәр яки хезмәткәрләр төркеме мәнфәгатьләре зуррак масштаблы оешма мәнфәгатьләреннән (тулаем дәүләт мәнфәгатьләренә кадәр) өстен булырга тиеш түгел;

7) *персоналны бүләкләү* — башкарылган эш өчен түләү. Ул гадел булырга һәм мөмкин кадәр персоналны да, оешманы да, яллаучыны һәм хезмәткәрне дә канәгатьләндерергә тиеш;

8) *үзәкләштерү*. Хезмәт бүленеше кебек үк үзәкләштерү дә — табигый күренеш. Әмма үзәкләштерү дәрәҗәсе конкрет шартларга бәйле рәвештә үзгәрә һәм иң яхшы житештерүчәнлек бирүгә юнәлтелә;

9) *иерархия* яки *скаляр чылбыр*. Бу — иң югарыларыннан башлап иң түбәндәгеләренә кадәрге житәкчелек итүчеләр. Житди сәбәп булмаганда, иерархиядән читләшү ялгышу дип санала, әмма иерархиядән читләшмәү оешмага зыян китерсә, бу тагын да зуррак ялгышу була;

10) *тәртип*. Матди тәртипнең формуласы — «һәрбер әйбернең үз урыны»; ижтимагый (социаль) тәртип формуласы — «һәр кешенең үз урыны». График таблицалар, схемалар ижтимагый һәм матди тәртип урнаштыруны һәм контрольдә тотуны шактый жиңеләйтәләр;

11) *гаделлек* — яхшылык теләү һәм гадел хөкем бердәмлеге нәтижәсе;

12) *персонал (эшләүчеләр) составының даимилеге*. Кадрларның еш алмашынып торуы — эшләрнең начар баруының сәбәбе һәм нәтижәсе. Үз эш урынының кадерен белгән уртача житәкче эшен еш алмаштыручы, үз эш урынына ябышып ятмаган талантлы менеджердан күпкә өстен;

13) *инициатива* — план эшләү һәм аны уңышлы гамәлгә ашыру. Тәкъдимнәр һәм гамәлгә ашыру иреге шулай ук инициатива төшенчәсенә керә;

14) *персоналны берләштерү* яки *корпоратив рух* — оешмада зур көч.

Хәзерге базарларда яхшы менеджмент кына фирманың отышлылыгын тәэмин итә алмый. Моның өчен маркетинг ысулларын да белергә кирәк.

МАРКЕТИНГ — фирма нәрсәләр житештерергә, иң күп табыш алу өчен аны кайда, ничек һәм нинди бәяләрдән сатуга тәкъдим итәргә тиешлеген хәл итү ысулларының гомуми атамасы.

Маркетингның төп идеясе — житештерелгәнне сату түгел, ә сатудан яхшы табыш алырлык әйберләрне генә житештерү.

Маркетинг турында сөйләгәндә, фирманың түбәндәгеләр белән бәйле эшчәнлеге күздә тотыла:

1) үз товарлары һәм хезмәт күрсәтүләре тәкъдим ителәчәк базарны өйрәнү тикшерү;
2) үз товарларыннды һәм хезмәт күрсәтүләренне рекламалау;
3) сатып алучылар игътибарын жәлеп итүнең төрле ысуллары ярдәмендә продукцияне үткәрү;
4) товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә бәяләрне дөрес кую;
5) сатып алучыларга тәкъдим ителәчәк товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрне сайлап алу;
6) фирманың продукциясен кем, кайда һәм ничек сатачагын билгеләү;
7) сервис хезмәте күрсәтүне оештыру.

Маркетингны «дүрт *P*» дигән мөһим өлешләргә бүлеп өйрәнәләр: продукт (product), бәя (price), үткәрү (promotion), урыны (place).

Чынлыкта маркетинг — фирма хужаларына табыш алу һәм шундый мөмкинлекләрне күп елларга саклау өчен нәрсә белән шөгыльләнергә кирәклеген тәгәлрәк аңларга ярдәм итүче ысуллар жыелмасы ул. Фирманың конкурентлык сәләтен тәэмин итү өчен ул ысулларның әһәмияте бик зур, шуңа күрә фирмалар аларга

елдан-ел күбрәк акча тоталар. Мәсәлән, АКШта куллану товарлары маркетингларына ел саен 300 млрд доллар сарыф ителә.

Фирманың базарга нәрсә белән чыгачагы һәм аның житештерү эшчәнлегенең ничек оештырылачагы ачыклангач, фирманың үсеше өчен акча средстволарын кайдан алачагы һәм бизнесның тиешенчә алып барылуын тәэмин итү өчен, аларны ничек тоту турында уйларга вакыт житә. Бу шулай ук **финанс менеджментына** да карый.

ФИНАНС МЕНЕДЖМЕНТЫ — фирманың тотрыклы үсешен тәэмин итү максатында аның акча ресурслары һәм агымнары белән идарә итү ысуллары һәм кагыйдәләре җыелмасы.

Финансистларның төп союздашлары булып һәрвакыт бухгалтерлар, ягъни фирма эшенең акчага күчерелгән нәтижәләре турында мәгълүматны тиз арада алучы һәм анализлаучы белгечләр торалар. Шундый мәгълүматтан башка фирма житәкчеләре бизнесның ни дәрәжәдә уңышлы баруы һәм анда киләчәктә түли алмау, хәтта банкротлык китереп чыгарырлык проблемаларның булу-булмавын төгәл белә алмыйлар.

Хәзер фирмалар белән идарә итү технологиясендә тагын бер мөһим өлкә барлыкка килде: ул — **мәгълүмат технологияләре**. Бу өлкәдәге белгечләр фирма эшчәнлегенең барлык яклары турында мәгълүматны тиз алырга һәм эшкәртергә мөмкинлек бирүче техник һәм программ системалар төзү белән шөгыльләнәләр. Моннан башка хәзерге тиз үзгәрүчән дөньяда бухгалтер да, финансист та, маркетолог та, фирма менеджеры да эшли алмый.

Менеджмент, маркетинг, бухгалтерия хисабы һәм мәгълүмат технологияләре белән бәйле проблемаларны уйлап һәм белеп хәл итү фирма эшчәнлегенең икътисади нәтижәсен билгели (10-12 рәсем).



10-12 рәсем.
Эшмәкәрнең карарлары аның керемен ничек билгели

Әгәр дә эшмәкәр үзенең эшен моңа кадәр бизнеста (башка кешенекендә булса да) эшләү тәҗрибәсеннән чыгып, менеджмент, маркетинг һәм финанс өлкәсендә дөрес карарларга ничек килү юлларын аңлап башлаган икән, ул әрдәнә идеяләрдән башка да отышлы бизнес төзи ала.

Үз бизнесын төзергә карар иткән эшмәкәр алдында торучы төп дүрт сорауны искә төшерик. Аларның соңгысы, әмма әһәмияте буенча икенче урында торучысы — бизнесны төзү, ә аннары аны киңәйтү өчен акчаны каян алырга?

Гадәттә, күп кенә кече предприятиеләр аларның хуҗалары туплаган акча нигезендә ачыла. Ә аларны алга таба үстерү өчен акча каян алырга?

10-13 рәсеменнән күренгәнчә, андый акча средстволары чыганаклары аз түгел. Күп эшмәкәрләр тышкы чыганакларга мөрәҗәгать итмиләр һәм эчке средстволар белән эшләү җаен табалар; эш башыннан ук «көтелмәгән кыенлыклар чыкса» дип туплаган резерв фондыннан, бүленмәгән табыштан һәм амортизациядән файдаланалар.

***БҮЛЕНМӘГӘН ТАБЫШ** — табышның, милекче үз кереме итеп аласы урынга (яки аны алганнан соң), фирманы үстерүгә юнәлтелгән өлеше.*

***АМОРТИЗАЦИЯ** — әкренләп туза баручы төп фондлар бәясен җитештерелә торган продукция бәясенә күчерү.*

Әмма еш кына әлеге чыганаклар гына җитми. Һәм шунда эшмәкәрләр тышкы чыганаклардан средстволар җәлеп итү мөмкинлекләре эзли башлый. Болар: банк кредиты (кыска сроклы — 1 елга кадәр, озак срокка — берничә елда кайтару срогы белән), үз капиталына хокукны кыйммәтле кәгазьләр (акцияләр) рәвешендә сату, кредитор бурычы, ягъни китереп торучылардан алган, әмма әле түләнмәгән җитештерү ресурслары булырга мөмкин.

10-13 рәсем.
Бизнесны төзү һәм үстерүне финанслау өчен файдаланылырлык акча средстволары чыганаклары

Бизнес эшмәкәрне баетырга да, кыенлыклар белән туплаган акчаларыннан мәхрүм итәргә дә мөмкин. Бөлү куркынычын киметү өчен, мондый эшчәнлеккә керешкәнче аны планлаштырып карарга кирәк. Моның өчен эшне башлаучы эшмәкәргә бизнес-план төзергә, анда (үзе һәм үз бизнесын үстерүгә акча сораячак кешеләр өчен) түбәндәгеләрне ачык итеп язарга киңәш ителә:

1) базарга нинди товар яки хезмәт күрсәтүләр тәкъдим итәчәк;

2) нинди сатып алучыларны һәм ничек җәлеп итәргә өметләнә;

3) конкурентларны ничек итеп отарга өметләнә;

4) бизнесны оештыру өчен нәрсәләр кирәк булачак.

Файдалы һәм реаль (үтәлерлек) бизнес-план әзерләү өчен эшне башлаучыга:

1) бизнесны үстерү шартларын бәяләргә, үз эшен башлау өчен гомуми икътисади хәлнең уңай булуын һәм кирәргә теләгән базарда эшләрнең торышын ачыкларга;

2) менеджмент планын төзергә, яңа фирманың оештыру структурасын (анда нинди бүлекчәләр, һәрбер бүлекчәнең нәрсә өчен җаваплы булачагын, кемнең кемгә буйсыначагын), җитештерү ысулларын һәм кирәкле җиһазлар яки аларны сату урыннарын, хезмәткәрләр санын, аларның квалификациясен һәм түләү ысулларын билгеләргә;

3) маркетинг планы төзергә, анда фирманың эшчәнлеге нинди базарларга яки сатып алучылар төркемнәренә юнәлдереләчәген, товарның, сатып алучылар игътибар итсен өчен, конкурентларныкыннан нәрсә белән аерылып торачагын, товарның нинди бәядән сатылачагын, сатучының кайда һәм ничек оештырылачагын һәм боларның барысы да ничек рекламаланачагын билгеләргә;

4) исәп-хисап ясарга һәм аларга нигезләнеп бизнесның финанс планын төзергә, анда бизнесны башлау өчен күпме акча кирәк булачагын, кайчан ул акчаларга зарурлык туачагын, аларны кемнән һәм нинди шартларда алырга тырышып карарга һәм яңа бизнеска акча кертүнең күпмегә файдалы булачагын күрсәтергә кирәк була.

Хәзер без икътисади акыллылыкның тагын бер рецептын беләбез.

Унынчы рецепт

Илнең икътисады уңышлы үссен өчен, конкуренцияне якларга һәм кайбер фирмаларның, сатып алучыларга югарырак бәяләрне көчләп тагу максатында, базарны монополияләштерергә тырышуына каршылык күрсәтү зарур.

БҮЛЕКНЕҢ ТӨП ЭЧТӘЛЕГЕ

Фирмалар ни өчен төзелә. *Фирмалар коммерция (сәүдә) эшчәнлеген башкаралар. Алар, кешеләргә кирәкле байлыкларны булдыру өчен, җитештерү ресурсларын кулайрак берләштерергә мөмкинлек тудыралар. Хуҗалык (коммерция) оешмалары төрле формаларда төзелә алалар. Россиядә әлеге формаларны Гражданнар кодексы билгели һәм ул түбәндәгеләрне үз эченә ала: хуҗалык ширкәтләре, хуҗалык җәмгыятьләре, җитештерү кооперативлары һәм муниципаль дәүләт*

предприятиеләре. Коммерция оешмаларының төрләре арасында аерма аларда катнашуы мөмкин булган кешеләр даирәсеннән, шулай ук аларның хокуклары һәм бурычларындагы аермадан гыйбарәт. Иң катлаулы һәм средстволар җәлеп итү өчен иң зур мөмкинлекләргә ия коммерция оешмасы — акционерлык җәмгыяте. Ул керемнәре зур булмаган кешеләргә дә фирма хуҗаларының берсе булу, АҖдә гаять зур акча средстволары туплау мөмкинлеге бирә. Акционерлык җәмгыятьләреннән башка хәзерге икътисадның күп тармакларын төзеп булмас иде.

Фирма эшчәнлегенең икътисади нигезләре. *Үз эшчәнлеген тормышка ашыру өчен фирма эчке һәм тышкы (сатып алына торган) ресурслардан файдалана. Фирма файдаланган тышкы ресурсларны сатып алудан — фирманың тышкы чыгымнары, ә эчке ресурслар алуга расходлардан (алар өчен акча түләнмәсә дә) эчке чыгымнар барлыкка килә. Сатудан төшем (тышкы чыгымнарны чигергәннән соң) фирманың бухгалтерия табышын тәшкил итә. Табышның эчке чыгымнардан калган өлеше фирманың икътисади табышы була. Икътисади табыш булганда гына фирма алга таба үсешкә өметләнә ала. Фирманың табышын арттыруның төп ысуллары: җитештерүгә һәм сатуга чыгымнарны киметү һәм товарларга бәяне дөрес кую. Бәяләр белән идарә итү мөмкинлеге билгеле бер базарда нинди конкурентлык хәле урнашуга, аның зур фирмалар тарафыннан ни дәрәҗәдә монопольләштерелгән булуына да бәйле. Конкурентлык хәленең берничә төре бар; аларны (аерым фирманың базар бәяләре куюга хакимлеге кечәю ягыннан) шундый тәртиптә урнаштырырга мөмкин: камилләшкән конкуренция, монополиячел конкуренция, олигополия, саф монополия. Базарның монопольләштерелү дәрәҗәсе никадәр югарырак булса, аның механизмы шулкадәр начаррак эшли, шуңлыктан бөтен дөньяда дәүләт конкуренцияне якларга омтыла.*

Эшмәкәр һәм фирма төзү. *Фирмалар (эшмәкәрләр тарафыннан) табыш рәвешендә керем алу һәм җәмгыять мәнфәгатьләрен канәгатьләндерү өчен төзелә. Эшмәкәрлек кешедә шундый эшчәнлеккә беркадәр һәвәслек һәм билгеле бер сәләт-күнекмәләр булуын таләп итә. Эшмәкәрләр төзегән яңа фирмаларның күбесе, берничә ел эшләгәннән соң, хуҗаларның ялгышулары нәтиҗәсендә ябылалар. Шундый типик ялгышуларның сәбәпләрен белү яңа төзелгән бизнесның ябылу ихтималын киметергә ярдәм итә.*

Отышлы бизнес төзү шартлары. *Сатуны һәм фирманың табышын арттыруны тәэмин итү өчен, эшмәкәргә аның эшчәнлегенең нәтиҗәле менеджментын булдырырга һәм рациональ рәвештә акча (инвестиция) кертергә кирәк була. Фирма товарларының конкурентлык сәләтен һәм бизнесның (фирманың) бәясен арттыручы проектларга акча средстволары кертү генә нәтиҗәле дип санала. Әлеге ике бурычны хәл итүнең төп шарты — фирманың маркетинг стратегиясен дөрес сайлау.*

Фирма белән нәтиҗәле идарә итү сәнгате. *Бизнесның дөрес үсешен тәэмин итү өчен, эшмәкәргә сатып алучыларда кызыксыну тудыра торган товар сайлау, аны җитештерү һәм сатуны нәтиҗәле итеп оештыру, рекламалау ысулларын һәм сатуны тизләтү (стимуллаштыру) җаен табу зарур. Болар барысы да фирманың сатудан төшемен һәм чыгымнарын, димәк, эшмәкәр алачак табышны да билгели. Бизнес-планны белеп төзү мондый мәсьәләләрне хәл итәргә булыша.*

ФИКЕР АЛЫШУ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. СССР икътисады иң зур предприятиеләргә нигезләнеп төзелгән була. Ни өчен бу нәкъ шулай эшләнгән һәм ул андый предприятиеләрнең хәзер кыенлыклар кичерүе белән бәйлеме?
2. СССР икътисадында предприятиеләр еш кына продукциянең аерым төрләрен җитештерүдә тулы монополистлар булган диярлек була. Бу аларның чыгымнары дәрәҗәсендә ни рәвешле чагылыш тапкан һәм хәзер Россия базарына чит илләрдән килгән конкурентлар белән көрәшүдә кыенлыклар барлыкка китергән?
3. Ни өчен эшмәкәрлек таланты илнең җитештерү ресурсы булып исәпләнә?
4. Ни өчен эшмәкәргә фирманың бәясен күтәрү отышлы?
5. Хәзерге заман маркетингы менеджерларның «уникаль сәүдә тәкъдиме» барлыкка китерү осталыгын фирманың отышлы булуының нигезе дип саный. Әлеге терминның мәгънәсе нинди?

Гаиләләр акчаны ничек алалар һәм тоталар. Керемнәрнең тигезсезлеге һәм аның нәтиҗәләре

БҮЛЕКТӘ КАРАЛУЧЫ МӘСЬӘЛӘЛӘР:

1. ГАИЛӘ КЕРЕМНӘРЕ НИЧЕК БАРЛЫККА КИЛӘ?
2. КЕШЕЛӘР АКЧАНЫ НӘРСӘЛӘРГӘ ТОТАЛАР?
3. ИНФЛЯЦИЯ КЕШЕЛӘР ТОРМЫШЫНА НИЧЕК ЙОГЫНТЫ ЯСЫЙ?
4. НИ СӘБӘПЛЕ ИКЪТИСАДИ ТИГЕЗСЕЗЛЕК БАРЛЫККА КИЛӘ? ЯРЛЫЛАРГА НИЧЕК ЯРДӘМ ИТӘРГӘ?



XIX гасырда яшәгән немец статисты Эрнст Энгель (бүген аны бөтен дөнья таный) болай дигән: шәхси куллану барлык илләрдә охшаш модель белән үсә, шуңа күрә гаилә керемнәре структурасын анализлау төрле илләр гражданнары байлыгын үзара чагыштырырга мөмкинлек бирә.

«Тусаң да, чукынсаң да, өйләнсәң дә,
үлсәң дә — барысына да акча түлә!»
Рус халык мәкале

Шунысын искәртик: икътисад дөньясының үзәгендә кеше, гаилә тора. Һәм, табигый ки, гаилә тормышы һәрчак икътисад фәненең игътибарын җәлеп итеп килә. Йорт, гаилә икътисадындагы кечкенә күләмле процесслар тулаем гомумдәүләт икътисадына зур йогынты ясый. Гаилә икътисады белән танышша башлау өчен проблемаларның кайберләрен генә, әмма иң әһәмиятлеләрен сайлап алдык:

— гаилә керемнәренең чыганаклары;
— гаилә чыгымнарының структурасы;
— гаиләләр байлыгындагы аерма һәм дәүләтнең аларны тигезләргә тырышуы;
— инфляциянең гаилә керемнәренә йогынтысы.

§ 23. Гаилә керемнәре һәм чыгымнары

Гаиләләр үз керемнәрен аларда башка кешеләргә файдалы җитештерү факторлары булу сәбәпле алалар. Ул милекне башка кешеләр яки фирмалар файдалануына биреп торырга (мәсәлән, фатирдагы бер бүлмәне башка шәһәрдән килүчеләргә билгеле бер түләү бәрабәренә бирү) яисә башка кешеләргә сатарга мөмкин булган товарлар җитештерүгә яки хезмәт күрсәтүләргә файдаланырга була.

Башкача әйткәндә, әгәр дә гаилә милкен башка кешеләр үз мәнфәгатьләрендә файдалана алмыйлар икән, аның белән акча эшләп булмый. Әйтик, автомобиль гаилә әгъзаларын йөртү өчен генә файдаланылса, ул керем китерми. Ул автомобильне йөртү дә керем бирми.

Әмма кем дә булса, мәсәлән, сату өчен алып килгән үз товарларын базарга кадәр илтеп куярга үтенсә, ул моның өчен түләячәк. Һәм бу очракта алынган акча берьюлы ике җитештерү факторы: автомобильне йөртү өчен куелган хезмәт һәм автомобиль рәвешендәге капитал өчен булачак. Димәк, башка кешеләр өчен кирәкле байлыклар җитештерүгә юнәлтелү ихтмалы булган милек кенә керем бирә. (Әлеге мисалда товарлар тутырылган сумкаларны базарга кадәр илтеп кую хезмәте шундый «байлык» иде.) Милектән нәкъ менә шулай файдалану өчен җитештерелгән байлыкларны сатып алучылар түли дә. Димәк, теләсә нинди керем теге яки бу җитештерү факторының хезмәт күрсәтүе өчен түләүдән гыйбарәт.

ГАИЛӘ КЕРЕМНӘРЕ — гаилә әгъзалары чит кешеләрдән яки оешмалардан ала һәм үз чыгымнарына түләү өчен файдалана торган акча средстволары.

Гаилә керемнәренең барлык төрләре классификациясе, аларның нинди җитештерү факторына ия булудан алынуына бәйле рәвештә, 11-1 таблицасыннан күренә.

Таблица 11-1

Житештерү факторы	Керемнәрнең төрләре
Ялланып эшләүче хезмәте	Хезмәт хакы
Эшмәкәр хезмәте һәм аның үз средстволарыка барлыкка китерелгән фирма капиталы	Эшмәкәр табышы
Фирманың житештерү капиталы	Процент рәвешендәге керем
Жир (табигый ресурслар)	Рента
Акча капиталы	Процент

Дөньядагы илләрнең күбесендә гаилә керемнәренең төп чыганагы — хезмәт өчен түләү. Әмма күп кенә гаиләләр, хезмәт хакы белән беррәттән, башка житештерү факторларына ия булудан да керем алалар.

Күп еллар буена безнең илдә эшләр башкача торды. 1917 елдан соң команда бирүгә корылган система капиталга һәм жиргә хосусый милекне юкка чыгарды, ә эшмәкәрлек сәләтләре күрсәтү Жинаять кодексының махсус статьясы белән тыела, «хосусый-эшмәкәрлек эшчәнлеге» өчен озак срокка төрмәгә ябу жәзасы бирелә иде.

Кешеләр ия була алган һәм аны «сату»дан керем алырга мөмкин булган бердәнбер житештерү факторы булып кеше хезмәте калды. Шуңа күрә Россиянең 90 нчы елларга шактый хәерче халык белән керүе гажәп тә түгел. XX гасырның соңгы унъеллыгы бусагасында гражданнарның 21 %ы 5—10 мең сум торучы милеккә ия иде. (Ул вакытта «Жигули» яки «Москвич» тибындагы жиңел машина яки йорты белән 6 сотый дача участогы якынча шул бәягә сатыла иде.) Кыйммәт бәяле милеккә россиялеләрнең 14 %ы ия булса, 65 % гражданнарның милке бәясе уртача 25 айлык хезмәт хакыннан артмый (якынча ул чор бәяләре белән 3250 сум) һәм алар бик тыйнак яши иде.

Ул вакытларда россиялеләрнең күбесен шәхси ярдәмче хужалыкның булуы (авылларда яки бакчачылык ширкәтләрендә, үз хезмәтләре белән азык-төлеккә һ. б. ихтыяжларны канәгатьләндерү өчен авыл хужалыгы продукциясе житештерү коткара. Мондый ситуация XXI гасыр башында да әллә ни үзгәрми: дәүләт статистикасы мәгълүматларына караганда, узган гасырның 90 нчы елларында авыл хужалыгы житештерүенең гомуми күләмендә аерым кеше хужалыкларының продукция эшләп чыгаруы ил буенча 2 тапкырдан күбрәккә арта һәм 57 % тан артып китә.

Шәхси хужалыкларга илдә житештерелгән бәрәңгенең – 91, яшелчәләрнең – 80, итнең 57 % ы туры килә.

Шәһәрләшү (халыкның күпләп шәһәрләргә күчүе) этабын узган илдә шәхси ярдәмче хужалыкларның шундый көчле үсешенең сәбәбе — күп гаиләләрнең акча керемнәре гаять түбән булуда. Яшәү өчен кешеләр натуралата керем — үз шәхси хужалыкларында житештерелгән азык-төлек алырга, аны гаиләдә кулланырга яисә өлешчә (сәнәгать товарлары сатып алу һәм коммуналь хезмәтләргә: электр энергиясенә, жылылыкка һ.б. түләргә акча алу өчен) базарларда сатарга тырышалар.

90 нчы елларда икътисадта һәм законнар чыгаруда реформалар башлангач, хәлләр әкренләп булса да үзгәрә. Закон гражданнарга хосусый милек хокукында

житештерү факторларына ия булырга рөхсәт итә. Дөрес, әле хәзер дә җиргә (аерым алганда авыл хуҗалыгы җирләренә) һәм башка табигый ресурсларга тулысынча хосусый милекчелек бар дип әйтүе кыен. Шулай да житештерү факторларына хосусый милекчелекне яңадан торгызу россиялеләрнең гаилә керемнәре структурасын үзгәртә башлады инде. Ул үзгәрешләр 11-1 рәсемендә яхшы күренә.

XX гасыр ахыры — XXI гасыр башында илдә нәрсә булды соң? Россиялеләрнең гаилә акча янчыклары турындагы таблица илдә параллель рәвештә үсә баручы ике көчле процесс булуы турында сөйли.

Беренчесе — яңа икътисади механизмнар барлыкка килү. Эшмәкәрлектән һәм милеккә ия булудан керемнәр өлешенең артуы (1982 — 1 %, 2001 — 20 %) нәкъ менә шуның белән бәйле.

Россия гаиләләренең 1982 елдагы керемнәре структурасы (% ларда)

Россия гаиләләренең 2003 елдагы керемнәре структурасы (% ларда)



11-1 рәсем.
Россия гаиләләренең 1982 һәм 2003 еллардагы керемнәре структурасы (% ларда)

Икенчесе — 90 нчы елларның беренче яртысында Россиянең бигрәк тә житештерүнең кимүендә күренгән икътисади кризистан әкренләп чыга баруы. Әлеге кризис гаиләләрнең керемнәренә нык тәэсир итте, чөнки:

1) икътисадның житештерү секторындагы күпчелек предприятиеләрдә ялланып эшләүче хезмәткәрләрнең хезмәт хакы (инфляция һәм эшмәкәрләр, ваклап сатучылар һәм банкирлар керемнәре белән чагыштырганда) бик әкрен үсте. Ул предприятиеләр үз продукцияләрен сатуда кыенлыклар кичерде, аларның керемнәре (димәк, үз хезмәткәрләренә түләү мөмкинлекләре) булмады;

2) эшсезлек өчен (хезмәт хакыннан кимрәк күләмдә) пособие алучылар саны артты.

Илдә 1999—2000 елларда башланган икътисади күтәрелеш халыкның керемнәрендә хезмәт хакы алып торган өлешнең 46,6 % тан (1994) 65 % ка (2001) кадәр артуына китерде.

Гаилә керемнәре турындагы мәгълүматлар икътисадта эшләрнең ничек торуын бәяләү өчен дә шактый кызыклы. Моны XIX гасырда немец статисты Эрнст Энгель ачыклаган. Ул тикшергән һәм тасвирлаган бәйлелекне (аның хөрмәтенә) **Энгель законы** дип йөртә башлаганнар.

ЭНГЕЛЬ ЗАКОНЫ: гаиләнең кереме арту белән туклануга чыгымнарның чагыштырма күләме кими; кием-салым, торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен чыгымнар аз үзгәрә, ә мәдәни һәм башка ихтыяжларны канәгатьләндерү өчен чыгымнар өлеше сизелерлек арта.

Тормыштагы төрле байлыклар, рәхәтлекләр кешеләр өчен бердәй файдалы түгел, шуңа күрә алар аерымланалар. Әлеге законның мантыйгы шуңа нигезләнгән.

Барыннан да элек кешеләр үзләренең азык-төлеккә ихтыяжларын канәгатьләндерүгә ирешәләр. (Бер икътисадчы шаяртып әйткәнчә: «Безнең азыкка ихтыяжыбыз ашказаныбыз күләме белән чикләнгән».) Шуңа күрә керемнәр артканда иң элек туклануга тотылган чыгымнар өлеше кими башлый. Аннары чират кием-салымга сарыф ителгән акча өлешенең кимүенә житә, әмма бу очракта «туену» процессы әкренрәк бара. Сәбәбе гади: мондый ихтыяжларны «мода» дигән көчле корал «куалап» тора.

Барыннан да бигрәк, кешеләргә торакка ихтыяжны канәгатьләндерү читен. 11-2 таблицадагы мәгълүматлардан күренгәнчә, илдә туклануга һәм кием-салымга чыгымнар түбәнрәк булган саен, торак өчен түләүләр югарырак була бара. Эш әлеге илләрдә торакның кыйммәтрәк торуында түгел, ә аның сыйфаты һәм тәэмин ителеше югарырак булуда.

Моннан тыш, торак,— автомобиль кебек үк, «абруйлы сорау» булган товар. Кешеләр уңайлылык өчен генә түгел, ә үзләренең җәмгыятьтәге урыннарын күрсәтү өчен дә сыйфатлы торак алырга тырышалар.

Эрнст Энгель болай дигән: шәхси куллану барлык илләрдә охшаш модельләр буенча үсә икән, димәк, гаилә чыгымнары структурасын анализлау:

1) бер илдәге төрле катлам кешеләренең байлыклары дәрәжәсен (критерий буларак, гаиләнең туклануга чыгымнарын да истә тотып);

2) төрле илләрдә яшәүче гражданнарның байлыклары дәрәжәсен чагыштырырга мөмкинлек бирә.

Таблица 11-2

Доньяның төрле илләрендә 2002 елда шәһәрләрдә яшәүче гаиләләрнең чыгымнары структурасы (% ларда)

Ил	Туклану	Азык-төлек булмаган товарлар	Торак һәм хезмәт күрсәтүләр	Транспорт	Белем алу һәм дәвалану
АКШ	10,0	6,5	25,5	13,5	17,5
Япония	15,0	6,0	24,0	10,0	15,0
Швеция	16,5	7,0	30,5	19,0	3,0
Греция	33,0	9,5	20,5	13,0	4,5
Португалия	35,0	11,0	15,0	16,0	6,0

Таблица 11-3

Россия гаиләләренең 1989 һәм 2002 еллардагы чыгымнары (% ларда)
(Россия Федерациясе Дәүләт статистика комитеты мәгълүматлары)

Чыгымнарның төрләре	1989	2002
Туклану	28,3	41,7
Азык-төлек булмаган товарлар	26,0	36,2
Хезмәт күрсәтүләргә түләү	31,3	17,5
Тупланыш һ.б. чыгымнар	14,4	4,6
Барлыгы:	100	100

Э. Энгель кинәшләреннән файдаланып, Россия һәм доньяның башка илләре гражданнарының байлык дәрәҗәләрен чагыштырып карыйк. 11-2 һәм 11-3 таблицаларда доньяның аерым илләрендә гаиләләрнең шәхси куллануга чыгымнары структуралары күрсәтелгән.

Россиядә чыгымнар структурасы (кешеләргә кулга бирелә һәм дәүләт органнары статистикасына керми торган «соры керем»нәрне исәпләмичә) доньяның алга киткән илләрендәгедән нык аерылып тора.

Энгель законыннан чыгып караганда, икътисади үсеш һәм үз гражданнарының байлык дәрәҗәсе буенча Япония һәм АКШ — лидерлар. Россия исә (анда туклануга чыгымнар — 41,7 %) таблицада урнаштырылган илләр арасында соңгы урында. АКШта, Япониядә һәм Көнбатыш Европаның күпчелек илләрендә туклануга чыгымнар моннан 70—100 еллар югары дәрәҗәдә булган. Димәк, Россия ул илләрдән үз гражданнарының байлыгын тәэмин итү буенча шулкадәр вакытка артта калган.

Гаилә икътисадына «инфляция» дигән куәтле процессның йогынтысын исәпкә алмаганда, гаилә бюджетларын анализлау тулы булмас иде.

§ 24. Инфляциянең гаилә икътисадына йогынтысы

Инфляциянең гаилә икътисадына кире йогынтысы бәяләрнең даими үсүе, һәм нәтиҗәдә акчаларның сатып алу мөмкинлеге кимү аркасында гаиләнең хезмәткә сәләтле әгъзалары керемнәренең кыйммәте югалу белән бәйле. Инфляция **гаиләнең номиналь** (күрсәтелгән) һәм **реаль** (чынлыктагы) **керемнәре** арасындагы аерманың нык үсүенә китерә.

НОМИНАЛЬ КЕРЕМ — граждан яки гаилә билгеле бер вакыт эчендә алган акча суммасы.

РЕАЛЬ КЕРЕМ — граждан яки гаилә үзенең номиналь керемнәренә билгеле бер вакыт эчендә сатып ала алырлык товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрнең күләме.

Гаиләләрнең реаль керемнәре үсү номиналь керем үсеше һәм бәяләрнең гомуми дәрәҗәсе үсеше темплары нисбәтеннән тора. Әйтик, бер елга хезмәт хакы — 30, ә бәяләр 40 % ка үссә, реаль керемнәр элеккесенең 92,9 % ын тәшкил итәр [(130 : 140) x 100], ягъни чынлыкта 7,1 % ка кимер.

Фактик мәгълүматларны исәпләүләрнең мондый ысулын кулланып, без, мәсәлән, 2000 елда хезмәт хакының 1998 елдагыдан 3,08 тапкыр артыграк булуын белербез (1998 ел — 1051 сум; 2000 ел — 3240 сум). Әмма шул ук вакытта сату бәяләренең күтәрелүе сәбәпле, реаль хезмәт хакы 2001 елда (уртача алганда) 1998 елдагыдан 14,6 % ка артыграк булган. Ә менә россиялеләрнең уртача еллык түгел, ә айлык (декабрь) хезмәт хакларын чагыштырганда, номиналь хезмәт хакының 2000 ел ахырында 1998 ел ахырындагыдан 2,12 тапкырга артыграк булуын һәм реаль хезмәт хакының 34 % ка үсүен белербез. Димәк, 2000 ел ахырыннан хезмәт хакы сату бәяләренә караганда тизрәк үсә, һәм россиялеләрнең реаль байлыгы да әкренләп арта башлый.

Номиналь һәм реаль керемнәр үзгәрешендәге мондый сизелерлек аерма илдәге бик күп әһәмиятле икътисади процессларга йогынты ясый. Барыннан да элек, реаль керемнәр кимү сәүдәнең торышында чагыла: кешеләр күпкә кимрәк товар сатып алырга сәләтле була. Һәм, киресенчә, реаль керемнәр арту товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү мөмкинлекләрен арттыра. Мәсәлән, әгәр дә 2000 һәм 1998 елларда товарлар сату күләмен чагыштырсак, ике елга үсешнең 0,5 % кына тәшкил итүен белербез. Ә менә декабрь белән декабрьне, ягъни реаль керемнәр номиналь керемнәрдән тизрәк үсә башлаган чорны чагыштырганда, россиялеләрнең 2000 ел ахырында кибетләрдән 1998 ел ахырындагыга караганда 15 % ка күбрәк товар сатып алулары күренә.

2004 елда халыкның реаль керемнәре 5,5 % ка, ә 2005 елда якынча 9 % ка арта.

Кешеләр, нәрсә белән шөгыльләнүләренә һәм нинди хезмәт хакы алуларына карап, инфляциядән төрлечә зыян күрәләр.

Бу яктан барлык гаиләләрне ике төп төркемгә:

1) **теркәлгән** (даими) керемле;
2) **үзгәреп торучан** керемле гаиләләргә бүләләр.

Беренче төркемгә керемнәре гаилә әгъзаларының хезмәт активлыгына бәйле булмаган гаиләләр керә: пенсионерлар, эшсезләр, студентлар, күп балалы гаиләләр. Шушы ук төркемгә хезмәтләренә теркәлгән (даими) ставкалар буенча дәүләт бюджетыннан акча алучылар: армия, хокук саклау, медицина, мәгариф, элемтә, социаль хезмәт һ.б. хезмәткәрләр керә.

Икенче төркемне гаилә әгъзалары житештерү тармакларында эшләүче, шулай ук эшмәкәр һәм ижат интеллигенциясе булган гаиләләр тәшкил итә. Аларның үз хезмәт активлыгын көчәйтү яки түләүне арттыруны таләп итүче забастовкалар оештыру юлы белән керемнәрен арттыру мөмкинлекләре күбрәк. Мондый гаиләләргә үзләренең реаль керемнәренең кимүен алдан кисәтү җиңелрәк.

Гаиләнең икътисади тормышы һәрвакыт тәвәккәллек сорый, ягъни тупланган акчаларны яки милекне өйләнә-тирәдәге көтелмәгән хәлләр яки шәхси зыян күрүләр нәтиҗәсендә югалту куркынычы бар. Страховкалау ул югалтуларны булдырмый калырга ярдәм итә (11-2 рәсем).

Страховкалау компанияләре билгеле бер түләү бәрабәренә гаиләләргә төрле көнелсез хәлләр булганда югалтуларны каплау хезмәте күрсәтә ала:

1) һәлакәткә очрау аркасында яки табигать бәла-казаларыннан зарарланган автомобильне ремонтлауга чыгымнарны кайтару;

2) янгын, су басу яки суүткәргечтән һәм жылыту системасыннан су агу нәтиҗәсендә зарар күргән очракта фатирны яисә шәхси йортны ремонтлауга тотылган чыгымнарны түләү;

3) юл-транспорт һәлакәтендә башка бер кеше автомобилен зарарласагыз, аны ремонтлау өчен чыгымнарны каплау (Россиядә хәзер барлык автомобиль хуҗалары өчен мондый хәлләр өчен страховкалау мәҗбүри);

11-2 рәсем.

Гаиләләргә файдалану өчен кулай страховка төрләре

4) житди травма яки инвалидлык алганда акча түләү;

5) дәвалануга киткән чыгымнарны каплау;

6) гаилә туйдыручысын югалткан очракта зур сумма түләү.

Мондый сорау туа: страховкалау компанияләре боларны ничек эшли ала? Җавап гади — акчалата андый түләүләрне алу өчен гаилә башта страховкалау компанияләренә билгеле бер сумманы кертергә тиеш. Әмма бу файдалы — күпчелек очракта соңыннан страховкалаучылардан алырга мөмкин булачак суммадан күпкә аз түләнә.

Страховкалау ике якның — страховкаланучы һәм страховкалаучының мәнфәгатьләрен һәм мөмкинлекләрен үзара файдалы килештерүгә нигезләнгән. Страховкаланучы гаилә үз милкенә килгән зыянны акчалата кайтарып алырга мөмкин, әмма байый алмый. Чөнки страховкалауда «зыян күрүне каплау зыянның күләменнән зуррак була алмый» дигән принцип эшли.

Хәзерге җәмгыятьтә страховкалау саклавыннан башка яшәү акылсызлык булыр иде. Террор актлары яки күрше фатирларда көнкүреш газы шартлау нәтиҗәсендә торакларын югалткан гаиләләр моны авыр кичерделәр. Шуна күрә төрле страховкалау полислары сатып алучы россиялеләрнең саны арта.

Барлык икътисади проблемаларны да гаилә үзе генә хәл итә алмый. Дәүләт моңа игътибар итмәсә, гаиләләрдәге кыенлыклар бөтен ил проблемаларына әверелә. Гаилә икътисадындагы хәлләрне даими күзәтү һәм андагы куркыныч яки тискәре процесслар үсешен булдырмау — ил белән акыллы идарә итү билгесе.

§ 25. Гражданнар байлыгындагы тигезсезлекләр һәм аларны киметү мөмкинлекләре

Алдарак без гаилә керемнәренең ничек барлыкка килүе һәм аларның ничек тотылуы белән таныштык.

Гаилә керемнәре мәсьәләсенең читләтеп үтелмәскә тиешле икенче бер ягы — икътисади тигезсезлек, ягъни гражданнар байлыгындагы аермалар.

Байлык тигезсезлеге, шуның аркасында килеп чыга торган социаль киеренкелек — ярлыларның байларга дошманлыгы кебек үк, иң борынгы проблемаларның берсе. Библиядә юкка гына: «*...Байларга Алла патшалыгына керүгә караганда, дөягә инә күзеннән үтү җиңелрәк*»,— дип язылмаган (*Матфей Инҗиле, 19 бүлек, 24 шигырь*).

Шуна күрә икътисад фәне күптәннән һәм даими рәвештә әлеге тигезсезлекне, аның тискәре нәтиҗәләрен өйрәнү, аларны киметү чараларын эшләү белән шөгыльләнә.

Бу проблеманың ике ягы бар:

1) керемнәр тигезсезлеге;

2) байлык тигезсезлеге.

Инде белүебезчә, кешеләр керемнәрне алар милкендәге җитештерү факторларын (үз хезмәтләре, капитал, җир) кешеләргә кирәкле байлыклар җитештерүдә файдалану өчен фирмаларга биреп торганда яки әлеге ресурсларны үз фирмаларын

11-3 рәсем.
Керемнәр тигезсезлеген тудыручы сәбәпләр

төзүгә керткәндә алалар. Мондый юл белән керем алуда баштан ук аның тигезсез булу ихтималы салынган. 11-3 рәсеменнән күренгәнчә, моның сәбәпләре:

1) кешеләрдәге житештерү факторлары кыйммәтенең төрлелеге (компьютер, житештерү факторы буларак, күрәк рәвешендәге капиталдан күбрәк керем китерә);

2) житештерү факторларыннан уңышлы файдалану төрлелеге (дефицит товар житештерүче фирма хезмәткәренең квалификациясе шул ук, әмма товарлары авыр сатыла торган фирмада эшләүчегә караганда ул югарырак хезмәт хакы алырга мөмкин);

3) кешеләр ия булган житештерү факторларының күләме (саны) төрле булу (башка шартлар бердәй булганда да, ике нефть скважинасына ия кеше бер генә скважиналы кешегә караганда зуррак керем ала).

Үз керемнәреннән файдаланып, кешеләр аларның бер өлешен өстәмә күләмдә житештерү факторлары алуга тота ала. Мәсәлән, гаилә үз хезмәт хакының бер өлешен банкка салырга һәм хезмәт хакы рәвешендә генә түгел, процентлардан да керем алырга мөмкин. Шулай итеп, **гаилә байлыгы**, ягъни ул ия булган милек (аны булдыру өчен бурычка алганнарны чигереп) хасил була. Әйтик, бер гаилә кибет сатып алу өчен банктан акча алып торган, әле хәзергә алынган акчаларның 50 процентын һәм бурычка алганга процентларны гына кайтарып бирде, ди. Бу очракта гаилә байлыгына кибет бәясенең 50 проценты гына керер.

Гаилә үз байлыгын васыять итеп, ягъни **васыятьнамә** белән балаларына калдыра ала. Ә бу исә байлык һәм эшчәнлектән кергән керемнәр төрлелеге өчен ныгый баручы нигез булдырып, байлык дәрәҗәсе төрлелеге буыннан буынга арта барырга мөмкин дигән сүз.

ГАИЛӘ БАЙЛЫГЫ — гаиләнең бурычлардан азат милке.

ВАСЫЯТЬ ИТҮ — милеккә хокукның милек хуҗасы ихтыяры белән аның үлеменнән соң гамәлдәге законнар нигезендә юридик яктан теркәлгән көчче.

Бер генә икътисади система да гаиләләрнең керем һәм байлыгы тигезсезлеген бетерә алмады. Хәтта СССРдагы командачыл система чорында да дәүләт тулысынча тигезләү принципларыннан ваз кичәргә (аларны «хәрби коммунизм» дигән чорда гына тормышка ашырырга тырышып карадылар) һәм керемнәрне «һәркемнән — сәләтенчә, һәркемгә — хезмәтенчә» принцибында формалаштырырга мәҗбүр була. Әмма кешеләрнең сәләт-мөмкинлекләре төрле булганлыктан, аларның хезмәтенең кыйммәте дә төрлечә, бу исә хезмәт өчен төрле күләмдә түләүгә, ягъни керемнәр төрлелегенә китерә.

Керемнәр һәм байлык тигезсезлеге гаять зур масштабларга җитәргә һәм илдәге сәяси һәм икътисади тотрыклылыкны куркыныч астына куярга мөмкин. Шуңа күрә дөньяның барлык алга киткән илләрендә андый тигезсезлекне киметү чаралары күрелә.

Шунысы да бар: керемнәрдә абсолют тигезлек кешеләрдә житештерүчән хезмәткә кызыксынуны бетерә. Кешеләр төрле булып туалар һәм төрле, кайчак бик сирәк очрый торган сәләтләргә ия булалар. Теләсә кайсы илдә математиканың ин биек үрләрен яулый алырлык, бик яхшы футболчы булырлык яки чәчәк атучы фирма төзерлек кешеләр һәрвакыт бик сирәк очрый. Шуңа күрә гомумдәүләт хезмәт базарында андый сәләтлеләргә ихтыяҗ тәкъдимнән күпкә артык. Ә бу андый кешеләрнең хезмәт итү сәләтләренә бәянең һәм аларның керемнәренең артуына китерә.

Ләкин бер үк төр сәләтләргә ия кешеләр бер үк вазифаларны төрлечә — төрле житештерүчәнлек белән һәм әзер продукциянең сыйфаты да үзгә — башкаралар. Бу аларның индивидуальлегенә, физик һәм нерв-психик үзенчәлекләренә бәйле. Ә төрле нәтиҗәләр биргән хезмәткә ничек түләргә; нәрсә әһәмиятлерәк: эшне башкару фактымы әллә аның нәтиҗәсеме?

Бердәй — «эш башкару факты»ннан чыгып түләнсә, бу зуррак житештерүчәнлек белән эшләүче һәм җәмгыять өчен файдалы сәләтләргә ия булучыларга ошамаячак. Аларның күбесе тулы көчкә эшләми башлаячак, һәм эшнең нәтиҗәлелеге сәләтсезрәк һәм ялкаурак кешеләр дәрәҗәсенә төшәчәк. Илнең икътисади алгарышы өчен мөмкинлекләр кимеячәк, һәм аның барлык гражданнарының байлыклары үсү темплары әкренәячәк.

Менә шуңа күрә дә кешеләр эшчәнлегенә төрлечә, хезмәтнең житештерүчәнлегенә һәм сыйфатына катгый туры китереп түләргә туры килә. Керемнәрнең билгеле бер күләмдәге тигезсезлеген нормаль хәл дип танырга кирәк; ул — кешеләрнең хезмәт активлыгын хуплау, бүләкләүнең әһәмиятле чарасы да.

Бу хакта XX гасырның күренекле инглиз икътисадчысы лорд Джон Мейнард Кейнс болай дигән:

«Фән котылгысыз җиңүгә ирешкәнче, ярлылыкны — тигез, ә байлыкны тигезсез бүлүнең берсен сайларга туры килә».

Икътисад тарихында ил хуҗалыгы үскән һәм аның гражданнарының гомуми байлык дәрәҗәсе арткан саен, керемнәрнең тигезсезлек дәрәҗәсе башта арта, ә аннары әкренләп кими башлый.

Күп илләрнең хөкүмәтләре инде күптән түбәндәге фикергә килгәннәр: керемнәрнең тигезсезлеген киметүнең иң гади һәм уңайлы ысулларыннан берсе — иң бай гражданнар өчен керемнәрдән дәүләт файдасына акча алуның иң зур ставкаларын кертү. Керемнәрнең төрлелеген киметүнең мондый юлы **«прогрессив салымнар»** дип исемләнгән.

Прогрессив салымнар кешеләрнең тигез хокуклылыгын бозмаслык итеп оештырылган. Салымнарның мондый системасы эшләсен өчен, гражданның бер елда алган барлык керемнәре суммасын белергә кирәк. Әгәр дә кешенең 2—3 керем чыганагы булган икән, аларның аерым-аерым һәрберсендә керемнәр салымның иң түбән чигеннән артып китмәскә дә мөмкин бит. Ә менә керемнәрнең гомуми суммасы күпкә югарырак булырга мөмкин.

Суммар керемнәр проблемасын хәл итү өчен, бөтен дөньяда махсус процедура, ел саен суммар керемнәр турында декларация тутыру кертелгән.

Дәүләт, салым декларациясе тапшырырга тиеш булып та, моны эшләмәгән кешеләргә каты җәза бирә. Алай гына да түгел, дөньяның күп илләрендә керемнәрне салым хезмәтеннән яшергән өчен җәза җинаять кодексын бозу өчен каралган җәзага караганда катырак та булырга мөмкин. Мәсәлән, АКШ мафиясенең иң атаклы башлыкларыннан берсе Аль Капоне күп кенә «караңгы» эшләре өчен җаваплылыктан котыла ала, ә бизнесның легаль төрләреннән алган керемнәрен яшергән өчен төрмәгә эләгә.

Иң бай гражданнарның керемнәренә прогрессив салымнан тыш, милеккә һәм мирас итеп калдырылган байлыкка салым да икътисади тигезсезлекне йомшартырга ярдәм итә.

Икътисади тигезсезлекне йомшартуның икенче бер мөһим ысулы — халыкның иң ярлы төркемнәрен социаль яклау дәүләт программасы.

Мондый ярдәмнең ачык ысулы — ярлыларга өстәмә акча средстволары яисә товарларның бер өлешен бушлай яки түбән бәяләрдән бирү. Моны, гадәттә, **социаль трансфертлар** ярдәмендә хәл итәләр, ягъни илнең бай гражданнарыннан җыелган салымнар исәбеннән формалаштырыла торган средстволардан ярлыларга акчалата һәм матди пособиеләр бирәләр.

***СОЦИАЛЬ ТРАНСФЕРТ** — ярлы гражданнарга дәүләт тарафыннан аларның тормыш дәрәҗәсен күтәрү өчен бирелә һәм баерак гражданнардан салымнар алу исәбенә формалаштырыла торган акча суммасы.*

Социаль трансфертлар системасыннан файдалану — ярлыларга ярдәм итүнең иң гади ысулы, әмма аны бер дә зарарсыз дип булмый. Эш шунда: социаль трансфертлар системасының җитди кимчелекле яклары бар.

Беренчедән, ул хезмәт сөючәнрәк, сәләтлерәк һәм активрак гражданнарда хезмәт хакы алу өчен интенсив эшләүгә кызыксынуны киметә, чөнки пособиеләр аларга «хезмәт хакы — көч кую» нисбәтенең канәгатьләнерлек дәрәҗәсенә ирешергә

мөмкинлек бирә. «Элеккеге классташыма караганда мин азрак акча алам, әмма аның кебек артык көч куеп та эшләмим!» дигән тормыш позициясе барлыкка килә.

Икенчедән, трансфертлар системасы һәм социаль ярдәм күрсәтүнең башка ысуллары җәмгыятьнең хезмәт сөючәнрәк, сәләтлерәк һәм активрак әгъзаларының җитештерүчәнрәк хезмәткә кызыксынуын киметә, чөнки керемнәре арткан саен, аларга (салымнар аша) керемнәренең зуррак өлешен ярлыларга ярдәм итү өчен бирергә туры килә.

Яхшы көйләнгән икътисади системада нәкъ менә сәләтлерәк, эш сөючәнрәк һәм булдыклырак гражданнарның икътисади активлыгы бөтен җәмгыятьнең икътисади алгарышын хәрәкәткә китерә, хәзерге вакытта бүленергә мөмкин булган «байлыклар пирогы»ның зураюына сәбәп була.

Менә шуңа күрә дә ярлылыкка каршы көрәшне социаль трансфертлар исәбеннән бигрәк, ярлы гражданнарга дәүләт тарафыннан бүләк ителгән түгел, ә аларның үзләре эшләп алган керемнәрен арттырырга ярдәм итү аша алып барырга кирәк.

Монда түбәндәге ысуллар нәтиҗәлерәк:

1) барлык гражданнарга да бертигез башлангыч шартлар, мөмкинлекләр тудыру. Һәркемнең эш буенча үсеше аның табигый сәләтләреннән чыгарга һәм берниндн социаль шартлар да гражданнарга бертигез шартларда эшли башларга комачауларга тиеш түгел; гамәлдә моның өчен:
 а) эшкә алганда раса, социаль һәм башка сыйфатлар буенча чикләүләрне тыярга;
 б) барлык балаларга нормаль үсеш шартлары тудырырга (моңа туклану, тәрбия, медицина хезмәте күрсәтү, урта һәм югары белем бирү дә керә) кирәк;
2) табигый сәләтләре азрак булган кешеләргә эш табу мөмкинлекләрен киңәйтү.

Ярлы гражданнарга ярдәм итүнең мондый ысуллары, чынлап та, нәтиҗәле булсын өчен дәүләтнең дә көч куюы таләп ителә.

Хәзер алга киткән илләрдә социаль программалар гаять киң җәелдерелгән. Дөньяның барлык алга киткән илләре дә керемнәре аз булган кешеләргә социаль ярдәм күрсәтү системасын даими рәвештә камилләштерәләр. Икътисадның нигезен — кешенең үзенә һәм якыннарына лаеклы һәм уңайлы мул тормыш тәэмин итү максатында эшләргә омтылуын җимермәс өчен, андый ярдәм күрсәтү билгеле бер кысадан чыкмаска тиеш.

Россия хәзер социаль сәясәтнең үз моделен эзли. Бу гаять катлаулы эш, чөнки ярлы гражданнарга ярдәм итүнең күләмен сизелерлек арттыру зарур.

Хәзер Россиядә ярлы гаиләләрне яклауга юнәлтелгән социаль программаларның масштабы чикләнгән. Аеруча түбән керемле гаиләләргә зур булмаган социаль түләүләр бар. Мисал өчен, бала вакыттан ук инвалидларга, ягъни тумыштан яки бик кечкенә чакта алынган физик һәм акыл ягыннан кимчелекләре булу аркасында үзләренә яшәрлек тә акча эшли алмаган кешеләргә социаль пенсияләр шушы категориягә керә. Шундый чагыштырмача кечкенә түләүләргә дә дәүләт шактый зур средстволар тотарга тиеш була. Ә дәүләт аларны каян ала? Бай гражданнар һәм коммерция фирмалары керемнәренең бер өлешен алу, ягъни салым салу исәбенә.

Әйтелгәннәрне йомгаклап, без икътисади акыллылыкның тагын ике рецептын әйтә алабыз.

Унберенче рецепт

Ил үз гражданнары базарлардагы тотрыклы сорауны тәэмин итәрлек һәм беркадәр акчаларын янга калдырып сакларлык, шулай ук милли (гомумдәүләт) икътисад үсешен финанслау өчен кирәкле страховкалау полислары алырлык акча эшләсә генә тотрыклы үсә ала.

Уникенче рецепт

Гаиләләрнең керемнәре һәм байлык дәрәҗәсе төрлелеген тулысынча бетерергә ярамый, әмма дәүләт икътисади тигезсезлекнең чиктән тыш көчәюенә юл куймаска һәм ярлы гражданнарга ярдәм йөзеннән социаль программалар үткәрергә тиеш.

БҮЛЕКНЕҢ ТӨП ЭЧТӘЛЕГЕ

Гаиләнең керемнәре һәм чыгымнары. *Ил икътисадының торышын өйрәнүнең әһәмиятле ысулы — гаилә керемнәре структурасын анализлау. Бу структура гаиләләрнең нинди милеккә ия булуларын чагылдыра. Андый милек даирәсе киңрәк булган саен, гаилә керемнәренең илнең милли (гомумдәүләт) керемендәге өлеше дә зуррак була. Дөньяның күпчелек илләрендә гаилә керемнәренең төп чыганагы — ялланып эшләүчеләргә бирелә торган хезмәт хакы. Россиядәге икътисад кризисы гаилә керемнәре структурасында хезмәт хакының өлеше 50 % тан кимрәк дәрәҗәгә төшерде. Гаилә керемнәре структурасы аларның абсолют күләменә һәм илнең икътисади үсештә ирешкән дәрәҗәсенә бәйле. Энгель законы буенча, байлык арткан саен туклануга чыгымнар гадәттә кими; шуңа күрә шушы өлешнең зурлыгына карап, гражданнарның байлык дәрәҗәсен бәяләргә була. Россиядә ул 40 % тан артык, бу — дөньяның икътисади яктан алга киткән илләрендәгедән күпкә югары.*

Инфляциянең гаилә икътисадына йогынтысы.
Ярлылык проблемасы бигрәк тә инфляция югары булганда көчәя. Бу исә реаль керемнәрнең номиналь керемнәр үсешеннән артта калуына бәйләнгән. Инфляциядән бигрәк тә теркәлгән керемле гаиләләр зыян күрә. Моннан тыш, инфляция тупланган акчаларның бәясе төшү сәбәпле дә гаиләләрнең хәлен начарайта: инфляция темплары банкка салынган акчаларга керемнәр дәрәҗәсеннән югарырак була. Шунлыктан Россиядә күп кенә гаиләләр тупланган акчаларын валюта (чит ил акчасы) сатып алу аша коткарып калырга тырыша. Ә бу исә ил икътисады өчен зур кыенлыклар тудыра, чөнки илдәге предприятиеләрне әлеге сакларга салынган акчаларны (реконструкция һәм җитештерелүче продукцияне яхшырту максатында) банк аша бурычка алып тору мөмкинлегеннән мәхрүм итә.

Гражданнар байлыгының тигезсезлегә һәм аны киметү мөмкинлекләре. *Теләсә кайсы илдә социаль тынычлыкның мөһим шарты — иң бай һәм иң ярлы гражданнарның керемнәре арасында чиктән тыш зур аерманы булдырмау. Керемнәрнең артык зур аермасын киметү өчен моңа дәүләтнең катнашуы зарур. Ул халыкның ярлы катлауларын социаль яклау системасы аша тормышка ашырыла.*

ФИКЕР АЛЫШУ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. СССРда планлаштыруга корылган икътисад шартларында күп байлыклар (торак, мәгариф, сәламәтлек саклау) гражданнар өчен гамәлдә түләүсез иде. Шул ук вакытта икътисадчыларның мондый әйтеме бар: «Түләүсез иртәнге аш булмый». СССР гражданнары өчен алда әйтелгән байлыкларны ни рәвешле «түләүсез» итеп саклау мөмкин булган?
2. Ни өчен Россиядә әле хәзергәчә хосусый торакны күпләп төзүне үстерү проблемасы авыр хәл ителә? (Күп икътисадчылар фикеренчә, шундый төзелеш җәелдерү аша илнең кризистан чыгуын тизләтергә мөмкин булыр иде.)
3. Кешеләргә кыйммәтле мал-мөлкәтне (фатир, йорт, машина җир, фирма һ.б.) балаларына мирас итеп тапшыруны тыеп, тигезсезлекне йомшартып булыр иде. Икътисади тигезсезлекне бетерү өчен моңа барырга ярыймы?
4. Россиядә тумыштан инвалид һәм үзләрен туйдыра алмый торган башка кешеләргә социаль ярдәм программалары бар. Ул программалар яшәү минимумына бик якын торучы социаль пенсияләр түләүгә нигезләнә. Мондый программалар ярлылык проблемасын сизелерлек йомшарта аламы?

УНИКЕНЧЕ БҮЛЕК

Дәүләтнең икътисади бурычлары

БҮЛЕКТӘ КАРАЛУЧЫ МӘСЬӘЛӘЛӘР:

1. ИКЪТИСАДИ ИРЕКЛӘР НӘРСӘ УЛ?
2. БАЗАР МЕХАНИЗМЫ НИНДИ ЯЛГЫШЛАР ҖИБӘРӘ?
3. ИЛНЕҢ ХУҖАЛЫК ТОРМЫШЫНДА ДӘҮЛӘТ НИНДИ РОЛЬ БАШКАРА?



Цивилизацияле илләрнең икътисади тормышында дәүләт гаять әһәмиятле берничә вазифа үти. Аларның иң мөһиме — икътисади ирекләрне һәм хуҗалык итү кагыйдәләрен яклау.

Иң гади хакыйкатьне онытмаска кирәк: хөкүмәт бирә торган барлык нәрсәләрне башта бездән алган була.

Джон С. Колеман

§ 26. Дәүләтнең икътисадны көйләүдә катнашу формалары һәм сәбәпләре

Моннан алдагы бүлекләрдә без берничә тапкыр дәүләтнең икътисади процессларда актив катнашуы белән очраштык: акча әйләнешен оештыруда, хезмәт базарын көйләүдә, ярлы гражданнарга ярдәм итүдә һ.б.

Әмма дәүләтнең икътисади вазифалары чынлыкта тагын да киңрәк һәм бу хакта икътисадчылар, сәясәтчеләр, коммерсантлар кызу бәхәсләр алып баралар. Андый бәхәсләрнең сәбәбен аңлау өчен, дәүләтнең икътисадтагы ролен һәм аны гамәлгә ашыру юлларын тәфсилләбрәк карап үтәргә кирәк.

Гражданнар актив хуҗалык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә теләсеннәр һәм моны эшләсеннәр өчен теләсә кайсы илдә нинди шартлар булырга тиеш? Бу сорауга җавапны 1723—1790 елларда яшәгән классик икътисад сәясәтенең күренекле вәкилләреннән берсе Адам Смит биргән.

Ул болай дип язган: *«Дәүләтне кыргыйлыктан (иң түбән баскычтан) иң югары дәрәҗәгә — иркен, мул тормышка күтәрү өчен нибары тынычлык, җиңел салымнар һәм идарә итүдә түземлелек кирәк; калганнарның барысын да вакыйгаларның табигый агышы хәл итәр»*. Башкача әйткәндә, дәүләт кешеләрнең хуҗалык итү эшчәнлегенә артык тыкшынмаска, әмма тыныч тормышны дошманнардан сакларга бурычлы.

Асылда, бу — дәүләт законнары, нормалары белән тәэмин ителү һәм гражданнарның аннан дөрес файдалануы өчен җаваплылыктан аерылгысыз икътисади ирекне белдерә.

ИКЪТИСАДИ ИРЕК,— гомуми «ирек» төшенчәсенең бер өлеше буларак, җәмгыять әгъзаларының, башка кешеләр мәнфәгатьләренә зыян китермичә һәм гамәлдәге законнар белән каршы килмичә, милек формаларыннан үзләренең эшче көчләреннән файдалану өлкәләрен, керемнәрне бүлү ысулларын һәм матди байлыкларны үзләштерү вариантларын ирекле сайлау мөмкинлеге ул.

Хәзергечә аңлаганда, икътисади азатлык хосусый милекнең кагылгысызлыгына һәм законнарга каршы килмәүгә нигезләнгән ирекне белдерә:

1) кеше яки фирма үзе өчен нәрсә файдалы, шуны җитештерә;
2) кем белән файдалы дип саный, шуның белән сәүдә итә;
3) керемнәрне кеше үзе сайлаган рәвештә саклый;
4) кеше үзенең туплаган акчаларын, керем алу өчен, үзе сайлап алган проектларга кертә;
5) үзең төзегәннән яисә эшләп алганнан, әйләнә-тирәдәгеләр мәнфәгатьләренә зыян китермичә, теләсә нинди формада файдалану;

6) үз иленең яки чит ил кешеләре белән теләсә нинди файдалы икътисади элемтәләргә керү;
7) үз хезмәтең нәтиҗәләренә яки үз фирмаң эшләп чыгарган товарларга бәяләрне үзең теләгәнчә кую;
8) әгәр дә килешүдә катнашучылар каршы булмаса, сәүдә итү буенча партнерларга түләү өчен теләсә кайсы илнең акча средстволарыннан файдалану.

Әмма теләсә нинди ирек тә яклауга мохтаҗ; югыйсә аны көч белән тартып алалар. Нәкъ менә ирекләрне (шул исәптән икътисади азатлыкны да) яклау (ягъни аларны гарантияләү) — теләсә кайсы дәүләтнең төп һәм даими бурычы (12-1 рәсем).

Икътисади ирекләрне саклауның иң яхшы ысулларын эзләү күп гасырлар дәвамында барган һәм түбәндәгеләрне үз эченә алучы төзек механизм булдыруга китергән:

— милеккә хокукны юридик беркетү;
— гражданлык законнары;
— судлар;
— арбитраж судлары;
— икътисади ирекләр һәм хуҗалык тормышы кагыйдәләрен саклаучы дәүләт органнары (прокуратура, тикшерү хезмәтләре һ.б.).

Милеккә хокукны юридик беркетү (теркәү) — җәмгыять һәм дәүләт кешеләрнең (физик затларның) һәм фирмаларның (юридик затларның) үзләре булдырган,



12-1 рәсем.
Дәүләт — икътисади ирекләр сакчысы

сатып алган, бүләккә яки мирас итеп алынган теләсә нинди милеккә хокукын таный дигән сүз ул.

Бсз 1 бүлектә ачыклаганча, милеккә хокук милекнең хуҗасына аңа ия булу, аннан файдалану һәм аның белән эш итү мөмкинлеге бирә.

Дәүләт хокук хезмәте органнары (милиция, суд, прокуратура) ярдәме белән шәхеснең әлеге хокукларын яклый. Әмма хәзерге цивилизацияле җәмгыять милекченең үз мөлкәте белән ничек теләсә шулай эш итү хокукын милектән андый файдалану әйләнә-тирәдәгеләргә зыян китерә башлаганчыга кадәр генә таный. Бу хакта соңрак тәфсилләбрәк сөйләнер.

Гражданлык законнары. Кешеләрнең хуҗалык итүдә үз-үзләрен тотышлары, гадәттә гражданлык законнарының бер мөһим өлешен тәшкил итүче күп кенә дәүләт нормалары һәм законнары белән көйләнә. Мәсәлән, Россиядә кабул ителгән Гражданлык кодексы:

— илдә рөхсәт ителә торган хуҗалык оешмалары формаларын;
— хуҗалык шартнамәләре төзү кагыйдәләрен;
— килешүләр буенча вазифаларны үтәү тәртибен һ.б. көйли.

Судлар. Әгәр дә хуҗалык эшчәнлегендә катнашучыларның берәрсе гражданлык законнары белән билгеләнгән кагыйдәләрне бозса, зыян күргән як яклау сорап дәүләт судына мөрәҗәгать итә ала. Гражданнар судларында төрмәгә ябу яки сөргенгә җибәрү кебек җәза бирүләр юк. Монда законсыз алынган мөлкәттән яки файдадан мәхрүм итү һәм һәртөрле штрафлар салу аша җәза бирелә.

Арбитраж судлары. Хуҗалык эшчәнлеге алып бару еш кына анда катнашучыларда бәхәсләр тудыра. Аларны хәл итү өчен арбитраж судларына мөрәҗәгать итәргә кирәк. Ул — фирмаларның үзара бәхәсләрен тикшерүче махсус орган. Барыннан

КЕШЕЛЕКНЕҢ ИКЪТИСАДИ ТАРИХЫ СӘХИФӘЛӘРЕ

Бөек азатлык хартиясе

Бөек азатлык хартиясе кешеләрнең үз икътисади хокуклары һәм ирекләре өчен көрәшенең мөһим сәхифәләреннән берсе булган. Аңа инглиз короле Иоанн Беззмельный 1215 елда 15 июньнең томанлы иртәсендә Раннимед бистәсендә кул куя. Әлеге документны корольгә аның үз бароннары әзерли һәм тапшыра. Алар, рыцарьлар һәм шәһәр кешеләре белән бергә, монархның даими талауларына каршы чыгалар һәм үз хокукларын тануны таләп итәләр. Хартия корольгә бароннардан акчаны дәүләт мәнфәгатьләре өчен аларның ризалыгы белән генә (ә мәҗбүр итү тәртибендә түгел) алырга рөхсәт итә.

Феодаль Европа өчен гадәти булмаган әлеге документ шулай ук корольгә ирекле кешеләрне законлы хөкемнән башка кулга алуны һәм мөлкәтләреннән мәхрүм итүне тыя. Хартиянең үтәлешен король үз вәгъдәләрен үтәмәгән очракта баш күтәрү хокукы алган, 25 бароннан торган комитет тикшереп торырга тиеш була. Бер ел үтүгә, король хартияне бозу сәбәпле, алар кораллы восстаниегә күтәреләләр дә.

Әлбәттә, Бөек азатлык хартиясе барлык инглизләрнең дә мәнфәгатьләрен якламый; шулай да ул гражданнарның мәнфәгатьләрен исәпкә алырга һәм хокукларын иң югары хакимият дуамаллыгыннан азмы-күпме демократияле ысуллар белән якларга тиешле икътисади тормыш тәртибе төзергә омтылу буларак тарихка кереп кала.

да бигрәк бу бәхәсләр хуҗалык килешүләрен үтәү хакында була. Арбитраж судларының карарларын (җинаять һәм гражданлык эшләрен тикшерүче судлар карарларын үтәү кебек үк) үтәү мәҗбүри.

Икътисади ирекләрне һәм хуҗалык тормышы кагыйдәләре үтәлешен күзәтүче дәүләт органнары (прокуратура, тикшерү хезмәтләре һ.б.). Нормаль хуҗалык тормышы кануннарын һәм икътисади ирекләрне яклау өчен, дәүләт гадәттә махсус оешмалар төзи. Алар исәбенә барыннан да элек законнардан дөрес файдалануны күзәтүче прокуратура керә. Күп санлы дәүләт тикшерү хезмәтләренең әһәмияте зур. Мәсәлән, «үлчәүләр хезмәте» — ул илдәге барлык сәүдә итүчеләрнең 1 килограммлы герләренең төгәл 1000 грамм (ә 950 яки 800 грамм түгел) булуын күзәтә.

Әгәр дәүләт алда санап үтелгән бурычларны хәл итү белән генә шөгыльләнсә дә, бу аны илнең икътисади тормышында иң әһәмиятле катнашучыларның берсе дип исәпләү өчен җитәр иде.

Ә чынлыкта дәүләт шөгыльләнә торган мәсьәләләр даирәсе күпкә киңрәк. Бу исә *базар механизмының* кайбер икътисади бурычларны, гомумән, яки яхшы итеп *хәл итә алмавы (камил булмавы)* белән бәйле.

Базарның камил булмавының сәбәпләре шунда: реаль тормышта базар механизмнарына җәмгыятьнең икътисади проблемаларын яхшы (идеаль) итеп чишү мөмкинлеге бирергә тиешле барлык шартларны да үтәп булмый.

Аларның иң әһәмиятлеләре түбәндәгеләр:

1) барлык базарда катнашучыларга да товарларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатлары һәм бәяләре турында тулы мәгълүмат җиткерелергә тиеш. Шул ук вакытта андый тулы мәгълүмат гадәттә кулланучыларда булмый, җитештерүчеләр аларны алдарга, сатыла торган байлыкларның зарарлы якларын яшерергә, файдалы якларын күпертеп күрсәтергә, күбрәк һәм кыйммәткәрәк сатарга тырышырга мөмкин. Кемдер (һәм гадәттә бу базар үзе түгел, ә дәүләт була) кулланучының (мәсәлән, тәмәке товарларының сәламәтлеккә зыянлы булуы турында) дөрес һәм тулы мәгълүматка хокукын яклауны үзенә алырга тиеш;

2) хәзерге цивилизацияле җәмгыятьтә барлык гражданнар да (аларның түләү мөмкинлеген исәпкә алмастан) файдаланырга тиешле байлыклар бар. Җәмәгать тәртибен саклау (милиция, прокуратура, судлар), илнең иминлеген һәм чикләрен саклау, таможня, ветеринария сагы һ.б. шундый байлыкларга керә. Базар механизмнары әлеге байлыкларны бүлүне тәэмин итә алмый, алар моңа бик үк яраклы түгел;

3) базар ике якның: сатучы һәм сатып алучыларның мәнфәгатьләре килештерелгәндә яхшы эшли. Нинди дә булса байлыкны сатуның сату-алу фактына бөтенләй катнашы булмаган кешеләр мәнфәгатьләренә караган очраклар да бар. Мәсәлән, химия компаниясе завод төзү өчен җир участогы сатып ала, бу килешү якындагы торак пунктларда яшәүчеләргә сизелерлек (уңай һәм тискәре) йогынты ясый. Бер яктан бу уңай йогынты: эш урыннары һәм җирле бюджетка керемнәр күбрәк булачак; ә икенче яктан — тискәре йогынты: әйләнә-тирәнең пычрануы артачак һәм кешеләр ешрак авырый башлаячак. Базар механизмы килешүләрнең әлеге тышкы нәтиҗәләрен истә тотып эш итә алмый.

Һәм шунда җәмгыятьнең икътисади тормышына дәүләтнең тыкшыну зарурлыгы туа.

Гадәттә, катнаш икътисади система шартларында дәүләт түбәндәге бурычларны хәл итүне дә үзенә ала:

1) базар кимчелекләре барлыкка китергән кире нәтиҗәләрне бетерү;

2) керемнәр һәм байлык тигезсезлеген аларны өлешчә яңадан бүлү исәбенә йомшарту (бу хакта 11 бүлектә тәфсилләп сөйләнде).

Базарның кимчелекле яклары:

1) базарларны монополияләштерү ихтималында;

2) коммерция (сәүдә) нигезендә иҗтимагый байлыклар барлыкка китерүдәге кыенлыкларда;

3) тискәре тышкы эффектлар һәм тышкы чыгымнар тууда күренә.

Базар кимчелекләрен капларга тырышып, дәүләт төрле ысулларны теге яки бу мәсьәләне хәл итүгә туры китереп сайлап ала.

Базарларны монополияләштерү. Базар механизмы үзеннән-үзе генә теге яки бу фирмага билгеле бер төрдәге товар базарын монополияләштерүдә каршылык күрсәтә алмый. Шул ук вакытта базарны монополияләштерү:

1) икътисади өстенлек;

2) конкурентлар белән төрле килешү-сүз куешулар яки конкурентларны юк итү аша башкарылырга мөмкин.

***БАЗАРНЫ МОНОПОЛИЯЛӘШТЕРҮ** — билгеле бер товар базарында сатучыларның яки сатып алучыларның берсенә гомуми сату, яки сатып алуның шактый зур күләме туры килгәндә, аның шушы базарда бәяләр һәм килешүләр шартлары формалашуга башка катнашучыларга караганда зуррак йогынты ясый алуы.*

Кайсы фирма базарда сатып алучыларга үз товарларына «бәя/сыйфат» нисбәтенең иң отышлы вариантын тәкъдим итә, шул икътисади өстенлеккә ирешә. Гадәттә, мондый өстенлекнең нигезе — камилрәк җитештерү технологияләре яки товарларны җитештерү һәм сатуны оештыру ысуллары кертү.

Фирма шундый эшчәнлек алып бару нәтиҗәсендә базарның күпчелек өлешен яулап алса да, монда куркыныч бернәрсә дә юк. Бу очракта базар механизмы үзенең төп бурычын уңышлы хәл итә — ул чикләнгән ресурсларның иң яхшы бүленешен тәэмин итә. Чынлап та, мондый хәлдә ресурсларның иң зур өлеше конкурентлык көрәшендә чикләнгән иң яхшы ресурсларны куллану һәм шуның нигезендә аз чыгымнар тотуга ирешү исәбенә җиңгән фирмага эләгә.

Монда дәүләтнең катнашуы да кирәк түгел. Әгәр дә андый фирма үз өстенлеген бәяләрне күтәрү өчен файдаланырга теләсә, ул шуның белән күбрәк чыгымлы, түбәнрәк бәяләр тәкъдим итүче башка фирмаларны кысрыклап чыгару өчен шартлар тудыра.

Базарны монополияләштергәндә эш башкачарак тора: саф монополия яки олигополия яхшырак технология яки җитештерүне оештыру исәбенә түгел, ә берничә зур фирманың үзара сүз куешып, башка конкурентларны кысрыклап чыгарулары яисә үз эчләренә алулары сәбәпле барлыкка килә. Бу очракта чикләнгән ресурслардан файдалануны тәэмин итүче фирмалар «базар хуҗалары»на әверелмәскә

дә мөмкин. һәм ресурслар монополияләштерелмәгән базардагыга караганда начаррак бүленә.

Дәүләт *базарларны монополияләштерүгә каршы чыгу һәм конкуренцияне яклау өчен:*

1) законнар эшли, аларга нигезләнеп, монополияләштерүгә омтылучы фирмаларны ачыкларга һәм җәза бирергә мөмкин;

2) базардагы вакыйгалар барышын күзәтә һәм намуссыз конкуренция очракларын ачыклый торган оешмалар төзи (Россиядә мондый эшчәнлекне «Монополиягә каршы федераль хезмәт» алып бара);

3) базарларны монополияләштерүгә каршы торырлык яки монополияне җимерерлек яңа фирмалар төзүгә булыша.

Нәкъ менә шундый вакытта базарны монополияләштерүне чикләү һәм нормаль конкуренцияне торгызу, базар механизмын уңышлы эшләтү өчен дәүләткә катнашырга туры килә. Дәүләт конкуренцияне яклау сәясәте үткәрергә — монополияләштерүгә каршы законнар эшләргә һәм аларны тормышка ашырырга тиеш. Төп бурыч — аеруча зур фирмаларга базарда монополь хакимият яуларга һәм сатып алучыларга үзләренең сату (бәяләрне дә кертеп) шартларын көчләп тагарга мөмкинлек бирмәү.

Монополияләштерүгә каршы законнар чыгаруның бер гасырга якын тәҗрибәсе күрсәткәнчә, базарларны монополияләштерүгә каршы көрәшнең иң яхшы ысулы — «гигант»лар белән көндәшлек итүче һәм шунлыктан базарларның нормаль эшләвен тәэмин итүче кече һәм урта фирмаларның үсешенә ярдәм итү.

Коммерция (сәүдә) нигезендә иҗтимагый байлыклар тудырып булмый. Кеше ихтыяҗлары арасында шундыйлар бар: алар барлык кешеләр өчен; «әгәр дә аннан берәү файдалана икән, моны инде башкалар эшли алмый» дип әйтеп булмый. Күп кешеләр файдалана алырлык байлыклар **иҗтимагый байлыклар** дип атала. Андый байлыкларга мисал итеп түбәндәгеләрне китерергә мөмкин: армия ярдәмендә илне саклауны тәэмин итү; түләүсез белем бирү; түләүсез паркларга, музейларга йөрү; урамнарны яктырту һ.б. Хосусый байлыклардан аермалы буларак, аларны кешеләр үзләре куллану өчен ала. Иҗтимагый байлыклар:

1) конкурентлы түгел — бер кешенең куллануы байлыкның гомуми санын киметми һәм аннан башка кешеләр дә файдалана ала (яктыртылган урам буйлап барганда, сез башка җәяүлеләр өчен яктылыкны киметмисез);

2) аерым бер кешегә файдалануны тыя алмый (җәяүлеләрнең берәрсе өчен урам яктыртылмыйча яки бөтен илне саклаучы армия аерым бер гражданны сакламыйча калырга мөмкин түгел).

Барлык кешеләр дә файдалана алырлык булу катлаулы икътисади проблема да тудыра: бер яктан, андый байлыкларга бәя куеп һәм алардан файдалану хокукын аерым бер фирма файдасына сатып булмый, ә икенче яктан, эшмәкәрләр һәм фирма хуҗаларының берсенә дә андый байлык җитештерү отышлы түгел һәм аларны дәүләт көче белән генә җәмгыяткә бирергә мөмкин.

Иҗтимагый байлыкларның гомуммилли һәм җирле төрләре була. Беренчеләре (армия, чикләрне саклау, ветеринария хезмәте һ.б.) тулаем хөкүмәтнең көче һәм чыгымнары исәбенә төзелсә, икенчеләре (урамнарны яктырту, урамнарны чүптән һәм кардан чистарту, шәһәр паркларында тәртип саклау һ.б.) җирле бюджеттан финансланучы муниципаль оешмалар исәбенә башкарыла.

Мондый хезмәт күрсәтүләрне коммерция (сәүдә) нигезендә булдыру һәм сатуны күз алдына да китереп булмый. Илнең барлык шәһәрләрен автомат рәвештә саклаучы ракетага каршы чаралар системасы төзүгә бер фирма да алынмастыр. Ул мәсьәләне барлык керемле гражданнардан алынган салымнар исәбенә яшәүче «дәүләт» дип аталган үзенә бертөрле «фирма» гына хәл итә ала. Иҗтимагый байлыкларның төрләре күп түгел (боларга алдарак әйтелгәннәрдән тыш, туклану продуктлары һәм даруларның сыйфатын тикшерү, аварияләр, йогышлы авырулар таралуны булдырмау, рекламаларның дөреслеген, сәүдә итүдә мәҗбүри масса һәм озынлык стандартларын тикшерү хезмәтләре һ.б. керә).

Дәүләт *иҗтимагый байлыклар тудыру өчен:*

1) гражданнар һәм фирмаларның дөрес мәгълүмат алуга хокукларын саклаучы законнар системасын булдыра («Реклама турында», «Медицина хезмәте, медицина эшләнмәләре һәм дәвалау чаралары» федераль законнары нәкъ менә шундый хокук документларына керә);

2) ил халкына иҗтимагый байлыклар бирүне тәэмин итүче оешмалар (мәсәлән, армия, чикләрне саклау һәм таможня хезмәтләре, «Ашыгыч ярдәм» һ.б.) төзи.

Тышкы нәтиҗәләрнең барлыкка килүе. Әгәр, мәсәлән, химия комбинаты атмосферага үз калдыкларын чыгарып әйләнә-тирәне пычрата, нәтиҗәдә бал кортлары үлә икән, бу әлеге комбинат дирекциясен һич тә борчымый, әмма умартачылар өчен зыянлы. Алар комбинатның куәтле чистарту корылмалары куюын телиләр — һава чиста булыр иде.

Әмма комбинат белән идарә итүдә яки аның продукциясенә бәяләр куюда умартачылар берничек тә катнашмыйлар; димәк, аларның мәнфәгатьләрен базар исәпкә ала алмый. Химия продукциясен сатып алучылар да һаваны чистартуга өстәмә акча тоту белән кызыксынмыйлар, чөнки бу сатып алына торган товарның кыйммәтләнүенә генә китерә. Шуның нәтиҗәсендә кырларның пычрануы химия продукциясе базарына чит **тышкы нәтиҗә** була, һәм бәяләр куйганда, ул берничек тә исәпкә алынмый.

ТЫШКЫ (ӨСТӘМӘ) НӘТИҖӘ — байлыкны сату-алуда турыдан-туры катнашмый торган кешеләр һәм фирмалар түләргә тиешле (яки алырга мөмкин булган) нинди дә булса байлыкны җитештерүдән күргән зыян (яки файда).

Җитештерү предприятиеләренең атмосферага чыгарыла торган калдыклар белән кырларны пычратуы тискәре тышкы (өстәмә) нәтиҗәгә мисал булса, рекламалар һәм кибет витриналары исәбенә урамнарны яктыртуны яхшырту — уңай тышкы нәтиҗә мисалы. Әмма ул нәтиҗә кибет хуҗалары һәм сатып алучыларның үзара мөнәсәбәтләрендә берничек тә чагылмый. Димәк, базар аны чикләнгән ресурсларны бүлүне көйләгәндә исәпкә алмый. (Бу очракта яхшы яктыртылган витриналы һәм яктылык рекламасы булган кибеттә сатыла торган товарларны җитештерүдә кулланылучы ресурслар күздә тотыла.)

Тышкы (өстәмә) нәтиҗәләр хуҗалык эшчәнлегенең кайбер төрләрендә тулаем җәмгыять өчен зур әһәмияткә ия булырга мөмкин. Әмма базар аларны исәпкә



12-2 рәсем.
Дәүләтнең икътисади вазифалары

алмый һәм ул нәтиҗәләр аның чикләнгән ресурсларны бүлүенә йогынты ясамый. Базар карарлары байлыкларның билгеле бер төрен житештерү һәм куллану белән бәйле барлык чыгымнарны һәм файданы истә тотмыйча кабул ителсә, ул карарлар камиллектән ерак торачак. Алай гына да түгел, гражданнарның аерым төркемнәре яки фирмаларның югалтуларын һәм файда күрүләрен искә алмау иҗтимагый каршылыклар тудырырга мөмкин.

Менә ни өчен дәүләт хуҗалык эшчәнлегенең тискәре тышкы нәтиҗәләре проблемасын хәл итүгә катнашырга; базар кимчелекләрен, аның шундый тышкы нәтиҗәләрне исәпкә алырга сәләтсез булуын капларга һәм андый хәлләр өчен яхшырак чишелешләр табарга мәҗбүр була (12-2 рәсем).

Тискәре тышкы нәтиҗәләр барлыкка килү белән бәйле проблемаларны көйләү мәсьәләсен хәл иткәндә дәүләт:

1) тышкы нәтиҗәләр барлыкка килү белән бәйле каршылыкларны билгеле бер рәвештә хәл итү мөмкинлеге бирә торган законнар системасын булдыра (мәсәлән, әйләнә-тирә мохитне саклау турында законнар);

2) тискәре тышкы нәтиҗәләр барлыкка килә торган хәлләрне күзәтүче һәм тиз арада законда каралган чаралар күрүче оешмалар төзи (мәсәлән, алар әйләнә-тирәне пычратучы предприятиеләргә штраф салалар яки хәтта андый предприятиеләрнең эшчәнлеген туктаталар);

3) тискәре тышкы нәтиҗәләрне киметү эшчәнлеген хуплый, ана этәргеч бирә (мәсәлән, актив рәвештә чистарту жайланмалары яки йомык су әйләнеше системалары төзүче предприятиеләргә төрле ташламалар ясый).

Цивилизацияле илләр (Россияне дә кертеп) соңгы унъеллыкларда тагын бер вазифаны — **кулланучылар хокукларын яклауны** дәүләт карамагына тапшырдылар. Чөнки базар механизмнары кулланучыларны сатучының (җитештерүченең) намуссызлыгыннан яки алдавыннан якларга бик үк сәләтле түгел.

Россия Федерациясендә 1992 елда кулланучылар хокукларын яклау турында махсус Закон кабул ителде һәм товарларны, хезмәт күрсәтүләрне сатучы фирмалардан әлеге Законның үтәлешен таләп итүче дәүләт органнары төзелде.

Күп кенә икътисадчылар фикеренчә, алда әйтеп үтелгән бурычларны хәл итү — җәмгыятьнең икътисади тормышына дәүләт катнашырга мөмкин булган өлкә. Һәм тагын да күбрәк икътисадчылар һәм сәясәтчеләр мондый катнашуны башка бурычларны хәл итүгә дә җәелдерергә кирәк дип исәплиләр. Монда, барыннан да бигрәк, икътисади үсеш темплары һәм җитештерүнең кимүендә кискен тирбәлешләрне булдырмау бурычы истә тотыла. Кайбер илләрдә андый дәүләт көйләве җитәрлек дәрәҗәдә актив һәм уңышлы тормышка ашырыла, ә икенчеләрендә, базар механизмнарының нормаль эшләвен нык бозар дип, ана бик сак карыйлар.

Хәзер Россия дә үзе өчен дәүләтнең икътисади эшчәнлектә катнашу моделен эзли. 90 нчы еллар башында төп бурыч командачыл системаны җимерүдән гыйбарәт була. Күпләр безнең ил өчен икътисади тормышка бөтенләй диярлек катнашмаучы «кечкенә һәм арзанлы» дәүләт кирәк дип уйлыйлар. Әмма алдагы еллар тәҗрибәсе шуны күрсәтә: тиеш килүче базар механизмнары барлык хуҗалык тормышын көйләү бурычын үзләренә алу өчен әле җитәрлек дәрәҗәдә көчле түгел, һәм Россия дәүләтенә икътисадка кире әйләнеп кайтырга туры киләчәк.

Хәзер безнең ил икътисадчылары һәм сәясәтчеләре арасында кызу бәхәсләр бара: хуҗалыкны кризистан чыгару һәм шул ук вакытта базар системасын ныгыту өчен дәүләт нәрсә эшләргә тиеш һәм эшли ала?

Иң кечкенә бурычларны хәл итү (базар житешсезлекләрен каплау һәм кеременнәр, байлыклар тигезсезлеген йомшарту) өчен дә дәүләтнең гаять зур күләмдә акча средстволары булырга тиеш. Россиядә иң яхшы дәүләт икътисади сәясәте моделен эзләүне әнә шул кыенлаштыра да.

§ 27. Ил икътисадындагы макроикътисади процесслар

Хәзерге Россиядә икътисади проблемалар — барлык сәяси бәхәсләрнең төп темасы. Һәм шундый үзәк проблемаларның берсе — илнең тулай эчке продуктын (ТЭП) үстерүгә ничек ирешергә? Россия президенты: «Якындагы 10 елда ТЭПны икеләтә арттыру — илнең икътисад өлкәсендәге төп бурычы»,— дип юкка гына әйтмәгән.

Ни өчен әлеге күрсәткечкә шундый игътибар бирелә, һәм ул аерым бер кеше тормышында нинди әһәмияткә ия? Икътисад фәнендә илнең тулай эчке продукты дигәндә, илдә бер елда җитештерелгән барлык соңгы куллану товарлары һәм хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләрендәге гомуми бәясен аңлау кабул ителгән. Шул ук вакытта **соңгы куллану товарлары һәм хезмәт күрсәтүләр** — кешеләр һәм

фирмалар тарафыннан алга таба башка төр байлыклар житештерү өчен булмаган куллану әйберләре ул. Мәсәлән, гаилә балага кием сатып алганда аны киеп йөрсен, аңа җылы һәм уңайлы булсын өчен (ә сатуга нинди дә булса башка байлыклар чыгару өчен түгел) ала. Ә менә автомобиль заводы металлны үзенә канәгатьләнү яки үз металына хужа булудан файда алу өчен түгел, ә шул металлдан сатуга чыгару өчен автомобильләр житештерү максаты белән ала. Бу очракта автомобиль — соңгы, ә металл — арадаш товар.

ТУЛАЙ ЭЧКЕ ПРОДУКТ (ТЭП) — илдә бер елда җитештерелгән, базар бәяләрендә кыйммәте билгеләнгән бөтен соңгы товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрнең бәясе.

ТЭПны исәпләү идеясе бик гади: моның өчен илнең чынлыкта куллану өчен бер елда байлыкларның нинди кыйммәтен җитештерүен ачыкларга кирәк. Андый исәпләүнең ничек алып барылуы 12-3 рәсемдә сурәтләнгән. Аннан күренгәнчә,



12-3 рәсем.

Тулай эчке продукт барлыкка китерү (урман, агач эшкәртү һәм йорт җиһазлары житештерү промышленносте мисалында)

илнең тулай эчке продуктына нинди дә булса фирма тарафыннан житештерелгән һәм сатылган товарларның барлык кыйммәте түгел, ә сатудан тәшемнең фирма үз көче белән барлыкка китергән өлеше генә керә. Ул кертемнең зурлыгы (аны гадәттә өстәмә кыйммәт дип атыйлар) — фирма товарлары өчен сатып алучыларның күпме түләргә әзер булулары һәм кирәкле житештерү ресурсларын башка фирмалардан алу өчен чыгымнар аермасы дип билгеләнә.

Рәсемдәге мисалда йорт жиһазлары детальләре житештерүчеләр аларны 35 мең сумга сата алган. Ә үзләре урман сәнәгате хужалыгыннан алган агач материалы өчен 14 мең сум түләгәннәр. Димәк, әлеге йорт жиһазлары детальләрен житештерүдә өстәмә кыйммәт: 35 000 сум − 14 000 сум = 21 000 сум.

Нәтижәдә өч фирма илнең тулай эчке продуктына 55 мең сум керткәннәр. Игътибар итик: әзер йорт жиһазлары сатудан тәшем дә шушы суммага тигез. Бу — очраклы туры килү генә түгел, ә ТЭПны исәпләү мантыйгы чагылышы. Бу күрсәткечнең зурлыгын ике юл белән билгеләп була:

1) бер ел эчендә илнең барлык фирмалары булдырган өстәмә кыйммәт суммасы;

2) бер ел эчендә илдә житештерелгән барлык соңгы куллану товарлары һәм хезмәт күрсәтүләре бәясе яки сатып алуларга чыгымнар суммасы.

12-4 рәсем.
Илнең тулай эчке продукты составы

Әгәр дә моңа башкачарак карасак, без шуны әйтә алабыз: ТЭП 4 өлештән тора (12-4 рәсем): 1) гаилә кулланылуы; 2) бизнес өчен җиһазлар сатып алу (инвестицияләр); 3) дәүләт сатып алулары; 4) чит илләргә товар сатудан (экспорт) төшемнең чит илләрдән алып кайтарылган товарлар (импорт) бәясеннән зуррак булуы.

ТЭПны исәпләү формуласын түбәндәгечә язарга мөмкин:

$$ТЭП = Г + Д + ШИ + (Э - И),$$

монда Г — гаилә (йорт хуҗалыгы) кулланылуы (шәхси куллануга товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр өчен чыгымнар); Д — дәүләтнең соңгы куллану товарлары һәм хезмәт күрсәтүләрен сатып алуы; ШИ — шәхси инвестицияләр, ягъни илдәге йорт хуҗалыклары һәм фирмалар киләчәктә өстәмә керемнәр китерәчәк проектларны тормышка ашыруга тоткан барлык чыгымнар; (Э – И) — экспорттан төшемнең импорттан кергән төшемнән артыграк булуы.

Шулай итеп, ТЭП күрсәткече — илнең ни дәрәҗәдә яхшы эшләвенең иң төгәл үлчәме, чөнки ул ил гражданнарының ничек яшәвен, аларның шәхси мәнфәгатьләрдә күпме байлыклар куллануын, алар эшли торган фирмаларның ничек үсүен, илдәге тормышны яхшырту өчен хөкүмәтнең нәрсәләр эшли алуын һ.б. күрсәтүче барлык процессларны характерлый. ТЭП күрсәткече белән беррәттән, илдәге хәлне анализлау өчен тагын түбәндәге үлчәмнәр файдаланылырга мөмкин:

— **тулай милли продукт (ТМП).** Ул ТЭПтан хуҗалары башка ил гражданнары булган, әмма Россия территориясендә эшли торган фирмалар җитештергән соңгы куллану товарлары бәясен алганга һәм хуҗалары Россия гражданнары булган, әмма башка дәүләтләр территориясендә эшләүче фирмалар җитештергән соңгы куллану товарлары бәясен кушканга тигез;

— **милли керем**. Ул ТЭПтан амортизацияне (фирмалар үз җиһазлары һәм биналары тузуны каплау өчен туплый торган акча средстволарын) һәм товарлар бәясенә кертелгән турыдан-туры булмаган салымнарны алганга тигез. Башкача аны җитештерү факторлары (хезмәт, капитал һәм җир) хуҗаларының барлык керемнәрен кушып белеп була.

ТУЛАЙ МИЛЛИ ПРОДУКТ (ТМП) — ил гражданнарыныкы булган барлык фирмалар җитештергән ахыргы куллану товарлары һәм хезмәт күрсәтүләрнең бәясе.

МИЛЛИ КЕРЕМ — ил гражданнары хезмәт хакы, табыш, процентлар һәм табигый ресурслардан файдаланган өчен рента рәвешендә алган барлык керемнәр суммасы.

Әлеге өстәмә күрсәткечләрнең һәрберсе илдәге икътисади хәлне аңлау өчен файдалы мәгълүмат бирә. Әмма аларның иң әһәмиятлесе ТЭП булып кала. Шуңлыктан Россиядә ТЭПны арттыру — илнең хуҗалык оешмаларының һәм хөкүмәтнең төп бурычы. Чөнки ул — Россия гражданнарының тормыш муллыгын күтәрү бурычы. Әмма әлеге бурычны хәл иткәндә теләсә кайсы ил хөкүмәте гаять катлаулы зур күләмле икътисади мәсьәләләр белән очраша. Аларга тукталып үтик.

Илнең тулай эчке продуктының үсү тизлеге һәм икътисади хәлнең иң әһәмиятле күрсәткечләре күп факторларга бәйле. Аларның бер өлеше — хөкүмәткә һәм Россия фирмалары директорларына буйсына, ә башкалары — реаль чынбарлык. Соңгыларына, мәсәлән, Россия фирмалары эшли торган климат шартлары, авыл хуҗалыгында уңышка йогынты ясый торган һава торышы үзгәрешләре, кышкы чорда җылыту өчен ягулык чыгымнары һ.б. керә. Шулай ук башка илләрнең конкурент фирмалары товарларын җитештерү күләме һәм структурасына да Россия хакимияте һәм фирмалары күзәтчелек итми.

Россия икътисады өчен, мәсәлән, нефтьнең дөнья базарына шушы энергия ресурсын табучы башка илләр тарафыннан кертелгән күләме һәм дөнья базары бәясе гаять әһәмиятле. Дөнья банкы 2004 елда бастырып чыгарган «Россия икътисады турында доклад»тан күренгәнчә, Россиядә ТЭПның 3,2 % ы 2003 елда экспорт өчен уңайлы шартларга (нефтькә югары бәяләр) туры килгән. Нәкъ менә шушы бәйлелек булганга күрә, дөнья банкы Россиядә ТЭПның 2004 елда 5 % тан артык булмаячагын фараз итә. Дөнья банкы экспертлары бәяләвенчә, Россиянең яңа тарихында әле беркайчан да икътисад, әгәр бер үк вакытта нефтькә бәяләр дә күтәрелмәсә, 5% тан артык үсә алмаган. Ә ул бәяләр бик куптәннән инде югары тора.

Россия икътисадына тискәре тышкы факторларның йогынтысын каплау өчен, дәүләт үз карамагында җитәрлек көчле чаралар тота (12-5 рәсем). Эш шунда гына: андый көйләүне ничек гамәлгә ашырырга, аның максаты нәрсә булырга тиеш.



12-5 рәсем.
Россия икътисадының эш нәтиҗәләренә нәрсәләр йогынты ясый?



12-6 рәсем.
Милли икътисад моделе

Әлеге сораута икътисад фәне болай дип җавап бирә: «Дәүләт зур күләмле икътисади тигезләнешне саклау турында кайгыртырга тиеш». Бу нәрсәне белдерә, һәм мондый мәсьәләне хәл итү гади кеше тормышына нинди йогынты ясый?

Шушы сораута җавап бирү өчен, безгә 12-6 рәсемгә игътибар итәргә кирәк; анда милли икътисадның җыелма моделе күрсәтелә.

Рәсемнән күренгәнчә, ил күләмендә товарларга тулаем сорау күпме акчаның әйләнештә булуына, гаилә һәм оешмаларның акча тоту һәм аны саклауда нинди модельгә өстенлек бирүләренә, керемнәрнең күпме өлешен салымнар рәвешендә дәүләтнең үзенә алуына һ.б. бәйле. Ә фирмаларның гомуми (тулаем) тәкъдиме, киресенчә, аларның үз товарларыннан күпме керем алу мөмкинлегеннән, җитештерү ресурсларының күпмегә төшүеннән, җитештерү чыгымнарының күләменнән, товарлар эшләп чыгару өчен нинди җитештерү куәтләренә ия булудан, өстәмә җитештерү ресурслары (хезмәт һ.б.) алу мөмкинлегеннән тора.

ТУЛАЕМ СОРАУ — йорт хуҗалыклары, фирмалар, оешмалар һәм дәүләт бер ел эчендә товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр өчен тотарга әзер акча суммасы.

ТУЛАЕМ ТӘКЪДИМ — предприятиеләр һәм оешмалар, аларда булган җитештерү мөмкинлекләре, урнашкан чыгымнар дәрәҗәсе һәм бәяләр белән, җитештерергә һәм базарга тәкъдим итәргә әзер барлык товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр күләме.

Милли базарда товарларга сорау һәм тәкъдим «очраша». Алар ил икътисадының җитештерү күләмен (ТЭП), эшкә сәләтле халык өчен эш урыннары санын һәм эшсезлек күләмен, товарларга бәяләр һәм инфляция арту тизлеген, экспорт һәм импортның масштабын билгели. Шуларны белгәндә һәм аңлаганда, без хөкүмәт тарафыннан үткәрелгән икътисади үзгәрешләрнең чикләрен күрә алабыз.

Чынлап та, әгәр дә илдә тулаем тәкъдим тулаем сораудан сизелерлек артып китсә, ә экспорт мөмкинлекләре чикләнгән булса, хөкүмәт тулаем сорауны арттыру чаралары күрергә мөмкин (мәсәлән, салымнарны киметү яки дәүләт сатып алуларын арттыру). Тәкъдим сораудан артып китсә, борчылырга урын бар: димәк, артык күп акча базарда бик аз товарлар «таба». Моның нәтиҗәсендә инфляция артырга мөмкин һәм аның тискәре нәтиҗәләргә китерүе бар. Мондый хәлләрне булдырмый калу өчен, хөкүмәт илдә акча массасын «кыса» (киметә) яки тулаем тәкъдимне үстерүгә этәргеч бирә ала.

Икътисадны тотрыклыландыру (макроикътисади тигезләнешкә ирешү) чаралары ике төрле:

1) фискаль (салым-бюджет) һәм
2) монетар сәясәт.

МАКРОИКЪТИСАДИ ТИГЕЗЛӘНЕШ — илдә (җитештерү күләмнәре һәм бәяләр ягыннан) сатылмый торган товарларның зур запаслары да, товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр җитмәүчелеге (дефициты) сәбәпле инфляция тизлегенең кискен арту куркынычы булмаган икътисади хәл.

Фискаль сәясәтнең асылы шунда: тулаем тәкъдим житәрлек булмаганда, дәүләт фирмалар керемнәренә салымнарны киметергә һәм күбрәк товар һәм хезмәт күрсәтүләр сатып ала башларга мөмкин. Шул чакта, бер яктан, фирманың үзендә бизнесны үстерү өчен табыш күбрәк кала, ә икенче яктан, фирмалар дәүләт оешмаларына товарларны күбрәк сата ала.

Киресенчә, тулаем тәкъдим артык тиз үскәндә (икътисадчылар әйтүенчә, «икътисад кызган» вакытта), дәүләт үзенең сатып алуларын нык киметергә һәм, энтузиазмны «суыту» өчен, салымнарны арттырырга, фирмалар хуҗаларының икътисади мөмкинлекләрен кыскартырга һәм шуның аша аларны җитештерүне алга таба киңәйтү фикереннән кайтырга мәҗбүр итәргә мөмкин. Шулай эшләмәгәндә икътисад товарларны кирәгеннән артык җитештерү куркынычы алдында кала, ә моның фирманы банкротлыкка чыгаруы, эшсезлекне үстерүе һәм социаль бәла-казаларга китерүе ихтимал.

ФИСКАЛЬ СӘЯСӘТ — салымнарны һәм дәүләт чыгымнарын макроикътисади тигезләнешне саклауга булышырлык итеп көйләү.

Шул ук бурычларны дәүләт **монетар сәясәт** ярдәмендә дә хәл итәргә тырышып карарга мөмкин. Макроикътисади тигезләнешне көйләүнең мондый ысулын

кулланганда, дәүләт Үзәк банк чараларына таяна; ул исә, үзенең махсус ысуллары (мәҗбүри банк резервлары ставкаларын көйләү, кредитлар бирү кагыйдәләрен билгеләү һ.б.) ярдәмендә, икътисадта акча тәкъдим итүне арттыра яки киметә ала. Шулай эшләгәндә фирмалар үз бизнесларын алга таба үстерү проектларын җиңелрәк финанслый алалар һәм тулаем тәкъдим арта.

Киресенчә, әгәр дә икътисад артык нык «кызган» булса һәм тулаем тәкъдим тулаем сораудан күпкә тизрәк үссә, Үзәк банк фирмалар куллана торган акча массасын «кысарга» һәм кредитларны кыйммәтләндерергә мөмкин. Андый очракта фирмаларга җитештерүне киңәйтү планнарының бер өлешеннән кире кайтырга туры килер һәм яңадан макроикътисади тигезләнеш торгызылыр.

МОНЕТАР СӘЯСӘТ — дәүләтнең, макроикътисади тигезләнешне саклау максатында, акча тәкъдим итүе һәм аның бәясе белән идарә итүе.

Макроикътисади тигезләнешне көйләү ысулларының үз уңай һәм тискәре яклары бар. Шуңа күрә андый тигезләнешне саклауның дәүләт сәясәтен сайлау һәм гамәлгә ашыру гаять катлаулы мәсьәлә, чөнки кабул ителгән һәр карар ил гражданнарының кайсы да булса бер төркеме мәнфәгатьләренә кагыла.

Дәүләтнең икътисади сәясәте максатларына ирешү шуның белән дә катлаулана: хөкүмәт әлеге тигезлекне саклау турында гына түгел, ил икътисадының циклы (кабатланмалы) үсешен дә кайгыртырга тиеш.

Хәзерге буын Россиялеләр тәҗрибәсе һәм башка илләрнең икътисади статистикасы күрсәтүенчә, икътисади үсеш — тотрыклылыгы бер илдә дә гарантияләнми торган процесс ул. Икътисади үсеш хуҗалыкның көчсезләнүе яки торгынлык белән алмашынырга мөмкин.

Ә ни өчен икътисадта үсеш тенденциясенең бозылуы, хәтта көчсезләнүе ихтимал? Бу бит җәмгыятьтә икътисади тормышның төп максатына — ил гражданнары тормыш муллыгының тиз үсешен тәэмин итүгә каршы килә. Базар механизмы мондый хәлләргә юл куярга тиеш түгел дә кебек: ул җәмгыятькә кирәкле товарлар гына җитештерүне һәм моны өстәмә кыйммәт зурлыгы уңай булырлык, ә милек хуҗалары табыш һәм башка төрле керемнәр алырлык итеп эшләүне таләп итә. Бу исә үз чиратында фирмаларны табыш белән сата алырлык күләмдә товарлар җитештерергә мәҗбүр итә.

Шулай да гамәли эшчәнлек белән шөгыльләнүчеләр һәм икътисадчы галимнәр инде шактый күптәннән шуны ачыклаганнар: кайбер товар базарларында хәл әле яхшыра (сату күләме арта), әле начарая (сату күләме кими). Моның сәбәпләре төрле булырга мөмкин, мәсәлән, табигать-климат шартлары. Әйтик, корылык нәтиҗәсендә ашлык яки мамыкны сатуга тәкъдим итү кимергә һәм бәяләр артырга, авыл хуҗалыгы продуктларын эшкәртүче тармакларның эшчәнлеге өчен шартлар начараерга мөмкин.

XIX гасыр ахырында ук дөньяның индустриаль яктан алга киткән илләре **икътисади кризис** дигән исем алган күренешкә тап булды. Хуҗалык эшчәнлеге өчен шартларның начараюы аерым товар базарларында гына түгел, тулаем бөтен ил күләмендә күзәтелде. Мәсәлән, АКШта Бөек торгынлык чорында (1930 еллар)



12-7 рәсем.
Икътисади цикл стадияләре (фазалары)

ТЭП 31 % тан күбрәккә кимеде, ә күпләп сату бәяләре (товарларны сатып булмау сәбәпле) 40 % ка түбәнәйде, эшсезлек дәрәҗәсе 8 тапкыр диярлек артты һәм ул эшкә сәләтле халыкның 25 процентын тәшкил итте. Әлеге кризистан АКШ 1940 елларда, армия ихтыяҗлары һәм союздашларны тәэмин итү зарурлыгы сорауны арттыргач кына чыкты.

Шундый зур һәм авыр кризисларның сәбәпләре һәм закончалыклары икътисадчы галимнәрнең житди өйрәнү-тикшерү предметына әверелде.

Шул чорда галимнәрдә мондый фикер туды: кайбер базарларда сорау һәм тәкъдим нисбәтенең кыска вакытлы тирбәлүләре артында, бәлки тирән һәм дәвамлы процесслар ятадыр? Нәкъ менә шул фикер хәзерге икътисад фәне тарафыннан актив рәвештә үстерелә торган **икътисади (эшлекле) цикллар** теориясе барлыкка килүгә нигез булды.

Гадәттә, икътисадчылар циклны түбәндәге типик чор-фазаларга бүләләр (12-7 рәсем):

1) *күтәрелү* — житештерү масштаблары киңәя;
2) *төшү, түбәнәю* — житештерү масштаблары тарая;
3) *пик* — житештерү масштабларының киңәюе төшү белән алмашына;
4) *иң түбән нокта* — төшү күтәрелү белән алмашына.

Хәзер теләсә кайсы илдә икътисади үсешнең цикллылыгын киметү һәм житештерүнең артык нык түбәнәюен булдырмый калу — иң катлаулы проблема. Шулай да XX гасыр ахырына күп илләр икътисади тирбәлешләрнең пикларын «шомартырга» һәм җимергеч кризисларны булдырмаска өйрәнделәр. Бу мәсьәләне хәл иткәндә дәүләт сәясәтенең макроикътисади тигезлекне саклаудагыга охшаш ук вариантлары (ягъни тулаем сорауны яки тулаем тәкъдимне көйләүнең фискаль яки монетар сәясәте) файдаланыла.

Макроикътисади сәясәтнең универсаль (барлык очраклар өчен дә яраклы) рецептлары юк. Һәр ил үз «икътисады өчен иң яраклы «кризис дарулары»н үзе,

еш кына — эшләп карау һәм ялгышулар аша табарга мәҗбүр була. Россия хәзер нәкъ менә шундый процесс кичерә. Әгәр дә безнең ил нәтиҗәле макроикътисади сәясәтне таба алса, ул XXI гасыр уртасына (чит ил экспертлары фаразлавынча), Кытай, Бразилия һәм Һиндстан белән беррәттән, икътисади үсеш лидерлары «дүртлеге»нә керәчәк. Әгәр дә моңа ирешелмәсә, Россия табигать байлыкларын чит илләргә сату исәбенә генә яшәүче хәерче, көчсез илләр рәтенә төшәчәк.

Алда әйтелгәннәргә нәтиҗә ясап, без икътисади акыллылыкның чираттагы рецептын әйтә алабыз:

Уночынче рецепт

Ил тотрыклы үссен һәм аның гражданнары яхшырак яшәсен өчен, дәүләт: 1) икътисади ирекләрне сакларга; 2) базарның йомшак якларын капларга; 3) гражданнарның керемнәре һәм байлыклары арасындагы артык зур аерманы йомшартуга ярдәм итәргә; 4) макроикътисади тигезлекне сакларга һәм циклы тирбәлешләрне «йомшартырга» тиеш.

БҮЛЕКНЕҢ ТӨП ЭЧТӘЛЕГЕ

Дәүләтнең икътисадны көйләүдә катнашу сәбәпләре һәм формалары. *Цивилизацияле илләрнең икътисади тормышында дәүләт берничә әһәмиятле вазифа башкара. Аларның беренчесе — икътисади ирекләрне һәм хуҗалык тормышы кагыйдәләрен саклау; бу — коммерция (сәүдә) эшләрен беркадәр алдан күреп башкарырга мөмкинлек бирә һәм уңышсызлыкка очрау ихтималын киметә. Икътисади ирекләрне һәм җәмгыятьтә кабул ителгән хуҗалык итү формаларын яклау өчен дәүләт законнар, суд системасы һәм хокук саклау органнары төзи. Дәүләтнең икътисад дөньясындагы икенче әһәмиятле вазифасы — базар механизмының йомшак якларын каплау. Моңа зарурлык бар, чөнки базар механизмнары, чынлап та, бик үк камил түгел, ә иҗтимагый тормышның кайбер мәсьәләләрен базар, гомумән, чишә алмый. Бу исә хуҗалык эшчәнлеге шартларын начарайта. Гомуми мәнфәгатьләрдән чыгып, дәүләт базарларны монополияләштерүдән саклый; гражданнарның керемнәре һәм байлыкларындагы аерманы киметә; илнең барлык гражданнарына кирәкле иҗтимагый байлыклар җитештерүне оештыра. Моннан кала, дәүләт хуҗалык эшчәнлегенең тискәре тышкы нәтиҗәләрен йомшарту яки булдырмау чараларын күрә (моңа экологик шартларны яхшырту чараларының бөтен җыелмасы да керә).*

Ил икътисадында макроикътисади процесслар. *Гражданнарның тормыш байлыгы илнең тулай эчке продукты ничек үсүгә бәйле. Аның зурлыгы илдә бер елда җитештерелгән һәм сатылган соңгы куллану товарлары һәм хезмәт күрсәтүләрнең гомуми суммасына*

яки илдәге барлык товар һәм хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләр бер елда тудырган өстәмә кыйммәтләр суммасына тигез.

Тулаем сорау һәм тулаем тәкъдим — алар ничек үзара йогынты ясаша һәм дәүләт аларны ничек көйли ала? Илдәге икътисади хәл тулаем сорау (гаиләләр һәм оешмалар товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә түләргә әзер булган акчаның гомуми суммасы) һәм тулаем тәкъдимнең (илнең барлык хуҗалык оешмалары урнашкан эшчәнлек итү шартларында сатуга тәкъдим итәргә әзер булган товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрнең гомуми массасы) үзара тәэсир итешүеннән тора. Әгәр дә тулаем сорау һәм тулаем тәкъдим зурлыклары нык аерылса, илдә макроикътисади тигезләнеш бозыла. Аны торгызу һәм саклау — хөкүмәтнең бурычы.

Макроикътисади тигезләнешне дәүләт ничек көйли ала? Андый тигезләнешне көйләү һәм икътисадның циклы үсешендәге тирбәлешләрне «шомарту» өчен, хөкүмәт фискаль һәм монетар сәясәт чараларыннан файдаланырга мөмкин. Бу — салым ставкаларын, дәүләт сатып алуларын яки илдәге акча массасын булдыру шартларын үзгәртүне белдерә. Шушы ук ысуллардан файдалану икътисади кризисларны булдырмаска һәм илдә икътисади үсешнең цикллылыгын «шомартырга» мөмкинлек бирә.

ФИКЕР АЛЫШУ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Ни өчен хәзерге Россиянең беренче адымнарыннан берсе — бәяләр билгеләүне либеральләштерү, ягъни фирмаларга үз товарларына үзләре бәя кую хокукы бирү булды?
2. Ни өчен дәүләт чикләрен саклау хезмәтен базар хезмәт күрсәтүе итеп оештырып булмый?
3. «Көчле дәүләт икътисади яктан гражданнарга файдалы» дип раслау дөресме?
4. Илдә макроикътисади тигезләнешне саклауны аерым бер хосусый фирмага тапшырырга мөмкинме?

Дәүләт финанслары

БҮЛЕКТӘ КАРАЛУЧЫ МӘСЬӘЛӘЛӘР:

1. НИНДИ САЛЫМНАР БУЛА?
2. САЛЫМ САЛУНЫҢ ЧИГЕ БАРМЫ?
3. ДӘҮЛӘТ НИЧЕК БУРЫЧЛЫ БУЛА?

Өстәмә дәүләт керемнәре чыганаклары табу өчен, Петр I сакалга салым кертә. Андый салымның түләнгәнлеген махсус жетон раслый; һәр сакал йөртүче аны (салым түләмәгәнгә сакалын көчләп кырмасыннар өчен) үзе белән йөртергә тиеш була.

Яхшы салымнар булмый.

Уинстон Черчилль,
1940—1945, 1951—1955 елларда
Бөекбритания премьер-министры

Россия дәүләт думасында озак вакытлар нефтькә дөнья бәяләре үсү нәтиҗәсендә барлыкка килгән өстәмә дәүләт керемнәрен нәрсәгә тоту турында сәясәтчеләрнең кызу бәхәсләре барды. Берәүләр фикеренчә, әлеге «күктән төшкән» акчаларны тиз арада армияне яңадан коралландыруга, авыл хуҗалыгына ярдәм итүгә яки мәктәпләр өчен компьютерлар алуга сарыф итәргә кирәк. Икенчеләре шул ук акчаларны, дәүләтнең бурычларын түләүгә һәм гражданнарга һәм фирмаларга салым ставкаларын киметкән очракта, бюджет югалтуларын каплау өчен файдаланырга тәкъдим итәләр. Мондый бәхәсләрнең сәбәбе нәрсәдә һәм, гомумән, дәүләт бурычлары нәрсә ул? Шуны аңларга тырышып карыйк.

§ 28. Салымнар — дәүләт керемнәре чыганагы

Базар механизмнарына һәм хосусый милеккә нигезләнгән икътисад системаларында дәүләтнең акча ресурслары чыганаклары — барыннан да элек, гражданнар һәм фирмаларның керемнәренә һәм милкенә салымнар. Дәүләт финансларының шундый төзелеше соңгы елларда әкренләп Россиядә дә формалаша.

ФИНАНСЛАР — 1) гаилә, предприятие, дәүләтнең акча средстволары, кыйммәтле кәгазьләре һәм башка акча йөкләмәләре; 2) дәүләт тарафыннан оештырылган һәм гомумдәүләт акча средстволары фондларын икътисади, социаль һәм сәяси мәсьәләләрне хәл итү өчен формалаштырыла һәм файдаланыла торган акча мөнәсәбәтләре җыелмасы.

Дәүләт финанслары дөньясы белән танышуны без хәзерге салым системалары төзелеше һәм эш итүләре белән танышудан башлыйбыз, чөнки салымнар һәрбер граждан тормышына (аларның нәрсә белән шөгыльләнүенә һәм кайда эшләвенә карамастан) турыдан-туры йогынты ясый.

Салымнар турында сөйләгәндә без граждан, йорт хуҗалыгы яки оешма өчен мәҗбүри булган; тәртибе һәм шартлары ил законнарында билгеләнә торган, дәүләт файдасына түләүләрне аңлыйбыз.

Салым салу — дәүләт белән бергә туган иң борынгы икътисади механизмнарның берсе. Салымнардан башка дәүләт, гомумән, яши алмый, ә үз армиясен тотудан, хәтта үз милли валютасыннан башка да кайбер очракларда ул эш итә ала.

Илнең салымнар системасына түбәндәгеләр керә (13-1 рәсем).

1) йорт хуҗалыкларыннан һәм оешмалардан дәүләт шушы ил законнары нигезендә үз керемнәрен булдыру өчен ала торган салымнар җыелмасы;

2) салымнарның аерым төрләре буенча түләүләрнең күләмен билгеләү ысуллары;



13-1 рәсем.
Илнең салымнар системасы структурасы

3) салымнар җыю һәм алардан файдалану ысуллары;

4) салымнар җыю белән шөгыльләнә торган дәүләт оешмалары.

Салымнар билгеләүнең озак вакытлар дәвам иткән һәм еш кына каршылыклы булган тәҗрибәсе икътисад фәненә салымнар системасының өч төп принцибын формалаштырырга мөмкинлек биргән. Аның буенча ул:

1) нейтраль (бер як мәнфәгатьләренә дә кушылмый торган);

2) гадел һәм

3) дәүләт өчен (керемнәр алу чыганагы буларак) нәтиҗәле булырга тиеш.

Әгәр салымнар системасы кешеләр һәм фирмаларның төп икътисади сорауларына (НӘРСӘ җитештерергә? НИЧЕК җитештерергә? КЕМ ӨЧЕН җитештерергә?) ничек җавап бирүләренә йогынты ясамый икән, ул **нейтраль** дип санала ала. Салымнарның тулысынча нейтраль системасын төзүгә (мәсәлән, илнең һәр гражданыннан бер үк суммада акча алуга) чынлыкта әле беркем дә ирешмәгән; әмма һәрбер дәүләт салымнарның нейтраль булуына омтыла, моның өчен, мәсәлән, ул бер үк салымны төрле кешеләр (яки фирмалар) түләгәндә, аларның кайберләре өчен төрле ташламаларны минимумга кадәр киметә.

Гаделлек принцибын гамәлгә ашыру тагын да кыенрак, чөнки «Нинди салымнар гаделрәк була?» дигән сораугa төрле илдә төрлечә җавап бирәләр. Дәүләт нәрсә эшли ала соң? Ул салымнар салым түләүчеләрнең мөмкинлекләренә туры килә торган система гына төзергә тырыша ала.

Нәтиҗәлелек принцибын бертөрлерәк аңлыйлар. Ул салымнар системасы, бер яктан, дәүләткә аңа зарур булган керемнәр бирергә, ә икенче яктан, артык кыйммәткә төшә торган һәм катлаулы эш булмаска тиеш. Әмма моны тормышка ашыру бик үк җиңел түгел. Мәсәлән, хәзер Россиядә һәр йорт хуҗалыгы үз җиркәсендәге торак өчен һәр елны түли торган «күчемсез милеккә салым» бар. Аның зурлыгы хәзергә әле аның түләнгәнлеге турындагы почта белдерүе кәгазе белән чагыштырырлык дәрәҗәдә генә.

Салымнар системасын төзегәндә һәр ил бер үк мәсьәләләрне хәл итә:

1) нәрсәләргә салым салырга (салым салуның нигезе нинди);

2) һәрбер салымның ставкасы (салым салу механизмы) нинди булырга тиеш.

Салым салуның нигезе. Салымнар җыю механизмы кешелек дөньясы тарафыннан меңнәрчә еллар дәвамында камилләшеп килгән. Шулай да Рим империясендәге салымнар системасын анализлап карасак, без аларда XX гасыр ахырында файдаланылган салым салу башлангычларын да күрербез.

Мәсәлән, римлылар туры һәм кыек салымнардан файдаланганнар. **Туры салым** дигәндә, һәрбер гражданнан һәм оешмадан дәүләт файдасына җыем күздә тотыла. Җыемның күләме төрле факторлардан торырга мөмкин. Әмма ул барыннан да бигрәк керемнәр күләменә яки милек бәясенә бәйле рәвештә билгеләнә.

Җан башына (ягъни һәрбер «тере җан»нан алына торган) салым туры салымга мисал була ала. Ул хәзер барлык гражданнар түли торган керемгә салымның «борынгы бабасы».

Туры салым белән беррәттән, элек-электән кыек салымнар да гамәлгә кертелгән; аларны гражданнар турыдан-туры дәүләт казнасына кертмиләр, алар башта билгеле бер товарлар сатучыларда туплана, ә аннары соңгылары җыелган салымнар суммасын дәүләткә тапшыралар.

Мәсәлән, шәрабка Рим пошлиналары кыек салым, чөнки аларны Римның барлык гражданнары түгел, ә шәраб белән сату итүчеләр генә түләгән. Акча алмаштыру һәм ваклау өчен җыем да шул ук төргә керә — аларны акчалар белән мондый эшләр башкару ихтыяҗы булган кешеләрдән генә алганнар. Хәзерге Россия чынбарлыгында товарларның аерым төрләренә **акцизлар** да кыек салымга керә (мәсәлән, тәмәке, зәркән һәм шәраб-аракы эшләнмәләренә яки торак сатуга салымнар).

АКЦИЗ — сатып алучыдан товарларның кайбер төрләрен алганда түләтелә һәм гадәттә шул товар бәясенә карата процентларда билгеләнә торган салым.

Акциз салымнары бөтен дөньяда киң таралган һәм сатып алучы товар өчен түли торган ахыргы бәянең шактый өлешен тәшкил итә. Акциз салымнарыннан файдалану (бигрәк тә ул башка да өлкәләрдәге акыллы икътисади сәясәт белән чиратлашканда) бюджетны ныгытырга һәм илнең киләчәктәге үсеше өчен средстволар алырга мөмкинлек бирә. XX гасыр алдыннан күренекле дәүләт эшлеклесе, премьер-министр, граф Сергей Юльевич Витте Россия бюджетын нәкъ менә шулай ныгыта.

Хәзерге салым механизмнары гаять күптөрле (Россиядә генә дә 40 ка якын төрле салымнар кулланыла), ә алардан файдалану махсус законнар белән көйләнә

Салымнар элек-электән барлык илләр һәм халыклар хакимнәренең уйлап табучанлыгын күрсәтүче яраткан өлкә була. Мәсәлән, Рим империясендә гражданнардан салымнар һәм җыемнарның шундый төрләре алынган:

1. *Базар күзәтчесен тотуга җыем.*
2. *Йөкләрне төягәндә һәм бушаткандагы порт пошлиналары.*
3. *Юл пошлинасы.*
4. *Килешүне теркәү салымы (сатулардан салым).*
5. *Ишәкләр өчен ярлыкка салым.*
6. *Мираска салым.*
7. *Акча алмаштыруга һәм ваклауга салым.*
8. *Квитанция язып бирүгә һәм мөһер куюга салым.*
9. *Йорт хайваннары өчен салым.*
10. *Коллар тоткан өчен салым.*
11. *Башкаланың азык-төлек фондын булдыруга салым.*
12. *Җир салымы.*
13. *Яшелчә бакчаларына махсус салым.*
14. *Шәрабка салым.*
15. *Бодайга салым.*
16. *Кыярга салым.*
17. *Фатир өчен түләүләрдән җыем.*
18. *Балык белән сату итүчеләрдән җыем.*
19. *Йөк ташучылардан җыем.*
20. *Мунчачылардан җыем.*
21. *Фахишәләрдән җыем.*
22. *Җан башыннан салым.*
23. *Хөрмә җимеше сатудан керемнәргә салым.*
24. *Корылма урнашкан җир участогына салым.*
25. *Статуялар куюга җыем.*
26. *Ярлы (фәкыйрь) кешеләр өчен җыем.*
27. *Фатирга салым.*
28. *Шәрабтан пошлина.*
29. *Мунчалар тотуга җыем.*
30. *Олы (танылган) кунаклар өчен җыем.*
31. *Елга сакчылары тотуга җыем.*
32. *Салым түләмәүчеләрне ябу өчен төрмә тотуга җыем.*
33. *Гарнизон тотуга җыем.*
34. *Сакчы вышкалары тотуга җыем.*
35. *Иң югары хакимият вәкиленә тугрылык хисләрен белдерү сыйфатындагы алтын венокка җыем.*
36. *Полиция хезмәт хакына җыем.*
37. *Плотиналар тотуга һәм төзәтүгә җыем.*
38. *Салым җыючылар тотуга җыем.*
39. *Хөкүмәт учреждениеләре өчен язу кирәк-яракларына җыем.*
40. *Тамашалар оештыруга җыем.*
41. *Район башлыгын тотуга җыем.*
42. *Ярлыларга матди ярдәм күрсәтүгә җыем.*
43. *Сәүдә әйләнешенә салым.*
44. *Сабынга салым.*
45. *Товарлар кертүгә һәм чыгаруга пошлиналар.*
46. *Капкадан керүгә пропуск пошлиналары.*

һәм бу барысы да түгел әле.

Рим кешеләре тагын 167 төрле салым түләгәннәр. «Нәрсәгә салым билгеләнә, шул кими» дигән әйтемне искә төшерсәк, бәлки Рим империясенең җимерелү сәбәпләренең берсе нәкъ менә шундый күп салымнар салуда булгандыр?

(Россиядә ул Салымнар кодексы). һәм аларның кайберләре максатчан, ягъни дәүләт чыгымнарынын билгеле юнәлешенә бәйле.

Россиядә, мәсәлән, минерал-чимал базасын торгызуга һәм юл фондлары булдыруга салымнар максатчан. Аларның беренчесе геологлар һәм бораулаучыларның файдалы казылмаларның сарыф ителгәннәре урынына яңа чыганакларын эзләп табу һәм сәнәгатьтә файдалануга әзерләү эшен финанслауга акча средстволары табуга юнәлтелә. Икенчесен (аны юл салымы дип атыйлар) юллар төзү һәм төзәтүгә җыялар. Кайбер салымнар үзләренен икътисади табигатьләре белән бәяләрне хәтерләтә. Бу төргә бигрәк тә **пошлиналар** якын тора.

ПОШЛИНА** — **дәүләт гражданнардан һәм хуҗалык оешмаларыннан билгеле хезмәт күрсәтүләр өчен ала торган түләү.

Мәсәлән, дәүләт россиялеләрдән:

— никах һәм балалар туу турындагы таныклык бирү;

— никахны гамәлдән чыгару процедурасын башкару;

— мирас итеп алуга хокукны раслау;

— шикаятьне судта карауга алу;

— илгә чит илләрдә җитештерелгән товарларны кертергә (ә кайчакта илдә җитештерелгән товарларны читкә чыгаруга) рөхсәт бирү өчен пошлина ала.

Гамәлдә әлеге пошлиналар — дәүләт хезмәтенең мөрәҗәгать иткән гражданнарга хезмәт күрсәтүләре өчен түләү, ә дәүләт үзе базарда хезмәт күрсәтүләрне сатучыларның берсе буларак эш итә.

Россиядә салымнарны федераль, региональ (төбәк) һәм җирле салымнарга бүләләр. Федераль салымнар РФ хөкүмәте керемнәрен тулыландыра, региональ салымнар — хакимиятнең төбәк органнары бюджетына, ә җирле салымнар шәһәрләр һәм башка муниципаль хакимият органнары бюджетына керә.

Федераль салымнар түбәндәгеләрдән тора: өстәмә кыйммәткә салым; акцизлар; физик затлар керемнәренә салым; бердәм социаль салым (взнос); кыйммәтле кәгазьләр белән эш итүгә салым; табигать ресурсларыннан файдаланган өчен түләүләр; хайваннар дөньясы объектларыннан һәм су биологик ресурсларыннан файдалану хокукы өчен; тирәлекне пычраткан, су объектларыннан файдаланган өчен; оешмалар керемнәренә салым; юл фондлары чыганаклары булып торучы салымнар: автомобиль юлларыннан файдаланучыларга салым, транспорт чаралары хуҗаларыннан салым; дәүләт пошлинасы; мирас итеп калдыру һәм бүләк итеп бирү тәртибендә күчә торган мөлкәттән салым; «Россия», «Россия Федерациясе» исемнәреннән һәм алар кергән сүзтезмәләрдән файдаланган өчен җыем; чит ил акча знаклары һәм түләү документлары (чит ил валютасында) сатып алган өчен салым; уен бизнесына салым; лицензияләр һәм этил спирты, составында спирт булган һәм алкогольле продукция җитештерүгә хокук биргән өчен җыемнар; файдалы казылмалар чыгаруга салым.

Региональ салымнарның төрләре: предприятиеләр мөлкәтенә салым; урман салымы; юридик затлардан белем бирү учреждениеләре өчен җыемнар; сатудан салым; эшчәнлекнең кайбер төрләре билгеләнгән керемгә бердәм салым.

Җирле салымнар: физик затлар мөлкәтенә салым; җир салымы; эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнүче физик затлардан теркәү җыемы; курортлар зонасында җитештерү максатындагы объектлар төзүгә салым; курорт салымы; сәүдә итүгә хокук өчен җыем; гражданнардан һәм предприятиеләрдән, учреждениеләрдән, оешмалардан (аларның оештыру-хокук формаларына карамастан) милиция тотуга, территорияне төзекләндерүгә, мәгариф һ.б. чыгымнарга максатчан җыемнар; рекламага салым; автомобильләр, хисаплау техникасы һәм персональ компьютерлар алып сатуга; эт тотучылардан; шәраб-аракы эшләнмәләре сатуга лицензион җыем; җирле аукционнар һәм лотереялар үткәрү хокукына лицензион җыем; фатирга ордер биргән өчен җыем; автомобиль транспортын тукталышка кую өчен җыем;

җирле символикадан файдаланган өчен җыем; ипподромнардагы ярышларда катнашу өчен җыем; ул ярышларда җиңүчеләрдән җыем; ипподромда тотализаторда уйнаучы затлардан җыем; биржаларда ирешелгән килешүләрдән җыем (кыйммәтле кәгазьләр белән эш итүгә салымнар билгеләү турындагы закон актларында каралган килешүләрне кертмичә); кинога һәм телевидениегә төшерү үткәрү хокукы өчен җыем; торак пунктларындагы территорияне җыештырган өчен җыем; уен бизнесы ачкан өчен җыем.

Салым салу механизмы. Салым салу механизмының нигезендә салым ставкалары тора: шулардан чыгып йорт (гаилә) хуҗалыклары яки оешмалар дәүләт керменә түләргә тиешле акча суммасы исәпләп чыгарыла.

САЛЫМ СТАВКАСЫ (НОРМАСЫ) — салым түләүче тарафыннан (салым салу берәмлегенә туры китереп) дәүләт керемнә кертелергә тиешле түләү зурлыгы.

Салым ставкасы — абсолют түләү суммасы яки шушы салым нәрсәгә салына (мәсәлән, керемнәр яки мөлкәт бәясе), шунын бәясенен бер өлеше ул. Әлеге ставканың сан зурлыгы нинди булырга тиеш, ул бердәм буламы яки нинди дә булса схема буенча үзгәрәме — болар гаять бәхәсле мәсьәләләр.

Дөньядагы илләр тәҗрибәсендә салым ставкалары төрләренең өч системасы:

— прогрессив;

— пропорциональ;

— регрессив ставкалар кулланыла.

Прогрессив системада салым ставкасы, салым салына торган керемнен яки мөлкәт бәясенең зурлыгы арткан саен үсә. Россиядә әлеге система, мәсәлән, XX гасырның 90 нчы елларында шәхси керемнәргә карата кулланыла иде. Ул системага бай гражданнар, байлыгы азрак булганнарга караганда, салымнар рәвешендә үз керемнәренен күбрәк өлешен түли дигән сүз.

Пропорциональ системада салым салу базасының зурлыгына бәйсез рәвештә салым салуның бердәм ставкасы (нормасы) файдаланыла. Россиядә мондый салым салу юридик затлар табышына салымнарда күренә.

Регрессив системада салымнарны исәпләү прогрессив системага капма-каршы рәвештә башкарыла: анда салым салына торган керем яки мөлкәтнең абсолют зурлыгы арткан саен салым ставкасы түбәнәя (кими). Регрессив система еш кына иң бай гражданнарның керемнәренә салым салганда кулайрак була. Моның сәбәбе гади — гадәти прогрессив системада аларга шулкадәр күп түләргә кирәк була ки, легаль (ачыктан-ачык) рәвештә салымнарны киметергә ярдәм итүче юристлар һәм салым консультантлары хезмәтенә аларга күпкә азрак түләргә кирәк була. Нәтиҗәдә дәүләт салымнар прогрессиясеннән отмый, ә оттыра. Ә, киресенчә, ставкалар югары булмаса, салымнардан «качу» өчен сәбәпләр азрак.

Алда бәян ителгән салымнар салуның төрлелеге очраклы түгел. Ул һәр илдә азмы-күпме гадел дип исәпләнә торган салымнар җыю системасын төзү зарурлыгыннан чыга. Салымнарның гаделлеге ике төрле — горизонталь һәм вертикаль — гаделлек аша тәэмин ителә.



13-2 рәсем.

Салымнарның горизонталь гаделлеге (һәр граждан үз керемнәренең 1/3 өлешен салым рәвешендә бирә)

Горизонталь гаделлек (13-2 рәсем) булганда тигез керемнәргә тигез салымнар салу күздә тотыла. Вертикаль гаделлек буенча (13–3 рәсем) (керемнәр дәрәҗәсенә бәйле рәвештә), төрле салым ставкалары кулланыла.

Һәрбер салым салу системасының үз җитешсезлекләре һәм уңай яклары бар. Алар еш кына аерым-аерым түгел, ә салымнар комплексы кысаларында файдаланыла (дөньяның барлык илләрендә дәүләт керемнәрен күптөрле салымнар ярдәмендә җыялар).

Салымның күләме җәмгыятьнең дәүләткә нинди бурычларны хәл итүне тапшыруыннан тора. Ул бурычлар җитдирәк булган саен, дәүләткә аларны хәл итү өчен күбрәк средстволар кирәк һәм илдә салымнар йөге авыррак була бара. Шушы ике мәсьәлә ягыннан салым салу механизмын һәм салымнар алу күләмен карап үтик.

Салымнар алу күләме. Салым салу системасының борынгыдан килгән тамырлары һәм бу өлкәдә кешелекнең гаять зур тәҗрибәсе булуга карамастан, «салымнар системасын ничек яхшырак итеп төзергә; салым салу ставкалары дәрәҗәсе нинди булырга тиеш» дигән бәхәсләр хәзергәчә тынмый.

Бер яктан караганда, дәүләт гражданнар һәм фирмалар керемнәре өлешен үз кулында күбрәк туплаган саен, социаль яклауга мохтаҗ гражданнарга, ул илдә мәгариф, сәламәтлек саклау һәм фәнне үстерүгә яхшырак ярдәм итә ала.



13-3 рәсем.

Салымнарның вертикаль гаделлеге (керемнәрнең салым рәвешендә бирелә торган өлеше керемнәрнең башлангыч суммасы үскән саен арта бара)

Икенче яктан, дөньядагы илләр тәҗрибәсе күрсәтүенчә, икътисадка салымнар «йөге» җиңелрәк булган саен, ул тизрәк үсә.

Нәтиҗәдә салым системасы һәрвакыт җәмгыятьнең төрле төркемнәре мәнфәгатьләре, шулай ук бөтен ил һәм аның асрым төбәкләре арасында килешү рәвешендә формалаша. Шуңа күрә икътисад фәненә гасырлар дәвамындагы практикада сыналган салымнар сәясәте принциплары билгеле булса да, салым системаларын төзүнең бердәм кагыйдәләре юк. Әлеге принципларны һәр ил үзенчә, аның алдында торучы бурычлардан чыгып кулллана.

Хәзерге Россиядә законнар чыгару һәм башкарма хакимият органнары утырышларында салымнарны һәм аларны җыю ысулларын ничек үзгәртү кирәклеге турында кискен бәхәсләр чыкмаган бер генә ел да юк.

Яңа салымнар кертү мөмкинлекләре хәзер беткән диярлек — законнар тарафыннан элегрәк расланган салымнарны тулырак җыярга омтылырга гына мөмкин. Россия хөкүмәтенең якындагы унъеллыкка бурычы — яңа салымнар уйлап чыгару түгел, ә булганнарын җыю механизмнарын яхшырту һәм салым салу механизмнарын икътисад фәне тәкъдимнәренә туры китереп камилләштерү.

Салымнар җыю ничек үзгәрә, алар ничек дәүләт чыгымнарына трансформациялөнә, хәзер шуны ачыклыйк.

§ 29. Дәүләт бюджеты ничек формалаштырыла һәм сарыф ителә

Беренче карашка, салымнарның «язмышы» гади: алар дәүләт идарәсе органнары бюджетына керә. Федераль салымнар — федераль бюджетны, ә җирле салымнар хакимиятнең җирле органнары бюджетын тулыландыра.

БЮДЖЕТ — керемнәр җыю һәм алынган средстволарны федераль яки җирле дәүләт хакимияте органнарының билгеле вакытка чыгымнарын каплауга файдалануның җыелма планы.

Мисал өчен, Россиянең федераль бюджетын алсак, ул Дәүләт думасы һәм Федераль җыен — илнең иң югары законнар чыгару органы тарафыннан раслана. Хөкүмәт бюджет проектын әзерли һәм аның үтәлеше өчен җаваплы. Ул (Финанс министрлыгы һәм Салым хезмәте аша) керемнәр җыюны һәм аларны бюджетта билгеләнгән юнәлешләрдә һәм күләмдә сарыф итүне оештыра.

Хокук һәм бурычларны законнар чыгару һәм башкарма хакимиятләре арасында шул рәвешле бүлү салым түләүчеләр керткән средстволарның сарыф ителүен иң югары, сайланып куела торган хакимият тикшерүендә тотарга, аларны дәүләт чиновниклары уйламыйча яки аерым кешеләр файдасына сарыф итүне булдырмый калырга ярдәм итә. Мисал өчен, Россиянең 2004 елгы бюджетын карыйк.

2004 елга федераль бюджетның төп күрсәткечләре турында белешмә
(мең сумнарда)

КЕРЕМНӘР, барлыгы	3 075 147 646
Шул исәптән: **1. Салымнардан керемнәр**	2 438 610 860
Табышка салым. Товарлар һәм хезмәт күрсәтүләргә салымнар	184 698 076
Лицензия һәм теркәү өчен җыемнар	1 075 461 986
Тулаем керемгә салым	162 249
Мөлкәткә салымнар	107 092
Табигать ресурсларыннан файдаланган өчен түләүләр	393 918 995
Тышкы сәүдәгә һәм тышкы икътисади чараларга салымнар	761 082 534
Башка төр салымнар, пошлиналар һәм җыемнар	23 179 928

Шул исәптән: **2. Салымнан булмаган керемнәр**	198 970 227
Дәүләт яки муниципаль милек булып исәпләнүче мөлкәттән файдаланудан яки дәүләти һәм муниципаль оешмалар эшчәнлегеннән керемнәр	151 729 060
Матди булмаган активлар сатудан керемнәр	14
Дәүләтнеке булмаган чыганаклардан капиталь трансфертлар керү	3
Административ түләүләр һәм җыемнар	2 202 116
Штраф санкцияләре, китерелгән зыянны каплау	1 367 663
Тышкы икътисади эшчәнлектән керемнәр	35 396 574
Башка төр салым булмаган керемнәр	8 274 797
3. Бюджет системасының башка бюджетларыннан түләүсез акча күчерүләр	35 772 940
4. Россия Федерациясе Атом энергиясе министрлыгы фонды	13 382 175
5. Бердәм социаль салым	388 365 440
6. Классификацияләнмәгән керемнәр	46 004
ЧЫГЫМНАР, барлыгы	2 288 787 437
Шул исәптән: Дәүләт идарәсе һәм җирле үзидарә	63 583 488
Суд хакимияте	26 406 465
Халыкара эшчәнлек	39 026 539
Гомумдәүләт оборонасы	364 155 109
Хокук саклау эшчәнлеге һәм дәүләт иминлеген тәэмин итү	265 541 898
Фундаменталь тикшеренүләр һәм фәнни-техник алгарышка булышлык итү	38 256 203
Сәнәгать, энергетика һәм төзелеш	51 245 176
Авыл хуҗалыгы һәм балык тоту	23 044 323
Әйләнә-тирә табигатьне һәм табигый ресурсларны саклау, гидрометеорология, картага төшерү һәм геодезия	10 692 324
Транспорт, элемтә һәм информатика	5 196 525
Гадәттән тыш хәлләр һәм бәла-казаларның нәтиҗәләрен булдырмау һәм бетерү	23 151 187

Мәгариф	98 341 314
Мәдәният, сәнгать һәм киногa төшерү	14 051 098
Массакүләм мәгълүмат чаралары	10 211 016
Сәламәтлек саклау һәм физик культура	38 105 335
Социаль сәясәт	138 344 767
Дәүләти һәм муниципаль бурычларны түләү	187 597 983
Дәүләт запасларын һәм резервларын тулыландыру	14 546 802
Бюджет системасындагы башка бюджетларга финанс ярдәме	797 379 975
Искергән коралларны утильләштерү һәм юкка чыгару (халыкара килешүләрне үтәүне дә кертеп)	9 295 223
Икътисадны мобилизацион әзерләү	840 131
Космик киңлекләрне өйрәнү-тикшерү һәм алардан файдалану	11 339 979
Хәрби реформа	5 533 847
Башка төр чыгымнар	1 806 997
Максатчан бюджет фондлары	12 071 483
Бюджет дефициты (—), бюджет профициты (+)	786 360 209
Финанслау чыганаклары, барлыгы	–786 360 209
Шул исәптән: ***Эчке финанслау чыганаклары***	–577 538 983
Тышкы финанслау чыганаклары	–208 821 226

Дәүләт чыгымнары статьялары исемлеге белән танышып чыккач, сез аларның дәүләтнең алдарак бәян ителгән вазифаларын чагылдыруын күрдегез. Бюджет төзү түбәндәге бюджет тәңгәллегенә буйсынырга тиеш:

Товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алуга чыгымнар + Трансфертлар = Салым һәм пошлиналарның керүе

***БЮДЖЕТ ТРАНСФЕРТЫ** — гомумдәүләт бюджетыннан түбәнрәк дәрәҗәдәге бюджетларга (аларны тулыландыру өчен) акча күчерү.*

Хөкүмәтнең керемнәре һәм чыгымнары тәңгәл килсә, дәүләт бюджетын *балансланган* дип атыйлар. Бу теләсә кайсы дәүләт финансисты өчен иң яхшы

вазгыять (абсолют яхшы вазгыять бюджет керемнәре чыгымнардан артык һәм акчаларны дәүләтнең киләчәге өчен саклауга салырга мөмкин булганда туа). Чарлз Диккенсның «Дэвид Копперфилд» дигән романы персонажларының берсе мистер Микобер кайчандыр барлык дәрәҗәләрдә — гаиләдән башлап дәүләткә кадәр — нәкъ менә шундый финанс сәясәте алып барырга чакырган: *«Еллык керем — егерме фунт, еллык чыгымнар — унтугыз фунт туксан алты пенс, нәтиҗә — бәхет. Еллык керем егерме фунт, еллык чыгымнар — егерме фунт алты пенс, нәтиҗә — ярлылык».*

Әмма дәүләт финанслары белән Диккенс сурәтләгән схема буенча (ягъни бюджет тәңгәллеге нигезендә) идарә итү чынлыкта гаять катлаулы: дәүләттән пенсионерлар, кризис кичерүче тармаклар, музыкантлар, укытучылар, галимнәр, армия һәрвакыт яңадан-яңа чыгымнар таләп итә. Һәм сораучыларның әлеге исемлеге бик зур. Һәрбер сораучының үз дәлиле, әмма дәүләтнең финанс ресурслары да чиксез түгел.

Әгәр дә дәүләт әлеге сорауларны канәгатьләндерергә уйласа, соңгы чиктә ул кыен хәлгә эләгергә, чыгымнар суммасы дәүләтнең салым салудан керемнәреннән артып китә башларга мөмкин. Башкача әйткәндә, тигезлекнең сул ягы аның уң ягына караганда зуррак булып чыга, һәм бюджет тигезлеге тигезсезлеккә әверелә.

$$\left(\text{Товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алуга чыгымнар} + \text{Трансфертлар} - \text{Салымнар һәм пошлиналарның керүе}\right) > 0$$

Бу дәүләт бюджетының **дефицит** белән төзелүен белдерә.

***ДӘҮЛӘТ БЮДЖЕТЫ ДЕФИЦИТЫ** — дәүләт барлык төр салымнар һәм түләүләрдән чынлыкта алырга мөмкин булган керемнәрдән артыграк суммадагы чыгымнарга баруны күздә тотканда барлыкка килүче финанс хәле.*

1993 елның декабрендә Россия Федерациясенең дәүләт бюджеты дефициты — 16 %, ә 1994 елның декабрендә инде 35 % (50,8 трлн сум) була. 1995 елга дәүләт бюджеты якынча 29 % дефицит белән кабул ителә. 2000 елга бюджет башта (90 нчы елларда беренче мәртәбә) дефицитсыз кабул ителә. Әмма соңрак дәүләт чыгымнарының көтелгәннән зуррак булачагы ачыклана, бюджетка төзәтмәләр кертергә туры килә. 2001—2003 елларда гына (нефтькә дөньяда бәяләр бик югары һәм шуңа нисбәттә нефть компанияләреннән керемнәр зуррак булу сәбәпле) Россия Федерациясе бюджеты балансланган, ә аннары профицитлы була.

***ДӘҮЛӘТ БЮДЖЕТЫ ПРОФИЦИТЫ** — дәүләт барлык төр салымнардан һәм түләүләрдән чынлыкта алырга мөмкин булганнан кимрәк суммадагы чыгымнарга баруны күздә тотканда барлыкка килүче финанс хәле.*

(Товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алуга чыгымнар + Трансфертлар – Салымнар һәм пошлиналарның керүе) < 0

Бюджет профицит белән төзелгән.

Әмма дәүләт ничек итеп үзе гражданнардан һәм фирмалардан алганнан күбрәк акча тота ала соң? Ул үз бюджеты дефицитын ничек хәл итә?

Дөньядагы илләр практикасында әлеге проблеманы хәл итүнең дүрт төп ысулы бар:

1) бюджет чыгымнарын киметү;

2) өстәмә керем чыганаклары табу;

3) дәүләт чыгымнарын финанслауга тотыла торган, «тәэмин ителмәгән» акчалар чыгару (эмиссия);

4) гражданнардан, банклардан, хуҗалык оешмаларыннан, башка дәүләтләрдән һәм чит ил финанс оешмаларыннан бурычка акча алу.

Бюджет чыгымнарын киметү. Бюджет дефицитын бетерүнең мондый юлы беренче карашка бик гади булып тоелса да, чынлыкта кыен ысул. Шуңа күрә Россия әле ул юлдан китә алмый. Ә монда мөмкинлекләр гаять зур, чөнки хәзерге вакытта ил икътисады дәүләт бюджетыннан гаять күп финанслана. 90 нчы еллар башына илдә бер елда җитештерелгән товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр бәясендә дәүләт чыгымнарының өлеше якынча 60 % тәшкил итте.

Узган елларда Россиядә шактый күп үзгәрешләр булды: дәүләт предприятиеләрен хосусыйлаштыруның киң күләмле кампаниясен искә алу да җитә.

Шулай да әле хәзергә илдә бер елда җитештерелгән продукциядә дәүләт чыгымнарының өлеше 50 % тан түбән төшми (алга киткән илләрнең күпчелегендә ул 40 %). Россия дәүләтенең икътисади тормышта катнашу дәрәҗәсе шундый зур булуның сәбәбе гади: дәүләт гадәттә җәмгыятьнең башка беркем дә финансларга теләми яки моны эшли алмый торган ихтыяҗларына акча кертә. Шуңа күрә дәүләт бюджетының андый чыгымнарын кыскартуның күңелсез нәтиҗәләргә китерүе ихтимал.

Шунысы ачык: социаль программаларны, ташлама һәм трансфертларны киметү гадәттә җәмгыятьтә киеренкелек үсүгә китерә һәм аның сәяси тотрыклылыгына зыян китерә. Хөкүмәтләр мондый адымга һәрвакыт соңгы чиктә — бюджет дефицитын бетерүнең башка өч ысулын гамәлгә ашырып булмаганда гына баралар.

Өстәмә керем чыганаклары табу. Әлбәттә, бюджет дефицитын каплауның иң яхшы ысулы — бюджетка өстәмә керемнәр җәлеп итү.

Әмма бу мәсьәләне хәл итү гаять авыр. Салымнар һәм пошлиналарны арттырып карарга була. Ләкин бу юл куркыныч, икътисад фәне инде күптән ачыклаган: салымнарны чиктән тыш арттыру дәүләт керемнәрен үстерүгә түгел, ә аларның кимүенә китерә.

Моның сәбәпләре ике:

— беренчедән, әгәр дә эш хакының зур өлешен дәүләт алса, кешедә хезмәткә кызыксыну югала;

— икенчедән, кешеләр үз керемнәрен салым салудан яшерә башлый, һәм илдә тиз арада **«күләгә икътисады»** (керемнәр салым салудан яшерелә торган эшчәнлек) үсеш ала, ә хуҗалык мөнәсәбәтләре нык криминальләшә.

13-4 рәсем.
Лаффер кәкресе — салымнар сәясәте моделе

Мондый картина Америка икътисадчысы Артур Лаффер тәкъдим иткән һәм аның хөрмәтенә «Лаффер кәкресе» дигән исем алган графиктан яхшы күренә. Ул график 13-4 рәсемдә сурәтләнгән.

Әлеге графикта без ике сызык күрәбез. Беренчесе — салымнар җыюның гипотетик кәкресе — салым салу ставкалары артканда (әгәр дә гражданнар һәм фирмалар аларның күләменә битараф булса) бюджетка салым керемнәре абсолют суммасының ничек үсү мөмкинлеген күрсәтә. Әмма чынлыкта ул ставкаларның зурлыгы барлык салым түләүчеләрне бик кызыксындырмаганлыктан, бюджетка керемнәрнең андый үсеше беркайчан да булмый. Киресенчә, һәм нәкъ менә шуны Лаффер кәкресе күрсәтә дә. Билгеле бер чиктән соң салым салу ставкаларының артуы бюджетка керә торган средстволарның абсолют зурлыгы үсүгә түгел, ә кимүгә китерә.

Кешеләрнең законлы һәм законсыз юллар белән салымнардан качу ысулларын эзләвендә аларның элек-электән күрсәткән уйлап табучанлыгына гаҗәеп мисаллар тарихта бик күп. Мәсәлән, XIX гасырда Англиядә этләргә салым кертәләр һәм аның күләмен хуҗалыктагы эт койрыклары санына пропорциональ итеп билгелиләр. Һәм күп кенә инглизләр кичекмәстән үзләренең сакчы этләренең койрыкларын кисә башлыйлар: «Койрык юк — салым да юк!» Шулай итеп, бобтейл — хәзергә кадәр сакланган койрыксыз овчаркалар токымы килеп чыккан.

Безнең ил гражданнарының да салымнардан качуда уйлап табучанлыклары шуннан ким түгел. Соңгы елларда хөкүмәт барлык түләнергә тиешле салымнарның 50—60 %ын гына җыя алды. Калган гражданнар һәм фирмалар төрле юллар белән керемнәрен салым инспекциясеннән яшерделәр. Һәм Россия хөкүмәте башка юл белән китәргә — шәхси керемнәргә прогрессив салымнардан (32 %) бердәм ставкага (13 %) күчәргә карар итте. Нәтиҗә нәкъ менә Лаффер кәкресендәгечә килеп чыкты.

Салым салу өлкәсендә бернинди чаралар да дәүләт керемнәре артуга китермәсә, туктаусыз рәвештә дәүләттән акча таләп итүләр хөкүмәтне «почмакка» куып кертә, һәм ул үз чыгымнарын каплауның иң хәвефле (эмиссион) юлын сайлый.

Тәэмин ителмәгән акчалар чыгару. Иң җиңел һәм тәвәккәллек сорый торган «бюджет тишеге»н ямау ысулы — ул дәүләт тарафыннан икътисадның чынлыктагы ихтыяҗларынннан артык күләмдә акча чыгарылу (эмиссия). Бюджет дефицитын каплауның мондый ысулы наркотик кебек — ул беркадәр вакытка баш авыртуын һәм борчылуны бетерә, ә аннары тагын да начаррак икътисади хәл тудыра.

Сәбәбе гади. Гомумдәүләт базары эмиссиягә тиз арада бәяләрнең артуы яки (дәүләт бәяләр үсүгә чикләүләр кертергә уйласа) кибетләрдә товарларны бетерү белән җавап бирә. Шуңа күрә бюджетның «оту»ы озакка сузылмый.

Дөньядагы илләр тәҗрибәсе күрсәткәнчә, бюджет инфляция белән «ярыш»та һәрвакыт оттыра. Чөнки чыгымнарны бүген һәм бүгенге бәяләр белән түләргә кирәк, ә салымнар элеккерәк бәяләрдән барлыкка килгән «кичәге» керемнәрдән алына. Нәтиҗәдә бюджет дефициты кимеми, ә арта.

Шулай да Россиядә дәүләт салымнарны аванс белән, ягъни фирма керем алганчы ук җыярга тырыша. Болай эшләү сәүдә фирмаларының тормышын бик нык кыенлаштыра һәм салымнардан качуда уйлап табучанлыкка этәрә.

Бурычка акча алу. Гражданнар һәм хуҗалык оешмалары кебек үк дәүләт тә, акча җитмәгәндә бюджет тигезсезлеген яңадан тигезләү өчен, аларны бурычка алып торырга мөмкин:

Товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алуга чыгымнар	+	Трансфертлар	=	Салымнар һәм пошлиналарның керүе	+	Заемнар

Дәүләт кемнән заемга (әҗәткә) акча алырга мөмкин?

Барыннан да элек — үзенеке (ягъни дәүләтнеке) булган банктан. Бу юлны 1992—1994 елларда Россия дә файдаланды. Мәсәлән, 1992 елга Россиянең дәүләт бюджеты турында Законның 18 нче статьясында болай диелгән иде: *«Россия Федерациясе Үзәк банкына 1992 елның икенче яртысында Россия Федерациясе Финанс министрлыгына, Россия Федерациясе республика бюджеты дефицитын каплау өчен, 10 еллык срокка, 1996 елдан башлап һәм еллык 10 процент белән бертигез өлешләрдә кайтару шарты белән кредит бирүне рөхсәт итәргә...»*

Әмма гомумдәүләт банкының дәүләткә кредит бирү мөмкинлекләре гадәттә чикләнгән. Моннан тыш, Үзәк банктан акча алган очракта дәүләт, әлеге банк хуҗасы буларак, аннан алырга мөмкин булган керемнәрне югалта. Шуңлыктан акчаны бурычка гражданнардан һәм хуҗалык оешмаларыннан алып тору отышлырак булып чыга. Әҗәткә алуның формалары күптөрле була, әмма ешрак ул **дәүләт кыйммәтле кәгазьләрен** сату аша эшләнә.

Аңлашыла ки, бурычка акча алып тору бер проблеманы (бүгенге көндә акча җитмәүне) хәл итү белән беррәттән, шунда ук иртәгәге көндә бурычларны түләү өчен акча табу зарурлыгын тудыра. Бурычка акча алу **дәүләт бурычларын** барлыкка китерә.

***ДӘҮЛӘТ КЫЙММӘТЛЕ КӘГАЗЬЛӘРЕ** — дәүләтнең үзе бурычка алган акчаларны һәм алардан файдаланган өчен процентларны кире кайтарып бирү йөкләмәсе.*

***ДӘҮЛӘТ БУРЫЧЫ** — дәүләт органнары алган һәм әлегә кредиторларга кайтарып бирелмәгән ссудалар суммасы.*

Дәүләт бурычы ике төрле була:

1) *эчке* — үз иле гражданнары, банклары һәм фирмалары, шулай ук эчке заемнар кыйммәтле кәгазьләре сатып алган чит ил кешеләре каршында;

2) *тышкы* — хөкүмәтләр килешүе нигезендә заемга акча биргән хөкүмәтләр, халыкара банклар һәм финанс оешмалары каршында.

Дөньяның күпчелек илләре хәзерге вакытта зур күләмле дәүләт бурычлары белән яши. Мәсәлән, АКШның мондый бурычы бер елда житештерелгән товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр бәясенең 63 % ын тәшкил итә (10 ел элек ул 45 % булган).

Бурыч дәүләтнеке булгач, моңа кешеләрнең нинди катнашы бар соң? Бурыч һәм аңа өстәлгән процентлар илдәге кешеләрдән салымнар алу исәбенә түләнә. Димәк, чит илләрдән кредит алу мәсьәләсе һәр гражданның мәнфәгатьләренә турыдан-туры кагыла.

Эшләрне акыл белән алып барганда зур дәүләт бурычы ил икътисадын жимерми һәм кискен социаль каршылыкларга китерми. Ә бурычка алынган акчалар тиешенчә файдаланылмаса, бурычны түләү бюджетка авыр йөк булып төшә. 1998 елда ул йөк Россия дәүләтенә шулкадәр авыр булды ки, хәтта хөкүмәткә үзенең бурычларын түләүдән ваз кичәргә туры килде. Бу исә шунда ук илдә финанс кризисы барлыкка китерде һәм хөкүмәттән дәүләт коммерция облигацияләрен үз кертемчеләре акчасына сатып алган күп банклар бөлгенлеккә төште. Димәк, әлеге кертемчеләр дә үз акчаларын югалтты. 2001 ел бюджетында бурычларны түләүгә 231 104 млрд сум яки дәүләтнең барлык чыгымнарының 18 % ка якыны юнәлтелде.

Бурыч зур булганда дәүләт сайлау зарурлыгы алдында кала: яки бурычны түләүне туктатырга (яхшырак вакытка кадәр); яки социаль программаларга чыгымнарны һәм гомумдәүләт икътисадына ярдәм итүне кыскартырга; яки тагын бурычка кереп, элек алган бурычларны түләргә.

Әлеге юлларның берсе дә ил житәкчелегенә дә, гражданнарга да шатлык вәгъдә итми. Мәсәлән, беренче вариант Россияне дефолтка барган, ягъни аңа акча биреп торучыларны тупас рәвештә алдаган ил дип игълан итүгә китерде. Ә дефолт (бурычларны түләүдән ваз кичкән) өчен катгый жәза бирү кабул ителгән — ул «алдакчы» илнең чит илләрдәге бөтен мөлкәтен, ә иң әһәмиятлесе, чит илләргә продукция һәм чимал (нефть, газ, акча) сатудан төшемне конфискацияләүгә кадәр барып житәргә мөмкин. Икенче юл (нәкъ менә аны 2001 елда Россия хөкүмәте, тышкы бурыч буенча түләүләр артык авырайгач, гамәлгә ашырырга теләгән иде) халыкның канәгатьсезлеген һәм Думадагы оппозицион партияләрнең каттый каршылыгын тудырды.

Мондый хәлне яхшы уйланылган һәм эзлекле дәүләт финанс сәясәте үткәрү юлы белән генә булдырмый калырга мөмкин.

БҮЛЕКНЕҢ ТӨП ЭЧТӘЛЕГЕ

Салымнар — дәүләт керемнәре чыганагы. *Үз вазифаларын башкару өчен дәүләт зур күләмдә акча средстволарына мохтаҗ. Дәүләт казнасына акча җыю керемнәргә, милеккә, гражданнар һәм фирмалар эшчәнлегенең кайбер төрләренә салымнар ярдәмендә тормышка ашырыла. Дөньяның күпчелек илләрендә салым салуның күпканаллы системасы кулланыла: керемнәр бер үк вакытта салымнарның күп төрләре ярдәмендә гамәлгә ашырыла.*

Дәүләт бюджеты ничек формалаштырыла һәм сарыф ителә. *Салымнар һәм дәүләтнең башка керемнәре дәүләт бюджетына туры китереп сарыф ителә. Аны хөкүмәт төзи һәм үти, ә закон чыгару хакимияте органнары раслый. Дәүләт чыгымнары структурасы илнең ихтыяҗларыннан, аның икътисадының торышыннан һәм җәмгыять дәүләткә йөкләгән вазифалардан чыгып билгеләнә. Еш кына дәүләткә җәмгыять таләп иткән барлык чыгымнарны түләргә керемнәр җитми. Мондый очракта бюджет дефициты барлыкка килә һәм дәүләт бурычка акча алырга мәҗбүр була. Шундый бурычка акча алу эчке һәм тышкы дәүләт бурычларын барлыкка китерә. Ул бурычлар буенча чынлыкта ил гражданнары «җавап тота», чөнки бурычларга нәкъ менә аларның керемнәреннән түләнәчәк.*

ФИКЕР АЛЫШУ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Бервакыт Токиода Финанс министрлыгы бинасы каршында дәүләт мәктәпләре укытучылары демонстрациясе уза. Алар хөкүмәтнең керемнәргә салымны киметү планнарына каршы чыгалар. Сез ничек уйлыйсыз: ни өчен әлеге планнар укытучыларның каршылыгына сәбәп була?
2. Физик затларның керемнәренә салым ставкаларын күтәрү белән ил гражданнарыннан кемнәр кызыксынырга мөмкин?
3. Россия хөкүмәтен дәүләтнең бурычын арттырырга нәрсә мәҗбүр итә?

Икътисади үсеш

БҮЛЕКТӘ КАРАЛУЧЫ МӘСЬӘЛӘЛӘР:

1. ИКЪТИСАДИ ҮСЕШ НИ ӨЧЕН КИРӘК?
2. НИ СӘБӘПЛЕ ИКЪТИСАДНЫ «КЕШЕЛЕК ҖӘМГЫЯТЕ БИОЛОГИЯСЕ» ДИП АТЫЙЛАР?
3. ИЛ ЮГАРЫ ҮСЕШКӘ НИЧЕК ИРЕШӘ АЛА?

Икътисади үсеш илгә төрле байлыклар һәм хезмәт күрсәтүләрне күбрәк җитештерү мөмкинлеге бирә. Шунысы мөһим: барлык көчләрнең ашыгычлыгы һәм читтән тыш киеренкелеге исәбенә түгел (андый хәл, мәсәлән, сугыш вакытында була), ә тотрыклы, гадәти, нормаль хуҗалык эшчәнлеге барышында җитештерүнең үсүенә ирешкәндә генә, икътисади үсеш турында сүз алып барырга мөмкин.





Икътисади проблемалар статистик тигезләнеш (сорау һәм тәкъдим) ягыннан гына (ә икътисадның органик үсеше ягыннан түгел) каралганда дөрес бәян ителмиләр.

Альфред Маршалл

§ 30. Икътисади үсеш нәрсә ул һәм аны ничек тизләтергә мөмкин

Без инде ачыклап үткәнчә, кешеләрнең ихтыяжлары чагыштырмача чиксез һәм алар даими үсештә: кеше үзенең бер ихтыяжын канәгатьләндерергә өлгерми, шунда ук яңалары барлыкка килә. Моннан тыш, кешелек дөньясының саны да даими арта.

Тарихчылар раславынча, халык саны 1 млрд ка житсен өчен кешелек дөньясына 10 000 елга якын вакыт кирәк булган. Әлеге вакыйга 1850 елда була. Ә аннары Җир шарында халык саны күпкә зуррак тизлектә үсә башлый: 1930 елда ул 2 млрд ка житә, ягъни нибары 80 ел эчендә халык саны 2 тапкырга арта. Тагын 45 елдан — 1975 елга Җир шарында инде 4 млрд кеше яши. Һәм демографлар исәпләвенчә, әлеге процесс акрынаймаса, 2020 елга дөньяда халык саны якынча 8 млрд ка житәчәк.

Әйтеп үтелгән ике факторның — кешеләр ихтыяжларының чагыштырмача чиксез булуы һәм дөньяның күпчелек илләрендә яшәүчеләрнең саны артуның бергә үрелеп баруы кешелек дөньясын байлыклар һәм хезмәт күрсәтүләр житештерүне даими арттыра барырга мәҗбүр итә. Менә шушы процесс **икътисади үсеш** дигән исем алган.

ИКЪТИСАДИ ҮСЕШ — илнең җитештерү мөмкинлекләренең елдан елга тотрыклы артуы.

Икътисади үсеш илгә төрле байлыклар һәм хезмәт күрсәтүләрне күбрәк житештерү мөмкинлеге бирә. Шунысы мөһим: барлык көчләрнең ашыгыч һәм чиктән тыш киеренкелеге исәбенә түгел (андый хәл, мәсәлән, сугыш вакытында була), ә тотрыклы, гадәти, нормаль хуҗалык эшчәнлеге барышында житештерүнең үсүенә ирешкәндә генә, икътисади үсеш турында сүз алып барырга мөмкин.

Инде билгеләп үтелгәнчә, икътисади үсеш тулай продуктның гомуми күләме артуда чагыла. Тулай продукт икътисади үсешнең һәм, димәк, ил гражданнарының тормыш муллыгын күтәрү максаты белән шартларны яхшыртуның объектив күрсәткече булсын өчен, аны исәпләүнең ике шартын үтәү зарур:

1) икътисади үсешне тулай продуктның реаль (ә номиналь түгел) күләме үзгәрү нигезендә бәяләргә кирәк. Тулай продукт күләменең ничек үсүе турындагы мәгълүматны гражданнарның реаль керемнәрен исәпләгәндәге кебек үк инфляция йогынтысыннан арындыру зарур;

14-1 рәсем.

Тизләнеш бирү факторлары йогынтысында икътисади үсеш закончалыкларының үзгәрүе

(1 — хезмәтнең капитал белән тәэмин ителеше үсү; 2 — фән һәм техника казанышлары нигезендә җитештерү технологияләрен камилләштерү; 3 — хезмәткәрләрнең белем дәрәҗәсен арттыру; 4 — чикләнгән ресурсларны бүлү ысулларын яхшырту; 5 — җитештерү масштабы эффекты чагылышы)

2) икътисади үсешне илдә җан башына туры килә торган тулай продуктның гомуми түгел, ә чагыштырмача зурлыгы үзгәрү нигезендә бәяләү яхшырак. Моның мәгънәсе шунда: тулай продукт зурлыгы (инфляцияне исәпкә алып төзәтмә кертүдән соң) илдә яшәүчеләр санына бүленә. Шунда гына уртача алганда илнең һәр гражданына туры килә торган «пирог кисәге»нең арту-артмавы ачыклана.

Әгәр дә ул «пирог кисәге» арткан икән, димәк, икътисади үсеш төп нәтиҗәне — ил гражданнары тормыш дәрәҗәсенең үсешен тәэмин иткән. Әгәр дә тулай продуктның җан башына исәпләнгән күләме кимесә, ил гражданнарының тормыш дәрәҗәсе дә начарлана. Бу исә илдә, гомумән, икътисади үсеш юк яки тулай продуктның гомуми зурлыгы үсү тизлеге илдә халык саны арту тизлегеннән кимрәк булуны белдерә.

Икътисади үсешне нинди факторлар исәбенә тизләтеп була соң?

Андый факторлар берничә һәм алар 14-1 рәсемдә схема рәвешендә күрсәтелгән.

1) *хезмәтнең капитал белән тәэмин ителеше үсү* — хуҗалык эшендә катнаша торган бер кешегә туры килә торган физик җитештерү капиталының уртача бәясе арту. Әгәр дә илдә саклык акчалар булса һәм ул акчалар ил икътисадына кертелсә, физик җитештерү капиталының (җитештерү биналары һәм җиһазларының) хуҗалык

эшчәнлегендә катнашучылар саны үсешенә караганда тизрәк туплануына ирешергә була.

Хезмәтнең капитал белән тәэмин ителеше үз нәүбәтендә хезмәт җитештерүчәнлеге үсүгә, димәк, ул җитештерүдә эшләүче кешеләр саны белән чагыштырганда җитештерелә торган байлыклар күләменең тизрәк артуына китерә (14-2 рәсем).

Әмма хезмәтнең капитал белән тәэмин ителеше үзе генә гражданнарның тормыш муллыгын икътисади үсеш нигезендә үстерү мөмкинлекләрен тәэмин итә алмас иде. Моның өчен башка факторларның да эшләве зарур;

2) *фән һәм техника алгарышы.* XX гасыр фәнни белемнәрнең нык артуы аркасында гына түгел, ә алардан товарлар җитештерүдә һәм хезмәт күрсәтүләрдә тиз һәм күпләп файдалану сәбәпле дә фән-техника революциясе гасыры булды. Боларның соңгысы күп технологияләрнең тамырдан үзгәрүенә һәм шуның нигезендә хезмәт җитештерүчәнлегенең гаять нык артуына китерде.

3) *хезмәткәрләрнең белем дәрәҗәсен арттыру.* «Белемле хезмәткәр — иң яхшы хезмәткәр». Бу хакыйкать бигрәк тә XX гасырда, хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруның төп двигателе фәнни-техник алгарыш казанышларын үзләштерү икәнлеге ачыклангач, үзен яхшы күрсәтте. Яңа, җитештерүчәнрәк җиһазлар белән эшләү, шулай ук яңа продукция эшләп чыгару күнекмәләрен тиз үзләштерү



14-2 рәсем.

Җыелган акчаларның һәм инвестицияләрнең хезмәтнең капитал белән тәэмин ителеше һәм байлыклар җитештерү күләме үсешен тизләтү факторлары буларак әһәмияте

ЭШЧЕ КУЛЛАР (КӨЧЛӘР) — кешеләрнең белем алу һәм эш тәҗрибәсе нәтиҗәсендә тупланган, өстәмә керем бирергә сәләтле белем һәм күнекмәләре.

һөнәри квалификация генә түгел, хезмәткәрләрнең белем дәрәҗәсен күтәрүне дә таләп итте.

Шуңа күрә XX гасырда икътисад фәненә **эшче куллар (көчләр) (человеческий капитал)** дигән төшенчә керде; аны арттыруга инвестицияләр еш кына икътисади үсешне физик капиталга салынган инвестицияләргә караганда күбрәк тизләтә;

4) *чикләнгән ресурсларны бүлү ысулларын яхшырту.* Ил үз карамагындагы житештерү ресурслары (квалификацияле эшчеләр саны, файдалану өчен яраклы жирләр мәйданы яки табигый байлыклар) күләмен тиз генә арттыра алмый (кайчак бу озак вакытка исәпләнгән перспективада да мөмкин булмый). Әмма чикләнгән ресурслардан яхшырак яки начаррак файдаланырга мөмкин.

Бу исә әлеге илдә шушы ресурсларны житештерүнең төрле тармаклары һәм төрләре арасында бүлү ысулларына бәйле. Төрле икътисади механизмнарның максаты нәкъ менә шундый бүлүне оештырудан гыйбарәт. Илдә икътисади үсеш тизлегенә ирешүдә икътисади механизмнарны камилләштерү зур әһәмияткә ия.

5) *җитештерү масштабы эффекты чагылышы.* Җитештерүнең масштабын арттыру (продукцияне күпләп житештерүне оештыру нигезендә) ресурсларны экономияләү һәм продукция чыгаруны файдаланыла торган кайбер ресурсларның күләме артудан тизрәк үстерү мөмкинлеге бирә.

Мәсәлән, зур заводның иркен цехларында кечкенә предприятие цехларына сыймый торган куәтле җиһазлар урнаштырып була. Ул очракта зур завод цехының бер квадрат метрына (кечкенә предприятиедәгегә караганда) күбрәк эшләп чыгарылган продукция туры килер. Димәк, зур завод төзү, цехларның гомуми мәйданы шундый ук булса да, берничә кечкенә предприятие оештыруга караганда, продукция эшләп чыгаруны ныграк арттырыр. Шунлыктан эре житештерү предприятиеләре төзү икътисади үсешне тизләтүнең әһәмиятле чыганагына әверелде. Әмма житештерү масштаблары артык зур булмаска, монополия барлыкка китереп икътисади үсешкә тоткарлык ясамаска тиеш. Икътисади үсешнең экстенсив түгел, ә торган саен күбрәк интенсив юлдан баруы мөһим.

ЭКСТЕНСИВ ҮСЕШ (лат. extensivus — киңәюче) — үсешкә кулланыла торган факторларны (файдалы казылмаларның яңа ятмаларын эшче көчләр миграциясе һ.б.) арттыру исәбенә ирешү.

ИНТЕНСИВ ҮСЕШ (франц. intensio — киеренке) — киңәйтелгән кабат җитештерү — икътисади үсешнең сыйфат ягыннан яңа төре (продукция җитештерү күләмен яңа технологияләр, алдынгы техника, кадрларның квалификациясен күтәрү аша арттыру).

§ 31. XXI гасырда кешелек дөньясын нинди икътисади мәсьәләләр борчый

Моңа кадәр без проблемаларны микро- һәм макроикътисади дәрәҗәләрдә, ягъни аерым базарлар яки гомумдәүләт икътисады дәрәҗәләрендә өйрәндек. Болар бөтен дөнья икътисады — геоикътисад (лат. *«geo»* — җир) мәсьәләләре. Аларга халыкара сәүдәне һәм халыкара финанс мөнәсәбәтләрен оештыру да керә; әмма эш аларга гына кайтып калмый. Кешелек дөньясы XX гасырда аеруча кискен тойган һәм XXI гасырда кешеләр тормышына нык йогынты ясаячак тагын берникадәр мөһим мәсьәләләр бар.

Аларның беренчесе — дөньяның иң бай һәм иң ярлы илләрендә тормыш муллыгы дәрәҗәләре арасындагы «упкын»ның зурая баруы (14-3 рәсем).

Хәзерге вакытта дөньяның иң бай 25 иле өлешенә (аларга сәнәгать аеруча алга киткән илләр, шулай ук экспортка нефть чыгаручы Якын Көнчыгыш илләре керә) бөтендөнья тулай эчке продуктының 80 процентыннан артыгы туры килә, ә ул илләрдә яшәүче гражданнарның гомуми саны Җир шары халкының 17 % ын гына тәшкил итә. (Аларны кайчак «алтын миллиард» дип атыйлар, чөнки абсолют аңлатмада якынча саннары шуңа тигез.) Тормыш муллыгы дәрәҗәләрендәге төрлелек масштаблары кимеми, ә үсә («тигезсезлек кайчысы» ныграк киңәя).



14-3 рәсем.
Дөньяның иң бай илләрендә яшәүчеләр һәм планетаның барлык калган халкы арасында «тигезсезлек кайчысы»

Бу берничә сәбәп белән бәйле; аларның берсе — иң ярлы илләрдә халык санының алар житештерә торган тулай эчке продукт күләменә караганда тизрәк артуы. Соңгысы дөньяның иң алдынгы илләрендәгедән тизрәк үссә дә (1965—1987 елларда бер елга 3,2 һәм 2,3 %), балаларның күп тууы житештерү үсешенең бөтен нәтиҗәләрен юкка чыгара. БМО мәгълүматларына караганда, 1960 елда Җир шарының иң бай илләрендә гражданнарның керемнәре иң ярлы илләрдә яшәүчеләрнекеннән 30 тапкыр артыграк булса, 1989 елда ул инде 59 тапкырга артып киткән.

Кызганычка каршы, киләчәктә дә төрле илләрдә яшәүче кешеләрнең тормыш муллыгы дәрәҗәсен сизелерлек тигезләүгә ирешү мөмкинлеге күренми. Моның өчен (хисаплаулар күрсәтүенчә) ресурсларны куллану дәрәҗәсен 40 тапкыр арттырырга кирәк. Әмма хәзерге фәнгә әлеге мәсьәләне хәл итәрлек технологияләр билгеле түгел. Моннан тыш, андый «сикереш» ясау өчен планетадагы ресурслар да житмәскә мөмкин.

Әлбәттә, тормыш байлыклары житештерүдә ресурсларның күп кулланылуын киметергә була, моның өчен мөмкинлекләр дә гаять зур. Мәсәлән, ресурслардан сакчыл файдалану технологияләре аркасында ТЭПның 1 долларын житештерү өчен АКШта хәзер суны Россиядәгегә караганда 6 тапкыр кимрәк кулланалар. Әмма андый технологияләрне үзләштерү зур инвестицияләр таләп итә; иң ярлы илләр үсештә артта калганлыктан, аларны гамәлгә ашыра алмыйлар.

XX гасырда дөньяның иң бай илләре мондый котылгысыз кыен хәлдән чыгу максаты белән иң ярлы илләргә үсеш программаларын гамәлгә ашыру өчен бурычка акча средстволары биреп торырга тырышып карадылар. Әмма финанс ярдәме күрсәтүнең андый программалары сизелерлек нәтиҗә бирмәде.

Дөньяда әле хәзергәчә хәтта массакүләм ачлыкны булдырмау мәсьәләсен дә хәл итүгәирешелгәне юк. Шул ук вакытта азык-төлек һәм авыл хуҗалыгы буенча БМО мәгълүматларына караганда, 2004 елда дөнья крестьяннары беренче мәртәбә 2 млрд т бөртекле ашлык җыеп алдылар, ул кешенең туклану рационының яртысын диярлек тәэмин итәргә житә. Хәзерге вакытта Җир шарында яшәүче һәр кешегә якынча 322 кг җыелган ашлык туры килә. БМО белгечләре фикеренчә, кешенең минималь рационы бер көнгә 2350 калориядән торырга тиеш. Ә дөньяда туклану продуктлары житештерү күләме инде хәзер үк планетада җан башына 2805 калория булдырырга мөмкинлек бирә. Бу исә минимумнан 20 %ка артык.

Шуңа карамастан дөньяда ачлыктан интегүчеләрнең саны арта. Хәзерге вакытта 852 млн га якын кеше (аларның һәр алтысының берсе — балалар) ачлыктан җәфа чигә. Әлеге сан 1990 еллар уртасындагы күрсәткечтән 18 млн га артыграк. БМО белгечләре мондый нәтиҗәгә килделәр: ачлыкның төп сәбәбе житештерелгән азык-төлекнең житмәвендә түгел. Ачлыктан интегүчеләрнең йә ашамлыклар сатып алу өчен средстволары яки үзләре карамагындагы җирне эшкәртү өчен ресурслары юк.

Хроник ачлык дөньядагы күп илләрнең үсеше әкренәюгә сәбәп булды, чөнки аларда сәламәт булмаган һәм кагыйдә буларак, аз белемле буын үсә. (2002 елда ЮНИСЕФ киң күләмдә үткәргән тикшерену нәтиҗәләрен бастырып чыгарды; ул электән билгеле хакыйкатьне раслады — житәрлек тукланмаучы балалар тиешенчә тукланучы яшьтәшләренә караганда начаррак укыйлар.) Пакистанда үткәрелгән тикшерену шуны күрсәтте: ярлы гаиләләрне азык-төлек белән тәэмин итүне яхшыртканда, мәктәпләргә малайлар — 4 %ка, ә кызлар 19 %ка күбрәк бара.

Бу исә теләсә кайсы илнең киләчәктәге үсешенә нигез була. ЮНИСЕФ мәгълүматлары күрсәтүенчә, фермер дүртьеллык минималь мәктәп белеме генә алган булса да, ул үзенең бөтенләй надан күршесенә караганда продукцияне 8,7 %ка артыграк житештерә. Угандада үткәрелгән тикшерену тагын бер әһәмиятле тенденцияне ачыкларга ярдәм итте: урта мәктәп тәмамлаган егетләр һәм кызлар СПИД ны 50 %ка сирәгрәк йоктыралар. Ә югары белемгә ия булучыларда әлеге «XX гасыр афәте»н йоктыру ихтималы белемсез яшьтәшләренә караганда 90 %ка кимрәк.

Шунысы гажәп: БМО бәяләре буенча дөньяның барлык илләрендә үз халыклары ихтыяжларын канәгатьләндерерлек азык-төлек житештерергә мөмкинлек бирерлек потенциал бар. Ә планетада һәр кешегә бер көнгә 3500 калория тәэмин итәргә житәрлек азык-төлек житештерелә (әле моңа ит, яшелчә, жиләк-жимеш, балык һәм башка кайбер продуктлар кертелмәгән). Шуның белән бергә, мәсәлән, 2002 елда дөньяның 54 иле (башлыча Африкадагы илләр) үз гражданнарын туйдырырга сәләтле булмаган.

Проблема исә шунда: житәрлек азык-төлек сатып алу кешеләрнең матди хәленнән килми. «Өченче дөнья» илләрендә халык санының бик тиз артуы житди куркыныч тудырса да, халык саны арту беркайчан да һәм беркайда да ачлык барлыкка китермәде. Ачлык социаль һәм икътисади тигезсезлек тудыра; халык саны арту илдә яшәүчеләрнең күпчелегенә белем бирү, медицина, эш урыннары, социаль тәэминат системаларыннан файдалану мөмкинлеге бирүче дәүләти һәм социаль механизмнар булмаган илләрнең халыклары өчен куркыныч.

Дөньяда ачлык проблемасын хәл итәрлек программаларның финанс бәясе чагыштырмача зур түгел. БМО бәяләвенчә, моның өчен бер елга 13 млрд чамасы доллар кирәк. Мәсәлән (чагыштыру өчен), Стокгольмдагы Дөньяны тикшерү институты мәгълүматлары буенча, дөньядагы илләр 2003 елда хәрби ихтыяжларга 932 млрд доллар тотканнар. АКШта һәм Европа берлеге илләрендә яшәүчеләр этләр, мәчеләр һәм аквариум балыклары сатып алуга бер елда 14,6 млрд доллар сарыф итәләр.

Алга киткән илләр житәрлек средстволар бүлү генә түгел, ул акчалардан нәтижәле файдалану һәм миллиардка якын кешене ачлыктан, үлем хәвефеннән коткару ысулларын таба алырлармы — моны киләчәк күрсәтер. Шунысы ачык билгеле: әлеге проблеманы хәл итүне кичектерү бөтен планетада тотрыклылыкка куркыныч тудыра.

БҮЛЕКНЕҢ ТӨП ЭЧТӘЛЕГЕ

Икътисади үсеш нәрсә ул һәм аны ничек тизләтеп була? *Кешеләрнең ихтыяжларын тулырак канәгатьләндерү өчен һәр илгә үз житештерү мөмкинлекләрен даими үстерергә тырышырга туры килә. Ул процесс «икътисади үсеш» дип атала. Икътисади үсешнең иң төгәл үлчәме — тулай милли продуктның җан башына туры килә торган зурлыгы үзгәрү, ягъни бер кешегә (уртача) туры килә торган продукт. Әгәр дә ил хуҗалыгының житештерүчәнлеге халык саныннан әкренрәк үсә икән, уртача продукт кими, һәм ул (иң начар очракта) ярлылыкка*

һәм ачлыкка, ә аннары халыкның бер өлеше үлүгә китерәчәк. Икътисади үсешне тизләтү, шулай ук балалар тууны көйләү кешелек дөньясын шундый бәладән коткарырга ярдәм итә. Икътисади үсешне тизләтүгә, барыннан да элек, җитештерү ресурсларыннан файдалануның күләмен арттыру исәбенә ирешергә мөмкин. Бигрәк тә хезмәтнең капитал белән тәэмин ителешен көчәйтү; фән һәм техника казанышлары нигезендә технологияләрне камилләштерү; чикләнгән ресурсларны бүлүгә ярдәм итүче икътисади механизмнарны яхшырту; хезмәткәрләрнең белем дәрәҗәсен күтәрү һ.б. факторлар үсешне тизләтергә зур мөмкинлекләр ача. Әлеге факторлар интенсив үсешне тәэмин итә, ә аның әһәмияте арта бара. Нәкъ менә интенсив үсеш аша халык саны арту һәм җитештерү факторларының нәтиҗәлелеге кимү аркасында килеп чыгучы ачлык куркынычын булдырмый калырга мөмкин.

XXI гасырда кешелек дөньясын нинди икътисади проблемалар борчый. *Геоикътисадның төп проблемасы — дөньядагы иң бай һәм иң ярлы илләр тормыш муллыгы дәрәҗәләре арасындагы упкынның үсүе. Моның төп сәбәбе — иң ярлы илләрнең халкы алар җитештерә торган тулай эчке продукт күләменнән тизрәк арта. Якын киләчәктә төрле илләрдә яшәүчеләрнең тормыш муллыгы дәрәҗәсен сизелерлек тигезләү мөмкинлеге күренми. Кешелек дөньясы хәзер үз үсешенең гаять кыен чигендә. Аңа принципта яңа, моңа кадәр булмаган нәтиҗәле, ресурслардан сакчыл файдалануга корылган җитештерү технологияләре табарга кирәк яки бай һәм ярлы илләр арасындагы каршылыклар алга таба да үсәчәк.*

ФИКЕР АЛЫШУ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Тулай милли продуктның (ТМП) гомуми зурлыгы һәм җан башына туры килүче ТМПның уртача зурлыгы арасындагы аерма илнең халык санынннан тизрәк үссә, бу ил икътисады турында нәрсә әйтеп була?
2. Ни өчен хәзер Россия өчен бердәнбер кулай вариант булып интенсив икътисади үсеш тора?
3. 30—50 нче еллар дәвамында СССРда икътисади үсешнең акрынаюы яки житештерүнең нык кимүе күзәтелмәде. Нинди сәбәпләр аркасында шулай булган?

Халыкара сәүдәне оештыру

БҮЛЕКТӘ КАРАЛУЧЫ МӘСЬӘЛӘЛӘР:

1. НИ ӨЧЕН ИЛЛӘР БЕР-БЕРСЕ БЕЛӘН СӘҮДӘ ИТӘ?
2. ПРОТЕКЦИОНИЗМНЫ НӘРСӘ БАРЛЫККА КИТЕРӘ?
3. ВАЛЮТА БАЗАРЫ НИ ӨЧЕН КИРӘК?
4. РОССИЯ КЕМ БЕЛӘН ҺӘМ НӘРСӘ БЕЛӘН САТУ ИТӘ?

Давид Рикардо халыкара сәүдәнең төп хәрәкәтләндерүче көчен ача; ул — чагыштырма чыгымнар (чагыштырма өстенлек) принцибы. Д. Рикардо алдан күреп әйткәнчә, мондый сәүдә анда катнашучыларның барысы өчен дә файдалы булганлыктан, цивилизацияле милләтләрне бер бөтендөнья җәмгыятенә берләштерәчәк.

Абсолют өстенлек принцибы шуннан гыйбарәт: һәрбер ил үз партнерларына караганда ресурсларга абсолют кимрәк чыгымнар тотып товарлар җитештерүдә махсуслаша икән, алар бер-берсе белән сәүдә итүдә оталар.

Тышкы сәүдәдән бердәнбер
отыш импорттан гыйбарәт.
Джон Стюарт Милль

§ 32. Халыкара сәүдә һәм аның ил икътисадына йогынтысы

Без инде искә алып үткәнчә, халыкара сәүдә — икътисади эшчәнлекнең иң борынгы төрләреннән берсе.

Озакка сузылган тикшеренүләр нәтиҗәсендә икътисадчы галимнәр халыкара сәүдәнең төп сәбәпләрен ачыкладылар. Символик рәвештә алар 15-1 рәсемдә күрсәтелгән; алга таба аларның һәрберсенә җентекләбрәк тукталырбыз.

Табигый ресурсларны (байлыкларны) тигезсез бүлү. Халыкара сәүдә барлыкка килү сәбәпләренең иң беренчесе табигать белән бәйле: ул — төрле илләр һәм халыклар арасында табигый ресурсларны тигезсез бүлү. Әгәр дә бер илдә нефть, икенчесендә хром ятмалары бар икән, аларның икесендә дә автомобильләр өчен детальләр хромланган корычтан эшләнсен, ә автомобильләргә ягулык салу станцияләрендә бензин булсын өчен, әлеге илләр нефтьне хромга алмаштырып, бер-берсе белән сәүдә итәргә тиеш булалар. Нәкъ менә шушы модель буенча Россия чит илләргә нефть һәм кара урлдык чыгара, ә үзенә, мәсәлән, банан һәм ананас кертә.



15-1 рәсем.
Халыкара сәүдәнең икътисади нигезләре

Әмма әлеге мантыйк илләрнең ни өчен үзләре җитештерә ала торган товарларны да сатып алуларын аңлатмый. Мәсәлән, америкалылар үзләрендә күчле автомобиль һәм телевизорлар җитештерү промышленносте булуга карамастан, Япония автомобильләрен һәм телевизорларын сатып алалар (импортлыйлар).

Статистикага караганда, автомобильләр Америка **импортының** 21, **экспортының** 11 %ын тәшкил итә. Үз илендә җитештерелгән яхшы сыйфатлы автомобильләрне саткан акчага чит илләрдән автомобильләр сатып алуның мәгънәсе нәрсәдә соң?

ИМПОРТ — бер илдә ишәүчеләрнең башка дәүләтләрдә җитештерелгән товарларны сатып алуы.

ЭКСПОРТ — үз илендәге икътисад тармакларында җитештерелгән товарларны башка илләрдә яшәүчеләргә сату.

Абсолют өстенлек принцибы. Шушы принципны аңлатырга теләп, икътисад фәне башта бер үк төрле продуктлар җитештерү өчен чыгымнарның абсолют төрлелегенә игътибар итте.

Мәсәлән, житен һәм шикәр чөгендере җитештерүгә чыгымнарның Россиядә һәм Украинада күпме булуын чагыштырып карыйк. Туфрак һәм климат шартлары үзгә булганлыктан, Украинада җитен 1 гектардан Россиядәгегә караганда күпкә кимрәк уңыш бирә, ә соңгысында, киресенчә, җылылык җитмәү сәбәпле, шикәр чөгендере уңышы кимрәк. Әгәр дә шушы илләрнең һәрберсе үзенекендә махсуслашса, ә аннары хезмәт нәтиҗәләрен үзара алмашсалар, ике халык та отачак. Алар сөрү җирләреннән нәтиҗәлерәк файдаланачак.

Менә шуңа күрә дә СССР заманында Россия җитен үстерүдә махсуслашкан. Һәм ул Украинага җитен тукымалар илтә, ә шикәрне шундагы басуларда үстерелгән чөгендердән җитештерүче Украинадан ала иде.

Икътисадчылар телендә җитештерү һәм сәүдәнең мондый халыкара махсуслашуы **абсолют өстенлек принцибы** дип атала.

АБСОЛЮТ ӨСТЕНЛЕК ПРИНЦИБЫ — әгәр дә илләр, үзләренең сәүдә партнерларына караганда абсолют кимрәк чыгымнар белән җитештерә ала торган товарларда махсуслашсалар, бер-берсе белән сәүдә итүдән оталар.

Абсолют өстенлек принцибы нигезендә махсуслашу бөтен кешелекнең Җир шарындагы ресурсларны нәтиҗәле файдалануда иң югары ноктага җитүенә китерә. Нәтиҗә буларак барлыкка килүче бөтендөнья хуҗалыгы товарларның һәр төрен моның өчен иң аз ресурслар сарыф ителә торган илдә җитештерүне тәэмин итә. Шуңа күрә халыкара сәүдәнең үсүе планетадагы барлык илләр өчен зур әһәмияткә ия һәм моңа хөкүмәтләр дә, халыкара оешмалар да зур игътибар бирәләр.

Чагыштырма өстенлек принцибы. Табигый байлыкларның тигезсез бүленүе һәм абсолют өстенлек принцибы турында белеп кенә, халыкара сәүдәнең мантыйгын аңлап булмый.

Икътисад фәнендә бу мәсьәлә XIX гасыр башында күп илләрдә беренчел индустрияләштерү тәгәлләнгәч үк ачыкланды. Кайбер илләр ул чорда лидерларга әверелде, һәм аларның төрле тармакларда продукция житештерүгә киткән чыгымнары азрак үсешкә ирешкән илләрнекеннән түбәнрәк булды. Әгәр дә халыкара сәүдә әлеге шартларда абсолют өстенлек принцибы нигезендә генә үссә, лидер илләр товарларны кимрәк үсешкә ирешкән илләрдән алуны туктатырлар иде. Ә мондый хәл булмады.

Халыкара сәүдә серләрен аңлауда чираттагы адымны инглиз икътисадчы галиме Давид Рикардо (1772—1823) ясады. Ул тышкы сәүдә үсешендә тагын бер принципны — **чагыштырма өстенлек принцибын** күрә алды.

ЧАГЫШТЫРМА ӨСТЕНЛЕК ПРИНЦИБЫ — һәр ил өчен (башка илләрдәгегә карaганда) сайлау бәясе чагыштырмача түбән булган товарларны экспортлау отышлырак.

Башкача әйтсәк, һәрбер илгә товарлар сатылачак илләрдәгегә караганда кимрәк сайлау бәясе таләп итеүә торган товарларны житештерүдә махсуслашу кулай.

Чынлыкта сәүдә эшендә беркем дә, әлбәттә, андый фәнни хисап алып бармый. Аларны тулысынча эчке һәм чит ил базарларындагы бәяләр нисбәте алмаштыра, чөнки ул нисбәт (башка шартлар тигез булганда) товарлар житештерүнең чагыштырма нәтижәлелеге аермаларына туры килә.

Шундый хәлне күз алдына китерик: 1 т цементның һәм 1 кв м пыяланың бәясе Россиядә 5 мең сум. Украинада 1 т цемент — 20 мең, ә пыяла 40 мең гривен тора. Россия эшмәкәре Украинага 1 $м^2$ пыяла экспортласа, төшемгә (40 мең гривен) ул 2 т цемент (ә Россиядә — 1 т) сатып ала.

Әгәр дә ул шул цементны Россиягә импортласа, аның өчен Украинага экспортланган пыяла житештерүгә баштагы чыгымнардан ике тапкыр артыграк — 10 мең сум алыр. Әлеге суммалар аермасы, ягъни 5 мең сум (10—5) икътисади яктан белемле эшмәкәрнең табышы булыр.

Мондый хисаплау үтә нык гадиләштерелгән булса да, бөтен тышкы сәүдә эшчәнлеге шундый анализ ясаганда төзелә. Теләсә кайсы эшмәкәр бик гади фикер йөртә: чит илләргә шундый товарлар чыгарырга кирәк ки, аларны сатудан төшемгә чит илдә шундый ук жирле товарларны үзебезнең базарларда алырга мөмкин булганнан күбрәк сатып алырлык булсын.

Гаять зур тышкы сәүдә фирмалары үзләренең сәүдә эшләрен нәк шулай оештыра. Алар барысы да үз эшчәнлекләрендә чагыштырмача өстенлек принцибыннан чыгып эш итәләр. Тышкы сәүдәнең мондый мантыйгы кичекмәстән эчке икътисади тормышта чагыла. Сәүдәгәрләр мәнфәгатьләре һәр илне:

1) анда булган ресурслардан рациональ файдалану;

2) экспорт һәм импорт эшләре аша икътисадны үз гражданнарына иң югары тормыш дәрәжәсенә ирешү мөмкинлеге бирерлек итеп махсуслаштыру юлын эзләүгә этәрә.

Мондый махсуслаштыру процессы дөнья базары үсеше өчен генә түгел, хезмәтне *халыкара бүлү һәм кооперацияләү* (ягъни төрле илләр фирмаларының соңгы

куллану байлыклары житештерүдә бергәләп эшләвен оештыру) өчен дә нигез була. Хезмәтне халыкара бүлүнең никадәр тирән булырга мөмкин икәнлеге түбәндәге мисалдан күренә.

АКШта яшәүче кеше, Америкадагы «Дженерал моторс» компаниясеннән анда житештерелгән «Понтиак» автомобилен сатып алганда, чынлыкта халыкара килешүне үти. Машина өчен ул 10 мең доллар түли, ә ул акча тагын бүленә: 3 мең доллар гади һәм күп хезмәт таләп итә торган жыю эшләре башкарылган Көньяк Кореяга; 1850 доллар — моторлар, хәрәкәтләндерүче мостлар, электрон жайланмалар өчен Япониягә китә; 700 долларны әлеге машинаның конструкциясен эшләгән өчен Германия ала; 450 доллар вак детальләрне эшләгән Тайвань, Сингапур һәм Гонконг фирмаларына күчерелә; 250 доллар реклама һәм автомобильләрне сатуны оештырган Англия фирмаларына жибәрелә; мәгълүматларны эшкәртү белән шөгыльләнгән Ирландия һәм Барбадос фирмалары күрсәткән хезмәт 50 долларга төшә. Барлыгы якынча 6 мең долларны башка илләрнең гражданнары ала.

АКШ гражданнары — «Дженерал моторс» идарәчеләре һәм акционерлары, фирмага хезмәт күрсәтүче адвокатлар һәм банкирлар, әлеге «Америка» автомобилен житештерүдә катнашучы башкалар өлешенә 4 мең доллар гына туры килә.

Халыкара сәүдә, әгәр дә ул чагыштырма өстенлек принцибына нигезләнсә һәм үз юлында берниндн каршылыкларга очрамаса, анда катнашучыларның һәммәсе өчен дә отышлы була.

Шулай да халыкара сәүдә үсеше һәрчак төрле каршылыкларга очраган. Аларның сәбәпләрен аңлау өчен, моннан 100 ел элек француз икътисадчысы Фредерик Бастиа (1801—1850) үзенең «Икътисади софизмнар» дигән китабы өчен язган хат белән танышыйк.

ДЕПУТАТЛАР ПАЛАТАСЫНА

Без яктылык чыгаруда гаять зур өстенлекле җиһазларга ия булган чит көндәш ягыннан көчле конкуренциягә дучар. Ул үз товарларын түбәнрәк бәяләр белән тәкъдим итеп, безнең гомумдәүләт базарын басып китәргә мөмкин. Ул көндәш — Кояш. Без петиция белән мөрәҗәгать итәбез: гадәттә, кояш нурлары безнең тармакларыбызга үтеп керә, һәм шуның белән безгә илне баету мөмкинлеге биргән табышлы җитештерүгә зыян китерә торган барлык тәрәзәләрне, тишекләрне ябу турында закон кабул итәргә.

Шәмнәр һәм шәмдәлләр җитештерүче фабрикантлар

Әлбәттә, Кояш яктылыгы белән көрәшү беркемнең дә башына килми. Әмма шундыйрак өндәүләр дөньядагы илләрнең хөкүмәтләренә таныш. Бизнесменнар, дәүләтне чит ил конкурентларына гомумдәүләт базарына юлны ябарга мәжбүр итү өчен, гаять зур көч куялар. Шул таләпләр басымы астында күп илләрнең хөкүмәтләре азмы-күпме активлык белән **протекционизм** (лат. *protectio* — ышыклау, канат астына алу) сәясәтен үткәрәләр.

ПРОТЕКЦИОНИЗМ — дәүләтнең илебез товар җитештерүчеләрен импортка төрле чикләүләр кую аша башка ил фирмалары конкуренциясеннән саклауга юнәлтелгән икътисади сәясәте.

Эчке базарга чит ил җитештерүчеләренең товарлары үтеп керү — күп илләрдә икътисади һәм сәяси каршылыкларның даими чыганагы. Хөкүмәт үз икътисади сәясәтен базарларда чит ил товарлары булудан отарлык, әмма оттырмаслык итеп корырга тиеш. Эчке базарда арзан чит ил товарлары пәйда булуның уңай һәм тискәре якларын карап үтик (15-1 табл).

Ул таблицаны анализлап, без ил гражданнарының төрле төркемнәренә хас икътисади мөнфәгатьләр арасындагы классик каршылыкны күрәбез.

Таблица 15-1

Чит ил җитештерүчеләре товарларына эчке базар ачуның уңай һәм тискәре якларына чагыштырма анализ

ПЛЮСЛАР	**МИНУСЛАР**
1) Гражданнар күбрәк товар сатып алу мөмкинлегенә ия булалар.	1) Үз илебез товарларын сату мөмкинлеге кими.
2) Сәүдә фирмаларының керемнәре арта, һәм дәүләт алардан зуррак суммада салымнар ала.	2) Үз илебез фирмаларының керемнәре кими, һәм дәүләт алардан кимрәк суммада салым ала.
3) Сатып алучылар импорт товарларын алганда түли торган салымнар суммасы арта.	3) Ил сәнәгатендә эштән азат итүләр башлана, эшсезлек арта, бу исә хезмәт хакыннан керемнәргә салымның кимүенә, эшсезлек өчен пособиеләрнең артуына китерә.
4) Эш урыны булган кешеләрнең тормыш дәрәҗәсе үсә, импорт товарлары сатып алу мөмкинлеге арта, эчке сәяси хәл яхшыра һәм хакимлек итүче партиянең чираттагы сайлауларда җиңү ихтималы арта.	4) Эшсезләр һәм ил фирмалары хуҗалары хөкүмәт сәясәтенә каршы чыгалар, һәм бу аның хакимиятне үз кулында калдыруга ышанычын киметә.
	5) Илнең товарларны чит илләрдән кертүгә бәйлелеге арта, бу исә аның сәяси бәйсезлеген киметергә мөмкин.

Тармак лоббилары (икътисади яктан көчле структуралар вәкилләре төркемнәре) басымы астында Россия хөкүмәте илебез товар житештерүчеләрен тулысынча һәм тиз арада бөлүдән саклау чаралары күрергә мәжбүр. Моның өчен дәүләт тарафыннан төрле импортны көйләү чаралары күрелә. Шундый көйләү чараларының киң таралганы һәм сыгылмалысы — дәүләт чиге аша узганда, чит илдә житештерелгән һәм сату өчен илгә кертелә торган товар хужасыннан дәүләт файдасына алына торган салым — **таможня пошлинасы**.

Пошлинаны түләгәч, илгә кертелә торган товар хужасы аңа бәяне арттырырга мәжбүр була, чөнки аңа зыян күрүне булдырмый калырга һәм табыш алырга кирәк. Нәтиҗәдә чит ил товары кыйммәтләнә һәм аңа конкурентлык сәләте бирә торган чагыштырма өстенлекнең бер өлешен югалта.

Мондый пошлиналарның кертелүе сатып алучыларның яңа — аерым — ил сәнәгатенең билгеле тармагына булышлык күрсәтү салымы түли башлавын белдерә. Ул тармак товарлары әллә ни көч куймыйча да конкуренциягә сәләтле була: чыгымнарны киметергә дә, сыйфатны яхшыртырга да, сатудан соңгы хезмәт күрсәтүне камилләштерергә дә кирәк түгел. Товарлар үзеннән-үзе чит ил конкурентлары аягындагы «пошлина герләре» исәбенә сатыла.

Әмма игътибар бирүне сорый торган тагын бер әһәмиятле аспект бар. Эш шунда: әгәр чит ил фирмалары безнең эчке базарларда сатудан керемне азрак алалар икән, безнең товарларны үз илләренә кертү өчен аларның акчалары да азрак булачак.

Башкача әйткәндә, таможня пошлиналары кертү илебез сәнәгатенең кайбер тармаклары өчен базарны киңәйтсә, бер үк вакытта башкалар өчен ул аны тарайта. Икътисадчылар: *«Әгәр дә без үзебезнең импорт турында кайгыртсак, безнең экспорт үзе турында үзе кайгыртачак»*,— дигәндә нәкъ менә шул күздә тотыла.

Протекционизм шундый борынгы сәясәт ки, икътисад фәне аның барлык «плюслары»н һәм «минуслары»н җентекләп өйрәнергә өлгерде инде. Нәтиҗә һәрчак бертөрле: ил сәнәгатенең кайсы да булса бер тармагына чит ил конкурентлары белән көрәштә ярдәм итәргә житди сәбәпләр булса да, моны импортны чикләү аша эшләмәгәндә яхшырак. Әлеге тармакларның илебездәге фирмаларына субсидияләр бирү күпкә нәтиҗәлерәк.

Эчке базарны һәм үз иле житештерүчеләрен саклау өчен, хөкүмәтләр протекционизмның «импорт квоталары» һәм «лицензияләр» дигән чараларыннан файдаланалар.

Импорт квотасы — билгеле бер житештерүче илдән бер елда билгеле товарларны илгә кертүнең хөкүмәт тарафыннан билгеләнә торган чик зурлыгы ул.

Тышкы сәүдә лицензиясе эчтәлеге белән квоталарга якын; ул — товарларның билгеле төрен илгә кертү яки илдән чыгару өчен дәүләт бирә торган рөхсәтнамә.

Импорт квоталары — базарны саклауның иң тупас ысулы. Башка илләр хөкүмәтләре аңа җавап йөзеннән кискен чаралар күрәләр, илләренә кертелә торган товарларга үз якларыннан да шундый ук квоталар билгелиләр.

«Сәүдә сугышлары»ның күптәннән килә торган тәҗрибәсе ныграк үсеш алган илләрне әлеге «сугышлар»да ике якның да җиңелүен аңлый белергә өйрәтте; андый «сугыш хәрәкәтләре»н башламау хәерлерәк. Болар барысы да, тотрыклы икътисади үсеш өчен халыкара сәүдәнең әһәмиятен аңлау белән берләштән, күп илләрне XX гасырда протекционизмнан ваз кичәргә, дөнья базарын оештыруның яңа ысулларын эзли башларга мәжбүр итте.

1947 елда 23 ил Тарифлар һәм сәүдә итү турында генераль килешүгә кул куйдылар (аны еш кына инглизчә язудагы беренче хәрефләрдән — *General Agreement on Trade and Tariffs* — ГАТТ дип атыйлар). ГАТТның нигезендә халыкара сәүдәнең күпгасырлык тарихы барлыкка китергән өч принцип ята:

1) ГАТТта катнашучы барлык илләр бер-берсенә карата, башкалар белән чагыштырганда бер яки берничә илнең хокукларын чикләмичә, бер үк экспорт һәм импортны көйләү чараларын күрәләр;

2) барлык илләр үзләренең чагыштырма өстенлекләреннән һәм хезмәтне халыкара масштабта рациональ бүлүдән тулырак һәм төгәлрәк файдалану юлын ачу өчен, таможня пошлиналарын киметергә омтылалар;

3) ГАТТта катнашучы илләр үз базарларын саклауның иң тупас формасыннан — импорт квоталарыннан ваз кичәләр.

Хәзерге вакытта шундый Килешүгә 100 дән артык ил кул куйды инде. Аның нәтиҗәлелеге ГАТТ әгъзалары булган илләрдә таможня пошлиналарының кимүендә күренә. Мәсәлән, 80 нче елларда сәнәгать нык үскән илләрдә чималга уртача импорт тарифы — 2,5 тән 1,6 %ка, ә сәнәгать продукциясенә 10,5 тән 6,4 %ка кадәр кимеде. ГАТТның уңышлары аның нигезендә Бөтендөнья сәүдә оешмасы (БСО) төзүгә китерде, аңа хәзер Россия дә керергә тырыша. Моның өчен озакка сузылган һәм авыр сөйләшүләр алып бара.

Мондый омтылышның сәбәбе гади: бер-берсенә карата цивилизацияле сәүдә принципларын үти барып, ГАТТ/БСО әгъзалары булган илләр әлеге Килешүдә катнашмаучы илләргә карата үзләрен бөтенләй башкача тоталар. Һәм бу Россия өчен кулай түгел. Ул — хәзергә дөнья базарында аутсайдер, ягъни соңгы урыннарның берсен алып торучы. Һәм Россия товарларына, демпингка каршы чаралар күрү сылтавы белән, чикләүче пошлиналарны АКШ та, Европа берлеге, Мексика, Бразилия, Һиндстан, Польша да кертә.

ДЕМПИНГ — товарны җитештерү чыгымнарыннан түбәнрәк яки билгеле бер базарда урнашканнан сизелерлек түбән бәягә сату.

Үзенең чит илләргә чыгарыла торган товарларына шундый киртәләр куелу нәтиҗәсендә Россия һәр елны сатудан төшемнең 2,5–3 млрд долларга якынын югалта. Россия товарларына чиктән тыш югары пошлиналар куюның һәр очрагы турында сөйләшүләр алып бару мөмкин түгел. БСОга керү генә моннан котылу чарасы була ала, әмма ул да эчке базарны пошлиналар ярдәмендә саклаудан ваз кичүне таләп итәчәк.

Россиянең БСОга кушылуы турында сөйләшүләр 1995 елдан бирле бара һәм шушы елларда безнең илдә мондый адым тарафдарлары һәм аңа каршы чыгучылар арасында кызу бәхәсләр дәвам итә. БСОга кушылу тарафдарлары үз оппонентларының игътибарын шуңа юнәлтә: дөньяның 146 иле (планетадагы барлык илләр диярлек) БСО әгъзалары булдылар инде, күптән түгел Непал һәм Камбоджа кабул ителде. Якындагы елларда БСОда әгъза булып торучы илләр саны артачак. Шунлыктан дөньякүләм сәүдәдә тигез хокуклы катнашырга теләүче теләсә кайсы ил БСО әгъзасы булырга омтыла. Моннан тайпылуның Россия өчен дә аерым мәгънәсе юк, чөнки экспорт безнең ил икътисадында гаять зур әһәмияткә ия.

Россия БСОга кушылса, ул:

— Россия товарларын чит ил базарларына хәзергеләре белән чагыштырганда яхшырак һәм чикләүләрсез кертү мөмкинлеге алачак;

— сәүдәгә бәйле бәхәсләрне хәл итүнең халыкара механизмнарыннан файдаланачак;

— чит ил инвестицияләре өчен уңайлы шартлар тәэмин итәчәк;

— Россия фирмаларының БСО әгъзасы булган илләрдә эш алып бару мөмкинлекләрен киңәйтәчәк;

— чит ил товарлары, хезмәт күрсәтүләре һәм инвестицияләрнең Россия базарына агымын арттыру нәтиҗәсендә илебездә җитештерелә торган продукциянең сыйфатын яхшырту һәм конкурентлык сәләтен арттыру өчен шартлар тудырачак;

— халыкара сәүдә кагыйдәләрен эшләүдә үзебезнең гомумдәүләт мәнфәгатьләрен истә тотып катнаша алачак;

— дөньяда үзенең «халыкара сәүдәдә катнашучы» дигән абруен яхшыртачак.

Мондый адымга каршы чыгучылар да бар: Россиянең БСОга керүе илебез җитештерүчеләре белән икътисади яктан алга киткән Көнбатыш һәм Көнчыгыш илләре фирмалары арасындагы конкурентлык көрәшенең кискенләшүенә китерәчәк. Шул ук вакытта Россия төньяктагы ил һәм андагы һава шартларында эшләү җылытуга, яктыртуга гына түгел, ә илнең һәм аның предприятиеләренең базарда конкуренциягә сәләтле булуын тәэмин итәрлек җитештерү куәтләре төзүгә һәм аларның эшләрен дәвам иттерүгә зур чыгымнар таләп итә. Шуның нәтиҗәсендә безнең ил фирмаларының чыгымнары зуррак була; БСОга кергәннән соң ачык икътисад шартларында алар тиз арада бөләргә, ә хезмәткәрләре эшсез калырга мөмкин.

Хәзер Россия хөкүмәте илнең нинди шартларда БСОга кушылуын тормышка ашырып булуы турында катлаулы сөйләшүләр алып бара, ягъни әлеге оешмага керүдән өстенлекләр алуның һәм моның бәрабәренә чит ил товарларын кертүгә тарифларны киметү, эчке базарларны ачу рәвешендәге ташламаларның отышлырак нисбәтенә ирешергә омтыла.

Шунысын да истә тотарга кирәк: дөнья икътисадында (әле илләрнең үз мәнфәгатьләре булганда) аерым дәүләт һәм чит ил җитештерүчеләре арасында каршылыклар һәрвакыт булачак. Каршылыкларны бетерү яки «шомарту»ны оештыру төп мәсьәлә булып кала бирә. Халыкара сәүдә оешмалары мәнфәгатьләрне килештерүнең (идеалдан ерак торган) бер ысулы гына.

XX гасырда халыкара сәүдә үсеше аны, чынлап та, дөньяның күпчелек илләре өчен икътисади үсешнең хәлиткеч факторына әверелдерде. Икътисадчылар исәпләвенчә, БСОны төзегәндә куздә тотылган бөтендөнья сәүдәсен либеральләштерүнең барлык бурычларын тулысынча хәл итү нык үсеш алган илләрдә һәр гражданның көндәлек керемен АКШның 40 центына яки бер елга 146 долларга арттырырга мөмкин. Моны аңлаган күп илләр XX гасыр башында уйга да килмәслек адымнар ясарга мәҗбүр булдылар.

Сүз илләрнең сәүдә берлекләре кысаларында (яки «ирекле сәүдә халыкара зоналарында») үзләренең милли базарларын тулысынча ачулары турында бара.

Ирекле сәүдәнең киң даирәгә билгеле зонасы алдарак атап үтелгән Европа берлеге (ЕБ); ул «Европа икътисад берләшмәсе» исеме белән 1958 елда оештырыла һәм хәзерге вакытта аңа Көнбатыш Европа илләренең күпчелеге керә.

§ 33. Валюта базары һәм валюталарның алмаштырылуы

Халыкара сәүдәнең (эчке сәүдә белән чагыштырганда) иң мөһим үзенчәлеге шунда: анда төрле акча берәмлекләре, ягъни төрле илләрнең валюталары хезмәт итә.

Һәр ил үз территориясендә барлык исәп-хисапның шул дәүләт валютасында гына башкарылуын тели. Чит илгә үз товарларын саткан фирмаларның керемнәренә салым да шушы валютада билгеләнә. Шунлыктан халыкара сәүдәдә:

1) товарларны алу-сатуны оештыру;

2) сәүдә эшләрен валюта белән тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү мөһим.

Мәсәлән, Колумбия фирмасы үз чәчәкләрен АКШка экспортлаганда аларны үз илендә песоларга сатып ала, ә Америкага долларга сата. Шулай итеп, экспортлаучы фирмага ике мәсьәләне хәл итәргә кирәк була: чәчәкләрне сатарга һәм сатудан төшемне үз иле валютасына әйләндерергә; һәм моны барлык чыгымнарны капларлык һәм табышлы булырлык итеп эшләргә кирәк.

Әгәр дә барлык илләр дә халыкара сәүдәне үстерү белән кызыксыналар икән, ни өчен соң әлеге валюта кыенлыклары тудырыла? Моңа берничә сәбәп бар:

1) дәүләтнең үз валютасы булу хөкүмәткә дәүләттән турыдан-туры акча алучылар белән исәп-хисап итү өчен акча эзләп табуны җиңеләйтә. Халыкның андый категорияләренә хезмәткәрләр (армияне дә кертеп), ярлы гражданнар, шулай ук дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр җитештерүче фирмалар керә. Сонгы чиктә дәүләт кәгазь знакларның өстәмә эмиссиясен гамәлгә ашыра ала;

2) дәүләтнең үз валютасы булу ил икътисадында эшләрнең барышы белән идарә итәргә мөмкинлек бирә;

3) андый валюта илнең тулы суверенлыгын, аның башка илләр хөкүмәтләре ихтыярыннан бәйсезлеген тәэмин итү мөмкинлеге бирә;

4) илнең үз валютасы булу башка илләр валюталары инфляция кичергәндә аңа бирешмәскә ярдәм итә.

Төрле валюталар куллану шартларында, халыкара сәүдәне алып бару өчен, кешелек дөньясында төрле илләр гражданнары һәм фирмалары арасында үзара исәп-хисап ясау механизмнары эшләнгән. Гадәттә, аны «валюта базары» дип атыйлар.

Әлеге механизмның нигезе — **валюта курслары** дип атала торган һәм аерым дәүләтләр валюталары бәяләрен күрсәтүче валюта алмаштыру пропорцияләре. Гадирәк итеп әйткәндә, валюта курсы — билгеле бер илнең акча берәмлеген сатып алу өчен түләнергә тиешле башка илләрнен акча знаклары саны ул.

ВАЛЮТА (АЛМАШТЫРУ) КУРСЫ — дәүләтнең бер акча берәмлегенең башка илләрнең акча берәмлекләренда чагылдырылган бәясе.

Мәсәлән, 2005 елның ахырында бөтендөнья валюта базарында валюталарның түбәндәге кросс-курслары (үзара бәяләре) урнашкан иде:

	АКШ доллары	Англия фунты	Канада доллары	Евро	Австралия доллары
АКШ доллары	1	1,7733	0,871839	1,213	0,7518
Англия фунты	0,56392	1	0,491647	0,6840	0,423955
Канада доллары	1,147	2,03397	1	1,3913	0,862315
Евро	0,824402	1,46191	0,718746	1	0,619785
Австралия доллары	1,33014	2,35873	1,15966	1,61346	1

Димәк, АКШның 1 доллары:

Англия фунтларында — 0,564 фунт;

евроларда — 0,824 евро торган, ягъни аны сатып алу өчен милли валютада шул кадәрле акча түләргә кирәк булган. Россиядә ул вакытта 1 доллар 28,209 сум торган.

1 евро 1,209 доллар торган, ягъни аны сатып алу өчен 34,109 сум түләргә кирәк булган.

Валюталар курсын нәрсә билгели? Нинди факторлар йогынтысында, мәсәлән, долларның сумнардагы курсының абсолют зурлыгы Британия фунтларындагыдан 41,7 тапкыр зуррак?

Күп гасырлар дәвамында дөнья икътисады әлеге сорауны бик гади хәл итеп килде. Искә төшерик: аерым дәүләтләр акча системаларының нигезен ике кыйммәтле металл: алтын һәм көмеш тәшкил итте. Күп илләр үз акчаларын шушы металлардан суктылар. Һәм төрле илләр валюталарын алмаштыру аларның составында кыйммәтле металлның күпме булуына бәйле иде. (Шуна күрә дә борынгы осталарның картиналарында валюта алмаштыручылар кулларына үлчәү тоттырып сурәтләнгәннәр.)

Металл тәңкәләрне кәгазь акчалар кысрыклый башлагач, милли валюталарны алмаштыру мәсьәләсе катлаулана. Моны хәл итү өчен **«алтын стандарты»** дигән система уйлап табыла, ул ярты гасыр чамасы — 1879 елдан 1934 елга кадәр яши.

«АЛТЫН СТАНДАРТЫ» — аерым бер дәүләт валютасын акча знаклары номиналын тәэмин итү дип игълан ителгән алтын авырлыгына бәрабәр алмаштыру механизмы.

Бу очракта да валюта алмаштыру пропорциясе «алтын буенча» дигән шул ук идеядән чыгып эшләнә, тик чын алтын әйләнеше урынына аның «вәкилләре» — кәгазь акчалар әйләнештә була. «Алтын стандарты» чорында валюта алмаштыру пропорциясе үзгәрми, башкача әйткәндә, валюталар курсы «беркетелгән» була.

Баштарак хөкүмәтләр хәтта (гражданнар теләге буенча) кәгазь акчаларны алтынга алмаштыруны үз вазифалары итеп карыйлар. «Алтын стандарты»ның җитешсезлеге шунда: инфляция шартларында гражданнар бәясе төшүче кәгазь акчаларны тизрәк алтынга алмаштырып калырга тырыштылар. Шуңа күрә Беренче бөтендөнья сугышы башлануга «алтын стандарты» классик системасы туктатылды. Сугышучы илләр хөкүмәтләре үз чыгымнарын берничек тә тәэмин ителмәгән кәгазь акчалар эмиссиясе белән кискен арттырырга мәҗбүр булды. Бу исә шунда ук зур инфляция китереп чыгарды. Ә Икенче бөтендөнья сугышы тәмамланганнан соң, «алтын стандарты»н, янартылган рәвештә булса да, тагын бер кат торгызырга омтылып карадылар. Әмма 70 нче еллар башында дөньяның алга киткән илләрендә валюта курсларын кәгазь акчаларның алтын белән тәэмин ителешенә бәйләп карау фикере бөтенләй кызыксыну тудырмый башлады.

«Алтын стандарты» идеясе бигрәк тә СССРда озак сакланды: 1950—1992 елларда 1 сум рәсми рәвештә 0,222168 г алтынга тиңләштерелә иде.

Дөньяның барлык илләрендә «алтын стандарты»ннан ваз кичү 70 нче елларда көчле валюта базары туугa сәбәп булды. Анда валюта курслары теге яки бу валютага ихтыяҗ (сорау) һәм тәкъдим нисбәте йогынтысында формалашты.

Валюта базарында сорау һәм тәкъдим зурлыгы барыннан да элек аерым илләр арасында үзара сәүдә итешү күләменнән тора. Моны белгән очракта, валюта базары барлыкка килү моделен схема рәвешендә күзалларга була. Ул модель 15-2 рәсемдә күрсәтелгән.

Әлеге рәсем АКШ һәм Япония арасындагы сәүдә-валюта мөнәсәбәтләрен тасвирлый. Аннан күренгәнчә, ул базарның катнашучылары:

— үз товарларын АКШка чыгарган һәм анда долларлар алган Япония фирмалары. Әмма үз илләрендә чыгымнарын каплау, салымнар түләү һәм табышны бүлү өчен аларга долларлар түгел, ә иеналар кирәк (билгеле, әгәр дә алар долларларда алган барлык төшемгә Япониягә кертү өчен Америка товарлары сатып

Тышкы сәүдәдә катнашучы илләр һәм фирмалар	Валюта ситуациясе	
	АЛЫРГА ТЕЛИЛӘР	АЛАРДА БАР
Товарларны АКШка экспортлаучы Япония фирмалары	ИЕНАЛАР ↕	ДОЛЛАРЛАР ↕
Товарларны Япониягә экспортлаучы АКШ фирмалары	ДОЛЛАРЛАР	ИЕНАЛАР

15-2 рәсем.
Валюта базары барлыкка килү механизмы

алырга теләмәсәләр). Димәк, Япония фирмалары долларларны иеналарга алмаштыруга мохтаж;

— үз товарларын Япониягә экспортлаган һәм төшемгә иеналар алган Америка фирмалары. Әлеге төшемне хәзер аларга доллларларга әверелдерергә һәм АКШка алып чыгарга, аннары үзләренең алга таба эшчәнлеге өчен файдаланырга кирәк. Чөнки Америка хөкүмәте үз территориясендә чит ил акчалары белән түләргә рөхсәт итми.

Шулай итеп, товар экспортлаучы Америка фирмаларына үз илләренә алып чыгу өчен АКШ долларлары кирәк. Ә аларның япон коллегаларында АКШ долларлары бар, әмма аларга иеналар кирәк, чөнки аларның илендә шушы валюта зарур дип табыла. Ике якның да ихтыяжларын валюта базары канәгатьләндерә: берәүләр долларларга — иеналар, икенчеләре иеналарга долларлар сатып алырга тели. АКШ валюта базарында японнар үзләре алган долларларны сатарга һәм иеналар алырга тырышалар, ә Япония валюта базарында америкалылар иеналар сату һәм долларлар алу килешүләре үткәрәләр. Валюта базарында иеналарга сорау (долларларда) һәм долларларга сорау (иеналарда) очраша.

Иеналарга алмаштыру зарурлыгы булган долларлар нәкъ менә долларга сату өчен тәкъдим ителә торган иеналар күләменнән зуррак булган саен, иеналарның долларларда чагылдырылган бәясе, ягъни иенаның долларга карата курсы күтәрелә. (Кайбер компанияләрнең иеналарны, мәсәлән, еврога сатарга теләвен дә истә тотарга кирәк.)

Валюта курсларын билгеләүче төп фактор — төрле илләр арасында үзара экспорт һәм импорт күләме нисбәте. Мәсәлән, Россиядә Америка товарлары АКШта Россия товарларына караганда байтакка күбрәк сатылса, товарлар экспортлаучы Америка фирмаларына яңадан долларга әверелдерергә кирәк булган сумнарның зур санына экспортлаучы Россия фирмаларының сумнарга әверелдерү зарур долларның азрак саны каршы тора. Мондый очракта һәр доллар өчен берничә сум түләргә кирәк була. Үзара алмаштыру өчен тәкъдим ителә торган сумнар һәм долларлар арасында аерма зуррак булган саен долларның курсы, ягъни аның сумнардагы бәясе югарырак була.

БҮЛЕКНЕҢ ТӨП ЭЧТӘЛЕГЕ

Халыкара сәүдә һәм аның ил икътисадына йогынтысы.

Халыкара сәүдәнең барлыкка килүе һәм үсешенең төп сәбәпләре: илләр арасында табигый ресурсларның (байлыкларның) тигезсез бүленеше; товарлар җитештерүдә абсолют өстенлекләрнең булуы; техник алгарышның темплары төрле булу һәм башка факторлар йогынтысы нәтиҗәсендә теге яки бу товарлар җитештерүдә һәр илнең чагыштырма өстенлекләре барлыкка килү. Җитештерүне махсуслаштыру һәм халыкара сәүдәне чагыштырма өстенлек принцибы нигезендә оештыру гамәлдә һәр илгә үзе өчен файдалы шартларда халыкара сәүдәдә катнашу, хәтта аның сату өчен яраклы

табигый ресурслары булмаса да, байтак акча эшләү мөмкинлеге бирә. Бер үк вакытта халыкара сәүдә чынлыкта барлык катнашучы илләрнең җитештерү мөмкинлекләрен киңәйтә. Мондый сәүдә — чикләнгән ресурслардан нәтиҗәлерәк файдалануны дөньякүләм масштабта тәэмин итү механизмнарының берсе. Ирекле халыкара сәүдә анда катнашучы барлык илләр өчен отышлы булса да, аларның күбесе халыкара килешүләргә теге яки бу чикләүләрдән файдалана. Ул чикләүләр дәүләтнең тышкы сәүдәгә салым салудан керем алу омтылышыннан, шулай ук эчке базарда импорт товарлары белән конкурентлык итүгә сәләтсез лоббистлар төркемнәренең дәүләткә басым ясавыннан килеп чыга. Тышкы сәүдәгә чикләүләр төрле рәвештә — импорт (ә кайчак — импорт һәм экспорт) товарлары күләмен турыдан-туры сан ягыннан чикләүдән алып товарларны экспортлау һәм импортлауга салымнарны (пошлиналарны) төрле күләмдә билгеләүгә кадәр булырга мөмкин. Импорт товарларының эчке базарга керүен чикләү сәясәте «протекционизм» дип атала. Ул илебезнең көчле фирмалары белән каршылыкларны булдырмау гына түгел, дәүләт бюджетын тулыландыру мөмкинлеге дә тудыра. XX гасырда илләр халыкара сәүдә оешмаларына һәм икътисади берләшмәләргә күбрәк керә башладылар. Аларның иң зурысы булган Бөтендөнья сәүдә оешмасына Россиягә дә, үз экспортчыларын башка илләрнең протекцион чараларыннан саклау өчен, керү зарур.

Валюта базары һәм валюталарның алмаштырылуы. *Дөньяның күпчелек илләре үз территорияләрендә товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр өчен барлык исәп-хисапның үз валюталарында гына башкарылуын таләп итә. Бу исә тышкы сәүдәдән төшемне бер ил валютасыннан башка илләр валюталарына күчерү зарурлыгы тудыра. Әлеге проблеманы валюта базары хәл итә; анда төрле илләрнең акча знаклары сатыла һәм сатып алына. Шушы базар аларның чагыштырма бәяләрен билгели, алар «валюта курслары» дип атала. Алар икенче бер ил акча берәмлеген сатып алу өчен күпме акча берәмлеге түләү зарурлыгын күрсәтә. Валюта курслары күпчелек очракта төрле илләр арасында экспорт һәм импорт нисбәтенә бәйле, чөнки нәкъ менә үзара экспорт-импорт эшләренең күләме үзара чагыштырыла торган валюталарга сорау һәм тәкъдим зурлыгын билгели. Моннан тыш, Россиядә 1990 елларның беренче яртысында валюта курслары шактый дәрәҗәдә кешеләрнең инфляциядән сакланырга тырышып, үз акчаларын валюталарда саклауга салуы белән билгеләнде. Валюта курслары үзгәрү, бигрәк тә аларның динамикасы ил эчендә инфляция процесслары үсешеннән сизелерлек аерылса, икътисадка зур йогынты ясый.*

ФИКЕР АЛЫШУ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Ни өчен Россия хөкүмәте илебез житештерүчеләренә (илнең озак вакытка исәпләнгән мәнфәгатьләре ягыннан) ярдәм итүне субсидияләр бирү юлы белән түгел, ә протекционизм (импортка пошлиналар кертү) ярдәмендә үткәрә?
2. Ни өчен Россиядә дәүләт гражданнарга валютадагы саклык акчаларын чит ил банкларына салуны тыя, ә Япониядә исә бу, киресенчә, хуплана?
3. Россиядә икътисади үсешнең нинди тибы өстенлекле һәм ни өчен?

У Н А Л Т Ы Н Ч Ы   Б Ү Л Е К

XX—XXI гасырлар чигендә Россиянең икътисади корылышы

БҮЛЕКТӘ КАРАЛУЧЫ МӘСЬӘЛӘЛӘР:

1. РОССИЯ ИКЪТИСАДЫ — УЛ КАЙСЫ ТӨРГӘ КЕРӘ?
2. НИ ӨЧЕН БЕЗНЕҢ ИЛДӘ ИКЪТИСАДНЫҢ ТИЗ ҮСЕШЕНӘ ИРЕШҮ КЫЕН?
3. РОССИЯДӘ ИКЪТИСАДИ ТОРМЫШ НИЧЕК ҮЗГӘРӘ?



...Узган гасырның соңгы унъеллыгында — җимерелгән икътисад һәм дөнья базарларында тоткан урыннарны югалту шартларында — Россия бер үк вакытта дәүләтчелекне торгызырга һәм безнен өчен яңа, базар икътисадын төзергә мәҗбүр булды.

РФ Президенты В. В. Путинның Россия Федерациясе Федераль җыенына юлламасыннан (26 май, 2004 ел)

XX гасырның соңгы унъеллыкларында һәм XXI гасыр башында Россия (бигрәк тә икътисадта) кыен вакытлар кичерде. Мондый хәл ничек килеп чыкты; ни өчен гаять зур территориясе һәм нефть, газ һәм башка казылма байлыкларның зур запаслары, күп санлы яхшы әзерлекле белгечләре булган ил озак вакытка икътисади кризиска дучар булды?

Әлеге сорауга җавап бирү өчен барыннан да элек XX гасыр ахыры — XXI гасыр башында илнең икътисады турында гомуми күзаллау булдырырга кирәк.

§ 34. Россия икътисады нинди категориягә керә

Дөнья икътисад фәнендә илләр ирешелгән икътисади үсеш дәрәҗәләре буенча түбәндәге өч төркемгә бүленәләр (16-1 табл.):

— *сәнәгате алга киткән илләр* (АКШ, Япония, Германия һәм Икътисади хезмәттәшлек һәм үсеш оешмасына — ИХҮОга — берләшкән дөньяның башка иң бай илләре). Әлеге илләр индустрияләштерүне тәгәлләгән, көчле икътисади механизмнар булдырган, аларның нык үсеш алган мәгариф, сәламәтлек саклау, фәнни-техник тәэминат системалары һ. б. бар. Иң мөһиме — аларда гражданнарның күпчелеге тормыш муллыгының югары дәрәҗәсенә ирешкән;

— *яңа индустриаль илләр* (барыннан да элек, «Азия аждаһалары»: Тайвань, Сингапур, Көньяк Корея). Ул илләр соңгы унъеллыкларда заманча көчле сәнәгать төзеделәр һәм нык үсеш алган икътисади механизмнар булдырдылар. Аларда хәзер мәгарифне, сәламәтлек саклауны үстерү бара, элегрәк түбән булган тормыш муллыгы дәрәҗәсе тиз үсә;

— *үсеп килүче илләр*. Бу илләр әле индустрияләштерү этабын узалар гына; алар транспорт челтәрләре һәм элемтә системасы булдыралар, заманча икътисади механизмнар төзиләр, үзләренең мәгариф системаларын, сәламәтлек саклауны һәм мәдәниятне җайга салалар. Аларның гражданнарының тормыш дәрәҗәсе бик түбән: Африканың күп илләрендә хәзергәчә меңләгән кеше ачлыктан һәм чиктән тыш ярлылык һәм сәламәтлек саклауның артта калуы аркасында тарала торган эпидемияләрдән үлә.

Таблица 16-1

Дөнья илләрен икътисади система типлары һәм икътисади үсеш дәрәҗәләре буенча классификацияләү

Илләрнең икътисади үсеш буенча төркемнәре	Икътисади система төрләре			
	Традицион	Командачыл	Базар	Катнаш
Сәнәгате үсеш алган илләр				АКШ, Япония, Германия һәм ИСХҮОның башка илләре
Яңа индустриаль илләр				Тайвань, Сингапур, Көньяк Корея
Үсеп килүче илләр	Африкадагы кайбер илләр	Куба, Төньяк Корея	Латин Америкасы, Африка, Азиянең кайбер илләре	Һиндстан, Мексика, Бразилия, Чили, Кытай

Ә Россия икътисади системаларның нинди төренә, илләрнең нинди категориясенә керә?

Бу сорау соңгы елларда безнең ил икътисадын реформалауның иң яхшы вариантларын билгеләргә тырышучы икътисадчылар һәм сәясәтчеләр даирәсендә кискен бәхәсләр китереп чыгарды.

Россияне үсеп килүче илләр исәбенә кертергә ярамый, чөнки безнең илдә:
— искергән булса да, көчле сәнәгать;
— таушалган булса да, гаять зур транспорт челтәре; искергән булса да, элемтә системасы;
— югары үсешкә ирешкән мәдәният һәм гомуми белем бирү системасы;
— күп сандагы фәнни һәм техник эшләнмәләр бар.

Шуның белән беррәттән, Россиядә тормыш дәрәҗәсе (әгәр дә аны дөнья илләре практикасында кабул ителгәнчә, җан башына туры килә торган тулай эчке продукт зурлыгыннан чыгып исәпләсәк) шактый түбән (16-1 рәсем). Моннан тыш, безнең илдә күп кенә әһәмиятле икътисади механизмнар бөтенләй юк яисә алар башлангыч халәттә генә. Шунлыктан Россияне икътисади үсешкә ирешкән илләр төркеменә дә тулысынча кертеп булмый.

Икътисади системага килгәндә, ул Россиядә кайбер үзенчәлекләргә ия.

Бер яктан, Россиядә директив планлаштыру системасы юкка чыгарылды, ә элекке дәүләт предприятиеләре мәҗбүри рәвештә хосусый фирмаларга әверелде (приватизацияләнде); икенче яктан, барлык тармаклар һәм төбәкләр хөкүмәттән



16-1 рәсем.

Дөньядагы илләрне керемнәр буенча чагыштыру (санаучыда — җан башына туры килә торган тулай эчке продукт сатып алу сәләте паритеты буенча АКШ долларында; ваклаучыда — җан башына туры килә торган ТЭП—АКШтагыга карата процентларда)

даими рәвештә нәрсә дә булса таләп итәләр, һәм хөкүмәт хәтта иң гади хуҗалык мәсьәләләрен дә (мәсәлән, җылыту сезонына әзерлек) хәл итүгә катнаша.

Бәхәсләрдән соң икътисадчылар шундый бердәм фикергә килә: Россияне Көнчыгыш Европа илләре кебек үк, аерым бер категориягә кертү дөресрәк була. Ул күчеш тибындагы икътисадка ия булган **социализмнан соңгы чор илләре**. Алар бөтенләй аерым сыйфатларга ия, сәнәгатьләре алга киткән һәм үсеп килүче илләрнекеннән аерылып торучы мәсьәләләрне хәл итәләр.

***КҮЧЕШ ИКЪТИСАДЫ** — хуҗалык итүдә элекке һәм яңа икътисади система элементларының беркадәр вакыт эчендә янәшә яшәве.*

§ 35. Россия Федерациясендә күчеш тибындагы икътисад формалашу

Безнең ил икътисадын 1991 елда башланган кризистан чыгару өчен түбәндәге берничә мәсьәләне хәл итәргә кирәк була:

1) хуҗалык эшчәнлеген либеральләштерү, ягъни россиялеләргә үз тормышлары өчен дәүләт җитәкчелегендә һәм дәүләт секторында гына түгел, ә мөстәкыйль рәвештә дә акча эшләү мөмкинлеге бирү;

2) макроикътисади тотрыклылыкка ирешү, ягъни икътисадка таралырга мөмкинлек бирмәү һәм аны чиктән тыш инфляциядән, тулай продуктның нык кимүеннән һәм эшсезлекнең тиз үсүеннән саклау;

3) ил икътисадының күбрәк чимал һәм энергия ресурслары экспортлауга юнәлеш тотуын үзгәртеп, аны конкуренциягә сәләтле соңгы куллану продукциясе (машиналар, халык куллануы товарлары һ.б.) җитештерүгә юнәлтеп, структур үзгәртеп корулар үткәрү;

4) институциональ реформаларны гамәлгә ашыру, ягъни базар икътисадына эшли башларга мөмкинлек бирүче яна законнар булдыру һәм хуҗалык эшчәнлеген башкару кагыйдәләре кабул итү;

5) социаль сәясәттә үзгәртүләр башлау, ягъни ярлыларга һәм хезмәткә сәләте булмаганнарга дәүләт ярдәменең гаделрәк һәм адреслырак булуына ирешү.

Икътисадны либеральләштерүгә тәфсилләбрәк тукталыйк.

Безнең ил икътисады 90 нчы еллар башына әле командачыл система принцибына корылган иде. Ә ул түбәндәгеләрне күздә тота:

— гамәлдә барлык предприятиеләрнең һәм җитештерү ресурсларының 100 % ка (тулысынча) җәмәгать (дәүләт) милке булуы;

— гражданнар һәм оешмалар сатып ала торган товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә бәяләрне һәм тарифларны катгый көйләү;

— хосусый хуҗалык эшчәнлегенең (ил эчендә сәүдә итүне һәм тышкы сәүдә килешүләрен дә кертеп) күпчелек өлешен тыю;

— законнар тарафыннан хосусый милеккә (бизнес белән шөгыльләнүнең нигезе буларак) юл куймау һәм хосусый эшмәкәрлек эшчәнлеге өчен җинаять җаваплылыгы;

— гражданнарга һәм оешмаларга чит ил валюталарын ирекле рәвештә сатып алу һәм сату хокукы бирмәү;

— хуҗалык оешмаларына нәрсәне ничек һәм кем өчен җитештерү турында күрсәтмәләр бирүче дәүләт оешмаларын саклау.

***ИКЪТИСАДНЫ ЛИБЕРАЛЬЛӘШТЕРҮ** — икътисади эшчәнлек ирегeн киңәйтү, хосусый инициативага (башлангычка) сәяси, хокукый һәм административ чикләүләрне тулысынча яки өлешчә бетерү.*

Алдарак әйтеп үтелгән шартларда базар механизмнары эшләп китә алмый иде. Шуңа күрә 1992 елда Россиянең икътисади системасын үзгәртеп кору чоры башлангач, дәүләтнең беренче бурычы икътисадны либеральләштерү булды. Әлеге

фәнни гыйбарә артында шактый гади фикер ята: кешеләргә хокукый рәвештә нәрсәне ничек һәм кем өчен житештерергә, ничек һәм күпмегә сатарга, сатудан алынган средстволардан ничек файдаланырга кирәклеген мөстәкыйль хәл итү мөмкинлеге бирелгәч кенә, базар икътисады барлыкка килә ала.

Әмма әлеге гади фикерне безнең илдә гамәлгә ашыру жиңел түгел иде. Моның өчен хөкүмәткә зур бәхәсләр, алдан күреп булмый торган нәтиҗәләр китереп чыгарган чаралар күрергә туры килде:

1) бәяләр белән дәүләтнең идарә итүеннән ваз кичү — бәяләр куюны либеральләштерү; гражданнарга, хуҗалык оешмаларына сатуга тәкъдим ителә торган товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә бәяләрне үзләренә билгеләргә рөхсәт итү;
2) ил эчендәге сәүдәне фәкать дәүләтнең генә оештыруыннан ваз кичү — эчке һәм тышкы сәүдәне либеральләштерү;
3) хосусый милек нигезендә бизнес белән шөгыльләнүне рөхсәт итү, андый хуҗалык эшчәнлеге өчен җинаять җаваплылыгын бетерү;
4) гражданнарга һәм оешмаларга чит ил валютасын валюта базарында барлыкка килүче курслар буенча алырга һәм сатарга рөхсәт итү;
5) дәүләт милкен хосусыйлаштыру.

Россия дәүләте тарафыннан барлык әлеге чаралар үткәрелсә дә, нәтиҗәләр һәрвакытта да көтелгәнчә булмады. Хосусыйлаштыру баштан ук гадәттән тыш күп бәхәсләр китереп чыгарды, һәм алар Россиядә әле хәзергә кадәр тынмый. Әмма шунысын әйтү гадел булыр: хосусыйлаштыру Россиядә милекнең структурасын тамырдан үзгәртте (16-2 рәсем). Моннан башка безнең илдә базар икътисадына яраклашкан фирмалар әле хәзер дә барлыкка килә башламаган булыр иде әле.

Бигрәк тә макроикътисадның тотрыклылыгын бозу, гадәттән тыш көчле инфляция һәм барлык тармакларда диярлек җитештерүнең тиз кимүе либеральләштерүнең иң күңелсез нәтиҗәләре булды. Һәм икътисад өчен куркыныч тудыручы процесслар белән көрәш узган гасырның 90 нчы еллары дәвамында дәүләт эшчәнлегенең мөһим юнәлешен тәшкил итте. Уңышка шунда ук ирешелмәде — Россия икътисады яңа базар модельләренә кыеннан күчә иде. Гасыр ахырына гына җитештерүнең кимүе аның үсүе белән алмашынды, ә инфляция бер елга 12—15 % ка кадәр төште.

Әлеге нәтиҗәләргә ирешү юлында Россиягә 1998 елгы финанс кризисын һәм дәүләт дефолтын кичерергә туры килде. Дәүләтнең бурычлары шулкадәр күп җыелган иде ки, хәтта ул халыкка сатылган кыйммәтле кәгазьләр («дәүләтнең кыска сроклы облигацияләре» — ДКСО) өчен түли алмады. Ә ул кыйммәтле кәгазьләргә күп кенә гражданнар һәм банкларның тупланган акчалары салынганлыктан, әлеге кризис күп гаиләләргә зыян ясады һәм чит ил валюталарына мөнәсәбәттә сумның бәясе нык төшүгә китерде.

Илнең икътисады — күпьяклы күренеш, һәм сумның бәясе шулай төшкәннән соң чит ил товарларына караганда безнең ил товарлары белән (бәяләр ягыннан) кызыксыну күпкә артты. Чынлап та, 1998 елның июнендә 10 доллар торган чит ил товары 70—80 сумга сатылырга мөмкин иде, чөнки долларның валюта биржасындагы бәясе 6,5 сумга тигез булды. Ә октябрь аенда дефолттан һәм сумның чынлыкта девальвацияләнүеннән соң шул ук товарны беркем дә 160—180 сумнан кимрәккә сатмады, чөнки ул вакытка доллар курсы 15—16 сумга



16-2 рәсем.
1991 һәм 2003 елларда Россия Федерациясендә милек структурасы
(Россия Федерациясе хисап палатасы материаллары)

кадәр үсте. Ә россиялеләрнең хезмәт хаклары ул кадәр артмады: шунлыктан Россия гражданнары һәм фирмалары күбрәк илебез товарларын сатып ала башладылар, бу исә безнең предприятиеләргә житештерү күләменең кимүен җиңәргә һәм аны арттыра башларга мөмкинлек бирде.

Алдарак китерелгән исемлектәге башка өч мәсьәлә буенча шулай ук алга китеш булды, әмма уңышлар хөкүмәт көткәннән һәм планлаштырганнан күпкә азрак иде. Әйе, Россия икътисадында яхшы эшләүче азык-төлек предприятиеләре күбәя бара, машина төзелешендә һәм җиңел промышленностьта уңышлы эшләүче предприятиеләр барлыкка килә. Шулай да илнең тулай продуктында һәм аның экспортында чимал һәм җылылык-энергетика ресурсларының өлеше әлегә арта гына. Һәм әле хәзергәчә бу тенденцияне җиңүгә ирешелмәде. Шуның белән беррәттән, РФ Президенты В. В. Путин 2003 елда Федераль Җыенга юлламада билгеләп үткәнчә, «Россиядә икътисади үсеш беренче нәүбәттә соңгы елларда дөньядагы хәлләрнең уңай торышыннан булды. Тышкы сәүдә өчен шартларның моңа кадәр күрелмәгәнчә яхшыруы исәбенә Россия безнең икътисад өчен сизелерлек икътисади өстенлекләр һәм өстәмә керемнәр алды.

Әлеге керемнәрнең бер өлеше безнең ил гражданнарының тормыш дәрәҗәләрен күтәрүгә юнәлтелде. Икенче бер өлеше Россия икътисадына инвестицияләнде. Тагын бер өлеше дәүләтнең тышкы бурычын каплауга файдаланылды...

Аңлашыладыр дип уйлыйм: әлеге средстволардан башка (мин уңай тышкы икътисади халәтне күздә тотам) социаль-икътисади үсештәге уңышларыбыз күпкә тыйнаграк булыр иде. Онытмыйк: андый уңай халәт безнең өчен мәңге була алмый һәм булмаячак».

Шуңа күрә Россия хөкүмәте һәм илебезнең бизнес эшлекләләре илгә керемнәр бирергә, шулай ук нефтькә, газга дөнья бәяләре кимегән очракта да кешеләрне эш белән тәэмин итәргә сәләтле, тирәнтен фәнни нигезләүләр таләп итүче җитештерүнең үсешен тизләтү ысулларын актив тикшерәләр. Мәсәлән, әлеге бурычларны хәл итү өчен илдә ирекле икътисади зоналар төзү турында карар кабул ителгән. Ул зоналарда фәнни нигезләүләр таләп итүче предприятиеләр (мәсәлән, салым салуның түбәнрәк ставкалары һәм дәүләт тарафыннан икътисадны көйләүнең башка мөмкинлекләре) исәбенә ташламалы шартларга ия булачак.

Соңгы ун елда илдә хуҗалык эшчәнлеге кагыйдәләренең бертөрле аңлашылуын тәэмин итүче законнар булдыру өчен дә аз эшләнмәде. Шулай да әле бу өлкәдә дә күп эшлисе бар: илдә базар икътисадының нормаль эшләве өчен зарур күп кенә хокук нормалары әле хәзергә кадәр юк. Ө кабул ителгән законнарның кайберләре уңышлы түгел, аларның аерым положениеләрен төрлечә аңлатырга була; бу исә дәүләт чиновниклары арасындагы күп санлы ришвәтчеләргә тормышны җиңеләйтә.

Җәмгыятьнең социаль — сәламәтлек саклау, мәгариф, ярлыларга һәм хезмәткә яраклы булмаганнарга ярдәм системалары — институтлары реформасын уздыру тагын да катлаулырак. Шул ук вакытта илдә күптәннән яшәп килүче проблемаларны (мәсәлән, торак өчен түләүнең элекке системасы: зуррак торак мәйданына ия булган баерак гаиләләр (кысан торакта җәфа чигүче ярлы гаиләләргә караганда) дәүләттән күбрәк ташлама ала) хәл итү өчен средстволар инде бар. Әмма социаль даирәдә үзгәртеп корулар катлаулы, алар халыкта еш кына ризасызлык тудыра, шуңлыктан әле хәзергә уңышлар бик аз.

Россиядә икътисади системаны сизелерлек үзгәртү процессы, һичшиксез, алга бара. Ирешелгән уңышлар аз түгел. Алар турында без еш кына онытабыз да. Әйтик, 90 нчы елларда туган кешеләр хәзер инде «азык-төлек проблемасы» дигән сүзләрнең нәрсә белдерүен аңламый. Ә 1991 елның көзендә безнең илдә кибет киштәләре шулкадәр бушап калды ки, барлык кеше ачлык килүен көтеп куркуга төште; ә Россия хөкүмәтендә ачлык була калса дип, кешеләрне цингадан — ачыкканда кешенең бер-бер артлы тешләре коелу авыруыннан — коткару өчен күпләп нарат ылыс әзерләү мөмкинлеге тикшерелде.

СССРда дистәләрчә еллар дәвам иткән бу курку ирекле сәүдә үсеше, азык-төлек базарында конкуренция нәтиҗәсендә җиңелде. Һәм шушы факт кына да безнең илнең үз икътисади системасын үзгәртеп коруга юкка гына алынмаганлыгын дәлилли. Әлеге юлда безнең башка зуррак уңышларга да ирешә алачагыбызга ышаныч бар.

БҮЛЕКНЕҢ ТӨП ЭЧТӘЛЕГЕ

Россия икътисады кайсы төргә керә. *Дөнья икътисад фәнендә илләр икътисади үсешнең ирешелгән дәрәҗәсе буенча өчкә бүленә: сәнәгате алга киткән илләр, яңа индустриаль илләр һәм үсеп килүче илләр. Россия икътисады, аңа хас сыйфатлар буенча әлеге төркемнәрнең берсенә дә кертелә алмый. Шуңа күрә Россияне, Көнчыгыш Европа илләре кебек үк, аерым бер категориягә — күчеш тибындагы, социализмнан соңгы илләр төренә кертү дөресрәк була, чөнки ул илләр үзенчәлекле сыйфатларга ия һәм сәнәгате алга киткән һәм үсеп килүче илләрдән аермалы мәсьәләләрне хәл итәләр.*

Россия Федерациясендә күчеш тибындагы икътисад формалашу. *Безнең илне 1991 елда башланган кризистан чыгару өчен, дәүләткә һәм җәмгыятькә берничә гаять катлаулы мәсьәләне хәл итү белән шөгыльләнергә туры килде. Алар түбәндәгеләр: хуҗалык эшчәнлеген либеральләштерү; зур күләмле икътисади тотрыклылыкны тәэмин итү; хосусыйлаштыру һ.б. Ул эшләр әле хәзер дә тәгәлләнмәгән, чөнки бу юлда һәрбер адым зур көч куюны, күп чыгымнар таләп итә һәм кешеләрнең мәнфәгатьләренә кагыла. Шуңа күрә Россиянең катнаш типтагы икътисади системага таба хәрәкәт итүе үтә нык тигезсез бара, бу исә илдәге икътисади үсешне һәм гражданнарның тормыш муллыгы үсеше темпларын тизләтүгә комачаулый.*

ФИКЕР АЛЫШУ ӨЧЕН СОРАУЛАР

1. Һәр көздә Россия Федерациясе хөкүмәте утырышында илдә җылыту сезонына әзерлек тикшерелә: барлык урыннарда да котельныйлар төзәтелгәнме; гражданнарның йортларын җылыту өчен ягулык запасы һәр җирдә дә җитәрлекме... Мондый тикшерүләр һәр елны булырга тиешме яисә бу икътисадны реформалауның тәгәлләнмәгәнлеген күрсәтәме?
2. 1998 елгы дефолт сумның долларга карата бәясе төшүгә китерде һәм Россиянең күп предприятиеләренә җитештерү күләмен һәм хезмәткәрләргә түләүне арттырып сату базарларын үзенә кире кайтару мөмкинлеге бирде. Илдәге җитештерүнең артуын тизләтү өчен дәүләтнең сум бәясен төшерергә тырышуы дөрес булырмы?
3. Хосусыйлаштыру Россия гражданнары арасында байлыкның гаять тигезсез бүленүенә китерде. Сезнең карашка ничек: хосусыйлаштырылган милкәтнең иң кыйммәтлеләрен яңадан гомуми дәүләт милкенә кайтарырга һәм яңадан хосусыйлаштыруның кулайрак ысулларын эзләп карарга кирәк түгелме икән?

А

Абсолют өстенлек принцибы (*принцип абсолютного преимущества*) — әгәр дә илләр, үзләренең сәүдә партнерларына караганда кимрәк чыгымнар белән житештерә ала торган товарларда махсуслашсалар, бер-берсе белән сәүдә итүдән оталар.

Активлар (*активы*) — милек хокукында аерым бер кешенеке, фирманыкы яки дәүләтнеке булып исәпләнүче байлыклар.

Акча (*деньги*) — махсус товар, ул — 1) барлык кешеләр тарафыннан һәртөрле башка товарлар һәм хезмәт күрсәтүләргә алмаштырып кабул итеп алына; 2) алмашу һәм исәп-хисап өчен, барлык товарларны үзара чагыштырып бәяләргә мөмкинлек бирә; 3) агымдагы керемнәрнең бер өлешен саклау һәм туплау мөмкинлеге бирә.

Акча эмиссиясе (*эмиссия денег*) — әйләнешкә акча знаклары (билгеләре) чыгару.

Акциз (*акциз*) — сатып алучыдан товарларның кайбер төрләрен алганда түләтелә һәм гадәттә шул товар бәясенә карата процентларда билгеләнә торган салым.

Акция (*акция*) — кыйммәтле кәгазь ул. Аны алган кешенең әлеге кәгазьне чыгарган акционерлык җәмгыяте капиталында өлеше була, бу акция аңа әлеге җәмгыятьнең бер өлеш керемен алу хокукы бирә.

Акцияләр курсы (*курс акций*) — акцияләрне кыйммәтле кәгазьләр базарында ирекле төстә кабат сатканда урнашкан базар бәясе.

«Алтын стандарты» (*«золотой стандарт»*) — аерым бер дәүләт валютасын акча знаклары номиналын тәэмин итү дип игълан ителгән алтын авырлыгына бәрабәр рәвештә алмаштыру механизмы.

Амортизация (*амортизация*) — әкренләп туза баручы төп фондлар бәясен житештерелә торган продукция бәясенә күчерү.

Артыклык (*избыток*) — сатучылар базарда гамәлдә булган бәяләрдән сатып алучыларның алу мөмкинлекләренә караганда (алар бу бәядән алырга әзер түгел) күбрәк товар тәкъдим иткәндә барлыкка килгән халәт.

Б

Базарны монополияләштерү (*монополизация рынка*) — билгеле бер товар базарында сатучыларның яки сатып алучыларның берсенә гомуми сату, яки сатып алуның шактый зур күләме туры килгәндә, аның шушы базарда бәяләр һәм килешүләр шартлары формалашуга башка катнашучыларга караганда зуррак йогынты ясый алуы.

Базар системасы (*рыночная система*) — капитал һәм җир аерым затлар милкендә булган, ә чикләнгән ресурслар базар законнары буенча бүленә торган икътисади тормышны оештыру ысулы.

Байлыклар (*блага*) — кешеләр тарафыннан үз ихтыяҗларын канәгатьләндерү чарасы буларак бәяләнүче һәрнәрсә.

Банк (*банк*) — 1) депозитлар кабул итү; 2) ссудалар бирү; 3) исәп-хисап эшләрен оештыру; 4) кыйммәтле кәгазьләр сату һәм алу эшчәнлеген башкаручы финанс оешмасы.

Бартер (*бартер*) — бер товарларны яки хезмәт күрсәтүләрне башкаларына акча кулланмыйча гына турыдан-туры алмашу.

Бәяләр механизмы (*механизм цен*) — бернинди мәҗбүр итүләрсез билгеле бер карарга килгән сатып алучылар һәм сатучылар мәнфәгатьләре каршылыгы йогынтысында базар бәяләре формалашу һәм үзгәрү.

Бухгалтерия чыгымнары (*бухгалтерские издержки*) — билгеле бер вакыт эчендә фирма товарлар житештерүгә һәм хезмәт күрсәтүләргә тоткан тышкы (ачык билгеле) чыгымнарының гомуми суммасы.

Бүленмәгән табыш (*нераспределенная прибыль*) — табышның, милекче үз кереме итеп аласы урынга (яки аны алганнан соң), фирманы үстерүгә юнәлтелгән өлеше.

Бюджет (*бюджет*) — керемнәр җыю һәм алынган средстволарны федераль яки җирле дәүләт хакимияте органнарының билгеле вакытка чыгымнарын каплауга файдалануның җыелма планы.

Бюджет трансферты (*трансферт бюджетный*) — гомумдәүләт бюджетыннан түбәнрәк дәрәҗәдәге бюджетларга (аларны тулыландыру өчен) акча күчерү.

В

Ваклап сату (*розничная торговля*) — куллану товарларын аз данәдә яки кечкенә күләмдә турыдан-туры сатып алучыларның үзләренә сату.

Валюта (алмаштыру) курсы (*валютный обменный курс*) — дәүләтнең бер акча берәмлегенең башка илләрнең акча берәмлекләрендә чагылдырылган бәясе.

Васыять итү (*завещание*) — милеккә хокукның милек хуҗасы ихтыяры белән аның үлеменнән соң гамәлдәге законнар нигезендә юридик рәвештә теркәлгән күчүе.

Г

Гаилә байлыгы (*богатство семьи*) — гаиләнең бурычлардан азат милке.

Гаилә керемнәре (*семейные доходы*) — гаилә әгъзалары чит кешеләрдән яки оешмалардан ала һәм үз чыгымнарына түләү өчен файдалана торган акча средстволары.

Генераль килешү (*генеральное соглашение*) — хөкүмәт, эш бирүче һәм профсоюз берләшмәләре арасындагы сөйләшүләр нәтиҗәсендә кабул ителгән, бөтен ил буенча эшче көчләрен сату-алу шартлары үзгәрешенең гомуми юнәлешләрен билгеләүче документ.

Гомуми чыгымнар (обшие издержки) — билгеле бер күләмдә продукция житештерүне оештыру өчен, фирма файдаланган яки файдаланачак ресурсларның тулы күләмен алуга тотылган чыгымнар.

Д

Дәүләт бурычы (*государственный долг*) — дәүләт органнары алган һәм әлегә кредиторларга кайтарып бирелмәгән ссудалар суммасы.

Дәүләт бюджеты дефициты (*дефицит государственного бюджета*) — дәүләт барлык төр салымнар һәм түләүләрдән чынлыкта алырга мөмкин булган керемнәрдән артыграк суммадагы чыгымнарга баруны күздә тотканда барлыкка килүче финанс хәле.

Дәүләт бюджеты профициты (*профицит государственного бюджета*) — дәүләт барлык салымнардан һәм түләүләрдән чынлыкта алырга мөмкин булганнан кимрәк суммадагы чыгымнарга баруны күздә тотканда барлыкка килүче финанс хәле.

Дәүләт казначылыгы (*государственное казначейство*) — дәүләт идарәсе тармаклары (ведомстволар) тарафыннан сарыф ителүче чыгымнарны түләүне оештыручы һәм дәүләт керемена килә торган акча средстволарын кабул итүче дәүләт оешмасы.

Дәүләт кыйммәтле кәгазьләре (*государственные ценные бумаги*) — дәүләтнең үзе бурычка алган акчаларны һәм алардан файдаланып торган өчен процентларны кире кайтарып бирү йөкләмәсе.

Демпинг (*демпинг*) — товарларны житештерү чыгымнарыннан түбәнрәк яки билгеле бер базарда урнашканнан сизелерлек түбән бәягә сату.

Депозитлар (*депозиты*) — акча хуҗаларының банкка вакытлыча саклау өчен тапшырылган барлык төр акча средстволары. Шулай ук алар банкка бу акчаларны кемнәргәдер кредитка бирү хокукын да бирәләр.

Дефицит (*дефицит*) — базарда сатып алучылар, гамәлдә булган бәяләрдән сатучыларның тәкъдим итү мөмкинлекләренә караганда (алар бу бәядән сатарга риза түгел), күбрәк товар сатып алырга ниятләгәндә барлыкка килгән халәт.

Дивиденд (*дивиденд*) — саф табыш суммасының акционерлык җәмгыяте акционерлары арасында алар хуҗа булган акцияләр санына карап бүленә торган өлеше.

Җ

Җитештерү факторлары (*факторы производства*) — кешеләр тарафыннан тормыш байлыкларын, кирәк-яракларын булдыру өчен файдаланылучы ресурслар.

З

Залог (*залог*) — заемчының (бурычка акча алучының) үз бурычын кайтара алмау очрагын истә тотып, аның тарафыннан банк контроленә яки карамагына сатарга рөхсәт итеп тапшырылган милке.

И

Икътисад (*экономика*) — хуҗалык эшчәнлеге процессында катнашучыларның гамәлләрен өйрәнүче фән.

Икътисади актив халык (эшче көчләр) (*экономически активное население*) — илдә эшле булган яки эшле була алган хезмәткә сәләтле яшьтәге гражданнарның гомуми саны.

Икътисади ирек (*экономическая свобода*) — гомуми «ирек» төшенчәсенең бер өлеше буларак, җәмгыять әгъзаларының, башка кешеләр мәнфәгатьләренә зыян китермичә һәм гамәлдәге законнарга каршы килмичә, милек формаларыннан үзләренең эшче көчләреннән файдалану өлкәләрен, керемнәрне бүлү ысулларын һәм матди байлыкларны үзләштерү вариантларын ирекле сайлау мөмкинлеге ул.

Икътисади системалар (*экономические системы*) — җәмгыятьнең хуҗалык тормышын оештыру формалары. Алар аерыла: 1) кешеләрнең, фирмалар һәм дәүләтнең хуҗалык эшчәнлеген координацияләү ысулы

буенча; 2) икътисади ресурсларга карата милек төре буенча.

Икътисади үсеш (*экономический рост*) — илнең житештерү мөмкинлекләренең елдан елга тотрыклы артуы.

Икътисади чыгымнар (*экономические издержки*) — фирманың товарлар житештерүгә һәм хезмәт күрсәтүләргә гомуми чыгымнары (товарлар житештерү һәм сатуны оештыруга турыдан-туры, шулай ук альтернатив чыгымнарны, ягъни фирманың ресурсларын башка төр эшчәнлек вариантларына файдаланмау сәбәпле алынмаган файданы да кертеп).

Икътисадны либеральләштерү (*либерализация экономики*) — икътисади эшчәнлек ирекен киңәйтү, хосусый инициативага (башлангычка) сәяси, хокукый һәм административ чикләүләрне тулысынча яки өлешчә бетерү.

Инвестицияләү (*инвестирование*) — керем алу максатыннан нинди дә булса берәр эшкә, эш башлауга озак вакытка капитал (средстволар) салу.

Импорт (*импорт*) — бер илдә яшәүчеләрнең башка дәүләтләрдә житештерелгән товарларны сатып алуы.

Интенсив үсеш (*интенсивный рост*) — (фран. «интенсив» — киеренке) киңәйтелгән кабат житештерү — икътисади үсешнең сыйфат ягыннан яңа төре (продукция житештерү күләмен яңа технологияләр, алдынгы техника, кадрларның квалификациясен күтәрү аша арттыру).

Инфляция (*инфляция*) — акча берәмлегенең теләсә нинди рәвештә бәясе төшү, ягъни сәбәпләр нинди булуга карамастан, икътисадта даими төстә бәяләр үсеше.

Ипотека ссудасы, ипотека кредиты (*ипотечная ссуда, ипотечный кредит*) — күчемсез милекне закладка салу шарты белән банк тарафыннан озак срокка бирелә торган акча ссудасы.

Ихтыяж (*потребность*) — кешегә хас хаҗәт, ягъни аның организмы эшчәнлегеп, иминлеген тәэмин итү яки канәгатьлек кичерүе өчен зарур нәрсәләргә мохтаҗлык тою ул.

Й

Йорт хуҗалыгы (*домашнее хозяйство*) — үз карамагындагы житештерү факторларыннан файдалану исәбенә керемнәр алу ысулларын, ул керемнәрне шәхси куллану өчен, товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр алуга тотуны мөстәкыйль хәл итүче бер яки бергә яшәүче берничә кеше.

К

Капиталның акчалата кыйммәте (*денежная стоимость капитала*) — билгеле күләмдәге капиталны сатып алганда түләнгән яисә аны сатканда алырга мөмкин булган акча суммасы.

Катнаш икътисади система (*смешанная экономическая система*) — хосусый милеккә нигезләнгән икътисади тормышны оештыру ысулы. Монда чикләнгән ресурсларны бүлү базарлар һәм шактый күләмдә дәүләтнең катнашында гамәлгә ашырыла.

Командачыл (күрсәтмә бирүгә корылган) икътисади система (*командная экономическая система*) — икътисади тормышны оештыру ысулы ул. Бу система яшәгәндә, капитал һәм жир дәүләт милкендә була, ә чикләнгән ресурслар үзәк идарә органнары күрсәтмәләре буенча һәм планнар нигезендә бүленә.

Коммерция белән шөгыльләнмәүче оешма (*некоммерческая организация*) — эшчәнлегенең төп максаты табыш алуга кайтып калмаган юридик зат, әгәр дә аның табышы барлыкка килсә, ул әлеге оешма вәкилләре арасында

бүленми, ә аның эшчәнлеген үстерүгә тотыла.

Коммерция банкы (*коммерческий банк*) — 1) депозитлар кабул итү; 2) ссудалар бирү; 3) исәп-хисап эшләрен оештыру; 4) кыйммәтле кәгазьләр сату һәм алу эшчәнлеген алып баручы финанс оешмасы.

Конкуренция (көндәшлек) (*конкуренция*) — билгеле бер төр чикләнгән ресурсларның күбрәк өлешен алу хакына барган икътисади ярыш.

Кредит (*кредит*) — кире кайтару (гадәттә процентлата түләү) шарты белән акчалата яки әйберләтә бирелгән ссуда.

Кредит кайтару сәләте (*кредитоспособность*) — заемчының (акча алып торучының) кредит шартнамәсе буенча үз йөкләмәләрен вакытында үти алуы, ягъни төп заем суммасын кире кайтару һәм аның буенча процентлар түләү мөмкинлеге булу.

Кредит шартнамәсе (*кредитный договор*) — банк һәм аннан акча алып торучы (заемчы) арасында төзелгән, ике якның да бурыч һәм хокукларын, барыннан да элек кредит белән тәэмин итү срогын, аннан файдаланган өчен түләүне һәм банкка акчаны кире кайтару гарантияләрен билгеләүче килешү.

Кулдагы акча средстволары (*наличные денежные средства*) — кәгазь акчалар һәм вак акча (тәнкәләр).

Кулда булмаган (банктагы) акча средстволары (*безналичные денежные средства*) — гражданнар, фирмалар һәм оешмаларның банклардагы счетларында сакланучы һәм банклардагы кемнең күпме акча средствосы булуы турындагы язмаларны үзгәртү юлы белән исәп-хисап ясау өчен кулланылучы суммалар.

Кирәгеннән артык товар җыеп тоту (*избыток, затоваривание*) — гамәлдәге бәяләр шартларында сатучылар, базарда кешеләр андый бәяләрдән алырга әзер булганга караганда, күбрәк товар тәкъдим иткәндә барлыкка килә торган ситуация.

Күчеш (чоры) икътисады (*переходная экономика*) — хуҗалык итүдә элекке һәм яңа икътисади системалар элементларының беркадәр вакыт эчендә янәшә яшәве.

Л

Ликвидлык — теге яки бу активлар хуҗасының аларны нинди җиңеллек белән акчага әйләндерүен аңлата.

М

Макроикътисади тигезләнеш (*макроэкономическое равновесие*) — илдә (җитештерү күләмнәре һәм бәяләр ягыннан) сатылмый торган продукциянең зур запаслары да, товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр җитмәүчелеге (дефициты) сәбәпле инфляция тизлегенең кискен арту куркынычы булмаган икътисади хәл.

Махсуслаштыру (*специализация*) — аерым төр эшчәнлекнең аны яхшырак алып бара белүче (башкаручы) кеше яки хуҗалык оешмасы карамагында тупланувы.

Маржиналь (чик) чыгымнар (*маржинальные, предельные издержки*) — эшләп чыгарыла торган һәр өстәмә берәмлек продукциягә реаль чыгымнар суммасы.

Маркетинг (*маркетинг*) — фирма нәрсәләр җитештерергә, иң күп табыш алу өчен аны кайда, ничек һәм нинди бәяләрдән сатуга тәкъдим итәргә тиешлеген хәл итү ысулларының гомуми атамасы.

Матди (жисми) булмаган капитал (*нематериальный, неосязаемый капитал*) — әйберләр (байлыклар) җитештерү һәм аларны сату өчен озак вакытлар дәвамында файдаланылучы белемнәр, сәләтләр һәм мәгълүматлар (мәсәлән, патентлар, лицензияләр, авторлык хокуклары, кешеләрнең осталык һәм сәләтләре, сәүдә маркалары.)

Менеджмент (*менеджмент*) — фирманың агымдагы һәм перспективадагы эшчәнлеген нәтиҗәле оештыру кагыйдәләре җыелмасы.

Милли керем (*национальный доход*) — ил гражданнары хезмәт хакы, табыш, процентлар һәм табигый ресурслардан файдаланган өчен рента рәвешендә алган барлык керемнәр суммасы.

Монетар сәясәт (монетарная политика) — дәүләтнең макроикътисади тигезләнешне саклау максатында, акча тәкъдим итүе һәм аның бәясе белән идарә итүе.

Монопсония (*монопсония*) — базарда товарларны бер генә сатып алучы (монопсонист) булганда һәм ул үзенең шушы өстенлегеннән файдаланып, сатучыларга товарларны алу шартларын, барыннан да элек, аларга бәяләрне көчләп тага алганда була торган ситуация.

Н

Номиналь керем (*номинальный доход*) — граждан яки гаилә билгеле бер вакыт эчендә алган акча суммасы.

О

Облигация (*облигация*) — кыйммәтле кәгазь ул. Аның хуҗасы бу облигацияне чыгарган фирмага яки дәүләткә беркадәр сумма биреп тора һәм билгеле бер вакыттан соң үз акчасын премия белән бергә кире кайтару хокукына ия була; әлеге премия күләме шулай ук облигацияне сатканда ук билгеләнә.

Ө

Өстәмә сорау яки җитештерү соравы (*производный спрос*) — товарлар җитештерүдә һәм хезмәт күрсәтүләрне оештыруда җитештерү факторларын куллану зарурлыгы аркасында аларга карата барлыкка килгән сорау.

Өстенлекле акция (*привилегированная акция*) — аңа ия булган затка, корпорация дивидендларын һәм корпорация ябылган очракта аның мөлкәтен бүлгәндә, гадәти акцияләр хуҗаларына караганда өстенлекләр бирүче акция. Мондый акция хуҗасы, гадәттә, фирма эшчәнлеге турында карарлар чыгарганда тавыш бирү хокукына ия булмый, әмма акционерлык җәмгыяте билгеле бер вакыт эчендә алган табыш дәрәҗәсенә карамастан, тәгәл билгеләнгән дивидендларны ала.

П

Пошлина (*пошлина*) — дәүләт гражданнардан һәм хуҗалык оешмаларыннан билгеле хезмәт күрсәтүләр өчен ала торган түләү.

Протекционизм (*протекционизм*) — дәүләтнең илебез товар җитештерүчеләрен, импортка төрле чикләүләр кую аша башка ил фирмалары конкуренциясеннән саклауга юнәлтелгән икътисади сәясәте.

Р

Реализацияләнүчәнлек (*ликвидность*) — нинди дә булса активларны аларның хуҗасы ихтыяры белән акчага әйләндерү җиңеллеге дәрәҗәсе.

Реаль керем (*реальный доход*) — граждан яки гаилә үзенең номиналь керемнәренә билгеле бер вакыт эчендә сатыла алырлык товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрнең күләме.

С

Сайлап алу бәясе (альтернатив чыгымнар) (*цена выбора — альтернативные издержки*) — иң кирәкле әйберләрнең кеше өчен булган кадере; чикләнгән ресурслардан сайлап алу юлы белән файдаланганда, аларны алу мөмкинлеге калмый.

Саклык акчалар (*сбережения*) — агымдагы кулланылыш белән бәйле барлык чыгымнарны түләгәннән соң калган керемнең бер өлеше.

Салым ставкасы (*ставка налога*) — салым түләүче тарафыннан (салым салу берәмлегенә туры китереп) дәүләт кеременә кертелергә тиешле түләү зурлыгы.

Саф табыш (*чистая прибыль*) — табышның салымнарны һәм башка мәҗбүри түләүләрне башкарганнан соң хуҗалык оешмасы карамагында кала торган өлеше.

Сәүдә (*торговля*) — хезмәт күрсәтү һәм товар кебек байлыкларны акчага сатып-алып алмашу. Бу гамәл ирекле һәм ике як өчен дә файдалы була.

Символик акчалар (*символические деньги*) — түләү чаралары алар (вак акча һәм кәгазь акча). Боларның бәясе һәм акча буларак түләү сәләте аларны әзерләүгә киткән чыгымнарны яки башка максатларга файдаланган-дагы кыйммәтен узып китә.

Сорау (*спрос*) — товар базарындагы сорау зурлыгының товарларның сатуга чыгарылачак бәяләреннән билгеле бер вакыт эчендә барлыкка килгән бәйлелеге.

Сорау законы (*закон спроса*) — бәяләр күтәрелү гадәттә сорау зурлыгы кимүгә, ә бәяләр төшү аның артуына китерә.

Сорау зурлыгы (*величина спроса*) — сатып алучылар билгеле бер вакыт эчендә (ай, ел) билгеле бер зурлыктагы бәядән алырга әзер булган (теләүләр һәм моңа мөмкинлекләре бар) натураль үлчәмдәге аерым төр товар күләме.

Социаль көйләнүле базар (*социально регулируемый рынок*) — катнаш икътисади системаның бер төре. Мондый системада җәмгыять һәм дәүләт икътисади үсешне тәэмин итәргә генә түгел, ә хуҗалык итү иреге, гражданнар һәм дәүләт арасында җәмгыять тормышы өчен җаваплылыкны дөрес итеп бүлү һәм гражданнар теләктәшлеге бирергә үрелү принципларын тулырак тормышка ашырырга омтыла.

Социаль трансферт (*социальный трансферт*) — ярлы гражданнарга дәүләт тарафыннан аларның тормыш дәрәҗәсен күтәрү өчен бирелә һәм баерак гражданнардан салымнар алу исәбенә формалаштырыла торган акча суммасы.

Ссуда (*ссуда*) — заем шартнамәсендә катнашучы бер якның кире кайтару, кагыйдә буларак, процентлата кайтару шарты белән икенче якка акча яки матди кыйммәтләр биреп торуы.

Т

Табигый монополия (*естественная монополия*) — объектив (табигый һәм техник) сәбәпләр аркасында товар җитештерү яки хезмәт күрсәтү бер фирмада тупланган һәм җәмгыять өчен файдалы булган тармак.

Табыш (*прибыль*) — а) бухгалтерлык исәбендә һәм салымнар салуда — товарлар сатудан килгән керемнең аларны җитештерүгә һәм сатуга киткән чыгымнар суммасыннан артыграк булуы; б) икътисад теориясендә — товарларны реализацияләүдән килгән керемнең аларны җитештергәндә кулланылган барлык ресурсларның гомуми альтернатив кыйммәтеннән артык булуы.

Тәкъдим (*предложение*) — билгеле бер чорда (ай, ел) аерым бер товарны базарда тәкъдим итү зурлыгының шушы товар сатылырга мөмкин булган бәяләр дәрәҗәсенә бәйлелеге.

Тәкъдим законы (*закон предложения*) — бәяләр күтәрелү гадәттә тәкъдим зурлыгы артуга, ә бәяләр төшү аның кимүенә китерә.

Тәкъдим зурлыгы (*величина предложения*) — сатучылар билгеле бер вакыт эчендә товарга урнашкан базар бәясеннән сатуга тәкъдим итәргә әзер булган (теләгән һәм тәкъдим итә алган) билгеле бер товарның натураль үлчәмдәге күләме (саны).

Тәкъдимнең бәя буенча сыгылмалылыгы (*эластичность предложения по цене*) — бәя бер процентка үзгәргәндә, тәкъдимнең зурлыгының үзгәрү колачы (% ларда).

Тигезләнешле бәя (*равновесная цена*) — житештерүчеләр (сатучылар) тәкъдим итәргә риза булган һәм барлык товарларны сатып бетерергә мөмкинлек бирүче бәя.

Товар (*товар*) — алмашу өчен житештерелгән матди предмет, жисем.

Төп хезмәт хакы (*основная заработная плата*) — хезмәткәр эшкә яллаучыдан үз вазифаларын: а) хезмәтнең стандарт шартларында; б) стандарт күләмдә һәм стандарт сыйфат белән үтәгән өчен ала торган акча суммасы.

Традицион икътисади система (*традиционная экономическая система*) — икътисади тормышны оештыру ысулы. Анда жир һәм капитал кабиләнең уртак милке була, ә чикләнгән ресурслар бик озак вакытлар яшәгән традицияләр нигезендә бүленә.

Тулай милли продукт (ТМП) (*валовый национальный продукт*) — ил гражданнарыныкы булган барлык фирмалар житештергән ахыргы куллану товарлары һәм хезмәт күрсәтүләрнең бәясе.

Тулаем сорау (*совокупный спрос*) — йорт хуҗалыклары, фирмалар, оешмалар һәм дәүләт бер ел эчендә товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр өчен тотарга әзер акча суммасы.

Тулаем тәкъдим (*совокупное предложение*) — предприятиеләр һәм оешмалар аларда булган житештерү мөмкинлекләре, урнашкан чыгымнар дәрәҗәсе һәм гамәлдәге бәяләр белән житештерергә һәм базарга тәкъдим итәргә әзер барлык товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр күләме.

Тулай эчке продукт (ТЭП) (*валовый внутренний продукт*) — илдә бер елда житештерелгән, базар бәяләрендә кыйммәте билгеләнгән бөтен соңгы товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрнең бәясе.

Тулы булмаган эшлелек (*неполная занятость*) — кеше рәсми рәвештә эшле булып саналып та, мәжбүри ялда булу аркасында, хезмәт хакы алмый, яки тулы эш көне эшләмәгәнгә күрә, тиешле хезмәт хакының бер өлешен генә ала торган ситуация.

Тышкы (өстәмә) нәтиҗә (*внешний, «побочный» эффект*) — байлыкны сатуалуда турыдан-туры катнашмый торган кешеләр яки фирмалар түләргә тиешле (яки алырга мөмкин булган) нинди дә булса байлыкны житештерүдән күргән зыян (яки файда).

Ф

Факторлар керемнәре (*факторные доходы*) — житештерү факторлары хуҗаларының аларны әйберләр, байлыклар житештерүне оештыру өчен файдалануга биргәннән килгән керем.

Физик капитал (*физический капитал*) — технологияләр ярдәмендә табигый матдәләрне кешеләргә файдалы байлыкларга әйләндерү өчен кулланы-

лучы биналар, корылмалар, машиналар, сугару системалары.

Финанс базары (*финансовый рынок*) — фирмалар эшчәнлеген оештыру өчен зарур финанс ресурслары сатыла торган базар.

Финанслар (*финансы*) — 1) гаилә, предприятие, дәүләтнең акча средстволары, кыйммәтле кәгазьләре һәм башка акча йөкләмәләре; 2) дәүләт тарафыннан оештырылган һәм гомумдәүләт акча средстволары фондларын икътисади, социаль, сәяси мәсьәләләрне хәл итү өчен формалаштырыла һәм файдаланыла торган акча мөнәсәбәтләре җыелмасы.

Финанс менеджменты (*финансовый менеджмент*) — фирманың тотрыклы үсешен тәэмин итү максатында аның акча ресурслары һәм агымнары белән идарә итү ысуллары һәм кагыйдәләре җыелмасы.

Фирма (*фирма*) — төрле байлыклар булдыру һәм аларны сату, шуның нигезендә табыш алу максатында җитештерү факторларын сатып яки арендага алучы коммерция оешмасы.

Фирманың базар бәясе (*рыночная стоимость фирмы*) — фирма тарафыннан чыгарылган акцияләрнең суммар бәясе (бәяләре расланган кыйммәтле кәгазьләр тотучы акционерлык җәмгыятьләре өчен) яки фирма икенче бер яңа хуҗага сатылырга мөмкин булган сумма.

Фискаль сәясәт *(фискальная политика)* — салымнарны һәм дәүләт чыгымнарын макроикътисади тигезләнешне саклауга булышырлык итеп көйләү.

Х

Хезмәт (*труд*) — кешеләрнең хезмәт күрсәтү рәвешендә файдаланылучы акыл һәм физик сәләтләре, күнекмәләре һәм тәҗрибәсе ул. Алар икътисади байлыклар җитештерү өчен кирәк.

Хезмәт базары (*рынок труда*) — үз хезмәтләрен фирмаларга сатарга әзер булган кешеләр белән аларның бу хезмәтләренә хезмәт хакы һ.б. түләргә риза булган фирмалар арасындагы икътисади һәм юридик үзара мөнәсәбәтләр бәйләнеше ул.

Хезмәт контракты (*трудовой контракт*) — эш бирүче белән эшкә ялланучы арасында хезмәтнең эчтәлеге, аның шартлары, шулай ук аңа түләү күләме һәм үзара башка йөкләмә-бурычлар турында аерым сөйләшүләр нәтиҗәсендә ирешелә торган килешү.

Хезмәт күрсәтү (*услуга*) — файдалы эшчәнлек рәвешендәге, кешеләр башка хезмәт күрсәтүләргә яки товарларга алмаштыра ала торган матди булмаган игелек.

Хезмәтнең капитал белән тәэмин ителеше (*капиталовооруженность труда*) — физик җитештерү капиталының хуҗалык эшчәнлегендә катнашучы бер кешегә уртача туры килә торган бәясе.

Хезмәт пенсиясе (*трудовая пенсия*) — гражданга законда билгеләнгән яшькә җиткәч, инвалидлыкка дучар булгач, туендыручысын югалткач, шулай ук тиешле еллар эшләгәннән соң (выслуга лет) бирелә торган даими акчалата түләүләр.

Хезмәт хакы (*заработная плата*) — хезмәткәргә билгеле бер вакыт эчендә (сәгать, смена, ай) куелган хезмәте яки билгеле күләмдәге эш башкаруы өчен зарур булган (мәсәлән, бер детальне эшләү өчен) хезмәтенә түләнә торган акча суммасы.

Хосусый милек (*частная собственность*) — аерым гражданнарның һәм алар берләшмәләренең теләсә кайсы төр икътисади ресурслар күләменә (өлешенә) ия булуга, файдалануга

һәм идарә итүгә дәүләт тарафыннан танылган хокукы.

Ч

Чагыштырма өстенлек принцибы (*принцип относительного преимущества*) — һәр ил өчен (башка илләрдәгегә караганда) сайлау бәясе чагыштырмача түбән булган товарларны экспортлау отышлырак.

Чикләнгәнлек (*ограниченность*) — кешеләр алырга теләгән әйберләр муллыгын житештерүгә кирәкле барлык төр ресурслар күләменең житешмәве.

Э

Экспорт (*экспорт*) — үз илендәге икътисад тармакларында житештерелгән товарларны башка илләрдә яшәүчеләргә сату.

Экстенсив үсеш (*экстенсивный рост*) — (лат. «экстенсивус» — киңәюче) үсешкә кулланыла торган факторларны (файдалы казылмаларның яңа ятмаларын, эшче көчләр миграциясен һ.б.) арттыру исәбенә ирешү.

Эмиссия банкы (*эмиссионный банк*) — илнең акча бердәмлекләрен чыгару (эмиссия) һәм шул илдә акча әйләнешен көйләү хокукына ия булган банк.

Энгель законы (*закон Энгеля*) — гаиләнең кереме арту белән туклануга чыгымнарның чагыштырма күләме кими; кием-салым, торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен чыгымнар аз үзгәрә, ә мәдәни һәм башка ихтыяжларны канәгатьләндерү өчен чыгымнар өлеше сизелерлек арта.

Эшмәкәр (*предприниматель*) — үз акчасына һәм бурычка алган акчага тәвәккәлләп, житештерү ресурсларын берләштереп, сатудан табыш бирәчәк байлыклар тудыру өчен фирма төзүче кеше.

Эшсезлек (*безработица*) — илдә урнашкан хезмәткә түләү күләменә риза булып эшкә ялланырга сәләтле һәм теләүче, әмма үз белгечлекләре буенча эш таба алмаучы яки бөтенләй эшкә урнаша алмаучы кешеләр булу.

Эшче куллар (көчләр) (*человеческий капитал*) — кешеләрнең белем алу һәм эш тәжрибәсе нәтижәсендә тупланган, өстәмә керем бирергә сәләтле белем һәм күнекмәләре.

Я

Яшәү минимумы (*прожиточный минимум*) — кешенең туклану өчен физиологик нормалардан түбән булмаган күләмдә азык-төлек алуы, шулай ук аның киемгә, аяк киеменә, торакка, транспорт хезмәтенә, санитария-гигиена предметларына ихтыяжын минималь күләмдә канәгатьләндерүе өчен кирәкле акча суммасы.

Икътисад белән кызыксынучылар һәм шушы мавыктыргыч фән турында күбрәк белергә теләүчеләр өчен «Вита-Пресс» нәшрияты рус телендә бастырып чыгарган түбәндәге дәреслекләр һәм уку әсбаплары тәкъдим ителә:

И. В. Липсиц. **Экономика**. *В 2-х тт. (Базовый уровень)*

Дәреслек материаллары укучыга теләсә кайсы илнең хуҗалык төзелеше һәм аның үсеш закончалыклары турында тулы күзаллау булдырырга ярдәм итәр.

Икътисад тәгълиматлары үсеше тарихыннан, күренекле икътисадчылар тормышыннан, танылган фирмалар эшчәнлегеннән мәгълүматлар язмаларны җанлы һәм кызыклы итә. Гамәлдә көчне сынап караута зур игътибар бирелә: моның өчен дәреслектә «Санап карыйк — уйлап багыйк» дигән рубрика бар.

Под ред. С. И. Иванова. **Основы экономической теории**. *В 2-х книгах.* (*Профильный уровень*)

Дәреслектә микро- һәм макроикътисад нигезләре икътисад теориясенең ике состав өлеше буларак ачыла. Дөнья икътисадының үсеше һәм эшләве, дөньядагы илләр хуҗалыгының глобальләшүен чагылдыручы процесслар белән бәйле төп мәсьәләләргә зур игътибар бирелә. Дәүләтнең һәм дәүләт икътисади сәясәтенең микро- һәм макродәрәҗәләрдәге әһәмияте күрсәтелә. Хәзерге Россия икътисадының үзенчәлекләре анализлана.

А. А. Мицкевич. **Сборник заданий по экономике** (*Микроэкономика*)

Россиядә беренчеләрдән булып микроикътисадтан мәсьәләләр тулы һәм системалаштырып бирелгән әлеге җыентыкка 1100 дән артык мәсьәлә кертелгән; аларның күбесе — оригиналь.

Җыентыктан икътисадны өйрәнүнең теләсә кайсы дәрәҗәсендә һәм әлеге фәннән теләсә кайсы дәреслек белән бергә файдаланырга мөмкин.

Е. Ф. Винокуров, Н. А. Винокурова. **Трудные задачи по экономике**

Әлеге китап — икътисад курсын иҗади үзләштерү өчен төзелгән оригиналь мәсьәләләр җыентыгы. Мәсьәләләр курсның төрле темаларына (шул исәптән җитештерү мөмкинлекләре кәкреләре, сорау һәм тәкъдим законнары, бизнесны оештыру, монетар теория, тышкы сәүдәнең нәтиҗәлелеге) карый.

А. П. Архипов. **Азбука страхования**

Дәреслектә страховкалауның төп төшенчәләре һәм билгеләмәләре ачып бирелгән; хәвеф-хәтәрләр классификациясе һәм алардан страховкалау ярдәмендә

саклану төрләре, страховкалау законнары, социаль һәм коммерция страховкалары төрләре бәян ителгән; страховкалаучы хокукларын саклау турында да сөйләнә.

А. П. Балакина һ.б. **Налоги России**

Салымнар грамоталылыгы турындагы чыгарылыш сыйныф укучылары өчен ил тарихында беренче мәртәбә нәшер ителгән әлеге уку әсбабында салымнарның кайчан һәм ничек барлыкка килүе, дөньядагы һәм Россиядәге салым салу системаларының ничек камилләшүе, ә иң әһәмиятлесе — Россиядә салымнар системасының төзелеше турында сөйләнә. Салымнарның төп төрләре — керемнәргә, мөлкәткә, җиргә, мирас итеп калдырылган һәм бүләк ителгән байлыкка салымнар җентекләп яктыртыла; кече бизнеска салым салу мәсьәләләре турында бәян ителә.

С. Н. Гудырин. **Основы маркетинга**

Әлеге уку әсбабы укучыларны маркетингның максат һәм бурычлары, аны җитештерү предприятиеләре, сәүдәне оештыру, дәүләт учреждениеләре, җәмәгать оешмалары һәм аерым кешеләр өчен куллану үзенчәлекләре белән таныштыра. Илебез һәм чит илләр предприятиеләре хуҗалык итү эшчәнлегеннән мисалларның киң файдаланылуы уку материалын аңлауны җиңеләйтерә.

В. Д. Симоненко, Т. А. Степченко. **Основы потребительской культуры**

Әсбапта «Нәрсә ул базар?», «Сәүдәнең төп принциплары», «Кулланучының рациональ бюджетын ничек планлаштырырга?», «Азыкка өстәлә торган матдәләр куркынычмы; штрих-код ни өчен кирәк?», «Маркировка нәрсә ул; товар знаклары, брендларның әһәмияте нәрсәдә?», «Кулланучылар нинди хокукларга ия; нинди дәүләт учреждениеләре һәм җәмәгать оешмалары аларга үз хокукларын якларга ярдәм итә?» һ.б. мәсьәләләр турында сөйләнелә.

В. Д. Симоненко. **Основы предпринимательства**

Әсбапта уку йортын тәмамлаучыларны кызыксындыра торган күп кенә сорауларга җавап бирелә: эшмәкәрлекнең төп принциплары нинди? Эшмәкәрлек фирмасын төзү технологиясенең нигезендә нәрсә ята? Эшмәкәр феномены (аны башкалардан аерып торучы сыйфат) нәрсәдән гыйбарәт? Ул нинди шәхси сыйфатларга ия булырга тиеш? Эшмәкәрлек эшчәнлеген дәүләт ничек көйли?

Конспект рәвешендә эшмәкәрлек төрләре бәян ителә. Идеяне (уй-фикерне) зиһенгә алу тәртибенә, маркетингка, рекламага, бәяләр урнашуга һәм эшмәкәрлекнең башка якларына аерым урын бирелә.

С. В. Федин һ.б. **Основы менеджмента**

Әлеге китаптан менеджерларның кем булуы, аларның хәзерге заман сәнәгатендәге роле, оешма эчендәге идарә итүнең нинди кагыйдәләргә нигезләнүе һәм башка күп кенә мәсьәләләр турында белергә була.

«Үзменеджмент»ка — үзеннең үсешкә ирешү һәм һөнәри үзбилгеләнү юлын сайлауга бәйле идарә итү технологияләренә аерым игътибар бирелә.

Учебное издание

Липсиц Игорь Владимирович

ЭКОНОМИКА

БАЗОВЫЙ КУРС

Учебник для 10—11 классов
татарской средней общеобразовательной школы

Казань. Издательство «Магариф». 2006

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

Липсиц Игорь Владимирович

ИКЪТИСАД

ТӨП КУРС

Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең
10—11 нче сыйныфлары өчен дәреслек

Редакторлары *И. И. Кадыйрова, Л. Г. Шәрифуллина*
Бизәлеш редакторы *Р. А. Сәйфуллина*
Техник редакторы *Ә. С. Трофимова*
Компьютерда биткә салучысы *В. С. Тимошкин*
Корректоры *С. З. Гыймалетдинова*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүчесе *Э. Ф. Нурмөхәммәтова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 28.12.2006.
Форматы $70 \times 100^{1}/_{16}$. Офсет кәгазе. «Таймс» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 22,1. Нәшер-хисап табагы 22,6.
Тиражы 7000 д. Заказ С-302.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс (843) 292-57-48.
http://magarif.kazan.ru
E-mail: magarif@mail.ru

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы» ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.


КАПИТАЛ БАЗАРЫ
БАНК СИСТЕМАСЫ
АКЧА ДӨНЬЯСЫ
Кеше хезмәте базарында
Икътисади үсеш